# казан утлары

5

МАЙ • 1977

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**5**

МАЙ
1977

## Бу санда

**И. ЮЗЕЕВ. Уйланулар.** Шигырьләр . . . . . 3
**М. ХӘСӘНОВ. Инженерлар** . . . . . . . . . . 10

ДУСЛАР ЖЫРЫ

**В. КОЧЕТКОВ. Учак.** Шигырьләр . . . . . . . 77
**О. ШЕСТИНСКИЙ. Әнием.** Шигырьләр . . . . 79

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**В. БРОНЕВСКИЙ. Октябрьга баш иям.** Шигырь . 82
**И. ВАРАВВА. Бүләк.** Шигырь . . . . . . . . . 83
**З. НУРИ. Җиңүче солдат, сүз синең хакта** . . . 84
**В. КАБАНОВ. Шагыйрь мактар иде аны** . . . . 91
**М. ГӘРӘЕВ. Җиңелмәс капитан** . . . . . 94
**Ф. ЯРУЛЛИН. Туган ягы кирәк кешегә.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 106
**В. ИВАНОВ. Мәгърифәтле Казан** . . . . . . . 110
**Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Көрәшкә бирелгән тормыш** . 114

СӘНГАТЬ

**М. ФӘЙЗУЛЛАЕВА. Татар драма театры һәм опера сәнгатебез** . . . . . . . . . . . . . 118

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

**Ә. БАЯНОВ. Яшь шагыйрьләр юлга чыга** . . . 124

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**С. ШАКИР. Илем өчен, җырым өчен** . . . . . 128
**И. ЗӘБИРОВ. Муса Җәлил иҗатында Ленин** . . 132

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Г. ХАНТЕМИРОВА. Иҗат яшьлеге** . . . . . . 137

ХАЛЫК ИҖАТЫ

**Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ.** Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә апа балаларына язган шигъри васыять-хат . . . . . . . . . . . . . . . 139

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Рөстәм Башкуров** . . . . . . . . . . . . . . 141
**Х. ГАРДАНОВ. Остазларның өйрәнчеге була** . . 141

БАРИ РӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

**Р. КУКУШКИН. Ул бүген дә, киләчәктә дә бар** . 143

МИРГАЗИЯН ЮНЫСКА 50 ЯШЬ

**М. МӘҺДИЕВ. Секстан белән йолдызлар үлчәргә** . 148

КАВИ ЛАТЫЙПКА 50 ЯШЬ

**Өмет белән карыйм дөньяга мин.** Шигырьләр . 153

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Э. МӨЭМИНОВА. Буяштым.** Шигырьләр . . . . 155
**З. ГОМӘРОВА. Зәңгәр чәчәк.** Шигырьләр . . . 156

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Сатира — һөҗүм коралы** . . . . . . . . . . . 158
**Ә. ЕНИКИ. Чикерткә.** Әкият . . . . . . . . 166
**К. ЗАДӘ. Таяк турында.** Шигырь . . . . . . 186
**НУРИ АРСЛАНОВ. Нурихан Фәттахка** . . . . 187
**М. ӘПКӘЛИ.** Пародияләр . . . . . . . . . . 187

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/II-1977 ел. Басарга кул куелды 8/IV-1977 ел. ПФ 13059. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 85000 экз. Заказ Б-45. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

## Илдар Юзеев

# УЙЛАНУЛАР

## *Нишләдем?*

Нишләдем?
Күкрәк читлегеннән, сыеша алмый,
Ташып чыга иде хисләрем.
Нишләдем?
Мин йөгәнсез чапкан бер тай идем,
Белми идем хыял чикләрен.
Нишләдем?
Тупасланганмәллә хисләрем?
Йөрәгемне салып күрегенә,
Гармун уйный идем кичләрен.
Нишләдем?
Яшьлегемнең шашкын дулкыннарын
Күкрәк читлегенә бикләдем.
Нишләдем?
Юрга тайдай түгел, йөк атыдай
Тартып барам заман йөкләрен.
Нишләдем?
Давылламый, эчтә ташый хәзер
Сабырланган яшьлек хисләрем.
Нишләрем?
Күкрәгемне ватып чыкса әгәр
Сыешалмый яткан көчләрем,
Яшьлегемнең шаян дулкыннары
Шашып әйтсә миңа:
«Нишләдең?!»

●

Гаиләдә төпчек бала идем мин,
Абыйлардан калган кием кидем мин.
Абыйлардан калган укны аттым мин,
Абыйлардан калган төпчек тарттым мин.
Абыйларым китте сугыш кырына,
Абыйлардан калды бары җыр гына:
«Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кала күлмәгем,
Күлмәгемне энем кияр,
Ярымны кемнәр сөяр?»

Абыйлардан калган юлда — тузаннар,
Яу кырында ятып калды туганнар.
Абыйларның төсен җирдә сакладым,
Абыйларсыз калган юлдан атладым.
Гаиләдә төпчек бала идем мин,
Абыйларның йөген тартам инде мин.
Абыйлардан калган каеш — билемдә,
Абыйларсыз заман йөге — иңемдә.
Абыйларның җыры чыңлый йөрәктә,
Парсыз калган ярга авыр бигрәк тә...
«Абыйларны онытыгыз!» — диялмыйм,
Абыйлардан калган ярны сөялмыйм...

## *Мин табарга тиеш...*

Әтиемнең күзләрендә
Узганнан сорау табам:
«Бигрәкләр дә ашыгасың,
Сабыррак булчы, балам!»
Улым күзләрендә күрәм
Киләчәкнең карашын:
«Тизләт, әти, адымыңны,
Акрынрак барасың!»
Бара торган Киләчәкнең,
Узганның, Бүгенгенең
Мин табарга тиеш мәңге
Аерылмас берлеген!

## *Калмас өчен...*

Урам тизлегенә иярәм мин
Килеп чыгу белән йортымнан,
Галәм тизлекләрен тоеп барам
Калмас өчен заман ритмыннан...

## *Тавыштан алда...*

Самолетлар оча тавыштан тиз...
Хыял белән якын арабыз...
Киләчәккә аваз артта кала, —
Тавыштан да алда барабыз!

## *Яңа нигездә иске сүз*

«Трактор белән йортны күчердем», — дип,
Әйе, шаккатырдың син безне...
Ә кубарыр көчләр табарсыңмы
Йөз ел тамыр җәйгән нигезне?..

## *Шофер узган юл*

«Көн эчендә дөнья әйләндем», — дип,
Шофер, кайткач, юкка кызадыр,
Синең узган юлны хатының да
Өй эчендә йөреп узадыр...

## *Нигә?*

Нигә рәнҗетәбез табигатьне?!
Тилмереп һәм әрнеп ул калыр.
Явызлыклар өчен кайчан да бер
Безнең оныклардан үч алыр.

## *Аһ, табигать...*

Күкрәдең, күктән тамчылар
Түгелде яшең булып,
Йөз явызны күрми узып,
Һич гөнаһсыз бер сабыйны
Ник суктың яшен булып?!

## *Челләдән соң*

Күкнең миллион күзләреннән
Җир йөзенә яшь тама.
Сөенечле тамчылар бу:
Әнә ич шат Җир-ана.

## *Йолдызларга карыйм...*

Чыгам да мин йолдызларга карыйм:
Алар ерак, алар тоныклар...
Бабайларның сәламнәрен илтер
Миннән соң туачак оныклар.

## *Чыгалмасаң*

Чыгалмасаң әгәр ваклыктан,
Тайпылырсың олы Хаклыктан.

## *Уйлама*

Уйлама үзеңне халык дип,
Шул халык эчендә Алып дип,
«Ул — халык эчендә Алып», — дип,
Әйтергә хаклыдыр халык тик...

## Мин Гулливер

Тырыш кырмыскалар эшен күргәч,
Уйга калып, башны кашыдым:
Гулливердай буем, көчем белән
Күпме мәгънәле йөк ташыдым?

## Узып китәм

Бәхет артыннан еракка
Өметем сузып китәм...
Тоттым дигәндә, ашыгып,
Яныннан узып китәм...

## Мәшәкать

Дөнья — мәшәкатьтән корылган,
Дөнья — мәшәкатьтән кырылган.
Мәшәкатьне — хуплыйм мин аны, —
Кырмасын тик, корсын дөньяны!

## Күпсенмә

Яшьлек ич ул: бар халык алдында үпсен лә...
Көнләшсәң дә, картлык, күпсенмә...

## Таулар кебек

Тышкы яктан бик тын күренсә дә,
Ни генә юк таулар эчендә...
Ачылмаган чишмәләрем тибә, —
Мин әлегә таулар көчендә.

## Гармунсыз авыл

Авылларда йөрим. Кем генә юк...
Бар моңлысы шунда... бар моңсыз.
Моңсыз авыл җирдә булмаса да,
Мин бер авыл күрдем гармунсыз.
Бар тирә — тын. Яшьлек — чәчәкләрен
Вакыты җитми йомган шикелле.
Нидер җитми җанга... Авыл йоклый...
Сандугачсыз урман шикелле.

## Шаляпинны тыңлыйм

Шаляпинны тыңлыйм: татар моңы, —
Бабайларда бер кандыр сыман,
Бергәләшеп алар, җырлый-җырлый,
«Карурман»нан чыккандыр сыман...

## Җан өчен

Таң белән языла шигырьләр,
Җан белән языла шигырьләр,
Таң өчен, дан өчен язылмый,
Җан өчен языла шигырьләр...

## Тоям

Тоям: бу моң килә борынгыдан,
Шаулап-кукрәп миндә тынгандыр...
Кайсыдыр бер ерак бабам минем
Билгесез зур шагыйрь булгандыр...

## Тыңламадым

Тыңламадым ул чак бер карт сүзен...
Шул ялгышым чәчне агартты,
Гомер буе акыл җыйгач белдем
Акыл иясе дип ул картны...

## Калдырмам мин

Шатлыкларны җирдә калдырып мин
Гомер юлын тәмам итәрмен,
Үз кайгымны ләкин калдырмам мин,
Үзем белән алып китәрмен.

## Ни җитми?

Ни җитми? Ник карыйм каерылып
Һич кире кайтмаслык чакларга?
Нәрсәдер калган күк, калган күк
Бишегем тирбәлгән якларда...

## Еллар узгач

Әйләндермә шатлыкны син хәсрәткә,
Әйләндермә мәхәббәтне нәфрәткә,
Еллар узгач, гомер кичкәч, син аңларсың:
Хәсрәтеңнең ул чак шатлык булганын,
Нәфрәтеңнең сөю-сафлык булганын
Син аңларсың,
Соң аңларсың...

## Посып тора

Йөрәкнең нәкъ бер читендә
Көнчелек посып тора,
Күңелләрне тарайтып шул
Кимчелек кысып тора.

## Бәхет килгәч

Кайгы килгәч, бар да уртаклаштылар,
Бәхет килгәч, әллә инде качтылар?
Мин бәхетле,— тик дуслар юк, берүзем,
Бәхетем белән ялгыз калдым,— бир түзем!..

## Өзелмә

Мин — бер яфрак, яралганмын
Әнкәй дигән каеннан,
Язмышым тик изгелектән,
Ал нурлардан каелган.
Хәзер үзем — каен, әнкәй,
Яфрагым бул, өзелмә,
Саклармын салкын җилләрдән
Кышларын да, көзен дә...

## Тост –экспромт

Бу тостны күтәрәм шул шәрәфкә:
Күз яше кушылмасын бу шәрабкә!
Бу шәраб булсын ачы, булсын татлы,
Без кылган эшләр-гамәлләр булсын хаклы!
Тамчысы да түгелмәсен,
Үз урнына салынсын,
Бу шәрабне күтеп торган
Баш та, йөрәк тә сау булсын!
Бу шәраб кан тамырларында
Яшен булып яшьнәсен...
Барлык шәрабләрдән өстен
Акыл һәм хис яшәсен!

## Әнкәйләрнең юраулары

Әнкәй мине төштә күргән, —
Юрыйм, син ышан, имеш,
Ап-ак болытлар өстендә
Паласта очам, имеш...
Әнкәйләр безне күрәләр

Аклык, сафлык юлында,
Югарыда, бик биектә:
Бөек хаклык юлында.
Паласларда очмасак та,
Шулай дип фараз итик,
Җирдә торып, әнкәйләрнең
Юрауларын рас итик!

## *Иртә таңнан җырлаганнар*

Зурнәй әйтә торган иде:
«Сүземне тыңла, бала:
Иртә таңнан җырлаганнар
Кайгылы-моңлы була...»
Шул ук гадәт: таңнан торып
Җыр язарга яратам...
Мин бит, зурнәй, башкаларның
Хәсрәт моңын таратам.

## *Кем анда?*

Онытыла язган көйне җырлап,
Назлап дәшә сыман кем анда?
... Шундый ачык итеп күрәм сине
Еракларда калган томанда...

## *Манзара*

Ярда — таллар йоклый арып-талып,
Җил дә изрәп калган. Сулар тын.
Сай күлләрне тирән уйга салып,
Гармун уйный бераү югартын.

# Мәхмүт Хәсәнов

# ИНЖЕНЕРЛАР

*«Кама таңнары» романының икенче китабы*

## 1



Улым Ислам быел да кунакка кайтты. Әмма бу юлы аның кайтуы мине куандырмады. Чөнки ул уйламаган-көтмәгән яктан хикмәт чыгарып гайрәтемне чигерде: ансыз да китек күңелле, ансыз да тормышның җәбер-золымын җитәрлек татыган инженер Вәгыйз Гайнановның гаиләсен пыран-заран китереп китте...

Иң элек Исламның телеграммасы килеп төште. Бу юлы да «кайтабыз» дип хәбәр иткән иде. Бу юлы да күңелем түрендә: «Әллә, ниһаять, башлы-күзле булдымы икән бу малай?» дигән уй туды.

Телеграмма иртән, мин эшкә чыгып китәр алдыннан килде. Һәдия дә өйдә иде.

— Кайчанрак кайтырлар икән соң алар? — диде ул.

Бик урынлы сорау иде бу.

— Хәзер беләбез аны.

Аэропортка шалтыратып, телеграммада күрсәтелгән рейс самолетының кайчан киләчәген сорадым. Көндезге икедә диделәр. Һәрхәлдә, Һәдия белән Гөлҗиһан апага кунакларны каршыларга яхшылап әзерләнергә була иде әле. Үзем иртә якта киңәшмәдә булырга тиеш идем, шунда киттем.

Ислам бу юлы да СССР Фәннәр академиясенең Себер филиалында бергә эшли торган иптәше белән кайтып төште. Кунакларны күршем Алексей Фомич белән бергә барып каршы алдык.

Кунакның исеме Петр Ильич, ә фамилиясе Басов икән. Тәбәнәгрәк кенә буйлы, йомры гәүдәле. Сакал-мыек җибәргән. Салам төсле саргылт-җирән сакалы үзенә килешеп тора тагын. Аның вак-вак атлап йөрүләре, өлгер-җитез хәрәкәтләре, бик илтифатлы итеп бөгелә-сыгыла исәнләшүләре, җаелеп елмаюлары шунда ук үзенә җәлеп итә.

---

Әсәр кыскартылып алынды.

Таныша торгач, физика-математика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәсе барлыгын да белдем.

Петр Ильич, безнең кыстауга буйсынып, машинаның алгы урынына — Алексей Фомич янына кереп утырды. Без Ислам белән арткы утыргычка урнаштык.

Безнең «Волга» Бигеш аэропорты каршындагы мәйданга җыелган машиналар арасыннан ерып чыкты да, олы юл буйлап, җил уйнатып, алга ыргылды.

Кунакларның бөтен игътибары руль тотып кайтучы Алексей Фомичта. Алар Фомич белән балык һәм балыкка бару турында әңгәмә алып баралар.

— Балык тоту — безнең хобби,— ди Петр Ильич, йомры гәүдәсен Фомичка таба бора төшеп.

Аның сүзләренә караганда, Новосибирск тирәсендә ул балык тотмаган елга, ул айкамаган күл калмаган. Ул хәзер дә бүген үк, я иртәгә таң белән барыбыз бергәләп Камага балыкка төшү турында план корып килә.

Сүз уңаенда, узган ел Янис тоткан балыкны да искә төшереп алдылар.

— Безнең Академиягә килеп җиткәләгәнче ул балыкның зурлыгы, ким дә түгел, артык та түгел, нәкъ акула кадәр булып өлгергән иде инде,— дип тәрттереп алды Петр Ильич. Көлә шайтан.

Исламның да җавабы әзер:

— Акуланың нинди булмас дисең!..

Мин дә сүзгә кушылып, Алексей Фомичтан, кай тирәгәрәк барсак яхшырак булыр икән, дип сорап куйдым.

— Теге, инженер Гургенидзенең туган көнен уздырган җирдән дә һәйбәтрәк урын булмас, — диде Фомич. — Беренчедән, балыклы урын. Икенчедән, ул тирәдә машина белән су буена ук төшеп була. Менә дигән чиста сулы чишмәсе дә шунда гына. Аннары килеп...

Алексей Фомич ул урынның отышлы якларын тезепме-тезде. Силикат кирпеч заводының беренче директоры балыкка гелән шунда йөри торган булган. Машина белән төшеп йөрерлек булсын өчен, бульдозерлар белән махсус юл да ачтырган. Һәр көн таң белән, эшкә барганчы, балык чиерттерергә төшеп менә торган булган ул.

— Безгә дә, Алексей Фомич, сезнең ярдәмегез кирәк булыр инде, — дидем мин, балыкка төшүнең мең төрле мәшәкатьләре турында уйлап.

— Кадерле кунаклар хөрмәтенә барысын да эшләрбез, — диде ул, һәр вакытта да күндәм күршем. Аннары кинәт кенә, бик әһәмиятле нәрсәне исенә төшергәндәй, сорап куйды. — Газ плитәсе кирәк булырмы икән?

— Һич кирәкми! — диде Петр Ильич, ике уйларга урын калдырмаслык итеп. — Ухаңың бар тәме аның төтен исе сеңүдә, күмерләр чәчрәп төшүдә... Һәм кара күк гөмбәзендәге йолдызларның шәүләсе чагылуда. Чын уха өчен ул компонентлар нәкъ тәм-төм кебек үк кирәк нәрсәләр...

Кайтып җитеп подъезд янына туктадык. Алексей Фомич, җәһәт кенә машинадан чыгып, багажниктан кунакларның чемоданнарын алып бирде. Үзем кертешим дип, әйберләрне күтәреп тә алган иде инде, әмма егетләр чемоданнарын үз кулларына алдылар.

Алексей Фомичны өйгә керергә чакыра башладык. Тик ул, булмый, кичектергесез эшләрем бар, бәлки соңрак сугылып чыгармын әле дип, машинасына утырды да выжт итеп китеп тә барды.

Өйгә кердек. Күрешү-танышу, исәнлек-саулык сорашу ыгы-зыгысы башланды.

Исламның тавышы аеруча көр иде.

— Күр, Петр, минем нинди яшь энием бар, — диде ул, Һәдияне күрсәтеп.

— Син бәхетле, Ислам Имамович!

— Минем нәни энекәем белән сеңелкәем кайда?

— Алар дачада, Кама аръягында...

— Әнә, бер чемодан күчтәнәчләр алып кайттык үзләренә...

— Рәхмәт, туганай, бик әйбәт иткәнсең!.. — Бу сүзләрне Гөлҗиһан апа әйтте.

— Яннарына барып кайтырбыз. Бүген-иртәгә үзебез дә барырбыз дип тора идек,— дидем мин.

Табын янына утырыштык. Пычак-чәнечкеләр ялт та йолт итеп кенә тора.

Ул арада Һәдия кайнар шулпа да китерә башлады. Аш алдыннан табын хөрмәтенә, аш-су хәзерләүчеләрнең исән-саулыгына берәрне күтәрергә булдык. Һәдиянең йөзе алсуланып киткән, күзләрендә очкын. Йөзендә дустанә елмаю балкый. Килешә аңар бу халәт.

Бераз тамак ялгап алганнан соң, табын янындагыларның кул хәрәкәтләре сизелерлек сүлпәнләнде. Аның каравы, телләр чишелде. Бөтен өйне гөр китереп утырабыз.

Петр Ильич минем КамАЗдагы төп эшем белән кызыксынды.

Мин, әлбәттә, барысын да сөйләп бирдем: үземнең инженер-электроник булуымны да, гигант заводның «электрон мие» — информация-хисаплау үзәге начальнигы булуымны да әйттем.

— Образлырак итеп әйтсәк, хөрмәтле Петр Ильич, — дидем мин, — безнең эш түбәндәгедән гыйбарәт: әгәр дә әзер машиналар җыелып чыгачак баш конвейер КамАЗның умыртка сөяге булса, без монтажлый торган электрон-хисаплау машиналары — аның үзәк нерв системасы ролен уйнаячак.

Сизеп торам, мин сөйләгәннәр Исламга да кызык. Шул форсаттан файдаланып, КамАЗның бүгенге хәле белән дә таныштырып киттем: бу гигант төзелешнең хәзерге вакытта унынчы бишьеллыкның иң «кайнар ноктасына» әверелүен, аны төзүдә 150 меңгә якын кеше катнашуын, ул кешеләрнең бик тырышып яңадан-яңа өстәмә йөкләмәләр алып эшләүләре турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем.

— Бу патриотик хәрәкәттән без-электрониклар да читтә калмадык, — дидем мин аңа, — КамАЗның координацион информация-хисаплау үзәген монтажлау белән генә чикләнмичә, «Франц-Пуатвен» фирмасыннан алынган уникаль стенд комплексын сафка бастыруны да үзебезгә бурыч итеп куйдык.

Аннары әңгәмәне икенче юнәлешкә борып җибәрдем. Телеграммасы «кайтабыз» дигәч, әллә Ислам өйләндәме икән, дип уйлавымны әйттем.

— Сиңа, егет, утыз тула түгелме соң инде? — дип сорап куйдым.

— Шулай бугай, — диде Ислам, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. Аннары, ашыкмыйча гына кулъяулыгын алып, калын кара кысалы зур күзлеген сөртте. Кулын алга сузып, аны тәрәзә ягына куеп карады: күзлек яхшы сөртелгәнме? Аның шулай минем сорауны гаменә дә эләмәве күңелемне тырнап куйды. Тукта, тагын бер исенә төшерим әле.

— Мин синең кебек чакта, беләсеңме, сиңа ничә яшь иде?.. Унны тутырып килә идең инде, дүртенче класс укучысы идең.

— Бик ихтимал. Син бит, әти, особый индивидуум.

«Бигрәк тә ул яктан...» дип, кабыргама кадамасын тагын дип сагаеп, тизрәк кунак ягына борылдым.

— Ә сез, хөрмәтле Петр Ильич, өйләнгәнме әле?

— Юк, мин дә буйдак, — диде ул, сакалын чеметкәләп. Аннары,

берьюлы Ислам өчен дә җавап биргәндәй, елмаеп өстәп куйды: — Һаман да шул бер бәла: вакыт җитми.

— Болай булса, сез дә электрон-хисаплау машинасына мөрәҗәгать итмичә булдыра алмассыз,— дидем мин, тегеләрне дә үз чиратымда кытыкларга теләп. — Тотасың да: миңа хәзер фәлән-фәлән яшь, фәлән җирдә эшлим, фәлән сум хезмәт хакы алам, өйләнергә телим, дип мөрәҗәгать итәсең...

— Ә ник? — дип элеп алды Петр Ильич. — Бу мәсьәлә буенча Балтик буе республикаларында дискуссия кебегрәк нәрсә оештырылды. Беләсезме, нинди нәтиҗәгә килделәр: социалистик җәмгыятьтә андый белдерүләргә урын булырга тиеш дигән фикер өстенлек алган. Ә Германия Демократик Республикасында исә «яшем егерме икедә, аксыл-сары чәчлемен, буем 1 метр 72 сантиметр, күзлек киям. Яхшы характерлы урта яшьтәге берәр иргә тормышка чыгар идем» кебек белдерүләрне һәрбер газетада, һәрбер журнал битләрендә очратырга мөмкин.

Ә мин, Лейпциг шәһәрендә халыкара ярминкәдә вакытта, шулай электрон-хисаплау машинасы ярдәмендә кавышкан гаиләдә кунакта булганымны сөйли башладым.

— Ләкин ул адым алай, сез уйлаганча, механик рәвештә генә эшләнми. — Бу сүзләрне Ислам әйтте. — Ул турыда язып, сөйләп колакларны тондырып бетерделәр инде. Перфокарталары туры килгән кешеләргә җавап җибәргәләгәнче, бу мәсьәлә бик җентекләп кабат-кабат тикшерелә. Тикшерү эшендә кагыйдә буларак, психоаналитиклар, графологлар, физиономистлар, социологлар, экономистлар катнаша. Гаять зур һәм вәкаләтле комиссия эшли анда. Хәер, гаҗәп тә түгел: никахта, русча әйткәндә, бракта брак җибәрергә ярамый...

Минем тагын, хатын-кызлар, гадәттә, тормыш тәҗрибәсе тупларга өлгергән, үзләренә караганда шактый өлкәнрәк яшьтәге кешеләрне сайлыйлар, дип әйтергә телем кычытса да, яшьләрнең әллә ни уйлаулары бар дип, бу фикеремнән кире кайттым.

Шул чак Петр Ильич ике генә бармагы белән сакалын чеметкәләп алды да:

— Әгәр дә мөмкин булса, берничә минутка һава алыштырып керсәк һәйбәт булыр иде, — диде. Үлеп тартасы килгән икән. Чәйгә кадәрле тәнәфес ясап алырга булдык. Петр Ильич, түземсезләнеп, шунда ук кесәсеннән сигарет чыгарып кабызды да, тиз-тиз атлап, кабинетка кереп китте.

— Улым... — дидем мин, аның артыннан юнәлгән Исламны туктатып.— Менә бу җиләкне ал әле. Рюмкаларны да калдырма.

Без кабинетка кергәндә кунагыбыз ачык тәрәзә янына утырып рәхәтләнеп тәмәке тарта иде инде.

— Кадерле кунаклар! Теләге булган кеше рәхим итсен, тартынып тормагыз, — дидем мин.

Коньяк, рюмкалар һәм җиләк тутырылган савытны диван буендагы бәләкәй өстәл өстенә куйдым.

Ул арада Ислам киштә янына барып басып, китаплар караштыра башлады.

— Петр, күз сал әле, — диде ул, искитмәле табыш ясаган кебек итеп.— Ультразаманча ич бу, ә!.. Нәрсәгә охшаганын сиземлисеңме?

Аның кулында кечерәк кенә катыргыга майлы буяу белән эшләнгән бер этюд. Зинаидадан калган нәрсә булса кирәк, миңа таныш әйбер түгел иде ул.

— Әйе, «Нон-Финито»га тартым...

Ислам миңа мөрәҗәг ...ь итеп:

— Әти, каян алдың бу «шедеврны»? — дип сорап куйды.

— Хәтерләмим. Очраклы рәвештә эләккәндер ул монда...

Кызу бәхәс башлау өчен шул җитә калды. Ислам белән кунакның сүз көрәштерүеннән мин Көнбатыштагы сәнгать дөньясында нииндидер «Нон-Финито» дигән яңа агым барлыкка килүе турында төшендем. Буржуазиянең үзләренә корал итеп, культ итеп алган бу агым теориясенең асылы, тамашачыларның фикер йөртү горизонтын «киңәйтү» яки тәэсир итү сәләтен «көчәйтү» хисабына, формадан баш тартуга кайтып кала икән. «Нон-Финито»ның төп принциплары: «Тән — сын түгел, ә хәрәкәт масса түгел, бәлки энергия».

Һәдия кереп, чәйгә дәште.

Кабат хәзерләнгән, көлеп торган табын янына утырыштык. Кай арада өлгергәннәр диген! Гомумән, Һәдиянең аш-суга оста булуы, уңганлыгы, чиста-пакьлыгы торган саен хәйран итә мине.

Яшьләрнең анда-монда уйлары юк, дөньяларын онытып, бүген үк балыкка бару, ниндирәк кармаклар хәзерләү турында планнар коралар. Мине дә үзләре белән барырга кыстыйлар. Бик барыр идем, ләкин бүген кичке дүрттә генеральный директорда киңәшмә буласы шул. Көн тәртибендә бер мәсьәлә: Мәскәүдән аерым теплоход белән киләчәк чит ил белгечләрен каршы алырга әзерләнү.

2

Чит ил вәкилләренең әледән-әле КамАЗга килеп торулары хәзер инде гадәти хәлгә әверелеп китте. Шушы арада гына АКШның сәүдә министры Дент, шулай ук дәүләт департаментының, сәүдә палатасы һәм финанс министрлыгының җаваплы хезмәткәрләре, фонд биржаларының эшлекле даирәләре, Америка промышленникларының милли ассоциациясе вәкилләре булып киткәннәр иде.

Һәм менә тагын яңа хәбәр: КамАЗны төзүдә катнашкан капиталистик илләрнең (ә алар бик күп) белгечләре, инженер-техник хезмәткәрләре, бизнесменнары зур дизельэлектроход белән иртәгә Чаллыга киләчәкләр.

...Шул ук көнне автозавод комплексының генеральный директоры Леонид Борисович Васильев мөхтәрәм кунаклар хөрмәтенә кабул итү мәҗлесе оештырды. Әмма чит ил вәкилләре, кичкә кадәр берничә сәгать вакыт бар дип, КамАЗга экскурсиягә барырга теләк белдерделәр.

Миңа кабат, нәкъ каршы алгандагы кебек, гид вазифасын үтәү өчен, автобусларның берсенә кереп утырырга туры килде.

Карыйм, бу автобустагыларның күпчелеге туристлар, ял итүчеләр, директор сүзе белән әйтсәк, иярченнәр. Каршы алганда, кемдер ничәләп кеше килүе белән кызыксынган иде. Шунда Леонид Борисович: «Эшкә дип атап килүчеләре әллә ни күп түгел, иярченнәре байтак аларның. Хатыннары, туган-тумачалары. Аларга тагын төрле илчелекләрнең ялга, экскурсиягә чыккан вәкилләре дә кушылган. Кыскасы, күнелегезне киң тотыгыз», — дип әйтеп куйган иде.

Үзара әңгәмә алып баручыларның сүзләренә колак салам. Күпчелеге инглиз телендә сөйләшә. Минем каршымда ук ике пар утыра. Хатын-кызы мини юбкадан. Тезләре генә түгел, ботларына кадәр шәрә. Изүләре дә, беләкләре дә ачык. Йонлач чуклы, киң кырыйлы эшләпәсе астыннан чыккан чәченең төсен аник әйтүе кыен: ниндидер зәңгәрсу-яшькелт төстә. Сул кулының нәзек беләгенә алтын елан чорналган. Чандыр ханым чак кына хәрәкәтләнү белән, елан, авызыннан үзенең ике җапле зәһәр угын чыгарып, күзләреннән шунда ук ут чәчә башлый. Баксам, еланның башы, ясмык кадәрле генә, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән сәгать икән.

Ир-аты беркадәр өлкәнрәк яшьтә. Аның инглизларга гына хас салмаклыгы һәрбер хәрәкәтеннән диярлек күзгә ташланып тора. Аны-сы тездән югары кыска чалбардан. Чак кына кәкрәеп килгән балтыр-сыйракларын җирән төстәге куе төк баскан. Аягында — табаны машина покрышкасыныкы сыман эре сырлы ботинка, башында — чуклы фәс. Ә йөзен, тирә-яктан түгәрәкләп, «скандинавия» сакалы уратып алган. Беренче карашка ул, инженер яки белгеч булудан бигрәк, берәр кәеф-сафа корып йөрүче туристны хәтерләтә иде.

Кузгалып китеп олы юлга чыгу белән, урынымнан күтәрелеп, пассажирларга инглиз телендә дәштем. Инглиз теле халыкара тел, аны бөтен дөнья белә.

— Хөрмәтле джентельменнар, дамалар! Мин сезнең автобусның гиды булам. Кызыксындырган сорауларыгыз булса, рәхим итегез...

Минем сүзләрем кунакларга хуш килде, ахрысы, кайсыдыр хәтта: «О, кэй!» дип сәламләгән кебек кулларын күтәреп куйды.

Беренче сорау немецча бирелде. Күрер күзгә шактый мөлаем, пөхтә киенгән урта яшьләрдәге кеше. КамАЗга эшкә килүче булса кирәк. Ул минем кем булуым һәм кайда эшләвем белән кызыксына икән.

Мин «КамАЗ»да инженер булып эшләвемне әйткәч, шуның өстенә аңа җавапны да немецча биргәч, автобустагыларның кызыксынуын тагын да арттыра төште. Шунда ук икенче сорау бирделәр. Монысы инде инглизчә һәм минем нинди өлкәдә инженер булып эшләвем турында иде. Җавапны да инглиз телендә бирдем.

Ул арада безнең эскорт ап-ак диварлар тезелеп киткән яңа Чаллыдан чыгып бара иде инде. Борылышка җитәрәк каерылып алга таба күз төшереп алдым. Машиналар, машиналар... Алда уннарча «Волга»-лар, «Чайка»лар, «ЗИЛ»лар. Алардан соң инде автобуслар колоннасы.

Шул вакыт бая гынак беренче булып сорау биргән немец кабат миңа мөрәҗәгать итте. Ул минем чит ил телләрен ничек белүем белән кызыксынды.

— Миңа чит илләрдә булгаларга туры килде, — дидем мин. — Эш белән. Шунда өйрәндем.

— Шулаймы?! — дип, күптәнге танышын очраткан сыман итеп элеп алды немец.— О-о, яхшы! Бик яхшы!..

Аннары инде кайсы шәһәрләрдә, нинди урыннарда булуым турында төпченеп сораштыра башлады.

Борынгы, әмма сокланырлык гүзәл Лейпциг һәм аның атаклы ярминкәләре турында беркавым сүз куертып алдык. Лейпциг ярминкәләре, кагыйдә буларак, «Интернациональ сәүдә һәм техник прогресс өчен» дигән девиз астында үтә бит.

Машиналар, җил уйнатып, тимер-бетон автострада буйлап тоташ агым булып бара. Бу юллар — автогигантның кан тамырлары. Алар аңар сулыш, җан бирәләр. Юл — ул тормыш, ди гарәп мәкале. Бу тирәдәге юлларга, алардагы хәрәкәткә карап гаҗәпләнәсең: никадәрле техника эшкә җигелгән монда.

Юлның уң ягында, берничә катлы йорт биеклеге итеп «КамАЗ» дип язып куелган махсус стендны узу белән, завод территориясе башланды. Пассажирлар барысы да тәрәзәләренә текәлделәр. Әй-йе, карап хәйран булырлык нәрсәләр бар шул монда!..

Ниһаять, килеп җиттек.

Без «12-А» объектында. Бу ак тимер-бетоннан коеп эшләнгән завод корпусының озынлыгы үзе бер километр чамасы бар. Аның буйдан-буйга сузылган тоташ тәрәзәләрендә кояш нурлары чагылып, күзләрне камаштыра. Алгарак чыгып торган фасадына зәңгәрсу чынаяк пли-

тәләр ябыштырылган. Панель парталларының буеннан-буена көмеш сыман ак алюмин путалар сузылган.

Мин кунакларны цех эчен карап чыгарга чакырдым. Әмма кунаклар цех корпусының як-якка ачып җибәрелгән иләмсез биек, галәмәт зур тимер капкаларының берсе янына якынлашу белән туктап калдылар. Цех эчендәге шау-шуны, колак тондыргыч тоташ гөрелтене ишетеп, бусага аша атлап керергә берсенең дә кыюлыгы җитмәде. Анда чыннан да хәйран тамаша. Каяндыр югарыдан, цех корпусының түшәме астындагы тимер араталарыннан көлтә-көлтә булып электросварка очкыннары коела. Сварка эшләре берьюлы берничә урында алып барылгангамы, бу күренеш, ничектер, гигант фейерверкны хәтерләтә иде. Якында гына пулеметтан аткан авазлар чыгарып, отбой чүкечләре эшли. Тагын нәрсәдер бик яман ухылдый, тирә-якны дер селкетә. Хәтта аяк астындагы җир тетрәнеп, вибрация ясап тора сыман...

Кунакларыбыз автогигант комплексының яртысын да карап бетерә алмадылар, алҗыдылар. Аларга берәр сәгатькә ял бирергә булдык. Шул арада аларны берьюлы биш йөз кешегә хезмәт күрсәтә торган эшчеләр ашханәсенә алып кереп чәй эчертеп чыктык. Стеналары милли орнаментлар белән бизәлгән, гөлләр үсеп утырган киң якты ашханә кунакларны янә хәйранга калдырды.

Чәйдән соң да кунаклар, йөрибез, карыйбыз дип, әллә ни атлыгып тормадылар, завод корпуслары янында туктаганда автобуслардан да чыкмый башладылар.

Кояш кичке якка авышкач кайтырга чыктык. Кузгалгач, тәрәзәләрнең ачып куелган өске өлгеләреннән талгын җил керә башлады. Бу хәл бөркү автобустагыларга җан өргәндәй тәэсир итте. Әфәнделәр һәм ханымнар яңадан җанланып, үзара гәп сатарга керештеләр.

Шул вакыт автобусның урта бер җирендә утырган бер әфәнде миңа мөрәҗәгать итте. Җыйнак кына гәүдәле, нечкә итеп кара мыек җибәргән. Тар җилкәле, кара тут йөзле булуы беләнме, беренче карашка ул кара тараканны хәтерләтә иде. Тавышы көр чыга үзенең.

— Мин Франциядән, — диде ул, — «Франц-Пуатвен» фирмасыннан. — Француз, бирергә теләгән соравын онытканн сыман, бермәлгә туктап калды да кинәт сорап куйды. — Мсье Кутузов ... сез чыннан да татармы?

Төп мәсьәләгә кагылышлы булмаган бу сорау бер мине генә түгел, башкаларны да сагайтты. Бу мыеклы французның тел төбендә ниндидер мәкер ятуын сиземләү әллә ни авыр түгел иде.

— Әйе, — дидем мин бер дә исем китмәгән кыяфәт белән.

— Бәлки сез руслашкан татардыр?

— Гафу итегез, мсье Шавалье... Фамилиягезне дөрес әйттемме?..

— О-о, әй-йе!

— Кабат гафу итүегезне үтенәм. Мин сезнең соравыгызны төшенеп бетә алмадым...

«Франц-Пуатвен» фирмасы вәкиле, тамаша кылырга әзерләнегез дигән сыман, як-ягына карап алды да дәвам итте:

— Татарлар турында, дөресрәге, Идел-Урал штаты татарлары турында, минем үземә, мәсәлән, бөтенләй диаметраль капма-каршы мәгълүматлар, информацияләр белән танышырга туры килде...

— Кызык, ниндирәк мәгълүматлар, ниндирәк информацияләр икән ул? — дигән булдым мин, чак кына ачуым кабара башлаганны тоеп. — Әгәр дә сер булмаса, шуны аңлатып бирсәгез иде?

— О-о, әлбәттә! Сез, мсье Кутузов, үзегезне инженер дип таныштырдыгыз. Мин танышкан мәгълүмат-информацияләрдә, мәсәлән, татар халкына, имештер, ана телендә уку-язу тыела. Гомумән алар үз телләрендә белем алу хокукыннан мәхрүм ителгәннәр. Телләре дә,

имөштер, бары тик рус теленең бер диалекты булып кына калган... Шунлыктан культуралары сүрелүгә, ягъни йомылуга таба бара...

— Шавалье әфәнде!.. — дидем мин, французның сүзен бүлеп. — Сез дөрес булмаган мәгълүматлар, искергән информацияләр белән эш итәсез.

Автобустагылар гөжелди башладылар. Кайберләре әңгәмәнең шундый борылыш алуына борчыла, хафалана, кайберләре исә, авызларын ерып, «шәп-шәп!..» дип хуплап торалар иде.

— Сез мине гафу итегез, Шавалье әфәнде, — дип дәвам иттем мин. — Хәзерге информация ташкыны чорында кичә яңа, кызыклы булып күренгән информацияләрнең дә бүген инде бик нык искергән булуы мөмкин... Гадәттә без андый информацияләрне, перфолентаны әрәм итмәс өчен, электрон-хисаплау машинасының табуляторына да кереп тормыйбыз...

Яңадан гөжләп алдылар. Күрәм, француз тыелу турында уйламый да. Минем әдәп саклап, читләтебрәк кенә җавап бирүем аны канәгатьләндермәде. Дәлилләр көтә булса кирәк.

— Ә татарларның фән һәм культура өлкәсендәге хәлләренә килгәндә эшләр менә болайрак тора бит, Шавалье әфәнде...

Мин аңа Америка, Англия университетларында «Идарә ителә торган атом-төш реакцияләре» дигән темага лекцияләр укып кайткан татар егете академик Сәгъдиев хакында сөйләдем, үземнең улым Ислам хакында әйттем.

Ул арада «Франц-Пуатвен» вәкиле бөгелә-сыгыла гафу үтенгән сыман итте дә сүзне икенчегә борып җибәрде.

— Мсье Кутузов, татар инженерларына хезмәт хакы ничек түләнә?

— Гафу, мсье Шавалье, соравыгызны яңә аңлап бетермәдем, — дидем мин.

— Пардон, мсье Кутузов... Рус булмаган инженерларга эш хакын ничек түлиләр дип соравым иде минем.

Менә бит, ә! Ничегрәк итеп җавап бирергә инде моңа? Каты бәрелер идең, әнә, үзен «Франц-Пуатвен»нан ди. Нәкъ без монтажлап ята торган стенд комплексы фирмасы вәкиле. Димәк, бергә эшләргә, аралашырга туры киләчәк. Аннары каты бәрелү — көчсезлек билгесе...

— Бездә инженерларны, АКШтагы кебек расаларга яки ФРГдагы кебек милләтләренә, мөлкәт хәлләренә карап бәяләмиләр, Шавалье әфәнде. Бездә инженерлар белеменә, стажына, квалификациясенә карап бәяләнә. Билгеле, боларда инженерлар арасында берниндидә аерма юк икән дип уйлый күрмәгез. Алай түгел. Бездә инженерлар күп һәм күп төрлеләр... Белгәнегезчә, Англиянең күренекле фәнни публицисты Джеймс Кроузер үзенең соңгы китабында инженерларны дүрт төрле классификациягә бүлә. Ә Гоу белән Будворт аңардан да уздырып җибәрәләр, алар, мәсәлән, инженерларны бәяләү өчен сигез төрле класс тәкъдим итәләр: диагност, эрудит, эстет, методолог, индивидуалист һәм башкалар... Боларның барысы да сезгә билгеледер дип уйлыйм. Әмма бу турыда, Шавалье әфәнде, коллегалар буларак, без башка вакытта сөйләшербез. Монда бер сез генә түгел...

— Пардон, мсье Кутузов!.. Әгәр дә мөмкин булса, тагын бер генә сорау. Монысы инде соңгысы...

— Рәхим итегез.

Кайнар табигатьле француз, әйтер сүзен әйтеп өлгерә алмавына курыккан кеше сыман, йотлыга-йотлыга тизә башлады.

— Юлда хикмәтле сүз ишеттем. Без утырып монда килгән дизель-электроходның исеме... Маутхаузен концлагеренда җәзалап үтерелгән генерал Карбышевның да бабасы татар булган, имеш?.. Әйтсәгезче, хакмы шул сүз?..

Автобуста утыручыларның күзләре миндә: ни дип җавап биргәнемне көтәләр.

— Әй-йе,— дидем мин.— Генерал Карбышевның бабасы чыннан да татар булган һәм «Карабаш» дигән кушамат йөрткән. Дмитрий Михайловичның үзе әйтүенә караганда, Карбышев фамилиясе шуннан калган.

Ниһаять, француз:

— Мерси, мсье Кутузов! — дип тынып калды.

Кунаклар янә бер кат гөрләшеп алдылар. Ул арада икенче рәттә, нәкъ каршымда утырган бер джентельмен кулын күтәрде. Озын һәм чандыр гәүдәле. Кыяфәте бик җитди. Иң элек ул, кайчан тынычланасыз инде дигән сыман, як-ягына күз төшереп алды. Бары тик шуннан соң гына үзенең кем булуын һәм кайдан килгәнлеген әйтте. Америка Кушма Штатларыннан икән.

— Мин бары тик бер сорау бирәм, — диде ул, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. — Сезнең бу супергигант заводыгызда ракеталар йөртүче, «Батыр» дип атала торган авыр тягачлар, хәрби машиналар чыгарылачак дигән версия йөри. Шул турыда сезнең үзегездән ишетергә теләр идем...

Американы сүзендә торды, бүтән сорау биреп маташмады. Сорау биргәндә дә, җавап көткәндә дә аның маскага охшаган йөзендә бер генә мускулы да селкенмәде.

— Әйе, андый версиянең Америкада булуы гаҗәп түгел, — дидем мин, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.— Бәлки ишетеп белә дә торгансыздыр, сезнең атаклы «Форд» корпорациясе белән КамАЗның кою производствосын җиһазлау турында сөйләшүләр дә алып барылган иде. Әмма сезнең конгресс, конгресстан да бигрәк Пентагонның вәкаләтле даирәләре, КамАЗга җибәреләсе җиһазларны хәрби статьяларга кертеп, бу эшкә каршы төштеләр. Әмма сезнең бизнесменнар ул кадәр ук беркатлылар түгел. Кем белән сәүдә итәчәкләрен бик яхшы беләләр. Нәтиҗәдә, әнә, сезнең «Пультман» концернына керә торган «Свиндел Дресслер» фирмасы белән үзара контрактка кул куелды. Бу контракт буенча фирма Кама автомобиль комплексы өчен кою заводы проектын эшләде, шулай ук бу завод өчен АКШтан җиһаз алдыруда хезмәттәшлек итә башлады. Бәлки белә дә торгансыздыр, шул уңай белән Мәскәүдә «Бэнк ОФ Америка» банкасы эшли башлады. Шулай ук Американың күренекле банкиры һәм җәмәгать эшлеклесе Дэвид Рокфеллер үзе килеп «Чейз Манхэттен» банкысын ачты... Һәрхәлдә, бу кадәресе сезнең өчен яңалык түгелдер, дип уйлыйм мин. Чөнки КамАЗ турында хәзер бик күп департаментларда, парламентларда, сенатларда, конгресс палаталарында авыз тутырып сөйлиләр. Ә хәзер соравыгызга җавап: юк, безнең завод хәрби машиналар түгел, ә халык хуҗалыгы өчен өч күчәрле, авыр йөк ташый торган автомобильләр чыгарачак.

Шунда күңелемә: «Теләгән тәкъдирдә җитештерелә торган теләсә нинди продукциянең төрен, ассортиментын тормыш ситуацияләренә карап үзгәртеп тә була...» дип төрттереп куйыйммы икән әллә дигән уй да килгән иде, әмма сүз озайтырга теләмичә тыелып калдым.

Тагын сорау бирделәр. Бая теленә салынган француз янында утырган яшь кенә бер мөлаем ханым күтәрелде.

— Мсье Кутузов, минем соравым бары сезгә кагыла, — дип башлады ул. — Сез, мсье Кутузов, башта немецча сөйләштегез, аннары инглизчә җавап кайтардыгыз. Француз теле дә читтә калмады... Бәлки, сез башка телләрне дә белә торгансыздыр?..

«Мадам» дип мөрәҗәгать итәргә телем бик кычытса да, тыелып калдым.

— Юк, мадмуазель, — дидем ахыр чиктә. — Мин бит полиглот түгел. Бары тик инженер гына. Аннары сез санап чыккан телләрне дә мин бик чамалы гына беләм. Кызганычка каршы, башка телләрне белмим шул...

— Өйрәнмисез дәме?

— О-о, мадмуазель! Анысы икенче мәсьәлә. Өйрәнәм, билгеле.

Бу игътибардан сылу ханым нурланып дәвам итте:

— Әгәр сер булмаса, бәлки әйтерсез? — дип сорап куйды ул.

— Сер түгел, әлбәттә. Соңгы вакытта мин туган телемне — татар телен үзләштерәм...

Кунаклар мине шаяра дип уйладылар, ахры, янә шаркылдап көлешеп алдылар. Мадам да, ярдәм эзләгән кеше сыман, як-ягына карангалап куйды. Мин тизрәк аңар ярдәмгә ашыктым.

— О-о, мадмуазель!.. — дидем мин, гафу үтенергә җыенган кебек итеп. — Тик сез мине дөрес аңлагыз. Бу сүзләрне мин чын күңелдән әйттем. Моның шулай икәнлеген исбат итү өчен ярдәмгә бөек Вольтерны чакырырга мәҗбүрмен. Аның туган тел, ана теле турында әйткән сүзләрен бәлки сез дә хәтерлисездер. Биш-алты ел эчендә, дигән даһи әдип, Европаның өч-дүрт төп телен өйрәнергә мөмкин, әмма кеше бөтен гомере буе бер телне үзләштерергә тиеш: ул да булса — туган телен. Шәп әйткән бит! Чыннан да, бары тик туган телен яхшы белгән, аның бөтен нечкәлекләрен үзләштергән кеше генә үзен тулы мәгънәсендә культуралы, халыкның патриот улы дип саный ала...

Юкка исбат итеп маташканмын икән, сылу ханым аңлады мине, яңадан яктырып-нурланып бер елмайды да:

— Мерси, мсье Кутузов! — дип сүзен түгәрәкләде.

Ул арада безнең автобус «Акчарлак» дип аталган (әле яңарак кына ачылган) кафе каршындагы мәйданга кайтып туктады...

Мәҗлес төн урталарына кадәр дәвам итте. «Танышу, дуслашу хөрмәтенә» дип, кемнәр белән генә чәкешелмәде, кемнәр белән генә гәп сатылмады. Хәтта аз сүзле, вәкарь белән генә сөйләшүче американың да йөзендә елмаю күрергә язган икән. Мин үтеп барганда, ул, бармак илле генә эчемлек салынган фужерын күтәреп: «О, кэй, сэр Кутузов!» — дип елмаеп калды. Тагын ниндидер юантык гәүдәле, алтын кысалы пенсне кигән бер бәндә, юлыма каршы төшеп, рус телен ватып-изеп автобустагы әңгәмә өчен рәхмәтен белдерде. Үзенең дә берничә соравы булып та, вакыт булмау сәбәпле бирә алмыйча калуына уфтануы турында әйтте.

Соңрак музыка яңгырады. Залның урта бер җирендәге ачыклыкка чыгып биючеләр дә табылды. Шул вакыт миңа сораулар биргән сылу ханым килеп, минем белән бергә биергә теләвен белдерде. Миңа да уртага чыгып, даманың озын, нәзек бармакларын сул учыма алып, уң кулымны шөпшәнеке сыман нечкә биленә салырга туры килде...

Бибез. Мадмуазельның кабарынкы җирән чәчләре иякләремне, иреннәремне кытыклады.

— Мсье Кутузов, сездә дә танцыга дамалар үзләре чакырамы?..

Шулчак күзләренә игътибар иттем мин моның. Карадым да хәйран булдым. Андый җете яшел, шулай еш төсен үзгәртә торган күзләрне минем гомеремдә дә күргәнем юк. Нәкъ радиоалгычның яшел «күзе» кебек ялтырап, янып торалар иде алар.

— О-о, мадмуазель! Тормыш бу, төрле чаклар була, — дигән булдым.

Биючеләр күбәйде. Сылу ханым мөлаем гына елмаеп:

— Сез, мсье, шундый зур, мәһабәт гәүдәле, нәкъ аю кебек...— дип куйды.

Елышуына караганда, аңар минем белән бию әллә ни җайсыз түгел иде кебек. Шулай да:

— Әллә уңайсызмы? — дигән булдым.

— О-о, киресенчә!.. Бик уңайлы...— Француженканың күзләре яңадан яшел ут булып кабындылар.— Яратам мин эре ир-атны...

Яа-а, бу Франция хатын-кызлары! Тикмәгә генә алар дөньяда иң нәзакәтле, иң дәртле булып саналмый торгандыр. Ир-атны хуштан яздыра, әсир итә, үзләренә бәйли һәм тота белүләре белән данлыклылар алар.

Музыка тәмамланды. Дамамны урынына кадәр озата киттем. Карасам, миңа четерекле сораулар биреп газапланган нечкә мыеклы, каратут йөзле француз белән бер өстәл артында утыра икән.

— Таныш булыгыз, — диде мадам, француз ягына ым кагып. — Минем ирем, Анри...

«Менә сиңа мә! — дип уйлап куйдым мин.— Ә үзе эре ир-атны яратам, дигән иде».

Куллар кысышып, кабат исемнәребезне әйтештек. Хатын-кызның исеме Каролина икән. Каролина Арну. Ул арада елгыр француз сикереп торып, миңа бик тә инде ярарга теләгән сыман кыланып, утыруымны үтенде. Җәһәт кенә чиста фужер алып вино салды һәм якыннанрак танышу хөрмәтенә эчеп куярга тәкъдим ясады. Каролина да бу фикерне хуп күреп, күзләрен утландырып, фужерын кулына алды.

— Мсье Кутузов, — дип башлады француз. — Сез бая миңа чак кына ачуландыгыз кебек... Сораулар биргәндә дип әйтүем. Әгәр дә алай икән, гафу үтенергә рөхсәт итегез.

— Зинһар, юкка борчыла күрмәгез.

Сизеп торам, мсьеның мине үз яныннан тиз генә җибәрергә нияте юк. Ул кабат утырган җирендә бөтерелгәләп алды да, җавап бирергә теләк белдергән укучы сыман, яңадан алга таба омтылып куйды. Аннары:

— Мсье Кутузов, тагын бер генә сорау... — дип авызын ерды.

— Рәхим итегез!

— Мсье Кутузов... «Кутузов» сезнең үз фамилиягезме?

— Әйе, үземнеке. Тик сез әйткәнчә «Кутузов» түгел, ә Котдусов. Татарлар арасында киң таралган исем ул.

— Алайса, пардон! Сез минем шулай төпченүем өчен кичерегез, әлбәттә. Без — французлар өчен фамилия гаять зур нәрсә. Бездә хәтта «фамилия ул — оҗмах ачкычы» дигән афоризм да бар. Минем бирергә теләгән соравым шул иде: атаклы фельдмаршал Кутузов сезнең нәселдән, сезнең бабаларыгызның бабалар нәселеннән түгелдер бит?..

— Юк. Безнең нәселнең фельдмаршаллар белән бернинди дә алыш-бирешләре булмаган.

Аннары Каролина минем шәхси тормышым белән кызыксынып, хатыныгыз кайда, кем булып эшли, дип сорады. Инде Һадиянең төзелештә гап-гади мастер булуы турында ишеткәч, янә кабынып, аны үз күзләре белән күрергә, танышырга теләвен белдерде.

Мин аларны таныштырырга, икенче тапкыр килгәндә кунакка чакырырга вәгъдә иттем. Ул арада сүз, кискен борылыш ясап, Анриның нинди концерннан, КамАЗга нинди йомыш белән килүе мәсьәләсенә күчте. Шунда миңа аның нәкъ без эшләп ята торган үзәк техник-контроль пунктын, махсус стенд комплексын җиһазлашырга һәм көйләргә килгәнлеге мәгълүм булды. Димәк, бу француз белән безгә әле бергә эшләргә дә туры киләчәк икән!

Сүз иярә сүз китте. «Франц-Пуатвен» фирмасы турында да, Париж янында безнең «Автопромимпорт» вәкилләре яши торган махсус «Оф-

фис» һәм Анри хезмәт итә торган «Акыллы машиналар» күргәзмәсе турында да әңгәмә корып алдык.

Нинди шайтан телемнән тарткандыр, «Франц-Пуатвен» фирмасыннан алынган контроль стенд комплексының компьютер системасына җитди генә үзгәрешләр кертергә җыенуыбыз турында да ычкындырдым. Булачак, бергә эшләячәк «коллегамның» йөзендәге мөлаем елмаюны җил тузгыттымыни; кинәт җитдиләнде, күзләренә кадәр түгәрәкләнде.

— Ул турыда уйламагыз да!..— диде ул, мине ниндидер зур, халыкара җинаятьтән йолып калырга теләгәндәй.— Патенттан, лицензиядән чак кына тайпылсак та дөньякүләм скандал чыгачак...

Мин үземнең гаҗәпләнүемне яшерә алмадым.

— Камилләштерү максаты белән дәме?

— Камилләштерү максаты белән дә,— диде француз.—Ул эш сезнең компетенциягә керми. Компьютерларны һаман үстерү, камилләштерә бару өстендә фирма үзе шөгыльләнә.

— Шулай итеп, конфликтка керербез микәнни?..

Француз күзен дә йоммады.

— Юк, кермәбез. Аның кирәге булмаячак. Чөнки мин сезне менә хәзер, алдан ук конфиденциаль рәвештә кисәтеп куям: бернинди үзгәрешләргә, тайпылуларга юл куелмаячак.

— Әгәр дә ул үзгәрешне производство таләп итсә?

— Ул вакытта компания белән яңадан эшлекле мөнәсәбәткә керергә туры киләчәк. Бу бик катлаулы эш: яңа контрактация, аккредитацияләр белән бәйләнгән. Һәм безнең шеф, минем патрон, андый сделкаларга бармаячак.

— Сәбәбе?

— Сәбәбе бер: конкуренция.— Анри килешле мыекларын як-якка тырпайтып, елмаеп алды да, миңа таба иелә төшеп, күзләремә туптуры карап өстәп куйды.— Сер булса да әйтим инде, миңа фирма консультанты яки анда сезгә «коллега» булудан бигрәк, гаять әһәмиятле ике төрле вазифа йөкләтелгән. Беренчесе: патент һәм ике арада төзелгән килешүнең сагында тору. Аның төгәл үтәлүен тикшерү.

— Икенчесе?

Француз әйтергәме, әйтмәскәме дигәндәй, пауза ясады, аннары дәвам итте.

— Ә икенчесе — бизнес. КамАЗ хәзер үзенә күрә дөнья күләм рекламага әверелде. Сезнең белән эш иткәндә бездә клиент-дивидендларга мохтаҗлык булмаячак, минемчә. Нәрсә әйтергә теләгәнемне аңлагансыздыр дип уйлыйм.

— Әйе, аңлашыла.

## 3

Бүген өйгә машина җибәрделәр. Эшкә барышлый, Яңа шәһәргә сугылып, «Франц-Пуатвен» вәкиле Анри Шавальены да үзем белән ала килергә тиеш идем.

Машина җил уйнатып алга томырыла. Тирә-якны күзәтеп барам. Адәм әйтеп адәм ышанмаслык үзгәрешләр монда. Мин Чаллыга килгән елда гына бу тирәләрдә тар юлга елышып авыл өйләре тезелешеп утыра иде. Язгы-көзге пычракларда ул өйләрнең карарлыгы булмый. Өзлексез йөреп торган машиналар көпчәге астыннан чәчрәп чыккан пычрак-тузанга шул кадәр баткан булырлар, әйтерсең лә алар яңарак кына язгы болганчык су астыннан калкып чыккан...

Бу тирәләрдә хәзер, әнә, бишәр катлы өр-яңа йортлар тезелеп киткәннәр.

Кая карама — ялт иткән тип-тигез асфальт. Әле яңарак кына июнь яңгыры явып үткән. Бәлки шуңа күрәдер, өй стеналарының, ишекләрнең, тәрәзәләрнең шәүләләре аермачык булып асфальтка төшкән. Җентекләбрәк карасаң, шул асфальт-тротуарда ишек өсләренә куелган рекламаларның сүзләрен дә укып булырлык.

Алда автоград күренде. Ап-ак кала. Берсеннән-берсе биек, берсеннән-берсе матур йортлар күкләргә ашып тора.

Әнә, чак кына арырак, кояш нурларына коенып, мәскәүлеләр төзегән йортлар тигез рәткә баскан. Җиренә җиткереп, пөхтә итеп салынган алар. Әйтерсең лә башкала, монда кешеләрен җибәреп кенә калмыйча, үзенең бер иң матур районын, иң сылу бер өлешен күчертеп утырткан. Монда, нәкъ җырларда җырланганча, башкаланың нуры да, рухы да, хәтта масштабы да чагыла сыман.

Киң урамның икенче ягында культура-агарту объектлары һәм административ биналар салынып ята. Уникешәр-уналтышар катлы бу йортларның архитектурасы да үзгә, игътибарны тартып тора. Кайберәүләрнең тышкы ягы вакланган гранит төсендә табигый таш белән бизәлгән, икенчеләре мәрмәргә охшатып ясалган, өченчеләре исә керамик плиталар белән тышланган.

Чак кына читтәрәк тагын да биегрәк йортлар салына. Алар инде яңа каланың «небоскреблары». Киләчәктә автоградны егермешәр, егерме дүртәр катлы биналар бизәячәк. Тирә-юньдә спутниклар үсеп чыгачак. Шәһәрнең агломерация системасы миллион кешегә исәпләнгән. Берәр елдан ул республикабызда Казаннан кала иң зур шәһәрләрнең берсе булачак, ә матурлыгы белән беренче урында торачак.

Чит ил белгечләре яшәгән корпуслар үзләренә бер «минирайон» булып аерылып тора. Тугызар катлы ап-ак корпуслар алар. Кирәкле корпусны бик тиз таптык. Номерына кереп торырга туры килмәде, мсье Анри Шавалье холлда мине көтә иде инде.

— Хәерле иртә! — дип кул бирешеп күрештек. Коры күрештек. Машинага да сүзсез генә чыгып утырдык. Сизелеп тора, французның кәефе юк. Сәбәбен соңрак белдем: кичә генә Каролинасын озаткан икән.

Шулай да, юлда барганда, дәшми-тынмый баруны әдәпсезлек санаптыр инде, сүз башлады.

— Мсье Кутузов,— диде ул, йөзен минем якка бора төшеп.— Әгәр дә мөмкин булса, мин сезгә бер-ике сорау бирер идем.

— Рәхим итегез, мсье Шавалье.

— Мсье Кутузов, сез социализм төзеп туймадыгызмы әле?

Мин аның соравына сорау белән җавап бирдем:

— Ә сез, мсье Анри, капитал хезмәтчесе булудан туймадыгызмы соң әле?

Француз елмайды.

— Сез сорауга сорау белән җавап бирмәгез. Әгәр дә инде мин хезмәтче икәнмен, ни өчен һәм ни бәрабәренә хезмәт итүемне беләм. Миңа түлиләр...

— Без акча дип түгел, киләчәк дип яшибез,— дидем мин.— Безнең бөек максатыбыз бар.

— Коммунизм, димәкче буласыз. Шулаймы?

— Шулай да булсын, ди...

— Ә аннан соң нәрсә? Морадыбызга ирештек, дип ләззәт дөньясына чумачаксызмы?..

— Юк. Коммунизм — ул әле беркем дә бернәрсә дә эшләмәячәк дигән сүз түгел. Кемдер коммунизмны: старт полосасы, дип атаган. Димәк, ярыш та, көрәш тә бүгенгегә караганда киңрәк колач алачак.

Анри мине кубат бүлде.

— Бу шул ук конкуренция түгелме соң?

— Һич юк! Аермасы җир белән күк арасыдай. Конкурентлар көрәшкәндә ил турында да, туган халкының язмышы турында да уйламыйлар. Аларның максаты бер: нинди генә юллар белән булса да мөмкин кадәр күбрәк өстәмә табыш алу, байлык туплау.

— Ләкин бит социализм да өстәмә табыш алу, мал туплау кебек төшенчәләрне инкарь итми.

— Әмма аермасы бар: кем һәм нәрсә исәбенә бит...

Ул арада безнең машина җыю заводы корпусының алгы ягына килеп туктады. Тиздән, бик тиздән менә шушы олы капкалардан маңгайларына «КамАЗ» дип язылган машиналар чыга башлаячак.

Эчкә уздык. Монтажланып ята торган стенд янында безне минем «питомецлар» — Николай Соснов белән Даниал Ризванов каршы алды.

Мсье Шавалье аларның кем булулары, кайда белем алулары, каян килүләре белән кызыксынды. Даниалның да татар икәнлеген белгәч, кабат телен шартлатырга мәҗбүр булды. Чибәр, үз дәрәҗәсен үзе белүче, төгәл хәрәкәтле, һәр вакыт пөхтә киенеп йөрүче Даниал французны чын-чыннан сокландырды булса кирәк.

Булачак «коллегабыз»ны эшнең барышы белән таныштыра башладык. Иң элек дүрт-биш катлы йорт биеклегендәге корпус эченә алып кердек. Аның эче гөрләп тора — монтаж эшләре бара. Урталай бүленгән махсус стенасының ике ягында да меңләгән киштәләр булачак, ә аларда машинаның запас частьлары урнаштырылачак. Киштәләр янында манорельслар буйлап кабина-лифтлар йөриячәк...

Складның икенче башында, меңләгән киштәләргә «җан кертүче» электриклар. Бригадирлары Алик та шунда. Чегән ул. Бригада членнары аның өчен җаннарын бирергә әзер — шул тикле яраталар.

Баштарак, электриклар килеп эшкә керешкән көннәрдә, алар арасында уен-көлкенең, шаяруның кирәгеннән артык күбрәк булуын күреп, күңелгә шик сыман нәрсә кергән иде. Баксаң, аларның эшләү рәвеше шул икән. Тәмәке көйрәтергә туктау белән цехның түбәсен күтәрердәй итеп шаярышып алалар да эшкә керешәләр. Ә эшләре соклanып туймаслык. Чыннан да үз эшләренең осталары, егетләрнең дә егетләре җыелган монда. Соңыннан тагын шул кадәресе ачыкланды: бригадага эшкә килүчеләр үзенә күрә бер сынау аша үтәләр икән. Эшкә керергә теләүче, контораның кадрлар бүлегеннән бригадир исеменә бирелгән кәгазьне тотып, Алик янына килә. Теге исәнлек-саулык сорашканчы, танышканчы ук, бригада членнары нинди дә булса бер низаг чыгарып, үзара гауга куптаралар. Бу эшне, кагыйдә буларак, «артист» кушаматлы балагур Кәрим башлый. Кычкырына, күтәрелеп бәрелә, бригадир өстенә атәч булып килеп кунакламый гына! «Җитте!.. Түзмәдем түгел, күп түздем. Күп алдалап йөрттегез инде... Монда чиләнеп бушлай эшләп йөрергә кем дип белдегез мине. Әйтергә оят... Сезнең бригадага килгәннән бирле алган хезмәт хакы тәмәкегә җитми. Әнә, КамАЗга орынып торган яңа совхозга китәм. Мөгезле эре терлек симертү комплексы салына... Анда да шул ук кнопкалар, шул ук идарә итү пультлары... Аның каравы, эшләвеңә күрә, учыңны тотып акча аласың. Әнә, безнең кебек ук электриклар шаярып кына да бишәр йөз сум төшерәләр, ди...»

Бригадир да кайнар кеше, авызыннан ут, күзләреннән очкыннар чәчә. Алдыңнан артың матур ди, чәнчелеп кит, дип өстәп куярга да онытмый.

Яңа кеше бу хәлләрне күреп пошаманга төшә. Чынлап торып эшкә дип килгән булса, бригадада кала. «Акча сугу» нияте белән генә йөргән булса — бүтән күренми...

Алик янына якынлашам. Ул эш белән мәшгуль. Киштәләрнең берсе эченә кереп урнашкан да тимер чыбыклардан «пәрәвез» үрә. Кара

болыттай чәчләре тузгыган. Мыеклары кабарып чыккан. Бары тик күзләре генә уттай яна.

Мине күрү белән, каскасын алып, ялт итеп башына чәпәде. Әмма каскасы сыймый, кызыл төстәге матур уенчыкка яки калфакка охшап, түбәсе өстендә генә тора.

— Хәерле иртә, Имам Хисамович!

— Исәнме, Алик. — Сүз югында сүз булсын дигән кебек итеп, чакматашы — Кәрим турында да сорашам.

— Ике көнгә совхозга киткән иде. Шефларга...

— Үзе белән тагын акча сугарга яратучыны ияртмәдеме соң?

Аликның эре тешләре генә ялтырый.

— Юк. Контора хәзер безгә кеше җибәрми. Үзебез алабыз...

Алик, эшеннән бүленеп, минем янга сикереп төште. Сизәм, сүзе бар. Ялгышмаганмын. Эшне дәвам итү өчен кирәкле материаллары бетү алдында, егетләр хәзергә элеккеге объекттан калган материаллар белән эшлиләр икән.

Ярдәм итәргә сүз биреп китеп бардым.

Яратам мин менә шулай шау-гөр килеп торган төзелеш мәйданнарын. Әгәр дә миннән индустриаль эпохабызның мәһабәт һәйкәле КамАЗны ничегрәк итеп күз алдына китерәсең дип сорасалар, ике дә уйламыйча: «КамАЗ миңа металл конструкцияләре челтәре, гигант краннары, электросваркаларның менә хәзерге кебек зәңгәр утлары, меңләгән моторларның тоташ гөрелтесе фонында, билен чылбырлары чыңлап торган киң монтажчы ремены белән буган, башына каска элеп алган баһадир егет булып килеп баса», дияр идем.

Әмма әлеге күңел күтәренкелеге эш бүлмәбезгә кайтып керү белән юк булды. Француз Шавальеның танырлыгы калмаган, нәкъ җәтмәгә кереп чуалган тавык кебек, кыткылдавын белә. Даниалга авыз ачарга да ирек бирми, очынып-очынып өстенә килә. Алларында, өстәлнең буеннан-буена, булачак контроль стендының чертеж-схемасы сузып салынган.

Гауганың нәрсәдән килеп чыкканлыгын бик тиз төшендем. Барысы да Даниалның теле авызына сыймаудан икән. Мактанырга, бәлки яңа коллегасының күңелен күрергә теләптер, ул французга безнең тарафтан схемага кертелгән үзгәрешләр турында сөйләгән дә биргән.

Сизелеп тора, бу хәл Даниалның да кәефен бик нык бозган. Ул түземсезләнеп тегеңә нәрсәдер төшендерергә тырышып карагандай итә. Әмма француз аның сүзләрен колагына да элми, техник контроль стендының схемасына без кертергә җыенган үзгәрешләр турында ишетергә дә теләми.

— Юк, юк! — диде ул кырт кисеп.— Бу турыда сүз булуы да мөмкин түгел.

Мсье Шавалье сүзне дәвам итәргә дә теләмәгән бер кыяфәт белән чертеж-схемалар ягына кулын гына селтәде.

Бу хәл Даниалны тәмам аптырашта калдырды.

— Без үзгәртмибез... Аңлыйсызмы сез мине. Үзгәртмибез... — дип кызганнан-кыза барды ул, — бары тик камилләштерергә генә уйлыйбыз...

Француз, безне юри котыртырга, чыгырыбыздан чыгарырга теләгәндәй, тыныч кына дәвам итте.

— Анысы сезнең эш түгел. Риза булмаган узеллары яки детальләре бар икән, рәхим итегез, фирмага рекламация бирә аласыз. Ике арадагы килешүдә андый искәрмәләр бар...

Бу юлы Николай да түзмәде.

— Ләкин бит без бары тик схеманы яхшыртырга гына телибез...

Мсье Шавальеның үз тугызы тугыз.

Анысы да сезнең компетенциягә керми. Кирәк икән, рәхим итегез, бүген үк фирмадан белгечләр чакыртырга мөмкин.

Минем өчен бу сүзләр таныш иде инде. Әмма мин, моннан ике-өч кенә көн элек, банкеттагы сөйләшүгә әллә ни әһәмият биреп бетермәгән идем. Анда телгә алынганнар сүз уңаенда гына әйтелгән фикерләр кебек кенә булып тоелган иде миңа.

— Ләкин бит без инженерлар... — дип исбат итәргә маташты Николай.— Стенд бит безнең завод өчен монтажлана. Димәк, ул безнеке...

Тел-көйгә килмәс француз әйтеп бетергәнне дә көтмәде.

— Ә патент безнеке...— Ул тагын да җитдиләнеп дәвам итте.— Ниһаять, аңлагыз инде, инженер әфәнделәр: бу стендның хәзергә безнең производстводан төшкәне юк. Аңлыйсызмы шуны? Сезнең КамАЗ хәзер реклама гына түгел, үзе бер күргәзмәгә әверелеп бара... Әгәр дә берәр бизнесмен, босс сездәге, сез камиллаштергән вариантын килеп күрсә?..

— Без аны витринага, экспозициягә яки анда халыкара күргәзмәгә куярга җыенмыйбыз.

Французның үз аргументлары:

— Сезнең КамАЗның хәзер күргәзмәдән ким җире юк...

Ул безнең сүзләрне ишетергә дә теләмәде. Күренеп тора, хәзер аны күндерү турында уйларлык та түгел. Һәм ул: «Хәзер үк генеральный директорыгыздан аудиенция сорыйм һәм бүген үк Париж белән элемтәгә керәм, мондагы башбаштаклыклар турында кичекмәстән фирмага хәбәр итәм!» — дип тузынды.

Аның каядыр соңга калудан курыккандай җил-җил чыгып китүенә караганда, мсье Шавалье чыннан да бу кисәтү белән генә чикләнергә тиешкә ошамаган иде.

Яшерен-батырын түгел, бу чит ил фирмасы вәкиле белән шулай телгә килү, шулай аңлашылмаучылык чыгу яшь коллегаларымның гына түгел, минем дә кәефне ярыйсы гына кырды. Менә шундый чакларда: «Миңа гына кирәкмени соң мондый җыен четерекле эшләр? Дөнья бөкресен мин генә төзәтергә тиеш түгелдер ләбаса!» дип, үзүземне битәрләп ташлаган чакларым да булгалый.

Бигрәк тә югары класслы белгечләр, яшь коллегаларым өчен йөрәгем әрни. Ә бит мин аларны: «Менә кайда масштаблар, заман колачы... Монда башкарылган эшләрне тиздән гасыр могҗизасы, Кама буе эпопеясы, дип атаячаклар», дип, искитмәле кызыклы иҗади эшләр вәгъдә итеп, Горькийдан алып килгән идем. Алар килеп төшкәч, шатлыгым күкләргә ашты, тормышым тулыланып, ямьләнеп китте. Икесе дә менә дигән инженерлар, икесе дә минем дусларым. Икесе дә перспективалы, өметле кадрлар. (Аларны монда минем «питомецлар» дип йөртәләр.) Николай Сосновның да, Даниал Ризвановның да техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәләре бар. Соңгы өч-дүрт елда без бергә эшләдек. Горький автомобиль заводының электрон-хисаплау үзәген тулысынча үзгәртеп кору белән шөгыльләндек. Аны тулысынча автоматлаштырылган информация-хисаплау үзәгенә әверелдердек. Коллегаларым миңа караганда шактый яшь булсалар да, математика-кибернетика буенча үзләрен шактый ук танытып өлгергән белгечләр.

Хәер, мсье Шавальены да аңларга мөмкин: капитал, монополия, конкуренция... Бер савытка салынган үрмәкүчләр кебек, өстәмә табыш, дип бер-берсен буалар, алдашалар, урлашалар, хәтта җинаятькә кадәр барып җитәләр. Капитал монополиясе экономик экспансиянең «удар көче» булып саналган корпорацияләрдә, эрерәк концерннарда, мәсәлән, техник яңалыкларны урлашу өчен, диверсияләр ясар өчен хәтта махсус кешеләр, штатлар тоталар. Бәлки ул безне дә, алардан сатып алган техник-контроль стенд-комплексын тагын да камиллаш-

тереп, башка берәр илгә сатарлар, дип уйлый торгандыр? Әлбәттә, шулайдыр.

Французның ризасызлыгы үзенекен итте, — яшь коллегаларымның кәефләре шактый кырылды. Ә бит алар тагын да кызыграк яңа идея туу турында сөйләнеп йөриләр иде.

— Нишлибез?..— дип, минем янга кинәшкә керделәр.

Мин икеләнергә юл калдырмадым: ничек башлаган булсак, шулай дәвам итәбез, дип кичекмәстән эшкә керешергә куштым.

*

* *

Улым Ислам белән кунагыбыз Петр Ильичның бер-ике көннән китәргә җыенулары турында ишеткәч, алар хөрмәтенә саубуллашу мәҗлесе оештырып алырга булдык. Берьюлы яшь коллегаларым белән дә таныштырырмын дип уйлап куйдым мин. Иш янына куш дигәндәй, Даниалның Горький шәһәреннән һаман да күченеп килергә кыюлыгы җитмәгән хатыны Наилә дә монда чак.

Шулай уйладык та, шимбә көнне иртән мәҗлес хәстәренә дә керештек. Иң өтәләнеп, тиресеннән чыгардай булып йөргән кеше әлеге дә баягы Гөлҗиһан апа. Уңганның кулында ут уйнар дип, белмичә әйтмәгәннәр шул.

Ислам өйдә иде. Кабинетта утырабыз. Киленнәр кебек, өлгер-житез хәрәкәтләнеп, ишек яныннан узып киткән Гөлҗиһан апа ягына ым кагып сорап куйды:

— Әти, бу нинди карчык?

Килеп ярдәм итүче, йомыш башкаручы дип кенә уйлаган булса кирәк.

— Бумы? Гөлҗиһан апа.

— Кем соң ул?

— Кайчандыр Һәдиянең фатир хуҗасы иде. Соңрак үзе йорт-җирсез калды...

Мин Гөлҗиһан апаның ничегрәк итеп бездә яши башлавы турында сөйләп бирдем.

Бу хәл болайрак булды. Көннәрнең берендә эштән кайтсам, куллырын тез башына кушырып, шушы Гөлҗиһан апа бездә утыра. Күзләрендә яшь.

Мин инде аның, тау башындагы йортын сүткәч, яшәр өчен кызына күчкәнлеге турында Һәдиядән ишетеп белә идем. Мин аның болай боегып утыруының сәбәбен сорадым.

— И-и, туганай! — диде ул.— Кая барып бәрелергә белмичә каңгыраеп йөргәннән соң, менә сезгә килеп сугылырга булдым әле. Эттән әрсез, чүптән кадерсез булып каласы көннәрем шушы икән. Бер кирегә китсә, гел кирегә тәгәри икән ул адәм баласының эшләре. Кияүне әйтәм әле. Эшләп сөендерә торган кеше түгел. Хәер, кешегә игелек күрсәтмәгән үзе дә игелек күрмәс, ди бит. Үзен, учактан алынган кайнар бәрәңге урынына, бер урыннан икенче урынга чөелдереп кенә торалар. Барысы да шул бер тамагына хуҗа була алмыйча эчүчелеккә бирелгәне өчен. Күрәчәк күз йомдыра дигәндәй, баштарак дәшмәдем... — Бераз тын алды да яңадан тезә башлады. — И-и, туганай, шул зинданнардан котылырга ярдәм итә алмассыңмы икән? Яшеренбатырын түгел, киңәш сорап та, ярдәм өметләнеп тә килдем. Түземлегем тәмам төкәнде. Муеныма ташлар бәйләп, суга салабыз дисәләр дә бүтән кайттым юк ул өйгә. Эт оясы анда дисәм дә, көфер сүз булмас.

Сөйләшеп, белешеп карармын, дидем мин. Шул юк кына сүзләр дә аның кайгылы-сагышлы йөзендә өмет чаткылары кабызды.

— Аптырауның ахыр чигенә җиткәч, гасабиланып, нииндирәк карарга да килергә белмичә тәмам йончыгач, сиңа дип килүем иде. Акыллы баштан акыллы киңәш дигәндәй, күз күргән, колак ишеткән кеше, мин әйтәм, бөтенләй үк этәреп ташламас әле. Һич югында, киңәш бирер, мин әйтәм...— Шулай бераз гөрләде дә кабат рәхмәтләр әйтеп чыгып та китте.

Шунда башыма бер фикер килде.

— Һадия, әллә карчыкны үзебезгә генә алабызмы? — дидем мин.

Һадия ялтырап китеп елмайды.

— И-и, Имам! Бу турыда минем дә күңелемә килгән иде. Тик телем әйләнмәде. Сиңа әйтергә кыймадым...

— Әйбәт ниятле кешеләрнең фикерләре шулай охшаш була инде ул! — дидем мин көлеп. — Бар, йөгер, чакыр үзен. Риза булса яши бирсен.

Менә шулай булды ул хәл. Үзебез дә рәхәтләргә тиендек. Тормышыбызның кайсыдыр бер килмәгән чите тулыланып киткәндәй булды. Үзе чиста, үзе уңган. Сүзгә тапкыр, телгә оста. Таң белән ул инде аякта. Кулында ут уйната. Балаларны карый. Иң элек безне, аннары килеп балаларны ашатып-эчертеп, сумкаларына ашарларына тыгып, мәктәпкә озата. «Бүген ничәләләр алдыгыз? Һаман да шул бер бетмәгән «4» тә «5»ме? «6»лысы кайчан була инде аның?» дип каршы ала балаларны. Мәйханә килә шулар белән.

Ике авыз сүз белән әйткәндә, йортка, тормышка хәзер Гөлҗиһан апа хуҗа. Тора-бара бюджет мәсьәләләре дә тулысынча аның карамагына күчте.

*

* *

Иң элек Наилә белән Даниал килделәр. Алар артыннан ук үзенең Ләйләсе белән инженер Вәгыйз Гайнанов та килеп җитте. Менә шунда очраштылар да инде Ләйлә белән Ислам. Исламга әллә нәрсә булды. Күптәнге танышын, алай гына да түгел, үзе өчен бик кадерле кешесен югалтып та, кинәт табу бәхетеннән тетрәнеп, өнсез булган кеше сыман, баскан җирендә кадаклангандай катты да калды. Күзләре Ләйләдә. Йөзенә кадәр үзгәрде егетнең.

Ләйлә дә үзенең күптән көткән кешесен, якын танышын очраткан сыман, кинәт әллә нишләп югалып калды.

Ул арада инде азрак исенә килергә өлгергән Ислам Ләйләнең каршысына ук килеп басты. Кунакның өстендәге җиңел ак плащын салдырып элеп куйды. Аннары ифрат та игътибарлы, йомшак мөгамәләле бер кыяфәткә кереп, кулы белән генә ишарә ясап, олы якка, залга үтәргә чакырды. Үзе дә, Ләйлә белән янәшә атлап, түргә узды. Мин да аларга иярдем.

Олы якны Даниал тавышы гөр китерә башлаган иде инде:

— Кешеләр үзгәрде хәзер, бик нык үзгәрде. Без барыбыз да стереотип коллары. Тыныч табигатьле, дөнья ыгы-зыгысына буйсынмаган, зур ихтыярга ия булган кешеләргә мин сокланып карыйм...

Ләйлә түргә узды. Үзе белән бергә ул бүлмәгә кояш балкышы алып кергәндәй булды, барысының да игътибарын җәлеп итте.

Чыннан да сокланырлык иде Ләйлә. Менә кемдә ул гүзәллек! Табигать юмартланса да юмартланыр икән. Бу сылуга гомерең буена карап торсаң да, күреп туя торган түгел. Чем-кара чәчләре пөхтә итеп артка бөтерелеп куелган. Кара кыйгач кашлары, озын керфекләре аңа дәрт сирпеп тора сыман. Ул, мин сиңа әйтим, тәкәббер озын муен, горур кыяфәт! Изүе чак кына уелып тегелгән куе зәңгәр төстәге күлмәгенең үзенә килешеп торуын гына күр әле. Җыйнак буй-сынына, неп-

нечкә биленә ятып, сыланып тора. Бернинди бизәнү-бизәнү юк. Йөзек-балдаклар, алтын алкалар, кыйммәтле муенсалар да такмаган. Хәер, андый бизәкләрнең кирәк түгеллеген ул үзе дә бик яхшы белә булса кирәк.

Шул чак Наилә телгә килде.

— Сезнең салам түбә Николайны күрмим әле мин? — дип сорап куйды ул.

Чыннан да, чакырылган кунаклардан бары бер Николай Соснов кына килеп җитмәгән иде.

Ул арада Һәдия кунакларны табын янына утырышырга кыстый башлады. Сый-хөрмәтнең, ризыкның исәбе-хисабы юк, табын чыннан да күккә чөеп мактарлык иде.

Һәдиягә карыйм да хәйран булам. Бер түбә астында яшәвебезгә ышанасы килми башлый. Шул кадәр рәхәт миңа, сөенеп туя алмыйм, кем әйтмешли, куанычым куеныма сыймый.

Баштарак күңелемне шикләнү-шомлану хисләре борчыган иде. Бигрәк тә аны моңсу-боек бер кыяфәттә күрү читен иде. Бәлки шуңа күрәдер, аның үзәкне өзеп карый торган зур күзләре белән очрашмаска тырыша идем. Ни өчендер ул миңа рәнҗидер төсле иде. Соңгы вакытта Һәдиянең читенсенү-ятсынулары кимеде. Кунакларны җилтерәтеп кыставын гына күр син аның!

— Кадерле кунаклар! Хөрмәтле дуслар!.. Утырышыгыз әле, утырышыгыз!

Ниһаять, табын түгәрәкләнде. Иң өлкән кеше буларак, тамадалыкны үз кулыма алдым. Беренче тостлар әйтелде. Чәнечке-пычаклар да ялт-йолт итеп кенә тордылар.

Шуннан соң инде дөнья түгәрәкләнгәндәй булды.

Урыннары кара-каршы туры килгән Ислам белән Ләйлә ягына күз салдым. Аларның бер-берсенә мөкиббән китеп утыруларын күреп, тәмам пошаманга калдым.

Исламның танырлыгы калмаган. Ләйләне күргәннән бирле әллә нәрсә булды егеткә. Күз карашларына кадәр үзгәрде, йөзен моңсу уйчанлык, җитдилек басты. Әнә ул, башын чак кына кыңгыр салып, иягенә таянган да, үзенең табын янында утырганын оныткан сыман, Ләйләгә текәлгән...

Ә Ләйләсе! Әле баягынак кына алсу иреннәреннән елмаю түгелергә тора иде аның. Ә хәзер... искәрмәстән генә күңеленә мәңге төзәлмәслек яра салынган диярсең, күз карашлары сагышлы, уйчан. Әмма бу халәт килешә аңар, ул һаман да гүзәл, һаман да сылу — теләсә кемне әсир итәрлек.

Шул чак кайчандыр миңа Вәгыйзнең Ләйлә турында язган сүзләре искә төште: «...Моңарчы әле минем аны үбү түгел, кочагыма да алганым юк иде. Гомумән, ул миңа бары тик карап соклану, җан ату өчен генә яратылган зат булып тоела иде». Дөрес язган булган икән. Ләйләнең самими сафлыгы, чыннан да, күңелне айкап үзенә әсир итәрлек иде.

Ул арада Һәдия:

— Кадерле кунакларны үз күчтәнәчләре белән сыйлыйк әле, — дип, табынга Басов белән Ислам тоткан балыкларны китереп куйды. Вак һәм аз булсалар да, тәмле итеп кыздырылган иде алар. Кунаклар, бөтен табынны бер итеп, «Их, тагын азрак булса!» дип көлешеп алдылар.

— Юк, юк!.. Сез көлмәгез әле, — дип акланып маташты Басов. — Без Ислам белән һаман да әле җаена гына төшенеп җитә алганыбыз юк. Әйткән иде диярсез, киләсе елга менә шушындый эре-эре балыклар тотачакбыз. Шулай бит, Ислам?

— Юкка хыялланмагыз, — диде Һәдия, турыдан ярып. — Камада балык юк ул хәзер...

Аның бу сүзләре табында утыручыларның колакларын торгызды:

— Ничек «юк?»...

— Чыннан да! Кама элек-электән балыклы булуы белән атаклы елга бит ул.

Һәдия бер дә исе китмәгән кыяфәт белән дәвам итте.

— Азайды хәзер. Нефть, мазут белән агулап бетерделәр.

Һәдиянең шулай уенын-чынын бергә кушып әйткән бу сүзләре янә зур сөйләшү, әңгәмә кузгатып җибәрү өчен җитә калды.

Шул вакыт, кызганнан-кыза барган бәхәсне бүлеп, музыка яңгырады. Ислам уйный иде аны. Әнә ул, илһам-дәрт белән клавишаларга басып, бөтен гәүдәсе белән алга таба иелеп уйный. Житкән чәче тузгып куя. Һәр хәрәкәте килешле, урынлы иде аның.

Аһәңле музыка Ләйләне дә әсир иткән. Бу минутта бу ике кешене ниндидер күзгә күренмәс җепселләр бәйләвен сиземләү өчен әллә ни зирәклек кирәк түгел иде. Менә аларның күзләре кабат очрашты... Ләйләнең дә керфекләре ымсындырып сирпелеп китте. Әмма бу бер мизгелгә генә шулай булды. Өметләр кузгатып, иркәләп караган күзләрен ул бик тиз читкә алды.

Бу музыка минем дә тәнемне чымырдатып җибәрде. Аркамнан салкын йөгереп үтте, яңак тирәләремдә бала йоннарым кабарганын тоеп калдым. Хәер, музыка тыңлаганда хисләре кузгалмаган кеше юктыр ул.

Музыкадан бигрәк, Ләйлә белән Ислам арасында хасил булган сәер бер мөнәсәбәт миңа шулай тәэсир итте, ахрысы. Күңелемдә шикшөбһәгә охшашлы бер тойгы туды...

Шундый уйлардан арынырга теләп кухняга, Һәдия белән Гөлҗиһан апа янына чыктым. Ул, шаулатып су агызып, вак-төяк савыт-саба юып маташа иде.

— Һәдия, бәлки ярдәм итешергәдер? — дидем мин, аның янына килеп.

Ул әйләнеп тә карамады.

— Юк, юк! Бар, кунаклар янында бул...

Шул чак минем аны җилкәләреннән алып кочаклыйсым килде. Аның җитез, шул ук вакыт нпле-җайлы хәрәкәтләренә карап тору үзе бер рәхәт иде.

Кунаклар янына чыктым. Шул чак түрдәге балконның ачык ишеге янында торучы Ислам белән Ләйләне күреп кабат пошаманга төштем. Юк, гади очрашу гына түгел иде бу. Менә бит, ә! Үзен ямьсез, читен бер хәлгә куя күрмәсен иде, шайтан малай.

Зал ишеге янында төркем булып кунаклар тора. Анда Даниалның Наиләсе барысын да үзенә каратып, акыл сата. Кунакларның күпчелеге ир-ат булуны һәм үзенә карата булган җылы мөнәсәбәтне тоеп, чытлыклана. Ирләр белән хатын-кызларның хокуклары, аларның һәрьяктан тигез булулары турында гәп сата. «...Чыннан да шулай ич. Без кай җиребез белән сездән ким соң? Бәлки интеллект ягыннандыр? Ләкин монда җенеснең берничди дә катнашы юк, бу — һәрбер шәхеснең үзенә генә хас сыйфаты. Бәлки эмоциянең күпкырлырак, катлаулырак булуы белән ир-атлар өстенрәк тора торганнардыр? Монда исә ике төрле фикергә урын юк: ул мәсьәләдә без, хатын-кызлар, сезгә караганда күп тапкыр өстенрәк, күп тапкыр отышлырак хәлдә торабыз...»

Бераздан табын яңы яңадан гөр килә иде инде. Әмма бу юлы әллә ни озак юанмадылар. Инде шактый соң дип, кузгалыша башладылар. Ә Николай тәки килмичә калды. Ислам белән Петр Ильич бераз һава алыштырып керәбез дип, кунакларны озата чыктылар.

* *
*

Бераз ял итеп алу нияте белән кабинетыма үтәргә дә өлгермәдем, ишек звоногы шалтырады. Берәр кунакның әйбере онытылып калгандыр дип уйлаган идем. Әмма бусагада аптыраган кыяфәттә Николайны күргәч, йөрәгем жу итеп куйды.

— Нәрсә булды, Николай?

— Кеше таптаттым.

— Кит аннан? Кайда, ничек итеп? Кайчан?

— Дәрестән чыккач...

— Бүген укыту көне түгел иде ич...

— Өстәмә дәрес билгеләгән булганнар. Соң шул... Шактый соң чыгылды. Сезгә вакытында килеп житим дип бераз кабаландым, ахрысы.

— Эх-х! — дип ачынып куйдым мин. — Таптаткан кешең исәнме?

— Милиция идарәсендә протокол төзегәндә исән иде әле. Әмма һушсыз диделәр.

— Нindiрәк кеше иде?

— Хатын-кыз...

— Ничегрәк булды соң ул хәл? Кайда булды?

— Үзәк больница тыкрыгы янында... Яшел ут сүнгәнче үтеп китим дип шактый кызу килә идем, шул чак тротуар кырыена килеп туктаган берничә кеше арасыннан искәрмәстән генә килде дә чыкты... Машина астына үзе ташланмадымы икән дигән версия бар... Шаһит булып барган өлкән яшьтәге бер апа кеше дә шулай диде. Машина астына кергәндә куллары белән йөзен каплаган иде, ди.

— Кем икәнен белдеңме соң?

— Милиция идарәсеннән мин барында шалтыратткаладылар. Хатынны таныганнар... Берничә сәгать кенә элек шул ук больницада ире үлгән булган...

— Һы-ы! Менә бит, ә... Хәле авыр димени?

— Әйе. Башы белән бәрелгән... Мие селкенгән, ди. Тагын бер аягы сынган. Исән калуы икеле, ди.

Карасам, Николай кулында көрән тышлы шактый калын дәфтәр. Аның әледән-әле шул дәфтәргә күз төшергәләп алуына игътибар иттем.

— Бу ни бу?

Николай кабат дәфтәрне караштырып алды.

— Әле монда керер алдыннан гына машинаның утыргычы астыннан табып алдым. Минем машинага салып больницага илткәндә теге хатынныкы төшеп калган булса кирәк. Тик укый алмадым. Татарча язылган. Көндәлек шикелле нәрсәдер, шуңар охшаган. — Николай сораулы күзләрен миңа күтәрде. — Бәлки сез караштырырсыз, Имам Хисамович... Хуҗасының кем икәнлеген белмәбезме?

Дәфтәрне миңа сузды.

— Ләкин бит аның тикшерү вакытында кирәк булуы бар.

— Кирәк булу белән алырмын.

Николайны табын янына чакырып карасам да, утырмады. Дерматин тышлы, шактый калын дәфтәрне миңа бирде дә китеп барды.

Дәфтәрне караштыра башладым. Чыннан да, көндәлек язмалар иде болар. Ай-көннәре дә бар. Тик еллары гына күренми. Тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: дәфтәр хуҗасы аңа онытканда бер генә тотынган булса кирәк, атналар, хәтта айлар буе кулына алмаган урыннары очраштыргалый.

Өстәл янындагы креслога утырдым да дәфтәрнең урта бер җирен ачып, укырга керештем. Хәрефләре тигез, тыныш билгеләре үз урынында. Күренеп тора, язмаларның хуҗасы укымышлы кеше.

Битнең башыннан укырга керештем.

«**14 май. Чәршәмбе.** ...Барысы да Ләбип Хәниповичның безгә, экскаваторчылар хәзерләү курсының кызлар группасына, механика буенча дәрескә керүеннән башланды. Бик сәләтле белгеч, яхшы укытучы, диделәр аның турында. Беренче карашка бик яшь булып күренде ул. Соңыннан белдем, аңар утыз өч яшь иде. Безнең группа кызлары күрү белән аңар гашыйк булдылар. Хәер, гашыйк булырлык та иде шул ул. Уртачарак кына буйлы, көләч йөзле, итагатьле. Җиренә җиткереп, пөхтә итеп киенә белә. Әле дә булса хәтеремдә, Ләбип дәрестән чыгып китү белән, атна саен чәчләрен буятып, әллә нича төрле төскә кереп, ир-ат белән мөнәсәбәттә үзенең җиңелчәрәк фикер йөртүе белән аерылып торган Дина: «Чур-р, кызлар! Бу Ләбип Хәнипович дигән адәми затны үземә каратам», — дип кисәтеп тә куйган иде. Группадагы кызлар: «Синнән булыр...» — дип, бары тик көлештеләр генә.

Баштарак минем Дина сүзләренә әллә ни исем китмәде. Чөнки бүлмәдәш дустымны яхшы белә идем. Мин инде җилкуар Динаны, бер харап буласың әле син, кызыкай, дип тиргәп, кисәтеп тә куйгалаганым бар иде. Ә аңар нәрсә, ул инде кеше сүзенә колак салудан күптән узган... Шунысы гаҗәп, Дина икенче көнне үк Ләбип Хәниповичның кайда торуын да, хатыны белән бер баласы булуын да, хәтта үз машинасы барлыгына кадәр белеп өлгергән иде...

**17 май. Шимбә.** Укулар һәйбәт кенә бара. Тиздән имтиханнар. Тик шунысы гаҗәп: барлык кызларның телендә — Ләбип Хәнипович. Аның йөзендәге пакьлек, беренче карашка ук күзгә ташланып торган самимилеге мине дә әллә нишләтте. Күңелемнең кайсыдыр почмагында аның шул сафлыгын саклап калу теләге туды. Көннәрнең берендә тулай торакта Динаның: «Каратам булгач каратам!» дип кабат масаюын күреп (нинди шайтан вәсвәсәсе котырткандыр) бүлмәдәшемне юри үчекләргә теләгәндәй итеп: «Юк инде, Диночка! Ләбип Хәнипович сиңа тәтемәс. Юкка нәфсеңне сузма. Аны мин үземә каратачакмын», дип мактанып ташламаммы! Миннән мондый сүзне һич кенә дә көтмәгән кызларга җитә калды: «Әллә чынлапмы?!» дип элеп тә алдылар. «Ә нәрсә?..— дидем мин.— Әйткән иде диярсез менә, Ләбип барыбер минеке булачак».

Минем бу сүзләрем Динаны чын-чыннан үртәндерде, башта билен тота алмыйча бөгелә-сыгыла көлгән булды, аннары минем якка кулын селтәп тезә башлады: «Уф-ф, көлдермә, ичмаса... Синең кебек старая девадан, монахинядан буламы соң ул! Син нәрсә, Ниса?.. Соң бит ул ир-ат... Аңар синең матур күзләрең белән энҗе тешләрең генә җитмәячәк...»

Бу юлы инде бүлмәдәш дус кызлар да авызларын йомып калмадылар, чынлап торып мине яклый, миңа теләктәшлек белдерә башладылар. «Ташласана, Дина! Тапкансың мактанырнәрсә...» дип тегене ирештерергә керештеләр. Әмма телләшүгә килгәндә Дина алай тиз генә бирешә торганнардан түгел иде. Ләң-ләң килеп чәпченүен белде. «Юк, юк!.. Нисадан булмаячак... Менә әйткән иде диярсез, Ләбип дигән чибәрегез барыбер минеке булачак. Нисаның андый адымга йөрәге җитмәячәк. Булса баштарак, яшьрәк чагында булыр иде. Яшьрәк вакытта, җилкуар чагында, чирканчык алуы җиңелрәк ул...»

Яшерен-батырын түгел, Динаның: «Старая дева, монахиня», дигән сүзләре чынлап торып йөрәгемне телгәләп үтте. Чыннан да, миңа инде егерме җиде яшь иде. Ә бит минем яшьтәшләрем күптән инде тормышка чыгып балалар үстереп яталар. Мәрхүмә әнием мине егерме яше тулар-тулмас вакытта ук тапкан булган.

Май айлары җитеп, җир бераз кипшетү белән Ләбип Хәнипович эшкә үз машинасы белән килә башлады. Ул аны, гадәттә училище ишегалдына кертеп, биек койма буенда калдыра торган иде.

Көннәрнең берендә, тәнәфес вакытында, урамга кояш яктысына чыктык. Ничектер шулай булды, Ләбип Хәниповичның машинасы янына җыелдык. Карыйм, Дина да шунда. Шул вакыт мин, аңар нәрсәдер исбат итәргә теләгәндәй, машинаның ишеген ачтым да руль артына кереп тә утырдым. Ләбип Хәниповичныкы булгач миңа нишләсәм дә ярый, янәсе. Карасам, ачкыч та үз урынында. Аны шылт итеп бордым да, стартерга бастым... Кинәт кенә газ бирүемне сизмичә дә калганмын. Машина урыныннан сикереп үк диярлек кузгалып китеп, каршыдагы койманы «сөзеп» тә алды. Сул яктагы фара белән подфарниклар чылтырап коелып та төштеләр.

Өнем алынып машинадан атылып чыксам, ни күрим, бу хәлләрнең барысын да Ләбип Хәнипович үзе күзәтеп тора икән. Җирләр ярылса, шунда гына кереп качкан булыр идем. Минем тәмам каушап, югалып калуымны ул да күрде, гафу үтенүләремә каршы борчылмаска кушты: гаеп үземдә, машинаны скоростьта калдырганмын, дигән булды.

Икенче көнне дәресләр бетеп өйгә кайтырга чыккач, көтеп торган, ахрысы, Ләбип Хәниповичны очраттым. Хәл-әхвәл сорашкандай итте дә, уенын-чынын бергә кушып, болай диде: «Ниса, сезнең автомашина йөртергә өйрәнәсегез килә, ахрысы... Теләгегез булса, рәхим итегез, өйрәтәм...» Әчемнән: «Сезгә ышансаң, сез өйрәтерсез...» дип уйласам да, телем белән: «Кызыклы тәкъдим, уйлап карарга ярый», дигән булдым. «Уйлап-нитеп торасы юк, иртәгеге көннән үк эшкә керешәбез». Шунда ук очрашу вакытын да билгеләде.

Якшәмбе көн иде. Машинага утырып Әлмәт шәһәре белән Актүбә эшчеләр поселогы арасындагы урман буена юл тоттык. Асфальт юлдан читкә төшеп, югары вольтлы электр линиясе үткән ачыклыкка килеп чыктык. Тирә-якта шар тәгәрәтеп уйнарлык тигезлек. Машина рулен күпме телисең әйләндереп-боргала, беркая да бәрелерлек түгел. Тирә-якта бер генә җан иясе дә күренми. Шунда мине Ләбип Хәнипович руль артына утыртты да бик җентекләп аңлата башлады. «Менә монысы сцепление... менә педаль. Монысы тизлек рычагы. Бу педаль турында да онытма, аяк белән тормоз салу өчен ул... Әйдә, кузгал... Курыкма, кыюрак бул. Монда чокыр-чакыр да, «сөздерү» өчен коймафәлән дә юк...— Үзе күзләре белән генә елмая.— Я, я!.. Кыюрак бул... Мин әйткәннәрне онытма. Әмма алар, мин күрсәткән хәрәкәтләр, автоматик рәвештә эшләнергә тиешләр. Хәер, экскаваторда да шулай, күзләрең бары тик грунт умыручы, һаваны айкап йөрүче кояшта булачак...»

Ниһаять, каушап-калтырап, барысын да ул күрсәткәнчә кыландырып машинаны кузгаттым... Дөресен әйтим, машина белән бергә күңелем дә урыныннан купкан сыман булды... Рульне чак кына сулга борам. Карасам, машина да бернинди икеләнүсез, гаять җиңеллек белән сулга борыла. Тизлекне арттырдым... Машина җил уйнатып алга ыргылды. Руль тоткан кулларым җиңелчә генә калтырана. Ләкин бу бик рәхәт калтырану иде.

Миннән күзен алмыйча янымда утырган Ләбип Хәнипович түземде: «О-о, Ниса!.. Болай булса атна-ун көн дә үтмәячәк, машина сиңа тулысынча буйсыначак», — дип куйды.

Ул көнне мотор кызганчы, радиатордагы су кайнап чыкканчы машина йөрттем. Мин бәхетле идем. Төнлә төшләремдә дә машина белән мәш килеп саташып чыктым.

Ләбип Хәнипович үзен гаять әдәпле, итагатьле тотты. Шулай да кичен тулай торакка кадәр озатып куйганда, соклануын яшерә алмаган кеше сыман: «Ниса, сез үзегезнең София Лоренга охшаганыгызны беләсезме?» — дип сорап куйды. Мин сүз озайтып, чытлыкланып тормадым, бары көлдем генә. Икенче көнне үк София Лоренның сурәтен табып карап утырдым. Шунда кичә Ләбип Хәниповичның мине шул

артистка белән чагыштыруына риза булгандай, тиле кебек елмаюым, «Көлмәгез, зинһар», дип, аңа каршы төшмәвем өчен оят булып китте. Озак карап тордым мин ул кино йолдызының рәсеменә. Кая инде безгә андый сылулык! Иягемнең чокырланып, иреннәремнең чак кына бүлтәеп торуларын искә алмаганда, минем ул чибәрләр конкурсында алтын таҗ яулап алган дөнья гүзәле белән бернинди охшашлыгым да юк.

Икенче көнне дә машина йөртергә өйрәндем. Тора-бара бу хәл миңа ничектер бик мәзәк булып тоела башлады. Баштарак, бу очрашуларны кызлар, бигрәк тә Дина күрдеме икән дип, (күрмәсәләр күрсәтергә теләп) күзләрем белән группа кызларын эзләгән чакларым да булгалады. Әмма соңрак бу тойгыны бөтенләй капма-каршы икенче бер теләк алыштырды: «күрмәсәләр генә ярар иде...»

**15 июнь. Сишәмбе.** Кызыгу-мавыгуның азагы яман дигәндәй, безнең Ләбип Хәнипович белән очрашулар тора-бара җитди төс алды. Атна-ун көн үттеме икән, машина миңа, мин машина хуҗасының ихтыярына тулысынча буйсынган идек инде. Җитмәсә тагын, яшәү яме, яшәү дәрте өстәп, гүзәл җәй айлары килеп җитте. Бу җәй башы миңа бүтән елларга караганда матуррак та, яктырак та, хәтта аязрак та булып тоелды...

Нәкъ шул көннәрдә имтиханнар башланды. Ләбип Хәнипович безнең группаның барлык кызларына да үз фәненнән «отлично» билгесе куеп чыкты. Шулай итеп, алты айлык курсларны тәмамлап, класслы экскаваторчы дигән документлар алып, төрлебез төрле якка таралыша башладык.

Мин генә Бөгелмәгә, элеккеге эш урынына кайтып китәргә ашыкмадым. Ләбип белән очрашуларыбызны дәвам иттек. Бераздан дөнья мәшәкатьләре күзгә күренмәс булды, тормыш ыбыр-чыбырлары онытылды. Нәкъ шул көннәрдә Ләбип миңа үзенең мәхәббәтен белдерде һәм бергә булыйк дип тәкъдим ясады.

Минем дә күңелемдәге тойгыларның ургып торган чагы иде. Мин дә: «Ә ник? Кемнәрнеңдер аерылып, кемнәрнеңдер кавышулары тормышта булмый торган хәл түгел ич», дигән уй белән яши башладым. Ә инде Ләбипнең кабат: «Бергә булыйк! Синнән башка яшәвем яшәү түгел», дигән сүзләреннән соң, мин дә үземнең шартларымны куеп, ризалык бирдем. Ләбип шул ук көнне хатыны белән аерылышу турында судка гариза илтте...

Мәхәббәтне, ут-ялкынны кәгазьгә төреп булмый, диләр бит. Минем Ләбип белән үзара булган мөнәсәбәтем турында сүз Лениногорск шәһәрендә горисполкомда бүлек мөдире булып эшләүче, әтием урынына калган туганнан туган абыема да барып җиткән иде. «Булдырдың, ниһаять!.. Сөендерден... Син дә үзеңә пар тапкансың икән. Страм!.. Нәкъ анекдоттагыча: «Бәләкәй арбасы белән, бала-чагасы белән» булган, алайса!.. Әнә, бөтен кеше көлә үзеңнән... Бүгенге көннән мин сиңа абый түгел, син миңа туган түгел», — шул булды аның бөтен әйткәне.

Мондый сүзләрне барыбер бер ишетәчәгемне көтеп алгангамы, әллә ни исем китмәде. Без, судтан соң ук барып язылышкач та, «бәрхет» сезоны алдыннан Ләбип белән Кавказ яки Кырым якларын әйләнеп кайтырга дип планнар корып куйдык. Нәкъ шул көннәрдә искәрмәстән генә килеп чыккан бер хәл, дөресрәге, бер очрашу барлык уй-максатларымны чәлпәрәмә китерде дә ташлады. Минем янга Ләбип Хәниповичның хатыны килде. Юк, кутәрелеп бәрелмәде, гауга да чыгармады. Алай итсә, хәтер калдырырлык сүзләр әйтсә, бәлки ул кадәр үк тәэсир дә итмәгән булыр иде. Бераз йөземә карап торды да, үзалдына сөйләнгәндәй: «Менә сез нинди икән!.. Шулай дип уйлаган идем аны. Ярар, хәерле булсын... Безнең инде барыбер гаилә булмаячак... Сезгә

үпкәләмим... Бәхетле булыгыз!..» диде дә чыгып китте. Күзләрендә яшь иде аның. Ул минутта аңардан да бәхетсезрәк кеше булдымы икән. Ир бирмәк — җан бирмәк дигән бит борынгылар. Кыйналган кеше кебек иде аның кыяфәте. Туктатмадым... сыңар бер сүз дә әйтмәдем. Әмма шул ук көнне үзем өчен тиешле нәтиҗә ясадым. Ике-өч кешене бәхетсез иткәнче, ни күрсәм дә ялгыз башым, тыныч колагым дидем дә, йөрәгемне биләп алган тойгы-хисләремне төбе-тамырлары белән мәрхәмәтсез рәвештә өзгәләп, Чаллы якларына чыгып киттем. Кемнеңдер җимерелгән бәхете өстендә корылган бәхетнең кайчан тулы булганы бар соң!..

**21 ноябрь. Җомга.** Бүген ял итәм. График буенча шулай туры килде. Бу дәфтәрне кулыма алмаганга да биш былтыр үткән...

Әйе, ул арада минем тормышымда да җитди генә үзгәрешләр булды. Мин Яр Чаллыда хәзер.

Дус-ишләрдән, таныш-белешләрдән, туган җирдән аерылып китүләре бик җиңел булмады, әлбәттә. Гомеремдә күз күрмәгән җиргә беренче тапкыр аяк басуларны, җитмәсә тагын, җыен ир-ат арасында берүзең эшли башлауларны үзе кичергән кеше генә беләдер. Барысы да, сайлап алгандай, типсә тимер, басса бакыр изәрлек ир-егетләр. Күзләрендә ут, тел дисәң, авызларына шайтан төкергән. Һәрнәрсәдән кызык табып, теш агартырга сәбәп эзләп кенә торалар. Менә шунда иң әһәмиятлесе — үз-үзеңне куя белү иде. Каушап калмадым, егетләр эшләгәндә баш күтәрми эшләдем. Алар көлгәндә көләргә тырыштым.

Билгеле, коллективның үз кешесе булып киткәләгәнче күңелсезлекләр дә булып алгалады. Бер вакыйга аеруча истә калган. Үзем генә экскаваторчы булып эшли башлаган көннәр иде. Төнге сменада, каткан грунтны умырткапда, тросны өздердем. Беренче смена кешеләре килде. Тиз генә яңа трос китертеп шуны алыштыру эшенә керештек. Тирә-ягыбызда күз күреме җитмәслек гигант котлованда уннарча һәм уннарча экскаваторлар гөр килеп эшләп торалар. Авыр самосваллар тоташ ташкын булып килә. Ә без ватылып ятабыз. Иптәшләрем алдында уңайсызлануымнан нишләргә белгән юк. Җан әрни, йөзләренә күтәрелеп карый алмыйм. Нәкъ шул вакыт күрше бригадада эшләүче бер экскаваторчы ярдәмчесе килеп, шаярып, иелеп эшләп торган җиремнән: «Һоп-ля!..» дип арттан килеп тоткан булды. Ачуымнан шартлыйм дип торам. Үз-үземне белешмичә, кинәт кенә турайдым да бар көчемә тегенең яңагына чабып җибәрдем. Кулларым яңгырап китте. Үзем дә гарьләнүемнән елый яздым. Тегенең дә күзе шакай булды. Яңагын уалап: «Син нәрсә?.. Әллә синең белән шаярырга да ярамыймы?.. Вот псих!.. Биткә суга бит... Аны кара!..» — дип янаган булды. Мин исә кызып китеп: «Хәзер үк яхшылык белән югал күз алдымнан!» дип ыжгырып өстенә килә башлагач, кабат: «Вот псих!..» дип, чигенә-чигенә китеп үк барды.

Соңгы сүзләрем үзенекен итте: экскаватор янында мәш килеп эшләп ятучы бригада членнары шаркылдап көлешә башлады. Кайсыдыр хәтта: «Молодец, Ниса!» дип мактап та куйды. Бу хәл бераздан күрше экскаваторларда эшләүчеләргә дә барып җиткән иде... Шуннан соң, әйтмәгәнем булсын, кул сузу түгел, минем алда килде-китте сүз дә ычкындырмый башладылар.

Гомумән, ундым мин хезмәттәш дусларымнан. Туган абыйларым кебек якын итәм үзләрен. Алар да Ниса дип, өзгәләнеп, ярдәм кулы сузарга атлыгып торалар.

Әмма берсенең, Габбас исемлесенең, башкаларга караганда күңеләмә якынрак икәнлеген бик тиз тоеп алдым. Олы гәүдәле, аз сүзле бу тыйнак егетне бер мин генә түгел, бригаданың барлык членнары да ихтирам итәләр, аның сүзенә колак салалар иде. Бер яшь слесарь (егет булып күренергә теләптер инде) җае чыккан саен сүгенергә яра-

та иде. Габбас тиргәмәде, җикеренмәде, тыныч кына: «Слушай, син... хатын-кызны ихтирам итмисең икән инде, һич югында, безнең колакларны кызган... Бүтән ишетмим, чтобы!..» — диде. Шул җитте. Егетебез алыштырып куйгандай булды.

Аннары Габбасның эшләү рәвеше хәйран итә мине. Экскаваторы автоматка көйләп куйган диярсең: тигез бер ритмга эшли дә тора, калтырамый-тетрәми, мөлдерәмә тулы чүмечennән бер генә кисәк балчыгы да коелмый. Аның эшләгәнен карап торуы үзе бер җан рәхәте.

Юк, алай эшләү минем кулдан килми. Килер сыман да түгел. Минем кулга күчү белән, дилбегәдә хатын-кыз икәнлекне тойган ат кебек, экскаватор «чыгымлый» башлый. Тыңлата алмыйча иза чигәм. Еш кына тау кадәрле «БелАЗ», «КрАЗ», «МАЗ»ларның тимер кузовларын «кыйнаштырам». Сирәк кенә булса да кабиналарын да «чукып» алгалыйм. Андый вакытта кабина эчендә утырган шоферның: «Син нәрсә, үтерергә җыендыңмы әллә?», дип, яшен суккандай, мәтәлә-кадала тәгәрәп төшүләрен күрү үзе бер мәзәк. «Җаның ул кадәр газиз булгач, бар, икенче экскаватор астына бас», дип кенә җибәрәм. Ә үзем тегенең түгәрәкләнгән күзләрен күреп, чыннан да шүрләп куям...

Шул вакыт Ислам белән Петр Ильич кайтып керделәр. Җинаять өстендә тотылган кеше сыман, дәфтәрне җәһәт кенә шапылдатып ябып куйганымны сизмичә дә калганмын.



### 4

Мсье Шавальe белән конфликтка керү барыбызның да кәефен җимерде.

Төзүчеләр бригадасы белән җитәкчелек итүче инженер Вәгыйзгә дә әллә нәрсә булды. Күренми. Сизәм, минем белән очрашудан читләшә. Хатыны Ләйлә белән араларына күләгә яттымы икән әллә? Ләкин бит минем гаебем юк...

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Николай бәхетсезлеге... Һәр вакытта да җитез, ачык йөзле, гел елмаеп тора торган яшь коллегам Николайга күз төшерү белән гаҗәпкә калдым. Йөзе агарынган, үзе арыган кыяфәттә. Гомумән ул бүген башыннан коточкыч зур фаҗига кичергән кешегә охшап калган. «Әллә теге, ул машина белән бәрдергән хатын үлдеме икән?» дигән уй чагылып китте башымда. Аның көяләнеп йөрүе, инәлүле күз карашлары тәмам тынычлыгымны алды. Барлык эшне Даниал карамагына калдырдым да Николайны бер читкә алып киттем.

— Я, сөйлә, нәрсә булды? — Искәрмәстән бирелгән сораудан егет югалыбрак калды.

— Хәзергә ул-бу юк...

— Хатын исәнме?

— Исән.

— Янында булдыңмы?

— Кичә кич.

— Соң?

— Аңына килгән... Әмма сөйләшерлек хәлдә түгел.

— Үзең күрдеңме?

— Әйе.

— Ниндирәк?

— Аның әле хәзергә карарлыгы юк. Башы тоташтан ап-ак бинт белән уралган. Күзләре белән авыз-борыны гына күренеп тора...

— Кем икәнен белдеңме?

— Белдем...

Николай, чыннан да, күп нәрсәне белергә өлгергән. Үлгән ирен туган җиренә, якындагы районнарның берсенә алып китеп җирләүләренә кадәр белгән. Аның шулай хәбәрдар булып торуы миңа ошады.

— Ә син аның София Лорен кебек искитмәле сылу хатын икәнлеген беләсеңме соң әле? Ә?..

Минем бу сүзләремнән соң Николай сүлпән генә елмаеп куйды.

«Менә шулай!» дип уйладым мин эчемнән генә.

*

* *

Эштән чак кына бушау белән өйгә элдердем. Бүген-иртәгә кунаклар китәргә җыена. Алар белән иркенләп сөйләшеп тә утырырга туры килмәде. Һай-й, шушы вакыт дигән нәрсәнең җитмәве!

Алар да ашыгалар. Иң элек ике-өч көнгә генә Харьковка, Петр Ильичның эти-әниләренә сугылып чыгарга уйлыйлар. Аннары инде Мәскәүгә кайтачаклар. Ә аннан Лондонга, яшь галимнәрнең ниндидер халыкара коллоквиумына китеп барачаклар икән.

Юкка гына йөгерә-чаба кайтканмын икән, өйдә бер генә җан иясе булсынчы!

Кабинетка кердем. Тәрәзә шыр ачык булуга да карамастан, тәмәке төтене исе. Көн бик тымызык шул, җилнең әсәре генә дә юк.

Кабинет яу узганга охшап калган. Китап киштәсе буенда, идәндә кунакларның чемоданнары ята. Исламның чемоданы ачык. Иң өстә берничә төрле журнал, китап һәм калын гына күн тышлы дәфтәр. Иң элек өстә яткан журналны кулыма алам. «Бюллетень ученых-атомников». Аннары күн тышлы дәфтәрне алып урта бер җирен ачтым. Мин үзем дә катлаулы сызмалар, төрле схемалар белән эш итә торган кеше. Әмма Исламның кулдан язган дәфтәренә күз төшергәч, җентекләбрәк караштыргач, исем китте. Баш җитмәслек формулалар, мең төрле цифр һәм расчетлар, интеграллар... Әй-йе, һәркемнең үз дөньясы шул.

Шунда ук, электр бритвасы тартмасы астында бер китап та бар. «Физики шутят». Физиклар әле шулай шаяра да беләләр микәнни? Китап шактый таушалган, кулдан-кулга йөртелеп укылганы әллә каян күренеп тора. Мин дә актарыштырам. Физиклар тормышына кагылышлы кызыклы хәлләр, мавыктыргыч вакыйгалар, мәзәкләр һәм кыска, әмма үткен итеп әйтелгән диалоглар тупланган икән. Кайбер язмалар янына, китап бите читенә, билгеләр куеп кителгән.

Мин дә, билгеләнгән урыннарның берсенә туктап, игътибар белән укый башладым. Альберт Эйнштейн Чарли Чаплинның фильмнарын ярата һәм аларны тудыручыны бик ихтирам итә торган булган. Көннәрнең берендә ул бөек комикка хат яза. «Сезнең «Золотая лихорадка» дигән фильмыгызны карадым. Сокландым. Аны һәркем аңлаячак һәм сез тиздән ул фильмыгыз белән дөньякүләм дан казаначаксыз», ди. Шунда ук Чаплинның җавабы. «Минем дә сезгә карап торган саен соклануым арта. Сезнең «Теория относительности» дигән нәмәстәгезне дөньяда беркем дә аңламый, шулай булуга да карамастан, сез иң данлыклы, иң атаклы кеше булып саналасыз».

Шуңар охшашлы тагын берничә «мәзәк» укыдым. Шактый гыйбрәтле һәм кызыклы икән бу китап. Вакыт табып бөтенләй укып чыкканда әйбәт булыр иде.

Китапны урынына куйдым да диваныма барып сузылып яттым. Уемда һаман бер нәрсә: улым Ислам. Күр син аны, Себер Академиясенең абруйлы бер галиме булып китте бит. Яшьли үк шулай канатланып, шулай югары күтәрелә алыр дип кем уйлаган!

Әнисе, мәрхүмә, улының инженер булуы турында хыяллана иде. Аның өчен инженердан да зур, инженердан да дәрәҗәле, абруйлы кеше булмагандыр шул, күрәмсең. Хәер, гаҗәп тә түгел. Ул чорда безнең бар күргәнебез, бар ишеткәнебез «инженер» иде. «Менә монысы Америкадан килгән инженер, диләр. Ә монысы — немец икән... Бусы бельгияле, ди...» Нижегородск автомобиль заводының бөтен Россиядән җыелган төп төзүчеләре — чабаталы крестьяннардан бик нык аерылып торалар иде шул. Чит ил инженерлары үзләре дә моны бик яхшы сизәләр иде булса кирәк, үзләрен бик эре, бик һавалы тоталар иде.

— Эх-х, әгәр дә Нәҗия исән булып, бүгенге улын күрә алса, нишләр иде икән? Ислам бит, әнә, инженер булып кына да калмады, тагын да югарырак күтәрелде.

Мәктәптә укыганда ук Горький шәһәренең безнең завод шефлык итә торган пионерлар сараена йөрде ул. Анда мең төрле радиоалгычлар җыйды, папирос тартмасы кадәрле генә транзисторлар ясады. Соңрак аларның радио белән читтән торып идарә итә торган төрле модельләре, күп кенә эшләр башкара ала торган роботлары Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә алтын һәм көмеш медальләр белән бүләкләнде. Пионерлар тарафыннан эшләнгән бер роботны заводта «эшкә җиктек». Автомобиль өчен деталь хәзерләүче пресс астына заготовкалар биреп торды. Хәрәкәтләре шул пресста эшләгән эшченекенә караганда төгәлрәк тә, җитезрәк тә иде. Соңыннан эксперимент ясап карау максаты белән прессның эшләү тизлеген биш тапкырга арттырып көйләдек. Бер үк вакытта роботның да «программасын» үзгәрттек. Нәтиҗәдә робот берүзе биш кеше эшен үти башлады. Хәрәкәтләренә күз иярми иде аның. Бу хәйран тамашаны күрер өчен башка цехлардан да киләләр иде. Бу эшләре өчен без пионерлар сараеның автоклубына менә дигән яңа автомобиль җыеп бирдек.

Горький пионерлары үзләренең бер роботларын шәһәр транспортында кондуктор урынына да файдаландылар. Бу турыда хәтта үзәк матбугатта да язып чыкканнар иде. Тимер «кеше» пассажирларны каршы ала: «Иптәшләр, билет алырга онытмагыз!» дип кисәтә, янына күбрәк җыела башласалар: «Иптәшләр, алгарак үтегез, чыгучыларга комачауламагыз», ди. Шуның өстенә әле һәрбер трамвай тукталышын бернинди ялгышусыз әйтеп бара. Шундый хикмәтләрне күргәч: менә безгә алмашка нинди алтын куллы, могҗизалар тудырырга сәләтле буын килә дип, сөенеп бетә алмыйсың...

Шундый уйларга бирелеп ятканда ишекнең звоногы шалтырады.

Аһ-ваһ килеп, тирләп-пешеп Петр Ильич кайтып керде. Шунда ук: уф-ф, бөркү! дип зарланырга да тотынды.

— Ислам кайда калды, Петр Ильич?

— Кайтмадымыни әле?..— диде кунак, сорауга сорау белән җавап биреп. — Без аймылыш булдык... автобуска утырганда. Ул сикереп менеп китеп барды, ә мин...

Күңелемдә шикле уй туды. Әйе, бу Санчо Панса нәрсәдер яшерә, әйтеп бетерми. Әйдә, хәерле булсын...

Читләтеп кенә Петр Ильичның әти-әниләре, туган-тумачалары, соңгы хезмәтләре белән кызыксынам. Ишетергә теләгәнем: Исламның эше, шәхси тромышы иде, әлбәттә.

Әмма сүз һаман да Исламны читләтеп уза торды. Әңгәмәне укуукыту мәсьәләләренә борып карамакчы булам. Педагогның эше җиңеләйгәндер, чөнки бит хәзер аларга ярдәмгә кибернетика, «укыта» торган машиналар килүе турында бер-ике сүз кыстырып куйдым. Сизеп торам, кунак өчен кызыклы тема түгел бу. Шулай да, әдәп йөзеннән генә, бары тик минем сорауга җавап бирергә кирәк булганга гына сүз башлады.

— Әйе, файдаланылалар,— диде ул, сигаретын көл савытына кагып.— Ләкин бит шул кадәресе дә бар: безнең академия уку йорты түгел. Анда бары тик физика, математика кебек фәннәрдән Бөтенсоюз олимпиадаларында җиңеп чыккан сигезенче, тугызынчы, унынчы класс укучылары өчен махсус программа белән укулар гына алып барыла. Анда, минем уемча, киләчәктә безнең фәнебезнең данын тагын да югарырак күтәрәчәк вундеркиндлар, булачак Эйнштейннар, Жолио-Кюрилар, Ландаулар укыйлар...

Шул чак Басов үзенең дә, нәкъ Ислам кебек, шул махсус программа белән белем алучылар арасында педагог булып эшләп караганлыгы турында сөйләп китте. Озак түгел, нибары ике ел чамасы гына укыткан. Бөтен йөзе белән елмаеп, урынсыз сүз әйтергә җыенган кеше кебек күз карашын читкә алып, өстәп куйды.

— Аннары китәргә мәҗбүр булдым... Фауст: «Я выдохся как педагог и превращаюсь в чорта снова...» дигән кебек, янадан фәнни эшкә күчтем. Яхшы укытучы булып туарга кирәклекне бары тик шунда гына төшендем. Грекларда: белем бирү укучылардан түгел, ә укытучылардан башлана, дигән мәкаль бар бит.

Ниһаять, үзем теләгән сүзләрне дә ишеттем, Исламны профессиональ лектор дип атады, табигый талант, диде. Аның лекцияләрен бик яратулары, аның дәресләренә яшьләрнең бик теләп йөрүләре турында сөйли башлады. Аны нечкә психолог, эрудит, бүгенге яшьләрнең характерлы, үзенчәлекле сыйфатларын гына түгел, аларның хыял-омтылышларын да тоя белүе, аларның уй-фикерләрен, акыл-зиһеннәрен генә түгел, йөрәкләрен дә кузгата белүе турында рухланып сөйләде. Аның лекцияләрен хәтта еш кына телевидение аша да тапшыралар диде.— Бүгенге аудиторияне алдалап булмый, — дип дәвам итте Басов.— Чын педагогка фундаменталь белем генә дә җитми хәзер. Моның өчен уникум булырга, тагын тел белән аңлатып булмый торган бик күп башка төрле сыйфатларга ия булырга кирәк...

Ул арада, кулларына сумкалар, яшел суган бәйләмнәре, укроп, петрушка кебек тәмләткечләр тутырылган сеткалар асып, Һәдия белән Гөлҗиһан апа кайтып керделәр.

Мин, җәһәт кенә торып, аларны каршы алдым. Әйберләрен алып куештым.

— Һәй-й, сезне!..— дип шелтәләгәндәй иттем.— Нигә базарга керәсегезне әйтмәдегез? Каршы барган була идем...

— Юк белән борчылма, — диде Һәдия. — Менә, кабат чыгып йөрмәс өчен берьюлы мулдан куптык...

Кухняга үттек.

Һәдиянең нәрсәдер әйтергә, ниндидер хәбәр белдерергә теләгәне йөзенә чыккан иде.

— Нәрсә?.. — дидем мин, аның күзләренә карап.

— Хәзер... кайтышлый, беләсеңме, кемнәрне күрдем?..

— Я? Соң, әйт инде.

— Ислам белән... Ләйләне.

Күңелем бу юлы да ялгышмаган икән.

## 5

Беренче күкрәү бөтенләй көтмәгән яктан килеп гөрселдәде. Башта электриклар бригадиры чегән Алик керде. Кулында кәгазь. Әле яңарак кына генеральный директорның төзү эшләре буенча беренче урынбасары Иван Данилович Голиков янында булган. Тегесе эшне дәвам итү өчен кирәк булган материаллар бирмичә чыгарган. Алай гына да тү-

гел, заявканың почмагында: катгый рәвештә тыям, дигән резолюция дә бар.

Заявканы караштырам. Бер дә алай искитәрлек нәрсәләр күрмим: берничә төрле тимер чыбык, кече диаметрлы кабель, контакттыр, изоляторлдыр. Җыен шурум-бурум.

Минем кергәннән артык җентекләп каравымны күрептер инде, Алик телгә килде.

— Без инде әле дә кирәк материалның яртысын гына сорыйбыз...

— Ә ни өчен яртысын гына? — дидем мин. — Кабат сорарга туры килмәсме соң?

— Килмәс. Чөнки без материалларны бермә-бер кимрәк тоту ысулын кулланабыз.

— Нинди ысул ул? Асылы нидән гыйбарәт ул алымның?

— Объектны секцияләргә бүлү һәм схеманы камилләштерү юлы белән.

— Авторы кем?

— Нәрсәнең?

— Шул ысулның дип соравым?

Чегәннең тавышы көр.

— Кем булсын, үзебез.

Эчемдә өермә. Голиков янына барып якаламыйча булмас. Үз-үземне көч-хәл белән тыеп утырам. Ә Алик эре ап-ак тешләрен күрсәтеп елмаюын белә. Бу минутта ул миңа бераз гамьсез, үз эше өчен борчылмый, җанмый-көймидер сыман булып күренде. Гүя ул директор янына коры барып, буш кул белән кайтмаган. Башка берәү булса, күптән инде чыгырыннан чыгып, шартлау дәрәҗәсенә җитәр иде.

— Заявкагызны миңа калдырыгыз, — дидем мин.

Алик артыннан ишек ябылырга да өлгермәде, кабинетка Даниал керде. Ул гадәттәгечә тыныч, сабыр. Үзенең өстәле янына килде. Ниндидер кәгазьләр караштыра башлады. Һәм һәр вакыттагыча тыныч кына, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән, минем чәчләремне үрә торгызырлык яңалык тапшырды.

— Имам Хисамович, Вәгыйзнең бездән китүе турында ишеттегезме әле? — диде ул.

— Юк... Ничек китте?

— Бөтенләйгә китте.

— Кая китте?

— Ул кадәресен белмәдем.

Бу хәбәр әллә нишләтеп җибәрде мине.

— Сәбәбе?

— Һаман да шул Иван Данилович инде... Телгә килешкәннәр булса кирәк.

— Ә ни өчен миңа бер сүз дә әйтмәде икән? Һич югында, мине күрергә тиеш иде ул...

— Белә алмадым. Миңа да бер-ике авыз сүз генә әйтте: мине авырлыклар куркытмый, тик әледән-әле үткәнемә төртеп күрсәтмәсеннәр, атлаган саен исемә төшереп тормасыннар, диде.

Бүтән түзәр чамам калмады. Җәһәт кенә тордым да директор урынбасары Голиков янына киттем.

Юлда да Голиков белән эчтән генә әрепләшеп бардым. Әйе, соңгы вакытларда ул чыннан да алып узынды. Һәйбәтләп сорыйсы, таләп итәсе урында приказ бирергә, дипломатик сөйләшүләр алып барасы урында өстәл сугып җикеренергә яратуын мин инде беләм. Әмма бу кадәресен көтмәгән идем. Шуңа аның кабинетына кергәч яман гауга куптардым. Соңгы вакытларда андый ызгыш-талашка тарыкканымны хәтерләмим. Һәм гомумән шул кадәр үк ярсыганым юк иде бугай әле.

Хәер, Голиков та кимен куймады: үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә җитеп тузынды ул. Йөзе китте, күзләре акаеп чыкты, бума хастасы тотамы икән дип торам.

Соңыннан, аның кабинетыннан чыккач, күңелдә чак кына үкенү хисе дә туды сыман. Чыннан да, бәлки ул кадәр үк кызарга кирәк тә булмагандыр... Бәлки Вәгыйзнең китүе бөтенләй башка нәрсәгә бәйледер?..

Тик нишләмәк кирәк, бу юлы да кызу канлылыгым үз-үземә аяк чалды. Артык дәрәҗәдә ýртәлгән идем шул.

Барысына да түзгән булыр идем, әмма ул үткәннәрне, кайчандыр Георг Абрамович Колун белән безнең үзара булган конфликтларны искә төшерде. Шуларга нигезләнеп мине җәнҗалчы, бәлачел кеше дип атады.

Миңа шул бик җитте. Аның үзен үк Колун сыңары дип атадым, аларның икенчесен дә мин җитәкче була алмауда, кешеләр белән эшли белмәүдә гаепләдем. Кешеләр өчен борчылмаган кеше, кешене иң борчыган кеше, дидем.

Яшерен-батырын түгел, Колунны да, Голиковны да мин беренче тапкыр күрүемдә үк күңелем белән кабул итә алмаган идем. Илкүләм эшләр башкарылганда андый антипатия кебек нәрсәләргә урын булмаска тиешлеген дә яхшы беләм. Тик нишләмәк кирәк, кинәт кенә башка кешегә әверелеп китеп булмый бит. Мин Голиковка, сез бүгенге көн җитәкчесе түгел, дип соңгы сүземне әйттем дә чыгып киттем.

Җитәкче. Бик еш кулланыла хәзер бу сүз. Чыннан да, кем соң җитәкче? Социологлар: үзенә буйсынган кешеләрне, коллективны нинди дә булса конкрет эшкә юнәлдерә белүче, диләр. Ләкин бит юнәлдерү үзе берничә төрле процесстан тора: сүз белән тәэсир итә белүче җитәкче бар. Аның бит әле нәкъ менә Голиков кебек көч белән, янау юлы белән үз теләкләренә ирешүчеләре, русча әйткәндә, принуждение ысулын кулланучылар да очраштыргалый. Бу юлга, гадәттә, авторитеты булмаган җитәкчеләр басалар. Хәзер инде андыйлар торган саен кими. Чөнки бүгенге көн эшчесе кешенең тоткан урыны, креслосы алдында баш ими. Хәзерге эшченең теге яки бу урында торган шәхесне ихтирам итүе-итмәве ул кешенең үз характерына, белеменә һәм кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуына кайтып кала.

Бүгенге эшче үз дәрәҗәсен, нәрсәгә сәләтле икәнлеген бик яхшы белә. Ә үз мөмкинлекләрен белгән кеше һичкайчан үзен урынсыз кимсетүгә юл куймый.

Кешедә җитәкчелек итү сәләте юк икән, аңа ачулану, төрле кисәтүләр генә ярдәм итмәячәк. Андый җитәкчене үз вакытында алыштыру хәерле. Әнә, Колун алыштырганны да көтеп тормады, юк булды, бөтенләй КамАЗдан ук китеп барды. Ләкин убыры китсә дә урыны калды дигәндәй, бик күпләрнең нервыларын тәмам эштән чыгарып, йөрәкләренә мәңге төзәлмәслек яра ясап китте.

Бүгенге бәрелешне генә күр инде! Йөр хәзер ут йотып, күңелеңә моң-зар, үкенү-әрнү төяп. Менә шундый вакытларда туа да инде кеше башында җыен тузга язмаган иләс-миләс уйлар...

Җәяүләп кенә өйгә таба атлыйм. Җил. Салкын вак яңгыр сибәли. Эңгер-меңгер чак. Ә күңелдә уйлар... Берсе икенчесен алыштырып кына торалар.

*

* *

Кабинетта телефон шалтырады.

— Тыңлыйм!..

Генеральный директор секретаре Ксения Семеновна икән.

Секретарьның сүзе кыска булды: ун сәгать егерме минутта генеральный директорда булырга.

Сорау бирүемне сизмичә дә калдым:

— Әллә ул-бу бармы?

— Ул кадәресен белә алмадым.

Ксения Семеновнаның тавышы шактый эшлекле һәм ярыйсы ук коры иде. Мондый официаль тонда чакырылдыңмы, көт тә тор, нәрсәдер бар. Кемгә-кемгә, ә миңа Леонид Борисовичның холык-фигылен дә, сәләтен-гадәтен дә өйрәнерлек булды инде. Гаҗәп акыллы, зирәк кеше. Ялгышкан, хата ясаган кешеләр белән ул мәрхәмәтсез. Андый вакытта аклану турында уйлама, кичекмәстән хатаңны төзәтү чарасын күр.

...Әле дә булса хәтеремдә, безнең бүлек тарафыннан тәкъдим ителгән сәгатьлек графикны иң элек «12-А» объектында сынап карарга дигәч, әлеге дә баягы Колун: «Ә ни өчен минем заводта сынарга? Төрле экспериментлар ясау, тәҗрибәләр үткәрү өчен бу бит лаборатория яки анда эксперименталь цех түгел!» — дип каршы чыгып маташкан иде. Ул хәтта тыелган алымнар куллана башлады: безнең бүлек инженер-техник работникларның соңгы айларда «бер дә юкка» күпме хезмәт хакы алуларын, бөтенләй «кирәкмәгән» җиһазларга, приборларга дәүләтнең күпме акчасын тотуларын күрсәтеп, югарыга жалобалар язды. Билгеле инде, шуннан соң Мәскәүдән комиссия килеп төште. Әмма комиссия килгәндә без графикның иң оптималь вариантын инде производствога кертеп өлгергән идек һәм комиссия безнең бу эшне хуплады гына.

Бер генә эш тә, бер генә җиңү дә көрәшсез бирелми шул...

Сүз дә юк, көрәш авыр нәрсә.

Иң куркынычы көрәш түгел, ә көрәштән ару, хәлдән таю. Булмый, ахрысы, дип төшенкелеккә бирелү. Андый чакта кешедә битарафлык туа. Бу инде яман нәрсә.

Мин үзем теге яки бу эштә уңышсызлыкка очрасам, каушап калмаска тырышам, тешемне кысып булса да түзәм. Барыбер үземнекен итәм дип, җан-фәрманга эшемә ябышам...

Башымда бары тик бер уй: генеральный директор нәрсәгә дип чакыртты икән? Бәлки Шавалье мәсьәләсе беләндер? Алай булуы да бик ихтимал. Төзелеш буенча урынбасары Голиков, җыен тузга язмаганны өстәп, әләкләгәндер яки, мин аның белән эшли алмыйм, дип докладной-фәлән язгандыр. Астыртын, хөсетле кешеләрдән теләсә нинди этлекне көтеп була. Гомумән, аның кебек очраклы рәвештә җитәкче булып алган кешеләрдән дә яманы юк: андыйлар үзләре дә яшәми, башкаларга да көн күрсәтмиләр. Эшләре җайлы барганда бер хәл, алар юмарт та, кешелекле дә була беләләр. Әмма юлларында үзләреннән өстенрәк, көчлерәк кеше очраттыларамы, рәхим-шәфкать көтмә, ул чакта инде бетте — алар мәрхәмәтсез.

Андый кешеләрне мин үзем бер якка таба гына хәрәкәт ителә торган юлны иңләп-томалап баручы бик иске, бик борынгы авыр йөк машинасы белән чагыштырып идем. Артта исә соңгы модель белән эшләнгән җиңел автомобильләр килеп тыгылганнар... ә теге, ташбака кебек, бөтен юлны иңләп үрмәләпме-үрмәли. Бар, гаепләп кара син аны! Ул да бит тик тормый, кыймылдый...

Шундый уйларга бирелеп, автозавод идарәсенә килеп җиткәнемне сизми дә калганмын. Ике атлап, бер сикереп икенче катка күтәрелдем.

Мине Ксения Семеновна каршылады. Ни өчендер, сәгатенә күз төшереп алды. Бары тик шуннан соң гына, елмайгандай итеп, стена буендагы креслоларга күрсәтте. Утырып торыгыз, янәсе.

Шул чак генеральный директор кабинетының ишеге ачылып китте. Аннан бер төркем хатын-кыз чыкты. Бака туе ясау юк, кемнедер йокысыннан уятудан курыккан сыман, пышылдашып кына сөйләшәләр.

Ксения Семеновна миңа ым кагып, кабинетка үтәргә кушты.

Леонид Борисович ялгыз иде. Иң түрдә — аркылыга куелган өстәл артында утыра. Мине күрү белән урыныннан күтәрелде. Йөзе житди аның. Керпе чәнечкеләре кебек тырпаеп торган чал чәчләре тагын да агара төшкән сыман булып күренде. Калын, йонлач кашлары астында җемелдәгән үткен күзләр үтәли тишәр төсле карый. Бу хәл сагайтты мине. Димәк, сөйләшү җитди һәм кискен булачак.

Мине үз каршысына ук утыртты. Тынлык урнашты. Үзе дә креслосына күчеп утырды. Һәм, кереш-фәлән ясап тормастан, турыдан-туры сүзгә керешге.

— Бу ни бу, хөрмәтле Имам Хисамович? Тагын нинди мөгез чыгарырга җыенасыз инде?!. Яңадан җәнҗал, яңадан скандал. Җиткәндер бит инде, ниһаять...

Аның болай кинәт ябырылуы әллә ни хәтәр түгел, үзенә күрә бер тактика гына. Бу тактиканы бичарадан-ничара дип кенә куллануы да минем өчен сер түгел.

— Чак кына сабыр итә алсагыз, барысын да төшендерәчәкмен, Леонид Борисович.

— Миңа төшендерделәр инде. Шундый итеп төшендерәләр, әле дә булса аңыма килә алмыйча утырам!

— Конкретрак мөмкин булмасмы?

— Конкретрак та мөмкин. Менә, «Франц-Пуатвен» корпорациясеннән жалоба бар. Халыкара контрактлар һәм патентлар ассоциациясенә мөрәҗәгать итү белән яныйлар. Әле яңарак кына Тышкы сәүдә министрлыгыннан шалтыраттылар. Анда да корпорация исеменнән катгый ультиматум алынган. — Леонид Борисович, үзен яклярлык яки ярдәмгә чакырырлык кеше эзләгәндәй, як-ягына карангалап алды. Аннары тавышын чак кына кимәтә төшеп кабат башлады. — Гомумән, сезнең бүлек кебек мәшәкатьле бүлекне моңарчы күргәнем юк иде әле.

— Бүлек димәгез, Леонид Борисович... Сез бит туры кеше. Ярып әйтегез... Бөтен ризасызлыкны мин тудырам. Шулаймы?

— Кул астыгызда эшләүчеләр дә кимен куймыйлар.

— Мәсәлән?

— Алар тирәсендә дә имеш-мимеш кебек сүзләр күп йөри...

— Гайбәт ул, Леонид Борисович, дан-шөһрәтнең турылыклы юлдашы.

Генеральный директор минем белән килешкән сыман дәвам итте.

— Шулай була күрсен иде, берүк. Югыйсә, әнә, сезне хәзер «бүлек» дип түгел, ә «кают-компание» дип атыйлар.

— Банда дисәләр дә сүзем юк, тик эшкә генә аяк чалмасыннар.

Директор мине ишетмәгәндәй дәвам итте.

— Әгәр дә хак булса, инженер Соснов кеше таптаткан. Прокуратура юлын таптый ди хәзер. Шуның өстенә әле тагын нииндидер уголовник... Һәркайсыбыз тарафыннан хөрмәт ителә торган Ризвановның да, әнә, семья мәсьәләсе бик четерекле ди... — Минем дәшмәвемне күргәч, директор, җайлабрак утырырга теләгәндәй, креслосында селкенгәләп алды.— Менә шул, хөрмәтле Имам Хисамович!.. «Франц-Пуатвен» фирмасыннан алынган сызма-схемаларга корректуралар, төрле үзгәрешләр кертү белән хәзергә сабыр итеп торырга туры килер...

Минем өчен җан өшеткеч сүзләр иде бу.

— Бу ни бу?.. Боерыкмы, әллә үтенечме?

— Монда формулировка нечкәлекләренең әллә ни әһәмияте юктыр, минемчә. — Директор чак кына пауза ясады да, бу темага бүтән әйләнеп кайтмаслык итеп ныгытып куярга теләгәндәй, өстәде.— Билгеле, мин фәлән-фәлән итәсез, и все! дип таләп тә итә алган булыр идем. Әмма сезгә карата андый кискенлек кулланасым килми. Чөнки сез сүз бирмәс, тугры-каты кеше булсагыз да, күп очракта хаклы буласыз. Тик, зинһар, сез мине дөрес аңлагыз. Мин сезне өйрәтергә җыенмыйм. Әм-

ма нишләмәк кирәк, тоткан урыным мине рәсми булырга мәҗбүр итә. Юридик яктан алар хаклы...

— Ә технологик камиллек ягыннан?

— Ул кадәресе хәзергә бәхәсле... — Директор урыныннан күтәрелде дә, озын өстәл буена тезеп куелган урындыкларны санап чыгарга теләгәндәй, һәркайсының артларына таяна-таяна йөренә башлады. — Аңламыйм мин сезне, Имам Хисамович...

— Нәрсәне аңламыйсыз?

— Кирәксә-кирәкмәсә дә гауга чыгаруыгызны, күрәләтә торып конфликтларга керүгезне аңламыйм...

Ул тынып калды. Аның дәшмәвеннән файдаланып, үзем алып киттем:

— Мин дә, Леонид Борисович, монда шелтә ишетергә дип килмәгән идем. Безнең бу инициативаны яклarsыз, һич югында, аның асылына төшенергә тырышып карарсыз, дип уйлаган идем. Белгәнебезчә, һәрбер җитди эшнең, һәрбер яңалыкның яклаучысы булырга тиеш. Югыйсә ул, нәкъ майланмаган арба кебек, шыгырдый башлый яки бөтенләй туктый. Үземә калганда, Леонид Борисович, мин монда бер дә әллә ни искитәрлек нәрсә күрмим. Әгәр дә инде без теге яки бу схемага, конструкциягә чак кына үзгәрешләр кертергә, технологияне камилләштерергә телибез икән, бу бит әле, сез әйткәнчә ук, мировой скандал чыгуга сәбәп була алмый. Элек-электән шулай килде: теге яки бу техниканы чит илдән ала идек тә үзебезнең энтузиазмны куша идек...

— Үткәндәге тәҗрибә хәзер безнең өчен начар киңәшче.

— Сез хаклы. Алар инде үтелгән этап. Хәзер бөтенләй башка. Заманалар бик нык үзгәрде. Идеяләр, информацияләр дәүләт чикләре белән санашып тормый хәзер. Шулай ук, хөрмәтле Леонид Борисович, чит ил җиһазларын, чит ил казанышларын эталон итеп яши торган вакытлар да үтте. Хәзер безнең корректуралар кертеп кенә түгел, теләсә нәрсәне нигездән үзгәртеп корырлыгыбыз да бар...

— Резонно! Ләкин ул төзәтмәләр, сез әйткән ул үзгәртеп корулар безнең башка тимер таяк булып төшмәсен иде.

Сизеп торам, генеральный директор тәмам суынды, йөзе яктырды. Миңа ул, йөрүеннән туктап, миңа текәлде.

— Имам Хисамович, сез миңа бик конкрет һәм кыска гына итеп әйтеп бирегез әле: сез керткән ул корректураларның, сезнеңчә әйтсәк, технологик камилләштерүләрнең асылы нидән гыйбарәт? Монысы — бер. Килеп туган бу күңелсезлекләрдән котылу юлы бармы? Монысы — ике.

Леонид Борисович, хәзер сүз сезгә бирелә дигән сыман итеп, яңадан креслосына барып утырды.

Әйе, кабыргасы белән куелган бу сорауларга җавап бирергә кирәк иде.

Мин шунда ук сүзгә керештем. Әйтеп-аңлатырга теләгән фикерем түбәндәгедән гыйбарәт иде. Билгеле булганча, конвейердан төшкән һәрбер машина махсус трасса — полигон буйлап сынау йөрүе уза. Бары тик шуннан соң гына әлеге техник-контроль стендына керә. Анда ул, нәкъ рентген аша үткән сыман, бик җентекләп тикшерелә. Берәр лампочкасы янмаса да шунда ук алыштырылырга тиеш. Моның өчен стенд янында меңләгән киштәле склад бар. Машинага кирәк булган деталь, запчастьне эзләп табу тулысынча автоматлаштырылган: монорельслар буенча йөри торган лифт-кабинага керәсең дә үзеңә кирәк булган кнопкага басасың. Күз ачып йомганчы син инде кирәкле запчастьләр саклана торган киштә янында... Ә безнең тарафтан кертелгән үзгәреш түбәндәгедән гыйбарәт. Әгәр дә киштәдә кирәкле деталь яки запчасть беткән булса, кнопкага бассаң да лифт урыныннан кузгалмый: вакытыгызны әрәм итмәгез, дигән кебек таблода ялт итеп кызыл ут кабына.

Минем яшь коллегаларым моның белән генә чикләнмәделәр: әле кичә генә Николай тагын да кызыграк тәкъдим кертте. Аны куллана калсак, бер кнопкага басу белән кайсы киштәдәге запчастьләрнең бетүен генә түгел, хәтта кимүен дә күрә алачакбыз. Бу хәл запчастьләрне алдан ук әзерләү хәстәрен күрү мөмкинлеген бирәчәк.

Шул урында Леонид Борисович түзмәде, мине бүлде.

— Бу эшләр, әлбәттә, өстәмә чыганаклар да сораячак. Шулаймы?

— Чыгымнар әллә ни зур булмас. Бары тик бер компьютер гына өстәләчәк... Анысы үзебездә дә бар, — дидем мин һәм электриклар бригадиры калдырган заявканы чыгарып директор алдына салдым. Леонид Борисовичның җайга-көйгә килә башлавын күреп, чак кына шаярып: — Сыерын сатып алып биргәч, мөгезенә бәйләгән киндерәсен генә кызганмассыз инде... — дип өстәп тә куйдым.

Директорның кысынкы иреннәрендә, мин кергәннән бирле беренче тапкыр буларак, дустанә бер елмаю балкып куйды.

— Сезнең юк нәрсә белән шөгыльләнмәвегезне яхшы белә идем мин. Чак кына сабыр итәргә мөмкин түгел идеме соң? Француз мәңгегә дип килмәгән ләбаса...

— Аннары соң була. Меңләгән стеллаж-киштәгә демонтаж үткәрергә туры киләчәк. Сез әйткән чыгымнарның да бермә-бер артуы мөмкин.

Бер мизгелгә тынлык булып алды.

— Ә икенче сорауга нәрсә диярсез? Француз әфәнде белән «дипломатик» мөнәсәбәтләрне җайга сала алырсызмы?

— Хәзергә берни дә әйтә алмыйм.

— Алайса, мине тыңлагыз. Күрүемчә, сезнең өчен хәзер ике юл калган: берсе — төрле экспериментларны кичекмәстән туктату, икенчесе— француз белән, фирма вәкиле белән уртак тел табу...

— Безнең өчен икенчесе кулайрак.

— Мин дә шулайдыр дип уйлыйм.

Мин аның кабат ялтырап-балкып елмаюын көткән идем. Әмма директор бары тик җитдиләнде һәм, әңгәмәнең төгәлләнүен сиздерергә теләгәндәй, кызу-кызу тезә башлады.

— Менә шул, Имам Хисамович. Бурычларыгыз билгеле, максатларыгыз зур, дәвам итегез. Әмма эшне озакка сузмаска. Минем Мәскәүгә җавап бирергә тиеш икәнлегемне дә онытмагыз. Өч көн срок сезгә. Җавап китергәндә рөхсәт-фәлән сорап тормагыз, бәрегез дә керегез. Аңлашыламы? Алайса, бик һәйбәт. Уңышлар телим!

## 6

Мине Мәскәүгә чакырып телеграмма килгән. Соңга калмас өчен, иртәгә иртүк сәфәр чыгарга кирәк. Анда КамАЗ чыгарачак автомашиналарның иң соңгы вариантын кабул итәчәк комиссия эшендә катнашырга тиешмен.

Хәлемне аңлатып, Леонид Борисовичка шалтыраттым. Ул бу хәбәрне бик тыныч кабул итте. Башта хәерле юл теләде, аннары командировкада булу гына мине «Франц-Пуатвен» корпорациясенә җавап бирүдән азат итмәячәге турында кабат кисәтеп куйды.

Бөтен өметем — яшь коллегаларымда. Экстренный киңәшмәгә җыелдык. Көйгә килмәс француз китереп чыгарган четерекле эшне ничек кенә булса да кичекмәстән җайга салырга кирәк иде.

Генеральный директор бер түгел, мең хаклы — көтмәгәндә килеп туган бу аңлашылмаучылыкның, чыннан да, бик яман, бик хәтәр яклары да бар. Шушы көннәрдә генә «Экономические проблемы и международные отношения» дигән журналда нәкъ безнекенә охшашлы ситуация

турында язылган бер мәкалә басылган иде. Анда АКШның «Дженерал мотрос» фирмасы Көнбатыш илләрнең берсе белән, килешү кагыйдәләрен бозды, дип конфликтка керә һәм Бөтендөнья патент-лицензия ассоциациясе аша теге илдән миллионнарча доллар штраф түләтә. Комсызлануда, бер-берсен талауда аларны өйрәтеп торасы юк, ул яктан аларның азау тешләре күптән шомарган.

Иң элек Даниал белән Николайны генеральный директор тарафыннан тәкъдим ителгән ике юл белән таныштырдым. Шунда ук вакытның гаять кыска булуын, җитмәсә тагын, үч иткән кебек, үземнең иртәгә таң белән командировкага китеп барачагымны әйттем.

— Нишлибез? Кайсы юлны сайлыйбыз? — дидем мин.

Яшь коллегаларым уйга калып каш җимереп торган арада: «Төп максатыбыз — мсье Шавальены цейтнот хәленнән чыгару булыр», дип үз фикеремне алдан ук әйтеп, кабат кисәтеп куйдым.

— Шулай итү мәслихәтрәк булыр. Без моның белән бары тик отачакбыз гына...

Соңгы көннәрдә күзенә ак-кара күренмәгән Николай: «Өченче юлы да бар... Нокаут ясау...» — диде.

Бу фикер Даниалга ошады, ахрысы: Николай хаклы дигәндәй, авызын ерды.

— Тыелган адым. Ярамый... Бигрәк тә дипломатиядә, — дидем мин. Шунда ук көйгә килмәс французны үз ягыбызга аудару юллары турында баш вата башладык.

— Әгәр дә кирәк икән, безнең идеяләребезнең соавторы булсын. Тик без башлаган эш белән, безнең тәкъдимнәр белән мавыксын, безнең белән бергә янсын-көйсен...

Даниал мине бүлеп:

— Янсын өчен кабызырга кирәк, — дип кыстырып куйды.

— Менә шул «кабызу» бурычы сиңа йөкләтелә дә инде, — дидем мин, аның фикерен куәтләп. — Инде ул да ярдәм итми икән, мин кайткач уйлашырбыз, үзебезнең хаклыкны башка юл белән исбат итеп карарбыз...

Беренче очраган трамвайга утырдым да автозавод янына китеп бардым. Һәдияне каршы алырга иде уем.

Сәгатемә күз салам. Берничә минуттан аның да эш сәгате чыгачак. Өлгерерменме икән?

Учкомбинат тукталышында төшеп калдым. Трамвай китеп барды. Нәкъ шул вакытта учкомбинатның ачык ишегеннән Һәдия килеп чыкты. Баскычтан да яшьләр кебек йөгереп кенә төште. Шул кызулык белән җил-җил атлап минем якка таба килә башлады. Аның күңеле шат, хыяллары якты иде булса кирәк.

Әмма мине күрү белән ул шып тукталды. Йөзендәге мөлаемлык та юып алгандай булды. Хәтта чак кына агарынып та китте сыман.

— Нәрсә булды?.. — диде ул, тәмам каушап-югалып.

— Берни дә юк, Һәдия...

— Чынын әйт... Ул-бу бармы әллә?

— Чын, Һәдия, берни дә юк.

Чак кына тынычланды кебек.

— Ә ничек килеп чыгасы иттең?

Мин көлмичә булдыра алмадым.

— Сагындым да килеп чыктым менә.

Һәдия мине култыклап алды.

— Мәшәкатьләнеп йөрисең калмаган...

Урам буйлап барабыз. Тирә-якта ыгы-зыгы. Трамвайлар... Олы киң урамнан тоташ агым булып машиналар агыла...

Сүз куешкан сыман, тыныч тыкрыкларның берсенә борылдык һәм ашыкмыйча гына юлыбызны дәвам иттек.

Һәдия үзенең эше, үз группасындагы кызлар турында сөйли. Тиздән саубуллашу кичәсе булачак икән. Аның өйрәнчекләре, төзүче һөнәрләре алып, төрлесе төрле якка таралачаклар.

— Хәзер инде балалар түгел алар. Шулай ук үз көннәрен үзләре күрерлек мөстәкыйльлек тә юк аларда. Иң хәтәр чаклары. Тормыш китабының беренче битләрен генә ачалар. Нәрсә көтә аларны? Күп нәрсәне белмиләр. Мәхәббәт тә озак көттермәс... Аннары гаилә. Кызганычка каршы, боларның берсе генә дә уку программасында күрсәтелмәгән. Төзүче дигән таныклык алу ул бит әле кеше тормышында кирәк булган барлык белемне дә үзләштерде дигән сүз түгел. Әгәр дә кодрәтемнән килсә, мин алар белән тагын бернича ел бергә булыр, бергә эшләр идем. Шулай булганда мин аларны хаталардан, ялгыш адымнардан йолып кала алыр идем кебек...

«Әй-йе, — дип уйлап куйдым мин. — Тәрбия эшендә иң әһәмиятлесе — тәрбияченең кем булуы. Хикмәт шунда».

Бераздан иске Чаллының тыныч урамнары башланды. Як-якта кайчандыр административ биналар булып саналган икешәр катлы агач йортлар, таш кибетләр. Моннан нибары ун ел гына элек бу тирәләр иске Чаллының үзәк урамнары иде.

Бераздан үзебез дә сизмәстән Кама буена килеп чыкканбыз. Елга өстеннән дымлы җил исә. Шундый рәхәт — йөзгә кушуч белән талгын су сипкән сыман. Ирексездән йөзеңне елга ягына куясың.

Көчле дулкыннар кагып тигезләгән комлык буйлап алга таба киттек. Аяк астыбызда вак дулкыннар чут-чут итә. Янымда Һәдия атлый... Аның бая югалып-каушап калуы мине бераз сәерсендергән иде. Җаен туры китереп, бу турыда үзенә дә әйттем.

— Искәрмәстән генә сине күргәч, чыннан да әллә берәр хәл булдымы икән дип уйладым шул, — диде ул.

— Кодрәтемнән килсә, мин сине, Һәдия, һәркөнне кич шулай каршы алыр идем, иртән эшеңә кадәр озатып куяр идем. Кулымнан килердәй булса, атнамның җиде көнен дә сиңа, балаларга багышлар идем. Белсәң иде икән, Һәдия... Күңелемдә сиңа карата изге хисләр күпмелеген. Тик, ничектер, һаман да әйтә алганым юк. Инде әйтәм-әйтәм дип, талпынып та куйгандай итәм...

Һәдия кабат сагайган сыман булды, хәтта адымнарын әкренәйтте. Аннары күзләрен тутырып миңа сирпеп алды да, әкрен генә әйтә салды:

— Кирәкми... Кирәкмәс, Имам...

Бу хәл мине яңадан аптырашта калдырды.

— Ник, Һәдия? Нигә алай дисең син?..

— Ничектер сүзләреңне... саубуллашырга җыенган кеше сыман итеп сөйли башладың.

Тизрәк тынычландырырга ашыктым.

— Алайса, зинһар, җаным, гафу итә күр. Мин бары тик сине яратуымны, үземнең синең белән бәхетле булуымны гына әйтмәкче идем... Ә бит мин бу якларга тик үткәнем белән очрашырга дип кайткан идем. Чынлыкта исә киләчәгем белән очрашырга язган икән...

Һәдия, үзе дә сизмәстән йөрәксенеп, кинәт кенә минем терсәгемне ике куллап эләктереп алды да күкрәгемә килеп елышты.

— Мин дә бәхетле, Имам! Бик тә, бик тә бәхетлемен... — дип башлады ул. — Бәхетнең нәрсә икәнен бары тик хәзер генә белдем, хәзер генә төшендем кебек. Минем хәтта тормышка, дөньяга карашыма кадәр үзгәрде хәзер. Элегрәк мин һәр туган көнне котым очып: бүген нинди хәвеф-хәтәр булыр микән инде? дип каршылый торган идем. Хәзер бөтенләй башка, Имам... Минем бар теләгем: шушы халәт озын го-

мерле була күрсен берүк.— Аннары кызыксынуын җиңеп дәвам итте.— Хәзер мин һәрбер туар көнне нниндидер могҗиза көткән кебек зарыгып көтеп алам, һәрбер туган көн өчен куанып бетә алмыйм. Син янымда булганда, Имам, минем сирәк-мирәк булып алган кайгы-хәсрәтем дә куанычлы. Чын әгәр! Вакыты белән, бик иртә тынычланмадыммы икән, дип тә уйлап куйгалыйм. Чыннан да, синең белән җаным тыныч минем. Тормышым өчен дә, балаларым өчен дә җаным тыныч. Үземне тормыш дулкыннары гына түгел, хәтта җил-давыллар да үтеп керә алмаслык нык стена артына яшеренгәндәй хис итәм. Вакыты белән, кеше җилкәсенә артыграк салынмадым микән, дип уйлап та куйгалыйм. Билгеле, вакыты белән укымышлы булмавыма уфтанып куйгалыйм. Баштарак, без бит тиңнәр түгел, дигән уй да туып бимазалый иде. Әмма синең миңа карата, балаларга карата булган шәфкатьлелегеңне күреп, ул уйларны башымнан чыгарып ташларга тырыша идем. Аннары син һаман мине күтәрергә, хезмәтемне күрергә тырыштың. Шул ук әткәй, хатын-кыз — мамык мендәр: күпертсәң күперә, күпертмәсәң киезләнә, дия торган иде.— Һәдия кинәт елмайды, керфекләрен сирпеп күзләремә карады:

— Аннары бит мин хәзер, ни әйтсәң дә, инженер Котдусов хатыны... Ә бу кечкенә нәрсә түгел...

Яр буеның бу өлеше кинәт киңәеп киткән сыман булды. Янгыр сулары юудан ишелеп, коры яр сыман нәрсә хасил булган. Әмма ул яр эче күптән инде вак куаклык, куе үлән белән капланган. Шул яктан яшь тал, шиңгән үлән һәм төрле чәчәкләр исе аңкып тора.

Җир өстенә эңгер иңә башлады. Су буена салкын төште. Без кайту ягына борылдык.

Өйдә безне яңалык көткән икән. Кунагыбыз Петр Ильич, ут капкандай аннан-моннан гына җыенган да, китеп тә барган. Бу хәбәрне безгә Гөлҗиһан апа әйтте.

— Ә Ислам?.. — дигән сорауның телемнән ычкынуын сизми дә калганмын.

— Ул кунакны озата китте.

Димәк, Ләйлә... Аның аркасында китми калган. Һәм мин, бүген үк, ул кайткач та, алып узынган егет белән үтемле генә итеп сөйләшергә кирәк булыр дип, күңелемә беркетеп куйдым.

Чәйләп алгач, Һәдия белән Гөлҗиһан апа мине юлга әзерли калдылар, ә мин кабинетыма кереп киттем. Исламның чемоданы урыныннан да кузгатылмаган, таратылган көе ята бирә.

Нәрсә уйлый бу егет? Һәрбер мавыгуның хәтәр ягы бар лабаса. Шул турыда уйламый микәнни соң ул?

Шул чак үзем өчен аяныч бер хакыйкать ачкандай булдым. Ислам заманында мин ясаган хаталарны ук кабатлый түгелме соң? Шулай ич. Тагын уйлар...

Тәрәзә каршына килдем. Олы урамның киң асфальтыннан сирәк-мирәк үткән машиналарның мотор тавышлары ишетелеп кала. Каршыдагы тыкрыкта, соң булуга да карамастан, зур җанлылык. Кая карама, кран уклары, көчле прожекторлар...

Исламны көтәм. Командировкага киткәнче сөйләшеп калырга кирәк. Акылсыз кеше түгел, бәлки аңлар.

Шундый уйлар белән креслога килеп утырдым. Тумбочка өстендәге лампочканы кабыздым. Шунда күземә Николай биреп калдырган көрән тышлы дәфтәр чагылды.

Кулыма алдым. Билгеләп куймаганлыктан, беркөн туктаган урынны таба алмадым. Урта бер җирен ачтым. Шунда астына сызып куелган

сүзләргә игътибар иттем. Карасам: «Ур-ра-а! Тормышка чыктым...» дигән сүзләр астына сызып куелган икән.

Шул сүзләрне укыгач, ирексездән: бу дуамал баш тагын нинди ахмаклык эшләде икән инде, дигән уй туып куйды. Хатыны, баласы булган укытучы белән бик җиңел танышуы, машина йөртергә өйрәнүләре һәм, ниһаять, шул Ләбип Хәнипович дигән бәндәгә тормышка чыгарга ризалык бирүләре миңа шундыйрак фикергә килергә, үземчә нәтиҗә ясарга хокук бирә иде кебек.

Укуымны дәвам итәм:

«...Габбаска карата булган хисләрем нәрсәдән башлангандыр, аңысын хәзер әйтүе кыен. Шулай да бер кичкенә генә вакыйганы онытасым юк. Январь ае яман салкын булды быел. Машиналарга да, безгә, экскаваторчыларга да, бик авырга туры килде. Көннәрнең берендә гадәттәгечә эшкә килдем. Габбас кабинадан сикереп төшеп исәнләште дә, машина ходта, кабул ит дип, кайтып китәргә җыена башлады. Шул чак ул туктап, минем бияләйләремә күз төшереп алды. Һәм гаять дәрәҗәдә гади генә итеп: «Бияләйләрең бик юка икән, Ниса. Мә, минекеләрне ки. Кичкә тагын да суытачак»,— дип, кулындагы бияләйләрен салып миңа сузды. «Ә үзең?...» — дидем мин, рәхмәт тә әйтергә онытып. «Мин кайтып барамич... Ә өйдә яңалары бар», — диде дә безне иkенче сменага алып килгән автобуска таба китеп тә барды.

Киндер белән тышланган иркен, йомшак бияләйне шунда ук киеп тә алдым. Анда әле Габбасның кул җылысы да суынырга өлгермәгән иде. Ул җылы кулымны гына җылытып калмады, шунда ук кайнар дулкын булып йөрәккә үк үтте. Шул вакыйгадан соң мин Габбас белән очрашу сәгатьләрен көтеп ала, эшкә ашкынып бара торган булдым. Мин — гашыйк идем.

Аңынчы инде мин Габбасның армиядә хезмәт иткәндә, тыныч вакытта, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән булуы турында да ишеткән идем. Ни өчен икәнлеген бары тик соңыннан гына белдем. Гаять тә гади нәрсә турында әйткәндәй, үзе сөйләде. Ә минем чәчләрем үрә торды...

Атом су асты көймәсендә хезмәт иткән Габбас. Төньяк Котып бозлары астыннан үткәндә була ул хәл. Зур тирәнлектә, ни сәбәптәндер, двигательләр эшләүдән туктый. Ремонтлау өчен тиз генә өскә калкырга команда була. Әмма уннарча метр калынлыктагы бозны көймәнең корпусы белән генә ваттыра алмыйлар. Аңынчы да инде көймә берничә тәүлек өскә калыкмаган була. Кислород запасы юк дәрәҗәсендә. Менә шунда башлана коточкыч маҗаралар. Йөз кешедән артыграк экипаж кислородсыз кала. Матросларның кайберләре һава җитмәүлектән өметсезлеккә бирелә башлый. Арада хәлдән таеп идәнгә егылучылар да булган.

Билгеле, көймәнең бозны ваттырырлык, хәтта эретеп бетерерлек тә көч-егәре булган.

Менә шунда иң соңгы чараны кулланырга булалар: атом ягулыгы белән эшләүче реактор бүлегенә кереп, төп двигательне ремонтлап карарга, дигән карарга киләләр. Бу гаять җаваплы, шул ук вакытта хәтәр эшне (үзләре теләк белдергәч) механик Габбас белән электрик Филимонов дигән егеткә тапшыралар. Радиоактив матдәләр белән зарарланмасыннар өчен, нәкъ космонавтлар кебек итеп, махсус скафандрлар, радиоактив нурлар үтмәслек киемнәр кидерәләр аларга...

Су өстенә калыккач, люкларны ачкач, һаваның су кебек шаулап керүе, кешеләрнең шул люк янына килеп йотлыгып сулаулары, кайберәүләрнең хәтта һуштан язулары турында сөйләүләрен тыңлаганда тәннәрем чымырдап киткән иде.

Шулай итеп, су асты көймәсе эшен тәгәлли.

Тиз арада Габбаска булган тойгым, йөрәк төбеннән күтәрелеп, бөтен тәнемә таралды, бераздан инде бөтен барлыгымны яулап алды. Әйтерсең лә миңа канат куйдылар. Ниһаять, язгы җилләр исте, 8 Март көне килеп җитте. Сигез кешедән торган бригада членнары бергә кушылып миңа истәлекле бүләк тапшырдылар. Шул ук айда минем туган көнем. Ял көненә туры китереп, шуны билгеләп үтәргә булдым. (Бергә эшләгән иптәшләрем алдында бурычлы булып каласым килмәде.) Яшьләрнең «Чалман» дип йөртелә торган кафесында өч-дүрт өстәлне бергә кушып, табын хәзерләттем. Кабат расходланмасыннар өчен, туган көнем икәнлекне белдертмичә генә барысын да мәҗлескә чакырдым. Яшерен-батырын түгел, бар теләгем Габбас белән якыннанрак танышу иде.

Ул кичне бригада членнарын танырлык түгел, барысы да искитмәле итеп киенгәннәр, һич кенә дә гади экскаваторчы егетләр димәссең. Үзем турында әйткән дә юк. Мине гел брезент тужуркадан, колакчын бүректән күреп ияләшкән егетләрем, телдән язган сыман ах-х! иттеләр дә баскан урыннарында катып калдылар. Ул көнне егетләрне әсир итәчәгемне үзем үк сизенгән идем. Андый чакта, ошарга теләгәндә, без хатын-кызларга иблис үзе ярдәм итә ди бит.

Ул кичне мин табын күрке идем. Музыкантлар да, безнең өчендер инде, күбрәк татар көйләрен уйнадылар. Ә бит анда илебезнең барлык милләт вәкилләре диярлек җыелган. Алай гына да түгел, КамАЗ хәзер халыкара төзелешкә әверелеп китте. Монда хәзер американлыларны да, французларны да, немецларны да, италиялеләрне дә очратырга мөмкин. Алар Кама автомобиль комплексының аерым заводларын җиһазларга тиешләр икән. Берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе достоин кавалерларны берүзем авызыма каратып утыруымны күреп, кафедагы башка кызларның күзләре янулары турында әйткән дә юк.

Ул кичне морадыма ирештем, барлык танцыларны да диярлек Габбас белән генә биедем. Аз сүзле, тыйнаклыгы белән аерылып торган Габбасның да теле чишелде: «Ниса, сез шундый сылу бүген... хәтта куркыныч сылу...» — дип комплимент та әйтеп куйды. Күңелем белән, «ә син курыкма», дисәм дә, телем белән, «көлмәгез инде», дип чытлыкланган булдым.

Мәҗлес көткәннән дә матур үтте. Әмма соңыннан, безгә хезмәт күрсәткән официантка кыз янына барып счет сорагач, аның «егетләр түләделәр инде» дигән сүзләрен ишеткәч кенә кәефем кырыла язды. Егетләргә: «Нишләдегез инде!» — дип үпкәмне белдерергә теләгән идем дә, кая ул, авызымны да ачырмадылар.

Шул көннән соң Габбас белән очраша башладык. Бик тирәндә, кайдадыр йөрәк төбендә яткан кайнар хыял-ниятләрне кабыза, үргып торган хис-тойгыларны кузгата алды ул. Акылымны җуяр дәрәҗәгә җитеп гашыйк булдым. Гомумән, әллә нишләдем мин. Була бит шундыйрак хәл... Кинәт уянып китсәң, тәрәзәләрдән күзләрне чагылдырып кояш нурлары бәрә. Тышта искиткеч матур көн. Юк, юк!.. Бер тышта гына түгел, күңел күге дә, ничектер кинәт аязланып, яктырып киткән. Гүя җанны кыйный, җанны рәнҗетә торган бер генә нәрсә дә калмаган. Тормыш мәшәкатьләре дә, борчулы уйлар да юк. Бары тик шул якты нурларны балкытучы, күңелләрне иркәләп назлаучы, берсеннән-берсе татлырак хыяллар вәгъдә итүче аяз көн генә бар. Андый вакытта кеше чиксез бәхетле... Габбасны күрүем, аның белән очраша башлавым миңа да нәкъ менә шулай тәэсир итте. Тормышыма искәрмәстән, һич кенә дә көтмәгән яктан яктылык сирпелдемени! Моңарчы белгәннәрем, күргәннәрем барысы да кинәт кенә әһәмиятен югалтып, мәгънәсез бер нәрсә булып калды. Габбаска карата чын мәхәббәтем мине бөтенләй икенче кеше итте. «Минеке бул» диде, карышмадым. Хәер, бөтен бар-

лыгымны билән алган хис-тойгыларыма каршы торырлык халәттә түгел идем инде мин.

Башта Чаллыда, аннары Мөслим районында аның тигез, мул тормышта яшәүче әти-әниләренә кайтып туй ясадык. Шулай итеп, кавыштык. Саубуллашканда әнисенең әйткән сүзләре хәтердә уелып калган. «Миңниса кызым, Габбасны ярат. Аның сөям-көям кебек сүзләргә саран булуына карама. Әтисе дә шундый, бераз йомыграк кеше. Мине сораганда да андый назлы сүзләр әйтеп тормады. Әйдә, диде, тормыш юлын бергә-бергә үтик, диде. Алтын таулар түгел, бары тик турылыклы, намуслы тормыш вәгъдә итәм, диде».

Миннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр ул көннәрдә. Кешенең шул кадәр дә бәхетле булуы мөмкин дисәләр, элегрәк үтерсәләр дә ышанмас идем. Нур өстенә нур дигәндәй (икебез ике яктан эшләп торгангадыр инде), бер бүлмәле генә булса да яңа квартира бирделәр.

Шулай куанышып кына яши башлаган бер чорда тормышыбыз күген хәвефле, шыксыз кара күләгә томалады: Габбас белән бергә атом реакторы бүлегенә кергән Филимоновның үлгән хәбәрен алдык. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Кременчуг шәһәренә яңа экскаватор алырга командировкага китәргә җыенган Габбасны Мәскәүгә чакырып телеграмма килеп төште.

Аннан кайтканда батыр, тимер ихтыярлы Габбасымны таныйрлыгы калмаган иде. Минем: «Нәрсә булды, ни өчен чакырганнар», дип ялынып-ялваруыма каршы тыныч кына: «Эх-х, Ниса! Чак кына сабыр итәсебез калган икән...» диде. Бу аның өйләнгәнлегенә үкенүен белдерүе иде...

Шул вакыт ишек ачылды. Аяк очларына гына басып Ислам кайтып керде. Кабинет ишеген ачу белән мине күреп алды.

— Ә-ә, әти... Салют! Ник йокламыйсың?

— Сине көтә идем...

Бу сүзләр аны чак кына сагайттылар булса кирәк. Әмма әллә ни исе китмәгән кыяфәт белән диван янына килеп чишенә башлады. Иң элек пиджагын салып урындык башына элде. Кискен хәрәкәт белән галстугын йолкып алды. Аннары үзалдына сөйләнгән кебек итеп тезә башлады.

— Баягынак кына Петр Ильичны озаттым... Үч иткән кебек син дә, Һадия апа да өйдә юк идегез. Бик тә инде сезнең белән адәм рәтле итеп саубуллашырга теләгән иде. Бик канәгать булып китте. Күп итеп рәхмәтләр әйтергә кушты.

— Ник алай ашыкты соң ул? Шулай капылт кына китеп баруын әйтәм...

— Сәбәбе шул: көндез Мәскәүгә шалтыраткан идек. Төп-төгәл өч көннән Лондонда, яшь галимнәрнең халыкара симпозиумында булырга, дигән хәбәр алдык. Андый сәяхәтнең, белгәнеңчә, мәшәкате зур. Чит ил паспорты алу, тегесе-монысы... өч көннең үткәне сизелмәячәк тә. Аның Чаллыда калуының төп сәбәбен бик яхшы төшенсәм дә, сорау бирдем.

— Ул симпозиумга син дә барырга тиеш идең түгелме соң?

— Тиеш идем.

— Соң?

— Бу юлга мин калып торырга булдым.

— Кызганыч. Андый сәяхәт гелән тәтеп тормас бит...

Сизәм, егетнең сер бирәсе килми.

— Зарар юк! Анда бармый калудан әллә ни югалтмам кебек...

— Бармыйча калу ярый идемени?

— Ярый. Жылы урын буш булмый диләрме әле?.. Андый җиргә барырга теләүче кандидатураларга мохтаҗлык булмаячак.

Тизрәк төп мәсьәләгә күчәргә кирәк иде. Һәм мин, кереш сүз ясапнитеп тормыйча, аның Ләйлә белән үзара мөнәсәбәтләре турында сорап куйдым.

— Һәрхәлдә, мин сине мондый адым ясарга сәләтле кешедер дип уйламаган идем...

Ислам бу сөйләшүнең, иртәме-соңмы, барыбер котылгысыз икәнлеген алдан ук сизенгән, алдан ук белгән, әлбәттә. Шуңадыр, минем сүзләремә әллә ни исе китмәде аның. Бу күңелсез әңгәмәне уен-көлкегә борып җибәрергә маташып карады.

— Син, эти, миңа мораль, вәгазь укырга җыенасың түгелме? Мораль уку, белгәнеңчә, картаю билгесе диләр.

— Бәлки шулайдыр. Әмма син мине тыңларга тиеш...

— Тыңлыйм! Бөтен игътибарым синдә, эти, — дигән булып каршыма ук килеп утырды бу. Аннары әйтә салды. — Ләкин алдан ук кисәтеп куям: минем Ләйләгә карата булган хис-тойгыларым хәзер инде үгет-нәсихәт тыңлаудан узган. Яраттым мин аны!.. Менә шул, эти.

— Ләкин бит ул ир хатыны...

— Беләм. Әмма берни дә эшли алмыйм. — Аннары ирен кырыйлары белән генә елмаеп әйтте. — Аннары, эти, шуны бел: мәхәббәт безнең чорда сирәк очрый торган дефицит нәрсә ул. Аны хәзер хәтта блат белән дә табып булмый.

Исламның илтифатсызлыгы, берниндн тартынусыз җыен тузга язмаган фәлсәфә сата башлавы бик үк ошамаса да, түздем, үз-үземне кулга алып, әңгәмәне дәвам иттем.

— Тирәнтен уйлап эшлисеңме бу адымны? Күңелеңнең вакытлыча гына иләс-миләсләнеп китүе түгелме?

Егет күзен дә йоммады.

— Түгел, эти.

— Уйланып җитмәгән адым ясап, кеше күңеленә мәңге кичермәслек, мәңге төзәлмәслек яра салуың бар. Шул турыда уйладыңмы?

— Уйладым, эти. Хәтта Ләйләнең кайда эшләячәге дә билгеле.

Бу кадәресен мин дә көтмәгән идем. «Үгет-нәсихәт тыңлаудан узган инде» дип, әнә нәрсә турында әйткән икән.

— Һәрхәлдә, Ислам, мин синең бу адымыңны аклый алмыйм. Гомерле булырмы ул мәхәббәтең, шул турыда да бик нык уйларга кирәк. Хуш исле гүзәл чәчкә дә көзен шиңә...

Ислам җавабын алдан ук әзерләп куйган сыман әйтте:

— Нишлисең бит, эти. Безнең беребез дә бу фани дөньяга мәңгегә дип килмәгән.

— Ислам,— дидем мин ахыр чиктә,— үзең турында гына түгел, чак кына булса да Вәгыйз турында да уйлар иден. Ул ансыз да шактый авырлыкларны күргән, җәбер-кимсетүләрне кичергән кеше. Кеше гаиләсен җимергән дигән хәбәр тирә-юньне аркылыга-буйга көненде айкап чыгачак. Шул турыда уйлар иден. Аннары алдында диссертация яклау кебек гаять зур эш тора. Гомумән, зур көрәш көтә әле сине алда. Ә көрәшкәндә, барыннан да элек, тылның нык булуы шарт. Иренә хыянәт итә алган аумакай хатын сиңа турылыклы булыр дисеңме?..

Минем соңгы сүзләрем Исламга ошамады:

— Ничек тә Гетера булмас!.. — диде ул, ниндидер сарказм белән.

Җавапсыз каласым килмәде, мин дә борынгы грек эпосына мөрәҗәгать итәргә булдым.

— Пенелопа булыр дип уйлыйсыңмы?..

Бу сүзләрдән соң Ислам кинәт үзгәрде. Пөхтә, әрепләшергә җыенган сыман, ниндидер бер ят елмаю хасил булды. Урыныннан күтәре-

леп йөреп килде. Бары шуннан соң гына кабат каршыма килеп туктады да, ишетмәсәң ишет алайса дигәндәй, әйтте:

— Нәрсә, эти, минем белән ачуланышырга, араны бозарга телисеңме әллә? Күп кенә яктан сиңа охшаган булуыма мин гаеплемени?..

Бу аның үткәннәрне искә төшерүе, Зинаида белән булган вакыйгаларга ишарә ясавы иде.

— Бу нәрсә? — дидем мин, каты итеп.— Миннән көлүеңме, әллә миңа үпкәңме?

— Юк, комплимент! — диде ул, күзен дә йоммыйча.

Ямьсез тынлык урнашты. Әмма озакка түгел. Ислам бу урынсыз сөйләшүгә чик куярга теләгәндәй итеп әйтте:

— Җитте, эти! Бу турыда бүтән сөйләшмик. Әгәр дә ялгышам икән, беркемне дә гаепләмәм. — Тавышына кадәр үзгәрде аның, йомшарды, мөлаемланды. — Тагын шуны әйтә алам, эти: минем бу адымым мине дә, шулай ук сине дә компрометировать итмәячәк. Борчылма. Андый адым ясыйм икән инде, ул һәр яктан акланган булыр.

Шуның белән сүз дә бетте дигәндәй, диванга урын җәя башлады. Миңа да аңа тыныч йокы теләп чыгып китүдән башка чара калмаган иде.

*
* *

Эштән иртәрәк кайттым. Ишекне ачып керсәм — өйдә Николай. Каядыр соңга калудан курыккандай, Һәдия дә киенеп тора.

— Кая җыенасыз? — дидем мин, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча.

— Барабыз әле, — дигән булды Николай да. — Һәдия апаның ярдәме кирәк булды бит әле, Имам Хисамович...

— Ә мин ярдәм итә алмаган булыр идеммени?

Николай урынына Һәдия җавап бирде.

— Монда эшләр, Имам, мәхәббәткә, йөрәккә бәйләнгән... Бүген больницадан Ниса чыга. Шуны каршыларга баруыбыз. Бәлки әле туптуры безгә генә кайтырбыз...

Николайның тешләрен санарлык.

— Ә мин тагы чын дустым дип йөргән булам, — дидем мин Николайга. — Әйт, дуслармы без?

— Бик дуслар, Имам Хисамович!

— Дус кем ул?

Николайның җавабы әзер:

— «Икенче мин», — дигән Зенон.

— Соң шулай шулгач. Чын дус ком сахрасында — суы белән, диңгездә — көймәсе белән, тормышта — киңәше белән уртаклашыр, диелә бер акыллы мәкальдә.

Николай җитдиләнә төште.

— Күңелегезне киң тотыгыз, Имам Хисамович, сезнең киңәш, сезнең ярдәм дә кирәк булыр әле.

— Менә монысы егетләр сүзе! Тик...

Сүзебезне Һәдия бүлде.

— Киттек, Коля. Югыйсә, соңарабыз.

Алар ишеккә юнәлделәр.

— Хәерле юл сезгә!

## 7

Командировкалардан шушындый күңел күтәренкелеге белән кайткан чакларымны хәтерләмим. Хәтта самолетның гүләве дә җинү маршы уйнавын хәтерләтә иде. Чөнки юлым уңды: барлык йомышларым да җиренә җиткереп үтәлде.

Тик минә яшь коллегам гына гомерендә беренче тапкыр үзенә йөкләтелгән бурычны үти алмаган. Әлеге француз Даниалның сүзләренә колак та салмаган. «Кеше ише генә дә кыланмый бит, мөртәт. Аптыраш та йөдәш аның белән», дип сөмсере коелып каршы алды мине яшь коллегам.

— Зарар юк, барыбер әмәлен табарбыз, сындырырбыз... — дидем мин.

Күңелем күтәренке иде минем. Хикмәт юлым уңуда гына да түгел. Яшь коллегаларым да җанга ял булырлык хәбәрләр белән каршыладылар. Николайның шатлыгы аеруча зур, ул машина белән бәрдергән хатын-кыз кризисны уздырган. Һәдия белән танышуына бик куанган. Ризвановның да үзенә күрә шатлыгы бар: хатыны Наилә Чаллыга күченеп килергә ризалык биргән.

Мсье Анриның гына кыяфәте ошамады. Авызын турсайтып, мыекларын кабартып йөри бирә. Юньләп сөйләшеп тә булырлык түгел үзе белән...

Ахыр чиктә егетләрем көйгә килмәс француз белән башкачарак эш итеп карарга булдылар. Берәр тынычрак кафега чакырырга дигән карарга килделәр. Бу тәкъдимне иплән кенә тегенең үзенә дә житкерделәр. Әмма Анри анда-монда барырга дип бер дә атлыгып тормый икән, кафега барудан катгый рәвештә баш тартты. Ләкин ул шунда өчебезне дә гаҗәпләндерерлек тәкъдим ясады: үзе безне кунакка чакырды. Бер шешә француз коньягы да бар, имеш. Авызын буранкалап, бармак битләрен үбеп алып, кулын кош очырган сыман өскә таба чөюенә карагандa, коньягы бик шәп булырга тиеш иде.

Әмма шунда ук бер шарты барлыгын да әйтте: эш турында, бигрәк тә техник-контроль стенд турында ләм-мим сүз катмаска. Чөнки бу мәсьәлә ул хәл итә алудан күптән узган, янәсе. Бу инде алдан ук безнең өметебезне кисеп, коралсызландырып кую иде.

Башка чара калмады, ризалык бирдек. Эштән соң машинага утырдык та яңа шәһәргә китеп бардык.

Иртәме-соңмы, стенд турында барыбер сүз кузгаласына ышана идем мин. Юлда да гел шул турыда гына уйлап бардым. Бәлки шуңа күрәдер, ак диварлары белән ялт итеп торган яңа шәһәргә җил уйнатып килеп җиткәнебезне сизми дә калганмын.

Анри сигезенче катта тора икән. Тәрәзәләре завод ягына караган. Ике бүлмәле гостиницаны хәтерләткән номер. Зәвык белән эшләнгән интерьер.

Анри безгә тәрәзәләр турысына куелган өчпочмаклы өстәл тирәсенә утырыша башларга кушты. Үзе табын хәстәрләргә кереште. Иң элек көл савыты һәм бер пачка сигарет белән шырпы куйды. Чуар этикеткалы фильтрлы сигареты да, хәтта шырпысы да үзләренеке иде.

Аннары лимон алып килде, аны юка гына итеп телемнәргә кискәләде, махсус савыттан шикәр оны сипте. Бер тартма конфет китереп куйды. Тартмасына ярым шәрә хатын-кыз сурәте төшерелгән иде.

Тик шуннан соң гына Анри каз йомыркасына охшашлы озынча-йомры фужерлар белән бер шешә коньяк алып килеп өстәл өстенә куйды. Чуар этикеткалы коньяк шешәсен күргәч, Даниал, бармагы белән этикеткага ымлап «1748» дигән санны күрсәтеп, миңа сораулы караш ташлады.

— Фирмалары шул елны оешкан, — дидем мин.

Квартираны күздән кичереп утырган Николайның карашы түрдәге өстәл өстендә торган хатын-кыз портреты янында туктап калды. Даниалга да, кара әле, дип мөрәҗәгать итте. Мин шунда ук таныдым: Каролина рәсеме иде бу.

Ул арада икенче бүлмәгә кереп киткән хуҗа да чыкты. Безнең өчебезнең дә портрет белән кызыксынуыбызны күреп:

— Минем хатыным Каролина, — диде ул. Үзе эш белән мәшгуль. Коньякны ачты. Аннары фужерларга бармак илле итеп кенә коньяк койды. Үзе һаман сөйләшүен белде. — Каролинаны сезнең шефыгыз мсье Кутузов күреп белә, — диде ул, мыек астыннан гына елмаеп. — Хәтта аның белән танцевать иткәне дә бар...

— Анри, — дидем мин, өй хуҗасын бүлеп. — Әйдәгез, хәзер үк үзенә бер төрле сделка ясап куйыйк әле...

— Рәхим итегез, мсье Кутузов!...

— Сез мине алай, рәсми тонда, мсье Кутузов дип түгел, бәлки менә минем яшь коллегаларым кебек, исемем белән генә атагызчы.

Француз дустанә елмаю белән балкып:

— Була ул, — диде.

Һәм ул шунда ук, бөтенләй акцентсыз диярлек, минем исемем һәм әтием исеме белән дәшә башлады.

Француз бая башлаган фикерен дәвам итте: хатын-кыз турында гәп сата башлады. Ул сүзне шактый еракта уратып, сәяси мәсьәләләргә бәйләп алып китте. Америкалылар, мәсәлән, Европаның бик күп илләреннән үзләренә инженерлар, фән-техника кадрлары җыялар икән. Моны алар «акыл аулау» дип атыйлар. Һәм бу нәрсә бизнесменнар өчен иң эффектлы, иң файдалы булып санала икән. Чөнки укытасы-нитәсе юк, рәхим итеп, шунда ук эшкә җигә дә башла. Ул кармакка бары тик французлар гына капмыйлар — океан артына китмиләр икән.

Мсье Шавалье моны үзенчә аңлатты.

— Безне Ватаныбызда өч төрле нәрсә тота: туган телебез, тәмле ашсуыбыз һәм... хатын-кызларыбыз.

Хуҗа беренче тостны да үзе тәкъдим итте.

— Әйдәгез, хөрмәтле кунаклар, бу тостны да кешелекнең яртысы, иң гүзәл икенче яртысын тәшкил иткән хатын-кызлар өчен күтәрик...

Мин икенчерәк тост көткән идем. Дуслык яки анда хезмәттәшлек хөрмәтенә эчәрбезме әллә дип уйлаган идем. Нишләмәк кирәк, хуҗа тәкъдименә кушылмыйча чара юк.

Анриның коньягы чыннан да әйбәт иде. Хәер, аның шундый икәнлеге шешәне ачу белән таралган үзенчәлекле татлы исеннән үк сизелгән иде.

Аякларыбызны сузып җибәреп, иркен, йомшак креслоларда иркенәеп утырабыз. Авызда сигарет. Ачып куелган тәрәзәләрдән, челтәр штораларны селкеткәләп, саф һава кереп тора.

Сүз ияра сүз китеп, инженерларга, белгечләргә кайсы илләрдә ничегрәк белем бирелүе турында әңгәмә кузгалды. Анри Франциядә укыган. Әмма патроннары аны (сәләтле дип булса кирәк) Англиягә «Бизнес Скул» дип йөртелә торган бизнесменнар мәктәбенә практикага җибәргән. Андый мәктәпләр турында минем дә ишеткәнем бар иде. Ул махсус уку йортларында, кагыйдә буларак, менеджерлар, ягъни индустриянең төрле сферасында эшли һәм идарә итә алырлык яшь инженерлар янадан ике ел дәвамында өстәмә белем алалар. Шул дәвер эчендә алар фән-техника революциясе проблемаларын, идарә итү теориясен, җитәкчелек итүдә социаль һәм психологик аспектларны, кул астында эшләүчеләрне материаль стимуллаштыру, өр-яңа идарә итү техникаларыннан кибернетиканы, электрон-хисаплау машиналарын, телемеханиканы эш процессында файдалану, шуның өстенә әле экономия, хокук, өлешчә социология фәннәрен дә өйрәнәләр. Ә риторика — аерым бер фән, ди. Чөнки булачак бизнесменга еш кына цех начальнигы яки берәр зуррак фабриканың баш инженеры ролендә, хуҗалык ситуацияләренә бәйләп, вәкаләтле комиссия алдында ун минут чамасы чыгыш ясарга туры килә икән. Шул ун минут эчендә ул производстводагы хәлне җентекләп анализларга һәм, теге яки бу авыр хәлдән чыгу юлын сайлап, конкрет карар кабул итәргә тиеш. Риторика занятиеләре аеруча

жанлы үтәләр икән. Чөнки булачак бизнесменның чыгыш ясавы видеомагнитофонга язып алына һәм бөтен коллектив белән тикшерелә. Кабул иткән карары дөресме? Фикере ачык әйтелгәнме? Үз-үзен ничегрәк тоткан? Тышкы кыяфәте, халәте — барысы да исәпкә алына икән.

Анри, сүз уңаенда, бездә кадрлар хәзерләү системасында булган кайбер кимчелекләрне дә тәнкыйтьләде. Бу өлкәдә алга киткән чит илләрнең практикасыннан шактый ышандыргыч, шул ук вакытта бик гыйбрәтле мисаллар да китерде.

Мсье Шавальеның сүзендә өлешчә генә хаклык та бар. Бездә хәзергә оештыру сәләтләре, зур потенциаль мөмкинлекләре булган чын мәгънәсендәге җитәкчеләр хәзерләүдә шактый кимчелекләр яшәп килә әле. Кызганычка каршы, кадрлар хәзерләү мәсьәләсе белән турыдан-туры шөгыльләнүче югары уку йортларында кешеләр белән эшләү сәнгатенә тиешенчә өйрәтмиләр. Кадрлар хәзерләү шаблонга, уку планнары стандартка, диплом өлешләре схемага әверелеп китә.

Әңгәмә, нинди генә виражлар ясаса да, әкренләп барыбер фән-техника революциясе, фәннең турыдан-туры җитештерү көченә әверелә баруына әйләнеп кайтты.

Ул арада кунакчыл Анри бушап калган фужерларга яңадан коньяк салды. Бу юлы инде тост-фәлән әйтмичә генә күтәрдек. Табын яңы гөрләп тора. Белмим, нилектән шулайдыр, соңгы елларда мин үземне еш кына бер фикердә тотам: теге яки бу күренеш инде бер тапкыр булган, хәзер яңадан кабатланган сыман тоела башлый.

Менә бу гөрләп торган табынны да минем инде күргәнем бар, шушындагы кебек бәхәсләрне дә ишеткәнем бар сыман булып тоела башлады. Әлбәттә, бар...

«Шеф» дип, минем өчен җаннарын бирергә әзер торган яшь коллегаларым Горькийдан килгәч булгалый иде андый әңгәмәләр. Туп-туры минем люкска килеп төшкәннәр иде алар. Николайга диванны биреп, Даниалга өстәмә койка куйдырып, өч буйдак бергә яши башлаган идек. Ял һәм бәйрәм көннәрендә яки эштән соңармыйча кайтылса, безнең номер гөр килеп торган «штабка» әверелә торган иде. Кешедән арынып торган чагыбыз булмады. Николай белән Даниал аркасында күп кенә талантлы яшь инженерлар, кызыклы кешеләр белән таныштым. Ду-у килеп яшәгән идек, әңгәмә, бәхәс кебек нәрсәләр бер генә минутка да тынып тормас иде. Нинди генә темалар, нинди генә проблемалар тикшерелеп хәл ителми иде анда!..

Гомумән, яшьләр белән булганда, алар белән аралашып яшәгәндә үзем дә җилкәмнән ун-унбиш ел гомерне алып ташлагандай хис итәм. Чөнки алар соклана, гаҗәпләнә, хәйран була беләләр. Ә андый кешеләргә ялкынланып кабыну, яну хас.

Хәзер дә сүз фән-техника өлкәсендә әледән-әле булып торган революцион сикерешләр турында бара. Әмма йорт хуҗасы бу фикер белән килешергә теләмәде. Мин инде хәзер гауга чыгар, авызын чамалап ачмаган французны әләп алып селкеп салырлар дип уйлаган идем. Әмма мин көткәнчә булмады. Николайның да бу мәсьәләгә карата шактый үзенчәлекле карашы бар икән.

— Мсье Анри, — дип башлады ул, тәмәке көлен кагып төшергәннән соң, — андый тойгы, андый тәэсир вакыты белән миндә дә булгалый. Андый тойгы, минемчә, үзебез яшәгән һәм моңарчы күрелмәгән гаять зур ачышларга бай эпохабызның «эченнән» торып караганга гына шулай тоеладыр... Йөз елдан соң үткән юлыбызга күз төшерә алсак, шик юк, фән-техника өлкәсендә без бары тик «революцион сикерешләр»не генә күрер идек...

— Бик примитив фикер йөртәсез кебек... — Бу сүзләрне кулларын күкрәк турысында кушырып утырган Даниал әйтте.

Барыбыз да аның ягына борылдык. Николай да җавапсыз калмады.

— Бәлки, — диде ул, әллә ни исе китмәгән кыяфәт белән. — Шуңа күрә дә мин ул сүзләрне аксиома дип тәкъдим итмим.

— Дөрес, — дип куйды Анри, үз чиратында салпы якка салам кыстырып, — Николай хаклы. Яңа фикер әйткәндә стандарт рецептлар булмый... Килешмисез икән, рәхим итегез, теләгән кадәр коррективалар кертә аласыз...

Даниал гадәттәгечә ирен кырыйлары белән генә елмаеп куйды. Сизелеп тора, аңа бу сүз көрәштеру ошый иде.

— Һәрхәлдә, техника политикасы турында фикер йөрткәндә интуиция һәм гипотезалар белән генә эш итүдән сакланырга кирәк. Андый вакытта дипломатия дә начар киңәшче... Шулаймы, Имам Хисамович?

Бу инде Даниалның мине дә сүзгә чакыруы иде.

— Карап-карап торам да, Николай, шактый нык төрттерде бит әле бу синңа...

Барысы да елмаештылар. Әмма Николай да бетте-бетте, әйттем исә кайттым дип кулын күтәрүчеләрдән түгел.

— Төрттерсен!.. — диде ул, Даниал ягына кулын селтәп. — Андый төрттерүләрне генә күп күргән без. Андый гына төрттерүләргә карата миндә хәзер иммунитет барлыкка килгән...

Ул арада сүз кисәк кенә борылыш ясады: егерменче гасырның икенче яртысындагы ачышлар, галимнәрнең тоткан роленә күчте. Бу мәсьәләгә карата да Анриның үз фикере бар икән. «Коллектив иҗат» дигән нәрсәне бөтенләй кабул итә алмавын ачыктан-ачык әйтте дә салды. «Фәнни ачыш», «фәнни иҗат» кебек сүзләр бары тик бөек исемнәр белән бәйле булуын исбат итә башлады.

— Йөзләгән урта кул композиторлар бергә җыелып «Патетик соната» кебек әсәр иҗат итә алмаган кебек, сәләтсез галимнәр дә, урта кул инженерлар да әллә ни кыра алмыйлар, — диде ул, үзенең хаклы икәнлегенә нык ышанган кеше сыман.— Тулы мәгънәсендә зур ачышлар өчен Коперниклар, Галилейлар, Эйнштейннар кирәк булгандыр...

— Гафу итегез, мсье Анри... — Тагын Даниал сүз алды. — Әгәр дә мөмкин булса, бер сорау бирер идем...

Француз гадәттәгечә итагатьле:

— Рәхим итегез, мсье Даниел.

— Хәер, сез инде ул сорауга өлешчә җавап та бирдегез кебек...

— Нинди сорау иде ул?

— Мин сездән, мсье Анри, ниндирәк лидерны өстенрәк күрәсез? дип сорамакчы идем. Шеф — диктаторнымы, әллә шеф — киңәшченеме?

— Талантлы диктаторны, — диде Шавалье, күзен дә йоммыйча. — Андый шефлар үз-үзләренә нык ышанучан, кыю-катгый һәм авторитетлы булалар. Иң яратмаганым — үз фикере, ныклы карашы, ачык идеясе булмаган кеше.

— Бу фикерегезгә мин дә кушылам, — дип дәвам итте Даниал. — Әмма коллегиаль хезмәтне бөтенләй инкарь итеп ташлавыгыз белән һич килешә алмыйм.

— Анысы сезнең эш. Әмма мин үз фикеремдә калам. — Анри аңгәмәдәшенең йөзенә текәлеп дәвам итте. — Безнең, француз халкының «Икәү булганда өрәк күренми» дигән мәкале бар. Һәрбер ачыш, зурмы ул, кечкенәме, иң элек бер кешенең, аерым бер шәхеснең башына килә... «Ачыш» сүзен «илһам» белән дә алыштырып булыр иде. Илһам ул тиз ясаган расчет, дигән Наполеон.

Сизелеп тора, Даниалның да тиз генә бирешәсе килми.

— Алайса, коллектив премияләр, гыйльми дәрәҗәләр бирелүен ничек аңлатырсыз? Минемчә, фән-техника революциясе чорында коллегиаль иҗатны инкарь итү дөрес булмас. Чөнки хәзер фәнни эшнең характеры торган саен үзгәрә бара, аерым шәхесләрнең, нинди генә акыл

ияләре булсалар да, рольләре торган саен кими... Сез ничек уйлыйсыз, Имам Хисамович? Дөрес сукалыйммы?

— Тукта әле, Даниал, — дип сүзгә кушылды Николай. — Тотасың да һаман мөрәҗәгать итәсең. Ул бит сиңа кешеләр чакырган саен чыгып баш июче артист түгел...

Шаулап көлешеп алдылар. Әмма өй хуҗасы Даниал куйган сорауны җавапсыз калдыруны килештермәде, ахрысы. Башын кыңгыр сала төшеп, коллегасына таба борылып утырды.

— Коллектив премияләр, гыйльми дәрәҗәләр, дисез сез, мсье Даниел. Аларга да реаль карарга кирәк. Минемчә, премияләр, гыйльми исемнәр бирү ул теге яки бу фәннең ниндидер дәрәҗәдә үсүен билгеләп үтүнең үзенә күрә төрле формасы гына...

Тагын шаулашып алдылар. Иң бөек ачышлар, табылган законнарның күбесе, кагыйдә буларак, бик очраклы хәлдән туалар, янәсе. Архимед, мәсәлән, үзенең законын ваннада юынганда ача. Ньютонга да бәхет бары тик башына алма төшкәч кенә елмая...

Шулай шау-гөр килеп утыра торгач, төн уртасы җиткәнне сизми дә калганбыз. Дәррәү кубып, Анрига рәхмәт әйтеп, саубуллаша башладык.

«Бик шәп!» дип уйладым мин, авызы ерылган Анрига карап. Алай ук теш үтмәслек чикләвек түгел икән... Климат үзгәрүнең беренче билгесе шушы була күрсен берүк.

Өй хуҗасы безне баскыч төбенә кадәр озата чыкты.



*

* *

Киткәнче Ислам белән тагын бер тапкыр сөйләшеп карарга кирәк иде. Чөнки теге көнне сөйләшкәндә теләгәнемне аңлатып җиткерә алмадым кебек.

Билгеле, мәхәббәткә каршы көрәшүнең, нәкъ тормышка каршы көрәш кебек, мәгънәсезлеген дә, барыбер көткән нәтиҗә бирмәячәген дә белә идем. Шулай да күңелемә җыелганны әйтмичә калыр хәлем юк. Кем белә, бәлки соң түгелдер әле? Бәлки әле уй-хисен, тыелгысыз дәртен басарлык ихтыяр көче дә бардыр үзендә. Һәрхәлдә, шулай булуына ышанасы килә.

Сөйләшергә җае да чыкты. Ислам үзе минем янга килеп, үзләрен аэропортка кадәр илтеп кую өчен машина сорады.

— Самолетыгыз кайчан китә? — дигән булдым мин, төп сүзгә керешү өчен җай эзләп.

— Кичке сәгать дүрттә.

— Яхшы. Алайса, үзем озатып куярмын.

Ләкин Ислам катгый рәвештә минем тәкъдимемне кире какты.

— Кирәкмәс, — диде ул. — Хәзергә Ләйләнең сиңа күренәсе килми. Шулай ук мин дә каршы...

— Димәк, бергә китәргә булдыгыз?..

— Әйе.

— Алай. Алайса, рәхәттән бигрәк михнәтне күбрәк күргән Вәгыйз яңадан бәхетен югалта булып чыга... Күрәләтә торып алдана. Эх-х, Ислам! Кешене алдалавы кыен эш түгел. Бигрәк тә Вәгыйз кебек беркатлы, Вәгыйз кебек ышанучан кешене...

— Аның тулы мәгънәсендә кеше булуына шигем бар... — диде ул.

— Каян алып әйтәсең аны?

— Сиземләвем буенча.

— Интуиция алдаучан була. Бәлки кеше сүзенә карап андый ялгыш фикергә килгәнсең? Әмма мин гайбәт-информацияләргә карап кына кеше турында андый фикергә килергә ашыкмас идем.

— Кешене танып-белү өчен күп кирәкми.
— Бу фикерең белән дә килешмәс идем. Аннары син аның үткәне белән дә бераз кызыксыныр идең... Мин үзем, мәсәлән, егылганны түбәләү ягында түгел. Егетлек булмый ул...
— Егылган түгел ул. Тумыштан шуышып-сөйрәлеп йөрүче зат...
Бу сүзләре белән нәрсә әйтергә теләгәндер Ислам, ул кадәресен төшенмичәрәк калдым. Авызымнан бары тик «аяусыз син!» дигән сүз генә ычкынуын тоеп калдым.
Ислам бүтән сүз куертып тормады, җәһәт кенә өс-башын алыштырды да каядыр чыгып китте.
Сораган вакытына машина җибәрдем. Илтә барган шофер аларның үз рейслары белән нәкъ күрсәтелгән сәгатьтә Новосибирск шәһәренә очып китүләре турында кайтып әйтте.

## 8

Искәрмәстән генә телефон шалтыравыннан сискәнеп киттем. Трубканы кулыма алдым.
— Әй-йе!..
Генеральный директор икән.
— Тыңлыйм, Леонид Борисович!
Тавышы кырыс. «Привет» дип кенә исәнләшкәндәй итте дә сүзгә кереште.
— Мине «Франц-Пуатвен» корпорациясе вәкиле белән арагызда чыккан низагның ахыры кызыксындыра...
— Ахыры нәрсә белән бетәсен хәзергә үзебез дә белмибез, Леонид Борисович. Ул бит алай ансат кына эшләнә торган эш түгел.
— Ә менә мин ул скандалның нәрсә белән бетәчәген чак кына төшенә башладым кебек. Тиздән, бик тиздән ифрат та ямьсез-чиле бер хәлдә калачаксыз...
— Каян алып әйтәсез аны?
— «Франц-Пуатвен» корпорациясе яңадан аваз салды... Сезнең һәм ярдәмчеләрегезнең анкета күчермәләренә кадәр таләп итәләр. Әнә, документларны оформлять итә башладылар инде...
— Нинди максат белән икән?
— Һәрхәлдә, башыгыздан сыйпар өчен түгелдер. — Аннан соң инде генеральный директор сүзен озакка сузмады: — Менә шул турыда сезгә искәртеп куюны үземнең бурычым дип санадым,— диде дә трубканы куйды.
Димәк, хәлләр торган саен җитдирәк төс ала. Леонид Борисович тикмәгә генә шалтыратмас. Мин инде аны беләм: вак-төяк өчен генә болай итми торган иде ул. Эшлекле, үзен яраттыра, ихтирам иттерә белә торган җитәкче. Мин Чаллыга кайтканнан бирле монда шактый җитәкчеләр алышынырга өлгерде. Беренче авырлыклар, кыенлыклар туура шиккә төшкән, төшенкелеккә бирелгән түрәләрнең күбесе бу тирәләрдән тизрәк шылу ягын карадылар. Аларга алмашка Леонид Борисович кебек дәвер колачын күрә, заман сулышын һәм бүгенге көннең динамикасын тоя белгән кадрлар килде. Әйе, зур ихтыяр көченә ия ул. Шуның өстенә абруе, дан-шөһрәте дә бар. КамАЗга килде дә (үзен бер дә СССР автомобиль транспорты министры урынбасары дип тормады) җиң сызганып эшкә дә кереште. Яңа директорның шунда ук бер әйбәт ягы ачылды: нинди генә яңалык турында ишетсә дә, шунда ук кызыксына, яңалыкның асылына төшенү, аны производствода куллану ягын карый. Ә яңалыкка мохтаҗлык юк монда. Хәзер монда КамАЗ төзелешендә: «Иң яңа», «иң зур», «иң беренче» кебек сүзләрне атлаган саен ишетергә мөмкин.

Тик менә шул тәвәккәл директорыбызга кинәт кенә әллә нәрсә булды. Техник-контроль стендына безнең тарафтан кертелә торган «корректуралар» нигә аны шул кадәр пошаманга төшерде?

Шунда ук яшь коллегаларны чакыртып алдым. Эшебезнең көе китебрәк торуын әйттем. Яңарак кына Леонид Борисович белән булып үткән әңгәмәнең эчтәлеге белән таныштырдым. Кисәтеп куюын да яшермәдем.

Беренче булып Даниал телгә килде:

— Ит яхшылык, көт яманлык, менә шул була торгандыр инде. — Бу аның кире беткән Шавальены тиргәве иде. — Әни, мәрхүмә: «Тиешсез кешегә иткән яхшылыкның ахыры хәерле булмый аның», — дия торган иде.

Кичекмәстән шул ук минутта Анрины чакыртып алып, күзгә-күз карап, кабат бер тапкыр сөйләшеп карарга булдык.

Бу юлы да Даниал үзенең шиген белдерде.

— Тәмле телебезне әрәм итү генә булмасмы икән?

— Юк, булмас, — дидем мин, аңа каршы төшеп. Сүз уңаенда бүтән чара, башка юл калмавы турында да өстәп куйдым.

Французның бая гына, стендның меңләгән киштә-стеллажларын монтажлаучы электросварщиклар тирәсендә чуалганын күреп калган идем. Әллә ни ерак китә алмагандыр әле, дип уйладым да, алдымдагы усилительнең кнопкасына басып, микрофонга кычкырдым:

— Мсье Шавалье!.. Мсье Шавалье! Сезнең хәзер үк конторага керүегез сорала... Конторага рәхим итегез!

Ике-өч минут үттеме икән, еш-еш сулап, Анри килеп керде. Моңарчы аны эзләүче дә, чакыртучы да юк иде. Бәлки шуңа күрәдер, бу хәл аңар шактый ук сәер булып тоелган булса кирәк.

— Нәрсә бар? Тыңлыйм сезне... Ни булды?.. — диде ул, туп-туры минем өстәл каршына килеп басып.

— Сөйләшәсе бар, — дидем мин, аңар утырырга урын тәкъдим итеп.

— Тыңлыйм сезне...

Сүзнең нәрсә турында буласын белгәч, мсье Шавалье, бүтән хәсрәтегез булмаса, юк белән башыгызны катырмагыз, дигәндәй кулын гына селтәде дә урыныннан ук купты. Әмма автозаводның генеральный директоры белән булып узган әңгәмә турында ишеткәч, сагайды, җитдиләнде.

— Әй-йе! — диде ул, тагын да җитдиләнә төшеп. — Корпорация бошлары белән мин тыгыз элемтәдә торам. Соңгы тапкыр сөйләшкәндә сез кертә торган үзгәрешләр турында яңадан сүз булды. Техник мәгълүматларны гына түгел, ул эшнең кемнәр тарафыннан башкарылуы турында да сораштылар.

— Мсье Шавалье, сүзегезне бүлгән өчен гафу итегез, әлбәттә. Нишләп әле сез «сез кертә торган» дигән сүзләргә аеруча нык басым ясап әйтәсез? Бу эштән сез дә читтә тормыйсыз бит. Без, мәсәлән, сезне ул идеяләрнең, ул технологик камилләштерүләрнең соавторы дип санныйбыз...

Француз минем маневрны шунда ук төшенде, күрәсең, ирен кырыйлары белән генә елмайгандай итте. Әмма күзләре һаман да салкын елтырый иде.

— Хокукларым була торып, башта ук катгый рәвештә каршы төшмәгәнмен, үз ихтыярымны көчләп такмаганмын икән, димәк, нәкъ сез әйткәнчә, бу эшкә бәйләнеше, катнашы бар кеше булып саналамдыр инде, — диде ул.

Аның көйгә килә башлавын күреп һәм уенын-чынын бергә кушып:

— Әгәр дә җавапка тарта-нитә калсалар, ул җавапны бергәләп бирербезме соң? — дип сорап та куйдым.

— Эш алай ук зурга китмәсен иде инде. Әгәр дә андый-мондый хәл булса, шуны белегез: таякның иң юан өлеше минем башка төшәчәк. — Аннары җитдиләнеп өстәде: — Эш урынымны югалтып кына да калмаячакмын, бөтен карьерам чәлпәрәмә килеп җилгә очачак. Бездә бит сездәге кебек бер урыннан чыктың да икенчесенә рәхим итеп барып кердең түгел...

Анри бу сүзләрне ихлас күңелдән әйтте кебек. Һәм без бу әңгәмәне:

— Бераз сабыр итик әле, ни күрсәк тә бергә күрербез, — дип, чын егетләрчә килешү белән тәмамладык.

*
* *

Таратып салынган чертеж-сызымнарын тәртипкә китереп маташа идем, кабинетка Даниал килеп керде.

— Имам Хисамович, сез Анрины күрдегезме әле?

— Юк. Ә нәрсә?

Даниал елмаеп дәвам итте:

— Танырлыгы юк аның...

— Нәрсә булган?

— Асыл кош тоткан диярсең инде менә! Кая басканын да белми. Монтажчылар арасына кереп алган да шаяра, көлә... Куанычы эченә сыймаган кеше кебек кылана.

— Әллә берәр хәбәр алдымы икән?.. — дидем мин, бу үзгәрешне үзебезнең эш белән бәйләп.

— Белмим шул, — диде Даниал. — Алай булган тәкъдирдә ул туп-туры сезнең янга керер иде...

Бу хәл миндә дә кызыксыну уятты. Цехка кергәч күрдем: мсье Шавалье чыннан да эшчеләр төркеме арасына кереп алган да кулларын селтәп-кизәнеп нәрсәдер сөйли, нидер исбат итә. Аны урап алган монтажчыларның авызлары колакларына җиткән.

Гөр килеп торган төркем, мине күргәч, тынып калды. Анри мине шәйләп алды да:

— О-о, мсье Имам Хисамович!.. — дип кычкырып җибәрде һәм, кулларын болгый-болгый, миңа таба килә башлады. Килә килешли үк яңалыгы белән уртаклашты. Бер сүздән барысы да аңлашылды: Каролинасы килгән икән.

Ләкин әйтергә теләгәне ул гына булмаган, үзләренең безгә кунакка килергә теләкләре барлыгын да белдерде.

— Каролина шулай тели, — диде Анри, һаман да рәхәт елмаеп. — Сезнең гаиләгез белән, тормышыгыз белән якыннанрак танышмакчы була.

— Рәхим итегез! — дидем мин.

Анриның сүзе бетмәгән булган икән.

— Тик, зинһар, атап хәзерләнмәгез. Без сезгә бүген үк барабыз, — дип өстәп тә куйды.

Өйне күз алдына китерәм: кунаклар каршыларга әзерме? Һәдиянен эше ничегрәк икән? Кайчанрак кайтыр, эшендә җыелыш-фәлән юкмы икән соң?..

Шунда ук Һәдиягә шалтыраттым. Билгеләнгән ул-бу күренми икән. Тавышы көр иде Һәдиянең. Әмма кичен кунаклар буласын, кунакларның да бик четерекле икәнен белгәч, ничегрәк каршыларбыз икән соң аларны дип, каушабрак калды.

Кичен төп-төгәл сигездә звонок шалтырады. Каролина ишектән керә-керешли үк, күптәнге дустын очраткан сыман, туп-туры Һәдиягә таба атлады һәм аны кочаклап алып, битеннән үбеп алды. Үзе нәкъ күгәрчен кебек гөрләп сөйләнепме-сөйләнә.

Һәдия исә елмаеп башын игәләп, ияген кагып тора. Бер кәлимә сүзен аңламагач, нишләсен соң?

Ул арада Каролина Анри кулындагы төргәктән алып Һәдиягә бөтен дөньяга билгеле «Шанель» дип аталган ислемай сузды. Әгәр дә мондый бүләк Зинаида кулына эләксә, куанычыннан үрле-кырлы сикерер иде. Андый әйберләрне кулына төшерү мәрхүмәнең хыял-максаты иде шул.

Тик Һәдиянең, әнә, әллә ни исе китмәде. Елмаеп, тыйнак-басынкы гына башын ия-ия, үзенең рәхмәтен белдерде.

Каролина мине дә онытмаган.

— Ә монысы, мсье Кутузов, сезгә!.. — дип, миңа да бер төргәк тоттырды. Бүләкне кулыма алу белән тойдым: китаплар.

— Мерси, мадам Каролина! Мерси!..

Нурия белән Һадига да бүләкләр булган. Әмма алар өйдә юк: берсе — пионерлар лагеренда, икенчесе — Кама аръягында дачада. Билгеле инде, Гөлҗиһан апа да өлешсез калмады.

Квартираны бер кат күздән кичергәннән соң, кунаклар чак кына тынычлангандай булдылар. Әмма табын янына утырып, алларына ризыклар китереп куйгач, яңадан ах та вах килә башладылар. Сый-хөрмәтне, әзерләнгән ризыкны күкләргә чөеп мактадылар.

Сүз иярә сүз китте. Мин тәрҗемәче. Күбрәк, җете-яшел күзләрен елтыратып, мадам Каролина сөйләнә. Үз-үзен тотышы ипле-әдәпле. Чын бер ихласлык белән елмаеп-балкып утыра. Барысының да күзләре аңарда.

Анри мыекларын тырпайтып киерелеп утырган да сигарет көйрәтә. Аның да күзләре Каролинада. Сөеп-иркәләп карый. Тикмәгә генә «мәхәббәт таш йөрәкне дә кешелекле итә» димәгәннәрдер шул.

Гөлҗиһан апаның үз хәсрәте иде.

— Ризыкларны яратмадылар, ахрысы...— диде ул, борчылып.

— Ник алай дисең, Гөлҗиһан апа?

— Ник дип, күреп торам ич. Бигрәк тә, әнә теге, нечкә билле чәчбинең ашау рәвешенең бер дә атасы-анасы юк. Ашыйм микән, юк микән дигән сыман, чәнечкесе белән кармаланып тик утыра...

Көлмичә булдыра алмадым.

— Юк өчен хафаланма, Гөлҗиһан апа. Сый-хөрмәтегез, хәзерләнгән ризыкларыгыз ифрат та һәйбәт булган. Рәхмәт сезгә. Ә аларның, үзең әйтмешли, чукып-төртеп утыруларына әллә ни исең китмәсен, ул халыкның бар ашаулары шул.

Әңгәмә барышында Каролина Һәдиянең кайда эшләве белән кызыксынды. Аның мастер икәнлеген белгәч, үзенең хәйран булуын яшерә алмады. Ирләр эшен башкарырга сәләтле, кыю икәнсез, диде, хәтта «батыр» дип атады.

Күпмедер вакыт утыргач, табын яныннан кузгалышып, тәнәфес ясап алдык. Гөлҗиһан апа: «Каячы, табынны яңартыйм әле»,— дип, өстәл янында кайнаша калды. Каролина урыныннан күтәрелү белән яңадан Һәдиягә барып сарылды. Куллары белән ишарәләр ясап нәрсәдер аңлата, нәрсәдер төшендерә башлады. Анри, бераз һава алыштырыйм, дип балконга чыкты.

Мин дә, бер-ике тапкыр тәмәке суырып алу нияте белән, кабинетыма кердем. Шунда мадам Каролина биргән бүләкне кулыма алдым. Һәм бик тә пөхтә итеп, ефәк тасма белән бәйләнгән төргәкне чишә башладым. Аннан Шавалье эшли торган фирманың тарихы бәян ителгән китап килеп чыкты.

Кабат шау-гөр килеп өстәл янына утырыштык. Әмма бу юлы әңгәмә баягы кебек үк җанланып китә алмады. Шунлыктан әллә ни озак юанмадык. Чәйдән соң кунаклар китәргә җыена башладылар.

Каролина, яңадан күгәрчен кебек гөрләп, Һәдияне иңеннән кочып,

битләреннән үпте. Анри да, үз чиратында, Һәдиягә дә, Гөлҗиһан апага да кат-кат рәхмәт белдерде.

Шактый соң иде инде. Шунлыктан мин кунакларны трамвай тукталышына кадәр озатып куярга булдым. Урамга чыккач та сүз гел Һәдия турында барды. Каролина Һәдиягә тәмам гашыйк булган иде.

— Менә ул чын матурлык кайда!.. — дип куйды ул. — Рухи гүзәллек, табигый матурлык шундый була ул.

Бу фикергә Анри да кушылды.

— Әй-йе, чын матурлык яклауга да, исбат итүгә дә мохтаҗ булмый...

Трамвай да озак көттермәде.

Без чын дусларча саубуллаштык. Ишекләр ябылды. Кунаклар, кул изәп, китеп тә бардылар. Бу минутта мин үзем генә калуыма чак кына сөенә дә идем. Башымда бер-берсен кысрыклаган уйлар өермәсе бөтерелә. Кеше язмышы, аның бурычлары, аның вәкаләтләре турында уйлыйм...

Кеше туып, тәпи йөри башлау белән дөньяның зурлыгына, галәмнең киңлегенә карап сихерләнә, хәйран кала. Күп тә үтми, ул фани дөньяга үз халкының, туган җиренең бер вәкиле булып килгәненә төшенә башлый. Һәм ул шул мактаулы, бер үк вакытта гаять җаваплы бөек миссияне үз җилкәсенә күтәреп алырга әзер булырга тиеш.

*

*     *

Бүген безнең улыбыз Һади да мәктәпкә барачак.

Без бик дуслар аның белән. Моннан берничә генә көн элек Һади йокларга яткач янына кердем.

— Ничек, улым, үсеп буламы?.. — дип, караваты янына килеп утырдым. Шунда ул минем кулымны нәни куллары белән тотып алды да куенына кысты.

Буш кулым белән рәтләп өстен яптым, аркасыннан сөйдем.

— Тизрәк йокыга китәсе иде, — ди бу.

— Улым, ник алай?

— Иртәгә сине тизрәк күрәсем килә...

Ничек итеп аны сөймисең дә, ничек итеп җылы гәүдәсен кочагына алып кысмыйсың ди!

— Әти!

— Әү, улым?

— Көннәр кая китәләр?

— Нинди көннәр?

— Менә бүгенге көн... Кичәге көн. Кая китәләр алар?

— Һы-ы!.. Көннәр кая китәләр дисең, алайса? Авыр сорау бирдең син, малай. Һәр үткән көн безнең тормышыбызда нәрсәдер калдыра, улым... Үзеннән соң эз калдыра. Син, мәсәлән, тиздән укырга барырсың. Язарга, укырга өйрәнерсең. Менә шулар сиңа үткән көннәр бүләге булачак алар... Без дә тиздән заводны төзеп бетерәбез. Тиздән машиналар чыгара башлыйбыз. Аларның барысын да безгә яңа туган көн булып узган гомер бирә...

Гадәттәгедән иртәрәк тордык бүген.

Өйдә ыгы-зыгы...

Ниһаять, бар да әзер. Һадины мәктәпкә үзем озатып куярга булдым.

Без урамда. Чалт аяз көн. Нәни улымның өстендә мәктәп формасы. Аякларында ялт-йолт итеп торган яңа ботинкалар. Кулында чәчәк букеты.

Юл бирегез! Туар көннәр кешесе килә...

Ул түгел, мин дулкынланам.

— Эти... Эти дим...
— Нәрсә, улым?
— Ә ник бик озак итеп, үскәнче укыйлар?
— Шулай кирәк, улым.
— Тиз генә булмыймы?
— Булмый, улым. Уку ул зур нәрсә. Үскәнче дә укырсың, үскәч тә укырга туры килер әле, улым. Гомер буе укыганда да бик таманга килә торган чорда яшибез...

Хәзергә әле анлап бетерми. Әмма бер нәрсә бәхәссез: янымда туган ил киләчәге, Ватан язмышы атлый...

Нәни улым белем алырга бара. Әмма белем алу гына аз. Бик аз. Баланың тәрбия алуы да шарт. Икесе ике нәрсә боларның. Кызганычка каршы, хәзергә әле бездә бу ике нәрсәне тиешенчә якынайта алу җитенкерәми. Миңа калса, тәрбия бирү белем бирүгә караганда да әһәмиятлерәк. Чөнки тәрбия — кешене кеше итә. Бары тик белем генә алган кешене мин мораль яктан камил, тәмам җитлеккән, һәр яктан өлгергән дип әйтә алмас идем. Гельвецкий: һәркем даһи булып туа, дигән. Әмма дөрес тәрбия алмаган кешегә карата минем шигем зур. Кәкре үскән агачтан туры күләгә көтмә, димәсләр иде аны. Баланы дөрес тәрбияләү — безнең бәхетле картлыгыбыз, начар тәрбияләү — киләчәктәге кайгыбыз, күз яшебез, башка кешеләр һәм бөтен ил алдында гаебебез, дигән сүзләре белән Макаренко бер түгел, мең тапкыр хаклы.

Өлкән абыйлар, апалар! Юл бирегез!.. Урам буйлап җиде яшьлек гражданин атлый. Зур тормышның ишеген ачар өчен мәктәпкә бара ул.

Менә мәктәп. Аның ишегалдында — мәхшәр. Балаларның кулларында чәчәкләр, чәчәкләр... Балалар үзләре дә чәчәкләр төсле. Ата-аналарның куанычы йөзләренә чыккан.

Баскыч төбенә мәктәп директоры чыгып баскан. Яшь буынны каршыларга дип чыккан ул. Аның тәбрикләү сүзләре яңгырый...

Ниһаять, беренче звонок.

Нәни Һади артыннан кул болгап калам. Хәерле юл, улым! Хәерле юл...

*

* *

Бар борчылганым Вәгыйз иде. Аны искә төшергән саен кай җиремдер әрнеп, сызып куя. Минем тормышыма шакып-нитеп тормыйча, өермә кебек бәреп кергән бу язмыш өчен мин һич кенә дә битараф булып кала алмыйм.

Әйе, кайчандыр тормыш юлында сөрлеккән, җәбер-кимсетелүне, рухи газапларны күп кичергән һәм хәзер дә искәрмәстән генә зур югалтуга дучар булган ул кешенең язмышы мине бик нык борчый. Аның турында еш уйлагангамы, Вәгыйз инде минем өчен чит-ят кеше түгел иде.

Ахыр чиктә түзмәдем, очрашырга, һич югында, сөйләшеп карарга кирәк дигән фикергә килдем. Туп-туры өенә барырга тартындым. Иң элек телефон аша сөйләшергә булдым.

Тырыша торгач, таптым үзен. Мин иканне белгәч, бәлки сөйләшергә дә теләмәс, сөйләшкән очракта да шактый ук ачы сүзләр әйтер, дип юкка гына хафаланганмын икән. Алай булмады. Тавышы көр, хәтта нәрсәгәдер сөенә дә иде кебек.

— Вәгыйз туган, саумы! Төнгә каршы мин борчый идем...— дип башладым мин.

— Таныдым, Имам Хисамович. Тавышыгыздан ук таныдым...

— Тормышлар ничек соң?

— Хәзергә ярый...

— Мәрхәбә түти исән-иминме?

— Ул да бер көйгә генә йөри. Сыкранса да кыймылдый...

Күреп, сөйләшергә теләвемне белдердем. Үземне, ничектер, гаепле кеше кебек хис итүемне әйттем.

— Юкка хафаланмагыз, Имам Хисамович. Беркемне дә гаепләмим... Барысы да үз урынында: ким дә түгел, артык та түгел. Киткән икән, әйдә, китә бирсен. Димәк, шулай кирәк булган. Аның шулай буласы көн кебек ачык иде. Үзем гаепле... Барысына да бары тик үзем генә гаепле. Тормышны аны, Имам Хисамович, хыянәттән башламыйлар... Бигрәк тә гаилә тормышын...

Вәгыйз сөйләде дә сөйләде:

— Бәлки, Имам Хисамович, үкенәсеңме? дип сорарга телисездер. Үкенәм. Бик үкенәм. Элегрәк уйламыйча эшләгән нәрсәләрем өчен үз-үземне үлгәндә дә гафу итәсем юк.

Соңгы сүзләреннән соң минем аны чак кына тынычландырасым, юатасым килеп китте. Вакыт үзенекен итәр... Вакыт дигән нәрсә мәрхәмәтсез дә, шулай ук дәвалаучы да дип әйтәсем килде. Әгәр дә очрашып, күзгә-күз карашып сөйләшкән булсак, һәрхәлдә, сүз башкачарак булыр төсле иде. Уен-көлкесеннән дә баш тартмаган булыр идем. Бер кыркылганга карап сарык та гомере буе шәрә йөрми, дип бәлки төрттереп тә куйган булыр идем. Әмма андый сүзләр телефон аша сөйләнмиләр. Үзең дә сизмәстән кеше күңеленә мәңге төзәлмәс яра салуың бар.

Бераздан икебез дә, сүзләребез беткән кешеләр сыман, тынып калдык. Вәгыйз шалтыратуым өчен кабат рәхмәтләр әйтте, шулай шалтыраткалап торуымны үтенде.

Саубуллашып телефон трубкасын куйгач кына әйтергә җыенып та сүзләремне әйтми калган кеше сыман хис иттем үземне. Һич югында, Мәрхәбә түтигә сәлам әйтәсе калган, дип уйлап алдым.

Кайтырга чыктым. Шактый соң булуга да карамастан, олы урамда җилдәй җитез автомобильләр, автобуслар. Ыгы-зыгы, шау-шу. Беренче очраган тынычрак тыкрыкка борылдым. Чак кына хәл аласы, саф һава сулыйсы килеп китте. Вәгыйзнең: «Тормышны аны хыянәттән башламыйлар», дигән сүзләре әле дә булса колак төбемдә яңгырап тора. Бу сүзләр күңел түренә уелып калды. Тавышы көр булса да, бәхетсез иде ул. Кайчандыр нәрсәдер көтеп, нәрсәдер өмет итеп, янып-көеп яшәгәндә ул күп тапкырга бәхетлерәк булгандыр, дигән уй килде башыма. Билгеле, шулай булгандыр. Чөнки Вәгыйз ул вакытта гашыйк иде. Иң изге, иң гади, кешенең рухи гүзәллеген чагылдыручы хис белән янып, рәхәт-куанычлы чын юану татып яши иде.

Кеше тормышы, кеше язмышы шулай яратылгандыр инде. Ул һәр вакытта да нәрсәдер көтә, өмет итә. Гүя ниндидер бер ак пароход килеп чыгар да, кеше шуңа утырып бик күп еллар буе хыялланып, зарыгып көткән максатына юл алыр сыман тоя. Әмма еллар үтә тора... Һәм кеше бары тик шунда гына үзенең юк белән хыялланганына, бөтенләй юкка ашкынганына төшенгәндәй була. Бакса, авызы ипигә туймыйча, менә була, менә морадыма ирешәм дип өметләнеп-ашкынып, ак пароход көтеп уздырган яшьлек еллары иң бәхетле, иң куанычлы еллар булган икән ләбаса! Бу хәлне, аянычка каршы (бәлки бәхеткә каршыдыр), бары тик чигәләрне бәс сукканнан соң гына төшенәсең икән. Һәм шул, менә була, тиздән бар да рәтләнер дип йөргән яшьлек елларыңны юксынасың, өзгәләнеп сагына башлыйсың икән...

Шундый уйларга бирелеп, шактый ук кәефем кырылып, кайту ягына борылдым.

Анри Шавалье безнең өчен, чын мәгънәсендә, авыртмаган башка тимер тарак булды. Тагын яңа хәбәр: «Франц-Пуатвен» корпорациясеннән комиссия килүе көтелә. Бу турыда да генеральный директор шалтыратып әйтте. Тавышы шактый ук борчулы иде аның. Техник-контроль стендын тапшыру-кабул итү процедурасы шау-шусыз, бәла-казасыз гына узса ярар иде, дип борчыла иде булса кирәк.

Стендны монтажлау тәгәлләнеп килә. Тартышсак тартыштык, барыбер үзебезчә иттек. Монтажчы-электриклар бригадасы билгеләнгән графикны узып эшли. Әйдә, тизрәк тәгәлләнсен иде инде. Бу четерекле эштән тизрәк котылып, үзебезнең төп эш — комплексның баш конвейеры белән генә шөгыльләнәсе иде.

Мин тагын бер хакыйкатькә төшенгәндәй булдым: мсье Шавалье тикмәгә генә безнең белән кызыксынмый, нәрсәдер ачыклый, үзе өчен бик әһәмиятле нәрсәнең асылына төшенергә, һаман да әле сер булып кала биргән чынбарлыкны аңларга тели иде.

Баштарак, яшерен-батырын түгел, Анриның искәрмәстән генә «чәнечкеле» сораулар биреп куюы минем җен ачуларымны чыгара иде. Нәрсә кирәк аңарга? Нигә дип әле ул эш яки минем белән генә кызыксынмыйча, минем ничек яшәвем, хәтта гаилә тормышыма да тыкшына? Һәдия, балалар, хәтта Гөлҗиһан апаның нигә кирәге бар аңар?

Бездә кунакта булганның икенче көнендә бугай, тагын бер сәер сөйләшү булып алды. Минем янга кабинетка керде дә: «Чоу!» дигән булып кул күтәреп кенә исәнләшкәннән соң, алданган яки ышанычы акланмаган кеше сыман, йөзенә канәгатьсезлек кыяфәте чыгарып, тезә дә башлады.

— Пардон, Имам Хисамович... Әгәр дә хак булса, балалар да, шулай ук теге, без күргән карчык та сезнең әниегез булмаган ич... Барысы да чит кешеләр икән ләбаса...

Мин җавап бирергә ашыкмадым. Чыннан да нәрсә диярга соң? Шулай ук аның соравын җавапсыз калдырырга да ярамый иде.

— Анри... — дидем мин әллә ни исем китмәгән кыяфәт белән. — Бу мәсьәлә сине шул кадәр кызыксындырамы? Синең өчен ул бик әһәмиятле нәрсәмени соң?

— Шулай да кызык!..

— Алайса, тыңла. Әйе, ул балаларның әтисе мин түгел. Әмма синең «чит кешеләр» дигән сүзең белән килешә алмыйм. Чит кеше балалары юк ул. Балалар чит кешенеке була алмыйлар. Шулай ук аналар карчыклар да чит кешенекеләр түгел... Балалар да, аналар да кешелек өчен бик изге нәрсәләр. Аларны беркемнең дә чит итәргә хаклары юк.

Шул сөйләшүдән соң ике-өч көн үттеме икән, яңадан минем яныма кергән бу.

— Хөрмәтле Имам Хисамович,— дигән булды, шактый ук төчеләнеп. — Каролинаның бер үтенече бар сезгә...

— Шулаймы?.. Бездә кунакның теләге изге нәрсә булып санала. Ягез әле, гүзәлләрнең гүзәле Каролинаның да теләген тыңлап карыйк.

— Ул сезнең телдә берәр кинофильм яки берәр спектакль-фәлән күрергә тели...

— Була ул! — дидем мин, бер дә исем китмәгән кыяфәт белән. Ә үзем эчтән генә уйлап куйдым: нәрсә күрсәтергә соң аларга? Бездә татар артистларының концертлары еш була. Шулай ук Чаллының үзендә дә халык театры бар. Әмма аларга ниндидер гадәти булмаганрак нәрсә күрсәтәсе иде бит. Моның өчен, әлбәттә, Казан белән элемтәгә кермичә булмастыр кебек иде.

Мин шунда ук Казанга шалтыраттым. Иң элек Татар дәүләт академия театры белән сөйләштем. Анда яңа сезонны ачып җибәрергә хә-

зерләнәләр генә икән әле. Минем белән сөйләшкән администратордан Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры турында сораштырдым. «Анда иртә дә, кичен дә «Шүрәле» балеты булачак», — диде ул.

Бик күп чикләрне кичеп, дистәләрчә илләрнең тамашачыларын таңга калдырган бу балеттан да кулайрак әсәрне табарга мөмкинме соң?

Шунда ук опера һәм балет театры белән тоташтыруларын үтендем. Өзлексез шалтыратып бимазалаудан кәефе кырылганга охшаган хатын-кызның: «Театр тыңлый», дигән тавышы ишетелде. Минем Чаллыдан, КамАЗдан икәнлегемне белгәч, әлеге дорфа-кырыс тавыш нәфисләнә төште. Билет яклары белән кызыксындым. Авыррак икән ул мәсьәлә. Шулай да КамАЗ кешеләре өчен бронь белән калдырылган урыннардан булса да өлеш чыгарырга мөмкин икән. Дүрт билетка заявка алды. Рәтләренә кадәр әйтте.

Калганы бик җиңел эшләнде. Аэропортка шалтыратып, Казанга һәм бүген үк аннан кире кайту рейсларын белештем дә самолетка билетларга заказ бирдем.

Бәхеткә каршы, Һәдиянең дә буш вакыты туры килде. Шулай итеп көтмәгәндә-искәрмәгәндә, Казан тикле Казанга барып спектакль карап кайтырга туры килде.

Һәм менә тагын көтелмәгән яңалык. Эш белән мәшгуль идем. Туган авылым Гәрдәледән совхоз директоры килеп чыкты. Йомыш белән. Тагын ярдәм кирәк үзенә. Салам парландыру өчен өстәмә бункерлар куйганнар да табаклы металл таба алмыйча иза чигәләр икән. Булышырбыз дип вәгъдә иттем. Әмма килүенең төп сәбәбе (үзе әйтүенчә) мине кунакка чакыру икән. Бүген кичен авыл культура йортында гадәти булмаган мәҗлес оештырыла ди. Кичке алтыда авылда булырга ризалыгымны алып китеп барды.

Аның артыннан ук Анри килеп керде. Керде дә, тавышын уйнаклата төшеп, сүз башлады бу.

— Хөрмәтле Имам Хисамович!.. Бәхет кошым Каролина килде. Сезне бүген кичкә үк кунакка чакырырга дип атап килдем. Мадам Һәдия белән, әлбәттә. Күрсәгез, ах-х! итәрлек Париж күчтәнәчләре дә бар...

— Гафу ит, Анри, бүген булмый,— дидем мин.

— Нигә булмый?..

Мин кабат гафу үтендем дә туган авылыма кайтырга вәгъдә бирүем турында әйттем.

Мсье, нәрсәдер исенә төшерергә теләгән кеше сыман, чак кына уйланып торды һәм әйтә салды:

— Имам Хисамович... Әгәр дә мөмкин булса, безгә дә авылыгызны күрсәтегезче. Үтенеп сорыйм сездән.

— Соң, рәхим итегез, — дидем мин. — Тик сез кунаклар көтәсез бугай бит.

— Сез булмагач, ул мәҗлес кичереләчәк. Сезнең хөрмәткә иде ул, Имам Хисамович.

— Киттек, алайса, бергәләп.

Көннәр тәмам кыскарды. Без юлга чыкканда гына якты иде әле. Хәзер инде, әнә, тулган ай калыкты. Тирә-юньне саргылт яктылыкка манчып, гаҗәеп зур тизлек белән машинага ияреп бара. Урман куерган урыннарда гына күздән югалып торгалый ул.

Безнең «Волга» җил уйнатып алга ыргый. Туган авылыма кайтып барам. Ниндидер сихри бер көч йөрәкне ешрак тибәргә мәҗбүр итә. Туган як! Шушы сүзне телгә алу да күңел түрендә иң якты тойгылар өермәсен, хисләр давылын кузгату өчен бик җиткән.

Урман бетте. Юлның як-ягында игe-чиге күренмәгән киңлек. Иген басулары болар. Әле кайчан гына монда күкрәп арыш үсеп утыра иде. Ә хәзер игене җыеп алынса да, ни өчендер җире сөрелмичә калдырыл-

ган. Ай яктылыгыннан басу кинлекләре алтын йөгертелгән сыман булып күренә.

Мотор бер көйгә генә гөрелди. Машинаның тигез тавышына охшап, күңелдә әкрен генә истәлекләр агыла...

Бу юл миңа бик яхшы таныш. Әти-бабаларым сөртенмәгән ташлар бик сирәктер бу юлларда. Миңа да күп тапкырлар үтәргә туры килде бу юлдан. Беренче тапкыр үткәндә сигез яшьләр чамасындагы ялан аяклы бер малай идем. Әле дә булса хәтеремдә, кызу көн иде. Ялан аякларым астында кайнар тузан. Аякларымны шапылдатыбрак бастым исә, табаннарны өтәрдәй булып кызган туфрак, терекөмеш сыман, якякка чәчрәп кала иде.

Ул вакытта әти-әниләрем, Нижегородскига автомобиль заводы төзергә дип, дөресрәге, тамак туйдырып, өс-баш юнәтеп булмасмы дип, бәхет эзләргә киткәннәр иде. Корым-сөремгә баткан, ысланып беткән бәләкәй генә пароходка утырып барган идек. Миңа билет алмадылар. Әти мескеннең акчасы җитмәгән иде. Билет тикшергән вакытта мине, тозлы балык исе аңкып торган галәмәт зур мичкәләр арасына төшереп, өстемнән биштәрләр белән томалап тордылар. Ул хатирәләр кадерле, әйтеп аңлаткысыз якын миңа.

Юллар, юллар! Әгәр дә язмыш дигән нәрсәгә ышансам, мин язмышны иң элек шул юллар белән чагыштырыр идем. Алар бит ил белән, халык белән бергә кайгыны да, шатлыкны да кичереп, һәрнәрсәнең беренче шаһиты да булып торалар. Ә бу юллар богау чыңнарын да, тоткыннарның моң-зарын да күп ишеткән. Юлдан яхшы да атлый, яман да атлый.

Ил өстенә афәт килгәч, бу юллар безнең авыллардан йөзләрчә һәм меңнәрчә кешеләрне сугышка алып киткән. Алып киткән, әмма күпчелеген алып кайтмаган. Юлларның шулай, соңгы юлга озата торган яман яклары да бар шул...

Әй-йе, адәм баласы кайда җан куясын, кайда туфрак буласын белми. Кеше дә, нәкъ очар кош кебек, әҗәлен еш кына туган туфрагыннан, газиз җиреннән читтә таба. Минем әти-әнине генә күр инде! Шушы Чаллыга орынып торган авылда туып-үссәләр дә, Горький каласы туфрагына барып, тигез җирне түмгәк иттеләр. Бәлки шуңа күрәдер, ул шәһәр минем өчен үтә изге, үтә кадерле. Анда әти-әниемнең һәм минем белән тормышның ачысын-төчесен күп эчкән тормыш иптәшем Нажиянең каберләре...

Туп-туры Кәримулла абзыйларга барып төштек. Өйдә карт белән ике нәни бала гына иде. Танышкан-исәнләшкән арада җаен туры китереп, Гарифулла белән килененең кайдалыгы белән дә кызыксындым.

— Партия җыелышы диделәр бугай. Килен дә, менә бу ике күзле бүкәнне ялт итеп кенә кертеп чыкты да, шунда йөгерде...

«Партия» сүзе Анриның да колагына кереп өлгергән. Шунда ук миннән: «Әллә коммунистлармы?» — дип сорап куйды.

Мин иң элек Кәримулла абзыйга мөрәҗәгать иттем:

— Нәрсә, икесе дә партиядәмени?

— Икесе дә. Киленне моннан ике ел элек алдылар. Ни әйтсәң дә, һөнәр иясе. Һөнәр иясе — ил терәге, диләр бит.

Анри өйне кабат күздән кичергәч, бер кырыйда стена буенда пианино торуын күреп, тагын сорау бирде.

— Нәрсә, берәр җитәкче работниклармы әллә?

Килендәренең дуңгыз караучы, өй хуҗасының гади механизатор булып эшләве турында ишеткәч, янә ышанырга да, ышанмаска да белмәде.

Авылда нинди бәйрәм булуы белән кызыксындым.

Кәримулла абзый хәбәрдар.

— Хәзер көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй, нәрсә булса да уйлап чыгарып кына торалар. Гаҗәп тә түгел. Халыкның ил-көн итүләрен генә күр син, кызыгып үләрлек.

Ул арада балалар янында чуалган Һәдия белән Каролинага игътибар иттем. Алар мәш киләләр. Өлкәнрәге кыз бала. Укырга йөрүе-йөрмәве белән кызыксындым. Юк, мәктәпкә керергә яше житмәгән икән. Ә менә музыка мәктәбенә йөри башлаган.

Карасам, Каролинаның кулында ноталар. Бәләкәй кыздан нәрсәдер сорый. Кыз берни дә аңламый, бары тик елмая гына. Аңа да тылмач кирәк иде. Килдем, кунак апаның сүзләрен тәрҗемә иттем. Каролина: «Бу ноталар белән кем уйный?» — дип сорый икән. Шушы бәләкәч уйный дигәч, мадам ах-х! итте. Бетховенны уйный икән лабаса!

Баш өстенә зәңгәр бант утырткан, шундый ук төстәге чәч үргеч белән нәни толымнарын үреп салган кызчык әллә ни ялындырып тормады. Пианино янындагы урындыкка менеп утырды да, Каролина кулындагы ноталарның берсен алып, ике куллап уйнап та җибәрде. Бетховенның балалар өчен язган «Сурок» дигән җыры яңгырады.

Бәләкәй музыкант уйный, ә Каролина йомшак, йонлач җәнлекне куенына алган сыман хәрәкәтләр ясап, бөгелә-сыгыла француз телендә җырлый. Кызчык канәгать, күзләрендә очкын. Авызы ачык нәни малайның да күзләре аңлашылмый торган телдә сөйләшүче, ул белмәгән телдә җырлаучы апа кешедә.

Без, ир-атлар, үзара гәп сатып утырабыз. Күбрәк Кәримулла абзый сөйләнә.

— Яшьләр гомер көтә, картлар үлем көтә, дигәндәй, гомер узды да китте, күрше. Хәзер менә, басу уртасында калган сука башы кебек мин утырам...

— Күпне күргән, озак яшәгән кеше шул сез, Кәримулла абзый, — дигән булдым, телемә башка сүз килмәгәч.

— Һәй-й, кем! Каян килеп озын булсын, ди. Тәрәзәгә бер күз салып алу кебек уза да китә икән ул гомер дигән нәрсә. Үткән гомер — искән җил, димәсләр иде аны.

Шул вакыт Кәримулла абзый җәһәт кенә урыныннан купты.

— Бәрәкалла! Намазымны оныта язганмын лабаса...

Тиз генә кече якка керде, мич алдыннан ялт итеп торган җиз комганын алды да, авыз эченнән генә догаларын мыгырданып, чыгып китте.

Анри тагын сорау ала башлады. Биш вакыт намазның һәм тәһарәтнең нәрсә икәнлеген аңлатып бирергә туры килде.

Ул арада тәһарәт алып, өс-башын алыштырырга өлгергән Кәримулла абзый керде. Авыз эченнән генә нәрсәдер укый иде булса кирәк, керә-керешли беркемгә бер сүз әйтмичә, хәтта як-ягына каранмыйча кече якка үтте.

Бабайның намазлык җәюен күргән нәни музыкант та, тс-с, шауламаска дигән сыман, имән бармагын ирене янына китереп, күзе белән генә кече якка ым какты. Уйнавыннан туктап, пианино капкачына кадәр ябып куйды.

Өйдә тынлык урнашты.

Намазлык өстенә тезләнгән ил карты Кәримулла абзый ягына күз салам. Ай-һай, картайган! Әмма аның йөзе житди, шулай картаюына, шулай бетешүенә уфтану яки үкенүнең әсәре дә юк. Андый тыныч халәт бары тик тормышның иң югары ноктасына күтәрелеп житеп, текә кыя кырыена килеп баскан кешеләрдә генә буладыр. Ул инде, үзе әйтмешли, шөкер, бу фани дөньяда бик күпне күргән. Егылган чаклары да булгалагандыр, әмма тагын торган. Ничек кенә булмасын, ул үз өлешенә тигән көмешен тыныч күңел белән кабул иткән, кеше бәхетенә

кызыкмаган. Шул мизгелдә бөкресен чыгарып утырган бу ил карты изге кешене, пәйгамбәрне хәтерләтә иде. Әнә, күз явын алырлык ап-ак күлмәге аша, яшеренгән канатлар булып, калак сөякләре төртеп тора...

Шул вакыт шау-гөр килеп Гарифулла белән Зәйтүнә кайтып керделәр. Безнең үзләрендә икәнлекне капка төбендәге машинаны күреп үк белгәннәр. Әмма кече якта кыйбла ягына йөз куеп намаз укып утырган картны күргәч, кинәт тынып калырга мәҗбүр булдылар.

Урам тутырып клубка барабыз. Төркемнең урта бер җирендә — Кәримулла абзый. Башында һәйбәт камчат бүрек, өстендә рәешкә генә кия торган яңа бишмәт, аякларында кәвешләр белән киелгән бизәкле сәхтиян читекләр. Буй-сын төз.

Киң, якты урам буйлап атлыйбыз. Өйләрнең ачык тәрәзәләреннән өй хуҗаларының гөр килеп сөйләшеп утыруларына кадәр аермачык булып ишетелеп кала. Кәримулла абзый әйтмешли, хәзер бит ашып-ташып торган иркенлек. Кунак-төшем, дус-ишләр, туган-тумачалар бергә җыела торган чак.

Бер ачык тәрәзәдән урамга тутырып җыр агыла...

Ай, былбылым, вай, былбылым,
Агыйделдә таң ата;
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да елата...

Җыр әллә нишләтеп җибәрде үземне. Тәнем чымырдап куйды. Кинәт кенә чиксез дулкынлану биләп алды. Шул мизгелдә бугазыма ниндидер төер менеп утыруын, күзләрем дымлануын сиздем.

И-и туган авылым! Бары тик синдә булганда гына туган телемнең яңгырашы, сафлыгы, аһәңе, нәфислеге мине тәмам әсир итә. Үтәдән-үтә күренмәле рәсемнәрне бары тик акварель буяулары белән генә ясарга мөмкин булган кебек, әбием сөйләгән әкиятләрне дә, халкым җырлаган җырлардагы сүзләрне дә бары тик саф ана телебездә генә сөйләп, бары тик үз телебездә генә әйтеп буладыр кебек. Туган телем — иркә гөлем, киндер сиңа күңел түрем. Тикмәгә генә: иң татлы тел — туган тел, анам сөйләп торган тел, димәсләр иде аны. Әйе, туган телнең рухын безнең буын гомерлеккә бәгыренә сеңдергән. Аның рухы кичке һавада да, яңа пешкән икмәк исендә дә, киң Иделнең дулкыннар кагуында да, агач яфраклары лепердәвендә дә бар сымак. Һәрхәлдә, мин моны күңелем белән шулай тоям.

Клубта да безне ачык йөз, якты чырай, тәмле тел белән каршы алдылар:

— Әйдәгез, әйдә, кадерле кунаклар! Рәхим итегез! Мәҗлесебезнең түр күрке булыгыз! — дип, кыз-киленнәр, чая җиңгәчәйләр кыстап кына да калмадылар, җилтерәтеп түр якка алып кереп тә киттеләр үзебезне.

Ә анда хәйран-тамаша, халык, халык. Алма төшәрлек тә урын юк. Барысы да күргәзмә карарга дип килгәннәр. Хәер, карарлыгы да бар шул. Зур залның буеннан-буена ике рәт итеп сузылган өстәлләр. Ап-ак эскәтерләр ябылган өстәлләрдә, күз явын алып, мең төрле ризык-нигъмәт тезелеп куелган. Нәрсәләр генә юк анда! Ул балга катырган чәкчәкләр, камырдан эшләнгән ак, кызыл, ал, сары роза чәчәкләре бәйләмнәре, шикәр комы сибелгән төшләр, әллә ничә төрле паштетлар, кабартмалар, кырыккатламнар, гөбәдияләр, «ат тояклары», кыстыбыйлар, өчпочмаклар, пәрәмәчләр, тары тәбикмәкләре, күзикмәкләр, кәбестә һәм бәрәңге бөккәннәре, хәтта көлчәгә кадәрле бар. Бусы инде дөньяны күп күргән әбиләр эшедер. Ә табын күрке — бәлешләр аерым урынга тезелеп куелган. Анда тулган ай кебек булып йөзләре килгән

ит бәлешләре дә, кабак, балан бәлешләре дә бар. Бер башта эчемлекләр: чымырдап торган әче баллар, әчендә кисәкләп боз салынган әйрәнгә кадәр куелган.

Шунда ук вәкаләтле комиссия членнары мәш килә. Һәрбер ризыкны кулларына алып, әйләндергәләп күрсәтеп, кем тарафыннан пешерелүен әйтәләр. Күргәзмәдә җиткән кызлар да, уңган киленнәр дә, җитез җиңгәчәйләр дә, озын гомер кичереп, бай тәҗрибә туплаган әбиләр дә катнашкан. Теләгән кешегә ризыкны авыз итәргә дә бирәләр. Чөнки аш-су, ризык турында төпле фикер тупларга кирәк. Җиңүчеләрне дә әнә кыйммәтле призлар көтә. Беренче бүләк — 120 сумлык сервиз.

Тик менә шартлары бик катгый икән: аш-суның формасы да, нәзакәтле хәзерләнүе дә, йөзе килүе дә, тәме дә, кыскасы, куелган барлык таләпләргә дә җавап бирерлек булсын.

Әмма безгә әллә ни озак юанырга туры килмәде. Совхоз директоры Бәширов барыбызны да берьюлы кочаклаган сыман итеп бөтереп алды да кунаклар бүлмәсенә алып кереп китте. Анда инде ике кеше бар иде. Таныша торгач белдек: аларның берсе райком вәкиле, икенчесе өлкә газетасы хәбәрчесе икән. Анысы күргәзмә турында репортаж язарга килгән.

Гөрләп самавар кайнап торган табын янына утырырга да өлгермәдек, алдыбызга берьюлы әллә ничә төрле ризыкларны китереп тә куйдылар. Анри белән Каролинага иң ошаган нәрсә — тутырган тавык булды. Каролина хәтта аның ничегрәк хәзерләнүе белән кызыксынып, рецептын да язып алды.

Без яңадан залга чыкканда совхозның жюри членнары җиңүчеләрне билгеләп, бүләкләрне тапшырганнар иде инде. Беренче урынны заманында мине кыр станында итле токмач белән сыйлаган Мингаян апа алган. Ул вакытта да механизаторлар: «Һай, Мингаян апа, ашыңның тәмлелеге лә!..» дип, тикмәгә генә мактамаганнар икән.

Хәзер инде өстәлләр тирәсендә халык гөж килә. Табындагы барлык ризык халык карамагына тапшырылган. Түрдәге өстәл тирәсенә өлкән кешеләр: хезмәт һәм сугыш ветераннары утырган. Яшь кызлар аларны чәй белән сыйлыйлар.

Йорт хуҗаларыбыз безне көтеп торалар икән. Җәһәт кенә җыелып, кайтырга чыктык.

— Безнең килен дә бүләкләнде, — дип куйды Кәримулла абзый.

Һәдиягә җитә калды.

— Шулаймы? Менә һәйбәт булган. Тәбриклим, Зәйтүнә!

— Махсус приз бирделәр, — диде Гарифулла, оялып-югалып калган хатынына ярдәмгә килеп.

Авыз иткәндә иң беренче булып ашалып беткән ризык өчен дә жюри аерым бүләк билгеләгән булган. Зәйтүнәнең төче коймагын ялтыратып кына куйганнар. Бик һәйбәт! Ул да аш-суның яхшы хәзерләнгән булуын күрсәтә түгелме соң?!.

Хуҗалар безнең китүебез турында ишетергә дә теләмәделәр: төн безнеке, иртәгә ял, дип дәррәү күтәрелеп, табын хәзерләргә керештеләр.

Анри белән без алма бакчасына чыктык. Менә таш җәелгән сукмак. Ул сиртмәле коега кадәр сузылган. Коеның бура, сукмак тирәләрен куе, йомшак үлән баскан — ят та тәгәрә.

Кайбер алмагачларның алмалары өзелмәгән, әнә тәрәзәләрдән төшкән яктылыкта ап-ак булып күренеп торалар. Аларның көзге сорт — антоновка алмалары икәнлеген исләреннән үк белеп була.

Бу бакча миңа бала чагымнан ук таныш. Менә шушы ян койма артында гына безнең өебез иде. Шушы койма аша гына сикереп төшеп, алмалардан күп авыз иткәләдем.

Безнең як койма буендагы бер карт алмагачның йодрык кадәрле алмасын өзеп алдым. Салкынча, саллы алма иде бу. Аның тешләрне

камаштырырлык ачы үткенлеге, шешәсе әле яңа гына ачылган газлы су сыман, авызымда беркавым кайнап торды.

— Һай-й, алмасы да алмасы!..

Малай чакта тикмәгә генә кермәгәнмен икән шул мин бу бакчага...

## 10

Вәгыйз Гайнанов турында берсеннән-берсе яманрак хәбәрләрне ишеткәч нәрсә дип уйларга да, ни дип юрарга да белмәдем. Хәер, сәбәпләре дә юк түгел. Башта Ләйләсе ташлап китте. (Хыянәттән дә әшәке нәрсә юк.) Аннары әнисе — Мәрхәбә түти дөнья куйган. Эшендә дә чатаклыклар чыккан дип сөйлиләр.

Әмма чын ир-егет андый гына югалтуларны күтәрә белергә тиеш иде кебек. Ирексездән Исламның Вәгыйз турында: «Ул егылган түгел, ә сөйрәлүче адәми зат», дип әйткән сүзләре искә төште.

Ничек кенә булмасын, Вәгыйзне эзләп табарга һәм ирләрчә бер сөйләшеп карарга кирәк иде. Ләкин аны эзләп табу мин уйлаганча ук җиңел булмады. Эш урынына шалтыраттым: эчеп-исереп берничә тапкыр прогул ясаганы өчен эшеннән куылган. Өенә киттем: анда тагын да яманрак яңалык. Җыен юлдан язган браматларны җыеп, күршеләренең тынычлыгын җуйган өчен, квартирыннан сөргәннәр. Шунда төшендем мин: бер генә сөрлексен адәм баласы, аннары инде беттең, очсызланасыңны көт тә тор икән.

Вакытымны югалтсам югалттым, әмма таптым Вәгыйзне. Танырлыгы калмаган егетнең. Менә ул дөньялардан киткәндәй булып каршымда утыра. Сизелеп тора, күңелен әрнү талый, хәсрәте хәттин ашкан. Күзләре эчкә баткан. Маңгаена тирән сырлар уелган. Ябыккан, бетешкән. Кием-салымы каткан. Көрешүебез ямьсез булды: кинәт кенә әллә нәрсә булды егеткә, иреннәре дерелдәде, теленә сүз килми гаҗизләнде.

— Нда-а, Вәгыйз!.. Тәки махы бирдең. Мин синең тигез җирдә абына торган гадәтең барлыкны белми идем, — дидем мин, телемә башка сүз килмәгәч. — Я, әйт, нәрсә булды сиңа? Ни җитмәде?..

— Акыл... Акыл җитмәде.

«Әллә катырак бәрелимме икән?» — дип тә уйлап куйдым. Әмма ярсу, газап, иңрәү, хәсрәт тулы бәгырьгә саксыз кагылу хәтәр нәрсә.

— Кеше үгете үт сытар, ди. Мин сиңа, Вәгыйз, үгет-нәсихәт укырга җыенмыйм. Шулай да бер-ике сүз әйтмичә булдыра алмыйм. Дәшмәскә хакым юк. Әйтче, зинһар, шулай кешелектән чыгарлык, акылыңны җуярлык нәрсә булды соң әле? Ярар, хатының китте ди. Әниең дөнья куйган. Әмма бит боларның берсе генә дә дөньяда булмый торган хәл түгел. Мондый югалтуларга без һәркайсыбыз әзер торырга тиеш. Син сау-сәламәт кеше. Кулыңда көч, беләгеңдә җегәр бар. Эшлим дисәң, рәхим ит, һөнәрең мактаулы...

Вәгыйз, оеп калгандай, һаман да тик утыра. Аның шулай йокылы-уяулы халәттә утыруы ачуымны чыгара башлады. Әмма түздем, күтәрелеп бәрелмәдем. Көнен-сәгатен билгеләп, кабат очрашырга (бу юлы инде бездә) сүз куешып аерылыштык. Аңынчы мин Вәгыйзгә эш табып, яшәргә урын барлап куярга тиеш идем.

Сүзендә торды, килде. Кунак булды. Һәдия дә үз итеп киңәш бирде. Ә Гөлҗиһан апа: «Тормыш булгач, Вәгыйз улым, ачысын да, төчесен дә авыз итәсең икән аны», —дип, кош булып кына сайрамады инде.

Вәгыйз, рәхмәтләр әйтеп, китәргә җыенды. Мин озатып куярга булдым. Чыгып китәргә генә торганда сәер бер очрашу булды: безгә Ниса килеп керде. Аны күрү егетне өнсез итте, ул: «Сез-з!..» дип, бары тик бер сүз әйтә алды.

Ниса да аны таныды кебек. Әмма әллә ни исе китмәде. «Исәнмесез!» дип күреште дә түргә узды. Анда аны шау-гөр килеп Һәдия каршы алды. «Әйдә, әйдә, Ниса җаным! Ник ешрак килми торгансыңдыр, сагындырып кына йөрисең...»

Урамга чыккач, Нисаны каян белүе белән кызыксындым. Вәгыйз бермәлгә җавап бирә алмыйча торды. Аннары минем якка борылмыйча гына болай диде:

— Күңелле очрашу булмады ул... Бу ханым белән танышу да исереп, тилереп йөрүгә бәйле. Сөйләсәм... нәфрәтегезне уятырмын дип куркам.

Аны кыстамадым. Әмма ул, белсәгез белегез инде дигән сыман, иплэп кенә хикәяли башлады.

Квартирында яшәгән чагы булган Вәгыйзнең. Бер төркем исерек башлар җыелып нык кына эчкәннәр. Төн урталары булуга да карамастан, Вәгыйздән тагын берәр шешә аракы таптыра башлаганнар. Хуҗа кунакның ишәге, ди бит. Вәгыйз урамда очраган беренче машинаны туктата да туп-туры «Кама» ресторанына юл тота. Үч иткән кебек, ул да инде ябылырга өлгергән. Шунда Вәгыйз хәйлә юлына баса. Ишек катында торган бер бәндәгә пальтосын, бүреге белән шарфын бирә дә ишек янына килә: «Яңарак кына чыккан идем... Түләргә акчам җитмәгән иде», дип эчкә үтә. Гөрләп торган ресторан тынган. Буфет та ябык. Вәгыйз ялынып-ялварып, икеләтә бәя биреп, тәки бер шешә коньяк ала. Урамга чыкса, кием-салымын биреп калдырган бәндәдән җилләр искән. Анда сугыла, монда бәрелә, ник бер җан иясе күренсен. Үзәкләргә үтәрдәй булып, салкын җил исә. Вәгыйз трамвай тукталышына йөгерә. Анда да адәм заты күренми. Рестораннан чыккан кызулык белән бераз түзсә дә, соңрак чыдар хәле калмый. Җан газиз бит, Вәгыйз урамның аръягында торган йортларга таба йөгерә. Бер подъездга керә. Кайнар батарея-фәлән булмасмы дип, икенче катка күтәрелә. Юк. Караса, ишекләрнең берсе бикле түгел. Коридорга уза. Стена буенда кайнар батареялар. Вәгыйз тиз генә җылыга аркасын куеп идәнгә чүгә. Менә кайда рәхәт, менә кайда җәннәт. Кесәсендәге шешәне чыгарып бераз гына өстәп тә куйгач, дөньясы түгәрәкләнгән сыман була. Шунда оеп утыра торгач, йокыга да китә... Чиләк-ләгәннәр доңгырдаганга уянып китсә, ни күрсен, идәнгә авып төшкән дә әйберләр өеп куелган урындыкны аударган икән.

Иң элек бер ишек ачыла. Аннан пумала башлы ярым шәрә хатынкыз килеп чыга. Вәгыйзне күрү белән шарран ярып разбой сала. Калган ишекләрдә дә кешеләр күренә. Шау-шу куба. Берсенең телефоннан милициягә шалтыратканы ишетелеп кала. Бераздан подъезд янына выжт итеп машина килеп туктый.

Менә шунда күрә Вәгыйз Нисаны. Ниса: «Керегез монда... Тиз булыгыз!» — дип, Вәгыйзне үз бүлмәсенә чакырып ала. Шулай итеп милиционерлар коры килеп, буш китеп баралар.

— Соңыннан мин ул изге җанны күрү нияте белән әлеге йорт янына да килгәләгән идем... Тик очрата гына алмадым. Өенә керергә кыюлыгым җитмәде, — диде Вәгыйз, сүзен түгәрәкләп.

Трамвай тукталышында саубуллаштык. Мин кайтканда Николай да бездә иде инде.

Әнә табын янында Ниса утыра. Өстендә кара плиссер белән бизәлгән ак кофта. Ул елмая. Елмайганда бит очлары чак кына уймакланып чокыраялар. Ә күз карашы? Бер күтәрелеп, керфекләрен сирпеп караса, бәхет нурлары белән коендыргандай итә.

Мин дә табын янына килеп утырдым. Чәй эчәбез, Николай теләктәшлек эзләгән сыман итеп әле Һәдия, әле минем якка күз салып алгалый. Аның нәрсә әйтергә җыенуын күңелем белән тоеп утырам.

— Имам Хисамович!.. — дип башлады ул дәртләнеп-илһамланып.— Әйтегезче Нисага... Сезнең сүзгә күнәр ул... Яратам мин аны. Чыксын миңа...

— И-и, Николай, — диде Ниса тыйнак кына. — Мондый хәлдә мин кемгә хаҗәт ди? — Бу сүзләрне әйткәндә аның йөзенә чак кына күләгә кунган сыман булды.

— Миңа!.. Миңа кирәк сез, Ниса! Сездән башка яшәү юк миңа. Әгәр дә миңа чыгарга ризалык бирмисез икән... Әйткән иде диярсез, китәм дә барам. Сүзем — сүз, Мәскәүгә китәм. Бөтенләйгә китәм...

Әйе, Николай чыннан да гашыйк иде. Ә аның кебек кешеләр әгәр дә яраталар икән инде — дөньяларын онытып яраталар. Тик нишләмәк кирәк, үзеңне көчләп яраттырып булмый шул.

— Юк, Николай...— диде Ниса әкрен генә һәм хиссез тавыш белән.— Сүз дә юк, сез әйбәт кеше. Ифрат та әйбәт!.. Акыллы, укымышлы. Тик сез мине дөрес аңлагыз. Мин хәзер бик теләгән тәкъдирдә дә ярата алмаячакмын. Беркемне дә. Минем өчен мәхәббәт үлде... Күмдем мин үземнең мәхәббәтемне. Хәзер мин кешене... бары тик кызганырга гына сәләтлемен. Күңелемдә бары тик шул хис барлыгын гына тоям мин.

Николайның ялыну-ялвару белән мөлдерәмә тулы күзләре Нисада. Тавышына җанны иркәләрлек җылылык өстәп әйтә салды:

— Мине... Мине кызганыгыз, Ниса. Шул хисегезне миңа бүләк итегез!.. Шуңа да риза мин.

Нисаның күзләрендә моңсулык.

— И-и, Николай! Сез нинди кызганыч буласыз, ди. Сездән дә бәхетле кеше юктыр бу дөньяда...

Шул чак минем башымда, караңгы төнне ярып узган яшен яктысы кебек булып, Вәгыйзне шәт кызгана да, бәхетле дә итә алыр иде бу гүзәл, дигән уй йөгереп үтте. Һәм шунда ук сорап куясы да иттем:

— Ниса, ә менә баягынак очраган егетне кызгана алыр идегезме?..

— Әйе, ул кызганыч кеше...

Нисаның җавабы күңелемә бик хуш килде. Кунаклар киткәч, Вәгыйз белән Нисаны якыннанрак таныштырасы иде, дигән фикеремне һадиягә дә әйттем. Гаҗәп хәл: кызгану турында сүз чыккач, ул да Вәгыйз турында уйлап куйган икән.

*
* *

Техник-контроль стендын кабул итү комиссиясенә тапшыру кеткәннән дә җиңел үтте. Инициативаны үз кулыма алдым. Шавальега шактый нәләшелгән иде инде. Бәлки шуңа күрәдер,ниндирәк сүз куллануың, ниндирәк тәэсир калдыруың турында уйламыйсың. Андый вакытта алар үзеннән-үзе туып кына торалар.

Шул зур эш хөрмәтенә җыйнак кына банкет сыман нәрсә оештырылды. Фирма вәкиле мсье Шавельега стендны камилләштерүдә ярдәм итүебез өчен, «Франц-Пуатвен» корпорациясе исеменнән бүләкләр дә тапшырылды. Җыйнак кына телефон-комбайннар иде алар. Үзендә үк телефоны, диктофоны, магнитофоны. Үзең өйдә яки кабинетыңда булмаганда шалтыратсалар, кем, кайдан, нинди йомыш белән шалтыратуларын язып ала торган аппарат ул. Ул аппаратлар миңа һәм минем кул астында эшләүчеләргә генә түгел, бәлки генеральный директорга да бүләк ителде.

Леонид Борисович, үземә генә ишетелерлек итеп, бу уңай белән болай диде:

— Ну-у, хөрмәтле Имам Хисамович, бу юлы да судан коры чыктыгыз бит, әй!..

— А как-же! — дигән булдым мин, чак кына кукраеп. — Аның шулай тәмамланасын мин белә идем.
— Каян белә идегез?
— Сизенү дигән нәрсә бар бит...
— Әйдә, әйдә, мактан инде.
— Мактану түгел бу, Леонид Борисович. Бер нәрсә бәхәссез, каршылыксыз җиңү юк.
Генеральный директор бүтән сүз әйтмәде, күз кырыйлары белән генә елмайды да, җиңү өчен дигән сыман итеп, кулындагы фужерын минеке белән чәкештерде. Моны күреп башкалар да фужерларына үрелделәр.

Машина алга ыргый. Асфальт өстендәге ярма сыман кар бөртекләре коры ком белән тузгып кала. Быел кар бик соңарды.
Юлның як-ягында яшь нарат үсентеләре. Шул агачларның җиргә кадәр диярлек төшеп-асылынып торган ботаклары астында моннан берничә көн генә элек күренгән беренче кар ятып калган. Әмма читтән караганда ул, бигрәк тә тизлек белән узып барганда, кар булудан бигрәк, җил очыртып илтеп ташлаган мамык кисәкләрен хәтерләтә. Әмма кояшның елмаюы нәкъ сырхау кешенеке сыман сүлпән-сүрән хәзер. Чөнки үзенең чуар шәлъяулыгын изәп көз саубуллаша, көз узып бара. Ә яше иллегә җиткән кеше өчен андый вакыт шактый ямансу, шактый моңсу чор. Димәк, тагын бер ел үтте, тагын бер яшькә олыгайдык...
Французларны Бигеш аэропортына озатып кайтып киләм. Әле яңарак кына Мәскәүгә очтылар. Аннан инде Парижга. Минем машинада, янәшәмдә утырып барганда мадам Каролина бер сер ачты. Анри инженер гына түгел, менә дигән журналист та икән әле. Чаллыда да тик ятмаган: «Кама могҗизасы» дигән китап тәмамлаган. Кайту белән дөньяга чыгарачак китабында безнең халыкка багышланган битләр дә шактый булачак икән. Самолет көткән арада (аэропорт тирәләрен әйләнеп йөргәндә) бу турыда Анри үзе дә әйтте.
— Безнең бик күпләребез өчен сез бары тик Россия генә идегез... — дип башлады ул.— Чынлыкта исә сез күптән инде Советлар Союзы икәнсез.
КамАЗда мсье Анри күп төрле күзәтүләр алып барган. Бигрәк тә татар хатын-кызларының тыйнаклыгы, тотанаклылыгы, өлкән кешеләргә карата булган ихтирамы аны тәмам әсир иткән. Табигатьнең нәкъ үзе кебек гади, нык, сәламәт милләтнең киләчәге ныклыгына ышанып, үз күзе белән күреп китүен яшермәде. Китабы чыгу белән берәр нөсхәсен җибәрергә дә вәгъдә итте.

Сүзендә торды Анри Шавалье. Китеп ике ай үттеме икән, Париждан бандероль килеп төште. Ачсам, исем-акылым китте — китап! Караштырам. Елкылдап торган яхшы кәгазьгә басылган. Тышлыгында — «КамАЗ-5320» маркалы машина сурәте.
Беренче битен ачам. Өзек-өзек җөмләләр. Язу ысулында авторның характеры ярылып ята. «КамАЗ нәрсә ул?» — дип сорау куйган, үзе үк җавап та биргән. «КамАЗ» — өч миллион квадрат метр мәйданны биләп торган җиде завод комплексы. Аны 150 меңнән артык кеше төзи. Бу супергигантны төзүдә, иңгә-иң торып, җитмештән артык милләт вәкиле катнаша. «КамАЗ» елына двигателе 210 ат көчле булган 150 мең автомашина чыгарачак. Өч күчәрле бу йөк машинасы 16 тонна йөк күтәрә, 80 километр тизлек белән йөри. Аны төзүдә (йөзләрчә чит ил фирмаларын санамыйча) 17 министрлык, Советларның 500 шәһәренең

6 меңгә якын заводы, комбинаты, фабрикасы катнаша. Алар аны төзү материаллары, конструкцияләр, яңа техника һәм технология җиһазлары белән тәэмин итәләр. Якында гына автоград үсә. Бүгенге көндә анда 250 мең кеше яши. Шәһәрдә 80 кибет, 30 мәктәп, 35 китапханә...»

Татарстан турында да мәгълүматлар бар. Аны нефть, химия промышленносте үзәге һәм машиналар төзү республикасы дип атаган.

Хатына күз салам. Хатның яртысы диярлек сәлам, рәхмәт сүзләреннән тора. Каролинадан да барчабызга сәлам әйткән.

«Хөрмәтле Имам Хисамович! Сүземдә тордым, «КамАЗ» турында күңелемдә булганны яздым. Объектив булдым кебек. Сезнең белән якалашып яшәгән чакларның истәлеге булсын. Дөресен әйтим, китап төрле фикер тудырды. Хуҗаларыма ошамады: «Тагын бераз КамАЗда калсаң, тәки коммунистлар партиясенә кереп кайтасы икәнсең», — дип төрттерүдән дә тартынмадылар. Яшерен-батырын түгел, патроннар белән ике арага бераз күләгә төшүгә дә сәбәп булды бу китап. Аның каравы, Коммунистлар партиясе органы «Юманите» күккә чөеп мактап чыкты. «Без теләсә нинди маркалы металл коя алабыз, катлаулы ЭХМнар чыгарабыз. Әмма бер үк вакытта 150 меңнән артык кешене бергә туплау, аларны киендерү, тораклы итү, һөнәргә өйрәтү һәм, ниһаять, эш белән тәэмин итү безнең кулдан килми», дигән сүзләрне ассызыклап басып чыгарды.

Сез тагын: бу Шавальены тәки үз ягыбызга аударып бетергәнбез икән, дип уйлый күрмәгез. Һич юк! Мин инанганымнан кире кайта торганнардан түгел. Вөҗданым белән алыш-биреш итә алмавымны сез яхшы беләсез. Алда әйткәнемчә, мин бары тик күңелемдә булганны гына язарга тырыштым...»

Кире беткән Анри күз алдыма килде дә басты. Хатын тулысынча укып чыкканнан соң күңелемә ниндидер җылы дулкыннар бәргән сыман булды.

*
* *

Ниһаять, килеп җитте ул көн. Бу көнне көткән арада бик күпләр кавыштылар, туй күлмәкләре киделәр. Яңа гына дөньяга килгән бәби тавышлары хезмәт симфониясе авазлары белән аралашты. Ул көн — 16 февраль — календарьда гади көн иде. Шулай булса да ул үзенең масштабы белән дөньяны таңга калдырган «КамАЗ» елъязмасына, илебезнең бөек төзелешләре тарихына мәңгегә кереп калыр. Чөнки ул көнне баш конвейердан көйләү-җибәрү режимында беренче «КамАЗ» маркалы автомобиль төште.

Шул ук көнне кич миңа Ислам шалтыратты:

— Әти, синме?.. Иң элек тәбрикләргә рөхсәт ит! Молодцы, әти!.. Дөньяны таңга калдырдыгыз...

— Рәхмәт, улым!.. — Аның мине шулай тәбрикләве күңелемә бик хуш килде. Ләйләне алып киткәннән бирле бу аның икенче тапкыр гына хәбәр салуы иде. Беренчесе моннан өч-дүрт ел элек: котлагыз, диссертациямне уңышлы якладым, дигән ике авыз сүздән торган телеграмма иде, һәм менә телефон звоногы... Әмма мин тиз генә кайтып төшәргә теләмим, сорау биргән булам.— Ничек шалтыратырга иттең әле?..

Ислам бер мизгелгә тынып калды. Аннары:

— Әти... миңа синең киңәшең кирәк, — диде.

— Гаҗәп... — дидем мин, һаман да әле үпкәсе бар кеше сыман итеп. Әмма ул моңа әллә ни игътибар бирмәде, сүзен дәвам итте.

— Бу адымымны, эти, синең белән киңәшеп эшлим дигән карарга килдем... — Мин дәшмәгәч дәвам итте. — Тормышымда зур үзгәреш булырга тора... Син ничек әйтәсең, шулай итәчәкмен.

Бу юлы да сүзен бүлдем.

— Кайчаннан бирле әле син шулай сүз тыңлаучан булып киттең?

Җавабын алдан ук хәзерләп куйган диярсең.

— Син акыллы киңәшләр бирә башлаганнан бирле... Тыңла, эти. Чаллыга кайту мөмкинлеге бар. Иртәгә иртән соңгы сүземне әйтергә тиешмен...

Аның шулай ифрат та үз итеп сөйләшүе, киңәш соравы һәм, ниһаять, яныма кайтырга җыенуы үзенекен итте, күңелем кинәт кенә бәхеттән мөлдерәмә тулгандай булды. Әмма йөрәгемне ачып салырга ашыкмадым: «Нинди рәк эш тәкъдим итәләр соң?» дип сорап куйдым.

— Зур эш, эти. Чаллыдагы Казан авиация институты филиалын мөстәкыйль политехник институт итеп үзгәртеп корырга җыеналар...

Барысы да аңлашылды.

— Чыннан да, зур эш икән...

— Нишлим, эти?..

Хис-тойгыларымны тыеп тормадым, тездем дә тездем.

— Монда, улым, ике уйлап торасы юк. Кайтыгыз... Әлбәттә, кайтыгыз! Ата-бабаңнар туган як икәнлекне онытма. Тик менә Лэйлә... Бу мәсьәләгә ул ничек карый?

— Аның турында сорама инде, эти. Туган яклары белән тәмам саташты ул. Төшләрендә күрә... Елаштырып та алгалый. Сәбәбе дә юк түгел... Әти-әниләре, туган-тумачалары белән бернинди элемтә юк. Хатларыбызга, телеграммаларыбызга бернинди дә җавап алмыйбыз... Хәтта телефон белән дә сөйләшергә теләмиләр. Шуннан үзең аңла инде. Җитмәсә тагын, Лэйләгә борчылырга да ярамый... Әни кеше булырга җыена... Кайтып төшү белән, эти, безгә синең ярдәмең кирәк булачак, әби-бабайлар белән татулаштыру миссиясен сиңа йөкләргә дип торабыз...

— Һы-ы, акылыгыз алтын икән! Өйләнгәндә миннән киңәш сорадыгызмы соң? Алай гынамы әле...

— Өйләнү ул, эти, тормыш итүгә караганда бик күпкә ансат икән бит.

Дулкынлануым үзенекен итте. Тизрәк соңгы сүзләремне әйтергә ашыктым.

— Ислам... Ишетәсеңме, улым?! Йөрмәгез әллә кайда каңгыраеп... Соңгы сүзем шул: кайтыгыз.

— Шунда ук квартира да вәгъдә итәләр...

— Анысы, Ислам, кечкенә мәсьәлә. Бездә дә сыярсыз...— Тавышымның калтыранып чыгуын үзем үк тоя башладым, шунлыктан әйтәсе сүземне түгәрәкләү ягын карадым. — Булды, улым... Бар да аңлашылды. Көтәбез... Кайтыгыз. Бергә яшик. Шуны бел, эти кешегә иң зур һәйкәл — аның улы!

Бу минутта тормышым тагын да мөбәрәкләнеп, тагын да түгәрәкләнеп киткән сыман булды.

## Виктор Кочетков,

рус шагыйре

### Учак

Ил-җир гизеп йөргән чегәннәрдәй
Сәфәр чыктым менә тагын да.
Ачык күк астында төн уздырам
Үзем яккан учак янында.

Чыбык-чабык арасыннан пыскып,
Уты аның чак-чак күренә.
Ә кайчакта, ялкын телен сузып,
Дөрли-дөрли өскә үрелә.

Тирә-якта әче җил сызгыра,
Тынга каба зәһәр сулышы.
Сүнми генә янса, учагымның
Җитәр әле миңа җылысы.

Караңгылык иңде үзәннәргә,
Йоклап китәр вакыт күптәннән,
Күзләремә никтер йокы керми,
Истәлекләр агыла үткәннән.

Саубуллашып калган егет чагым
Килеп төште тагын хәтергә:
«Тәүге тапкыр янып сөюемне
Җырга салып ничек әйтергә?»

Яшьлегемә тиң җыр табармын, дип
Өметләнмәгән соң кем генә!
Тик никадәр генә тырышсам да,
Килми ул җыр, килми телемә.

... Мин сискәнеп киттем көтмәгәндә
Ишетелгән арба тавышына.
Искәрмәстән шунда юлчы агай
Килеп туктады да каршыма, —

Сүнгән төпчегенә учагымнан
Ут кабызып алды тын гына.
Кырын ятып бераз җылынгач, ул
Китеп барды тагын юлына.

Күпме эзләп табылмаган сүзләр
Күңелемә килде шул чакта:
Сөюебезне тиңлим бер-беребезгә
Җылы биреп янган учакка.

Ул да шулай башта акрын гына
Сүнәр-сүнмәс кенә дөрләде.
Ә аннан соң дулап кабынды да
Сүрелүне кабат белмәде.

Аерым торган чаклар аз булмады,
Күп кичердек җилен, салкынын.
Тик шулай да барыбер сүндермәдек
Үзебез яккан учак ялкынын.

## Елга ярында

Күзләренең нуры сүнеп барган
Бер ат йөри елга буенда.
Йөгәненә таккан чөлдерләрнең
Челтерәве моңсу тоела.

Ярдан иелеп карый дулкыннарга,
Әйтер сүзе гүя бар аның.
Салмак искән кечке җил тузгыта
Тигәнәкләр сырган ялларын.

Ә дулкыннар уйный таллар белән,
Кошлар аваз сала тугайда.
Чыклар түгел, атның күзләрендә
Мөлдерәмә яшьләр бугай ла.

Телчән саесканнар кызып-кызып
Әрепләшә иде үзара...
Кинәт шым булдылар: карт бахбайның
Тын уйларын нигә бозарга!

Сизенделәр, ахры, атның алар
Башын нигә аска игәнен:
Болыннары белән соңгы тапкыр
Хушлашырга аның килгәнен.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәләре.

## Олег Шестинский,

рус шагыйре

### Әниемә

Ераклашкан саен — мәңгелеккә
мине ташлап киткән ул көннән,
һаман саен сизгерләнә барам —
тирә-юньгә, һәр тавыш-өнгә,
миңа төбәп баккан һәркемгә.
Я ишетми калырмын димен,
миңа дәшеп сүз әйтерсең дә...
Әле дә ярый, япа-ялгыз түгел,
янәшәмдә — яхшы кешеләр.

### А. П. Керн кабере янында

*Л. Балайга*

Яңгыр коя, яңгыр шаулый,
ташына да шашына.
Тамалар эре тамчылар
аның кабер ташына.

Фани гамьне юа яңгыр,
фани уйны куа җил.
Әйдә, яңгыр, үт үзәккә,
тамчың белән кис тә тел!

Тирә-юньдә — шау Табигать —
уҗым, авыл өйләре...
Монда...
Ята Анна Павловна,
Аның өзелеп сөйгәне.

Яңгырда чыланып мин дә
сагыш белән барладым
күңелдә мәңгегә калган
сөйгән газиз ярларны...

Үткәнне гөнаһ дисәң дә,
яхшыга юрасаң да —
шул кыска көннәр яктырта
гомерне — аҗагандай.

Торган саен балкый гына
алар белән үткәнем.
Тик алар белән тойганмын
бәхетнең ни икәнен!

Калганы — дөнья куу
тормышның арбасында.
Күз яшен яшереп көлү
гайбәтләр арасында.

●

Дуслык — нур ул,
Кочагыңдагы сирень-чәчәк,
чәчләреңне иркәләүче талгын җил ул...
«Дуслык» дигәч,
әнә шулар
күз алдына баса иде
элегрәк — яшьрәк чакта.

Хәзер исә...
гомер дигән сират күперен кичә-кичә...
әгәр берәү «дуслык» дисә,
әйтәм:
дуслык —
кар-буранлы төндә адашкач,
соңгы шырпы белән
өшегәнне җылыта алу.
Дуслык —
һәр икеңә кыен чакта
иптәшеңне
җылы сүзең белән
юата алу.
Дуслык —
һәлак булган сафташыңның балаларын
тәрбияләү,
кеше итү.

## Амазонка буйлап йөзгәндә

Монда нинди генә яшеллек юк!
Табигатьнең могҗизасы —
без белмәгән дөньясы!

Әнә какао агачлары,
җимешләре кыяр сыманнар.
Әнә пальма ботакларында
асылынып тора маймыллар.
Әнә анаконда —
лианаларга уралган да,
тора, ахры, нидер сагалап...
Бер крокодил ачкүзләнеп
әйләндергән зуп-зур ташбаканы.
... Ара-тирә кала яр буйлап,
әкияттәге кебек,
тәпиләрдә басып торган өйләр —
индеецларның авыллары...

... Чү! Әллә, ходай, ялгышаммы,
каен!
Үзебезнең сылу ак каен!
Монда,
җыен киек-җанвар, елан өнендә
безнең каен үсә диген!
Яшьлек ярын күргән кебек булдым.
Күңелләргә тулды сөенеч.
Хисләнүне бүлде юлдашым:
— Бу бит каен түгел, туган!
— Ничек инде каен түгел?..
— Монда каен үсми.
Бу агач тик охшаш кына аңа.
Күрәсеңме, ботак очларында
бик бәләкәй оя-боҗралар.
Бөҗәк-кошлар керә шунда
еланнардан качып.

Күчтәнәчтән мәхрүм калган нарасыйдай
калдым боегып.
Ә бераздан,
тынычлангач, хисләр утыргач,
хәтергә алгач үткән көннәрне
тәмам үземә кайттым.
Моңа кадәр дә соң
азмы ялгыштың син, бала җан!
Битлек кигәннәрне чын дип йөрдең,
чын йөзлене «битлекле!» дидең.
Җиде ятны дустан артык күрдең кайчак,
чын дус сүзен —
ялагайлар сүзенә тиң куйдың.
Чын сөюне «мәкер!» дидең кайчак,
рыялыга теләп җан ачтың...
Алданусыз яшәү, ахры, мөмкин түгел.
«Инде ялгышмамын бүтән!» дисең.
Кабат алданганнан соң
тагын шуны кабатлыйсың:
«Инде ялгышмамын...»
Гел шулай...

Р. ФӘЙЗУЛЛИН тәрҗемәсе

**Владислав Броневский,**
поляк шагыйре

## Октябрьга баш иям

Рус революциясенә баш иям мин
Полякча итеп, маңгайны җиргә тидереп —
Баш иям эшче-крестьяннарга һәм хәрби көчкә
Бөтен дөньяга эшләгән өчен игелек.

Башымда ләкин паннар эшләпәсе түгел,
Козырегында чедән кауры юк аның,
Ул — төрмә бүреге, белегез: иясе
Шлиссельбурда Варынский булганын.

Алачыкларда яшәргә теләмибез без,
Баш иеп патшалар каршына бармадык.
Камчылар чыжлауга чик куйдык!
Үзебез калкырга кирәкне аңладык.

Баш иям Рылеев каберенә мин,
Баш иям Желябов рухына,
Көрәштә кем кыю атлады, кем яудан кайтмады —
Түбәнчел итеп мин баш иям шушыңа.

Мавзолее Ленинның фикернең үзе кебек гади,
Ленинның фикере — ул гади эшчәнлек.
Ә эше Ленинның бөек һәм гади
Революция көче белән үлчәнде.

Баш иям Сталинградтагы каберләргә,
һәм Берлин, һәм Мәскәү каберләренә.
Без шул кургашлы еллардан күпер салабыз
Заманның киләчәк көннәренә.

Салабыз без аны һәм рус җирендә һәм Польша илендә.
Кан белән мул итеп сугарган һәр таштә
Бердәмлек көчәя көрәштә һәм эштә.
Ә тормыш — чәчәктә: бөреләр ачыла
Җиңүче батырлар кабере янында, —
Күрәбез күкләрдә аларның мәңгелек гомере таңын да.

**Иван Варавва,**
Кубань шагыйре

## Бүләк

Җылы яктан, Кубань буеннан,
Яшел болын, саргылт кырлардан
Килеп җитә алар Горкига
Яу утында көйгән юллардан.

Чәчләрендә дары төтене
Төсләре бар — яудан килгәннәр.
Сугышканнар Чонгар янында,
«Кылыч бездә — үткен!» дигәннәр.

Күздә сагыш, йөздә борчу бар:
«Ник сырхаулый һаман юлбашчы?»
Әйтә күңел: «Бүләк китердек...
Казак сые шифа булмасмы?!.»

Бүләк исә толпар ат түгел
Һәм бурка да түгел, кылыч та.—
Кояш белән эче туп-тулы,
Казак аны тота бер учта.

Ул — дәү карбыз! Җиңү чаңнары
Һәм ал байрак аның эчендә.
Сөю, нәфрәт, һөҗүм көчләре —
Барчасы бар аның көчендә.

Тышы яшькелт, буй-буй тасмалы —
Нәкъ җир шарың белән бер инде:
Шау чәчәктә барча почмагы! —
Ильичка ул шулай күренде.

Кул тидерде. Җиңү канатын
Хыялында җилпеп очты ул.

Һәм елмайды Ленин кояштай,
Шул җир шарын гүя кочты ул.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре.



## Зәки Нури

# ҖИҢҮЧЕ СОЛДАТ, СҮЗ СИНЕҢ ХАКТА

Тагын Май...

Авыр һәм газаплы сугыш истәлекләрен күңелләрне тагын-тагын борчый һәм куандыра төшеп яңарткан ай. Кешелек бәйрәме дә, безнең кешелеклегебез бәйрәме дә ул.

Күп кенә илләр һәм халыкларны иркен сулышлы көнгә китергән, аларның культураларын юкка чыгаруга чик куйган, иреккә буган богауларны өзгән Май ае! Аның сугышта үлгәннәргә һәм сугыштан исән калганнарга тарихның иң биек калкулыгына мендереп куелган һәйкәле исә — безнең Бөек Җиңү.

Әйе, шагыйрь Александр Прокофьев шушы май аеның тугызынчы числосын «Бөек көн» дип бик урынлы атады, чөнки:

**Киң колач белән, кырыс һәм кайнар**
**Гади солдатлар көрәшкән җирдә**
**Алтын канатын җәйде зур Җиңү,**
**Кабул итсенгә дус илләр бергә.**

Шул сугышның җиңүчесен — дөресен әйткәндә, аның төп көчен! — зурлап тагын-тагын күп нәрсәне әйтәсе бар әле. Халык хәтерендә ул төрле елларда, төрле чакларда төрлечә итеп аерым-аерым сызылган сурәтләр булып, әлбәттә, күптән яши инде. Ә менә аның киләчәк гасырларга барып җитәсе гомум портретын еллар буе сызарга да сызарга кирәк. Бу — минемчә, бүгенге һәм киләчәктәге барча буын әдипләрнең дә изге бурычы.

...1941 елның 22 июне таңында Гитлер гаскәрләре безнең илебезгә дәһшәтле ут давылы яудыра башлады. Үлем белән яшәү көрәшенең беренче минутлары иде бу. Күгебезне фашист самолетлары өере каплаган шушы беренче минутларда ук синең портретка тәүге штрихлар эшләнә башлады, җиңүче солдат. Илебезнең күп санлы һәм күп милләтле каләм осталары бергәләп кереште бу эшкә. Ул чакта әле син безнең дөнья шаулатачак Җиңүебез юлына бары аяк кына баскан көрәшче идең. Ә Җиңүгә илтәсе юллар исә коточкыч каты сугышлар аша, чамасыз күп түгеләсе каннар аша узасын кем генә белмәде ул чакта.

Әдипләребезнең дә күбесе, илбасарларга каршы рәхимсез көрәшер өчен, кулына корал алып һәм штыкка тиң ителгән каләмен тотып, фронтның алгы сызыгына — ут эченә китте. Илһамыбызны һәм партияле иҗатыбызны Ватанны саклау эшенә хезмәт иттерү теләге, сугыш турындагы кырыс хакыйкатьне киләчәк буыннарга язып калдыру теләге бездән шуны таләп итте. Ә сугышның чик буйларындагы беренче атакалардан башлап Мәскәүдәге Җиңү парадына хәтле булган авыр юлын, хәтта аның тар сукмакларын да калдырмыйча, реаль буяулар белән кәгазьгә төшерергә кирәк иде: киң панорамалар да күрсәтелсен, һәр аерым көрәшчеләрнең эчке дөньясын ачкан «җирле әһәмияткә ия» бәрелешләр дә күздән ычкынмасын. Көндәлек батырлыкның табигате нидән гыйбарәт? Дошманны җиңәргә солдат ничек өйрәнә һәм яуда аның яңа сыйфатлары ничек ачыла? — шул сорауларны ачыкламыйторып сугыш турындагы бер әсәр дә тулы канлы әсәр була алмый.

Кыскасы, сугышчан сафка баскан музалар, күңелләрне канатландырып, солдатларның җиңүгә ышанычын ныгытып, туплар һәм бомбалар белән бергә шаулады.

Әдипләрнең алга әйдәгән көчле һәм кырыс сүзе көрәшчегә, әйтик, командир приказы яки Совинформбюроның дулкынландыргыч яңа хәбәре шикелле үк, кадерле һәм кирәк иде. Фамилиясендә үк хәрби сыйфат күренгән белорус шагыйре Максим Танк әйткәнчә, ул сүзләр:

> **Эссе чүлдә бер йотым су көткән кебек,**
> **Салкын якта кайнар учак яккан кебек,**
> **Ачыкканда ипи авыз иткән кебек,**
> **Һөҗүм өчен патрон көтеп яткан кебек,—**

көтеп алындылар.

Җиңүче солдатның сынаудан-сынауга ныгый һәм көчәя барган каһарманлыгын сүз белән сурәтләү, аның нинди каршылыклар кичереп, тормышның нинди кыенлыкларын җиңеп яңадан-яңа сугышчан сыйфатлар белән баюын тирән психологик чаралар аша күрсәтү ул көннәрдә дә бик кирәк иде. Ә хәзер ул бигрәк тә кирәк.

Сугышның чиксез кыен шартларында халык язмышы һәм аерым шәхес язмышлары турында мөмкин кадәр тулырак сөйләү ихтыяҗы солдат көнкүрешен, штаблар эшчәнлеген һәм башка бик күп нәрсәләрне энәсеннән җебенә кадәр җентекләп белүне таләп итте һәм таләп итә. Ләкин белгән кадәресен истән чыгармау да мөһим иде: бу эшкә алынучы һәр әдип һәлак булганнарга һәм яуда исән калганнарга үз йөрәгендә үлмәс һәм сүнмәс мәхәббәт сакларга тиеш. Чөнки сугыш бит асылда һәр йортка килеп керде, фронт бөтен илебез буйлап узды. Ул әле хәзер дә безнең тәннәрдәге яра эзләре һәм йөрәкләрдәге әрнүләр булып яши. Бүгенге көннәргә һәм хәзерге заманга аның йогынтысы гаять зур. Сугыш сабакларыннан без киләчәк өчен дә бик күп нәрсә алырга тиешбез. Чөнки җирдә әле баштанаяк коралланган империализм бар, төрле континентларның төрле районнарында фашистик көчләр һаман әле баш калкытып торалар. Сугышның чын мәгънәдә сәнгатьчә эшләнгән елъязмасын үткән көннәрдән бүгенге көнгә кадәр җиткерә алган, укучы йөрәгенә үтеп кергән китапларны вакыт искертә дә, онытгыра да алмый. Алар, революцион традицияләр һәм хезмәт традицияләре белән берләштән, армия белән халык бердәмлеген тагын да ныгыту, яшь буыннарны социалистик патриотизм һәм интернационализм рухында, Ватанга бирелгәнлек, аны сакларга һәр вакыт әзер тору рухында тәрбияләү өчен кирәк.

Сугыш темасына язылган китапларыбызның тарихи миссиясен, аларның сугышчан әһәмиятен КПСС Үзәк Комитеты совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңүенә 30 ел тулу уңае белән махсус кабул иткән карарда әнә шулай бәяләде.

Сугыш елларында совет халкының фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыгын киң һәм күпкырлы итеп тасвирлаган әсәрләр илебезнең барлык тугандаш республикаларында да күпләп иҗат ителде. Алар арасында инде бөтен дөньяга билгеле гүзәл китаплар да аз түгел. Безнең Татарстан әдипләре генә дә, мәсәлән, 40 тан артык роман һәм повесть, шул хәтле үк сюжетлы-вакыйгалы поэма, егерменән пьеса, күпләгән очерк, хикәя һәм шигырь китаплары бастырдылар. Әгәр татар язучыларының һәр өчтән икесе сугышта үлеп калуын да (фронтларда 33 әдибебез һәлак бул-

ды...) искә алсак, алда китерелгән саннарның мәгънәсе никадәр зур икәнен тагын да тирәнрәк аңларбыз. Ул китапларның күбесе илебез халыклары телләренә һәм чит телләргә тәрҗемә ителде. Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»нә кергән шигырьләре, сугышчан һәм поэтик батырлык темасына караган китаплар арасында беренчеләрдән булып, Ленин премиясе белән бүләкләнде. Соңрак елларда чыккан китаплар арасыннан Габдрахман Әпсәләмовның Ватан сугышының өч яшь батыры турындагы өч повестен, Хисам Камаловның «һәркемнең гомере бер генә» исемле романын, Геннадий Паушкинның чик буе сакчылары, Юрий Белостоцкийның очучылар тормышын чагылдырган повестьларын күрсәтергә мөмкин. Үзләренең хәрби биографияләрен гомумиләштереп, Әмирхан Еники «Без дә солдатлар идек», Әдип Маликов «Яшьлек утравым» дигән повестьларын яздылар. Самат Шакир үлем лагеренда җәзаланган коммунист, командир һәм әдип Хәйретдин Мөҗәйнең сугышчан юлын ачыклады һәм аның сугыш елларында язган әсәрләрен укучыга җиткерде. Бу темага караган китапларның хәзер күпчелеге яшь буын авторларның еллар буе эзләнүләре, документлар өйрәнүе нәтиҗәсендә туа. Шамил Рәкыйповның әдәби-документаль повестьлары — нәкъ шундыйлар. Ул очучы Мәгубә Сыртланова һәм аның полкташлары турында «Кипарислар җыры» дигән тагын бер китап чыгарды. Кырымны азат итү сугышларын тасвирлаган бу әсәр әнә шундый матур символик исем белән аталган.

Кыскасы, бу темага совет язучылары һәм социалистик илләрдәге каләмдәш дусларыбыз язган әсәрләр санап бетергесез! Димәк, тикшерәсе һәм беләсе нәрсәләр күп, тупланган тәҗрибә зур — хәзер, шулардан чыгып, киләчәк өчен яңа иҗади проблемалар билгеләргә кирәк.

Җиңүче солдатның күренекле рәссамнарыбыз эшләгән титаник һәйкәле Берлинның үзәгендә — 1945 елның маенда безнең гаскәрләребез бәреп кергән Рейхстагка якын гына бер урында тора. Аның бөтен кыяфәтендә тантаналы бөеклек һәм чиксез тирән символик мәгънә бар: биек постамент өстендә ялан баш кыю солдат басып тора. Өстендә поход гимнастеркасы, киң җилкәсенә плащ-палатка япкан. Аның уң кулында фашистлар свастикасын аяк астына салып туракланган зур кылыч, ә сул җилкәсенә исә зур ышаныч белән нәни бер кызчык сыенган. Еракка төбәлгән караш. Кысып йомылган иреннәр. Әмма йөрәге түреннән көчле тавыш белән: «Батырлыкка дан! Бернәрсә дә онытылмады, беркем дә онытылмас!» дигән сүзләр күкрәп чыгадыр шикелле.

Биредән аның үткен күзләренә Европада ул үзе азат иткән илләрнең якты таңнары да, Германия фашизмын һәм Япония милитаризмын тар-мар иткәннән соң күп кенә илләре колониаль коллыктан инде азат булган ерак Азия, Африка, Латин Америкасы киңлекләре дә ачык күренә булыр.

Кайчандыр бөек Ньютон болай дигән: «Әгәр мин бүтәннәрдән ераккарак карый һәм ерагракны күрә алганмын икән — димәк, мин гигантлар җилкәсенә басып торганмын». Безнең җиңүче солдатыбыз да нәкъ шулай: аны Октябрь революциясе җиңгәч туган безнең гигант Ватаныбыз җилкәсе, илнең экономик куәте шундый биеклеккә күтәргән. Әнә шуңа да ул карашы белән бик ерак араларны иңли ала. Басып торган постаменты да аның үзенә бер төрле аерым материалдан ясалган: образлы итеп әйтсәк, ул материалны коммунизмның җиңүчән идеяләре белән безнең морально-политик бердәмлегебез катнашмасыннан торган иң нык корыч диярга мөмкин.

Җиңүче солдат портреты матур әдәбиятта нинди штрихлар белән сызыла соң?

Ул — барыннан да элек, партия тәрбияләгән яңа, егерменче гасыр кешесе, Ватанның саф намуслы, идея ягыннан нык чыныккан патриоты. Аның ил дошманнарына каршы аяусыз көрәшкә әзерлек хисе беркайчан да сүнми-сүрелми. Үзенең батырлык эшләргә һәр вакыт ашкыну хисләрен шагыйрь һәм солдат Фатих Кәрим сүзләре белән:

**Дошманга ялкын сибүче**
**Җил булып барсам иде.**
**Тәвәккәллек, батырлыкта**
**Җыр булып калсам иде,—**

дип өзеп әйтә ул. Шагыйрьнең тимер һәм тимерче турындагы балладасындагыча уйланып, тимер тауны — дошман танкын бернинди куркусыз чәлпәрәмә китерә ул

һәм «сулый танк янында — гүя аны өреп яндыра». Чөнки җиңүгә бару юлында аның адым саен, минут саен күңелендә кабатланган иманы шундый:

**Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла,—**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

Муса Җәлил әйткәннәр белән нихәтле аваздаш фикер:

**Батырлык һәм илгә тугрылыкны**
**Шушы үлем белән белдерик!..**

Аннары менә шагыйрь һәм солдат Алексей Сурковның инде безнең гаскәрләр немец җиренә барып кергәч әйткән сүзләре:

**Югалту көннәре, кайгы-хәсрәт көннәре аша**
**Килдек без бу илгә — һөҗүмче иленә.**
**Бер адым чигенми, һич тә бил бөкмичә**
**Күтәрде һәр солдат зур йөкне иңенә.**

Кутуйча итеп әйтсәк исә, җиңүче солдат бер генә сүзгә — «Алга!» сүзенә генә өйрәнгән батыр ул. Ул ата-бабасы корган илендәге изге йорты турында уйлап көрәшә һәм шунда тизрәк кайтыр өчен Берлинга ашыга. Ул горур атлый, чөнки чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөри ул. Аңа «һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык». Берлинга ул «иле белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен» чиксез ачу белән бара. Илне сагыну аның көч-дәртен арттыра, рухын канатландыра: «Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу хәтле сагынмас идем». Һәм «сугышчы баһадирларның исемнәрен йолдызлар белән күккә язып булсачы!» дигән нәтиҗәгә килә әдип Кутуй, солдат Кутуй.

Ә бу соңгысы исә һәр вакытта да кешенең югары мораль сыйфатларга ия булуын күздә тота. Бары тик шундый солдат яки партизан, шундый офицер яки генерал гына үз бурычына турылыклы була белә, үз эшенең хаклыгына ышанып көрәшә, кирәк булган чакта исә, я самолеты белән дошман самолетын шартлатып, я үз гәүдәсе белән дошман амбразурасын каплап шуны исбат итә ала. Батырлык эшләүне аның йөрәге таләп итә, батырлык аңа ирекнең үзе шикелле үк кадерле нәрсә. Шуңа күрә ул «көчемне дә, гомеремне дә кызганмыйча дошманнан рәхимсез үч алырмын!» дип солдат анты яки партизан вәгъдәсе язылган кәгазьгә кул куйды. Соңыннан исә ул үз фамилиясен, штык очы белән уеп, Рейхстаг ташына язды. Бу — бер үк вакытта аның «кешелек тормышында сугышлар гомумән булмаска тиеш!» дигән документка салган имзасы да иде.

Әмма җиңүче солдат 1941—1945 елларда бөек Маркс һәм ялкынлы Тельман иленә, Гёте һәм Гейне, Бах һәм Бетховен иленә каршы сугышмады, Германияне, немец халкын мәсхәрәләмәде ул. Аның миссиясе — халыкларны фашизм афәтеннән коткару иде. Чөнки бит тулаем алганда халыкларның берсенең дә кешелеккә дошман булуы мөмкин түгел.

Берлинның үзендә башын фашист балтасы кискән Җәлил сүзләрен хәтерлик. Ул бөек Маркс иле һәм давыллы Шиллер ватанының «алар бакчасында үскән гөлләр»гә — немец халкының мәгърур егетләренә мөрәҗәгать итә:

**Борыгыз муенын комсыз карчыганың!**
**Кояш чыксын алман җиренә,**
**Күтәрелсен Тельман трибунага,**
**Маркс, Гейне кайтсын иленә!..**

Илле миллионлап кешенең башына җиткән сугышны кабызган җиргә — җан тетрәткеч вәхшәтләр эшләгән фашистларның үзләре тарафыннан җәрәхәтләгән герман иленә совет солдаты азатлык алып килгәч, ул анда бик күп ачларны күрә, немец баласына ипи телеме тоттыра, бик күп картлар-карчыкларны, хатын-кызларны

үлемнән аралый. Юк, гадел сугышчы йөрәге намуслыларга үч белән дә, көч белән дә янамады һәм янамый. Ә совет иленә басып кергән, дәүләтебезне юк итәргә план корган көчле һәм мәкерле фашистлар исә халыкларга үчле иделәр.

Үз кулына эләктерергә теләгән җирләрнең зурлыгы турында уйлап, Гитлер «немец сабаны белән сөреләсе ул мәйданнарны кылыч яулап алырга тиеш» дигән. Инде билгеле булган документларга караганда, Советлар илен ул гаять зур бәлеш белән чагыштыра һәм аны «бердән, кулга төшерергә, икенчедән, аның белән идарә итәргә, өченчедән, аны эксплуатацияләргә кирәк» дип яза. Җинаятьчел максатларны тормышка ашыру өчен, шундый ук җинаятьчел чаралар билгеләгән күрсәтмәләр дә (Герингның «яшел папкасы», палач Кейтель приказлары һәм инструкцияләре, Розенберг указлары, «Ост» һәм «Барбаросс» исемле планнар) сугышны башлаганчы ук бик күп алдан эшләнә. Аларның коточкыч эчтәлеген аңлату өчен хәтта сүз табуы кыен. Гитлерчылар, үзләре теләгән колонизаторлык режимын гамәлгә ашыру өчен, совет кешеләрен куркытып һәм күпләп кырып, ә калганнарын Себергә куып бетерергә уйлаганнар, яулап алынган җирләргә исә немецларны күчереп урнаштырырга хыял корылган.

Шушы документлардан кайбер юлларга гына булса да күз салып үтик:

...Табигый ки, гигант мәйданның бугазын мөмкин кадәр тизрәк томаларга кирәк. Моның өчен иң яхшысы — безгә кырын караган һәркемне атып үтерү.

...Көнчыгыштагы тарихи һәм әдәби истәлекләрнең берсенең дә әһәмияте һәм кыйммәте юк.

...Үтерелгән һәр немец солдаты өчен... кимендә 50—100 коммунистны юк итәргә.

...Халыкны яхшы ашату турында сүзнең булуы да мөмкин түгел... Аны биологик яктан хәлсезләндерү өчен бик күп юллар бар... яулап алынган җирләрдә без халык санын аңлы рәвештә киметергә тиешбез...

...Аерым өлкәләрне планлы рәвештә аерып-бүлгәләп алу — рус халкының көчәюенә каршы иң мөһим чара. Рус булмаган халыкларны теләсә нинди очракта да Мәскәүгә исәп тотмаска диган фикергә инандырырга кирәк... Ул халыклар үзара аралашсын-бәйләнешсен өчен анда немец теле кертүне уйларга...

Нацистлар совет кешеләренә хас иң изге һәм иң көчле көчкә — халыклар дуслыгына әнә шулай кизәнәләр, үзләренә үлем белән янаган шул дуслыкны таркатып, Россияне яшен тизлеге белән ай ярым-ике ай эчендә басып алырга җыеналар...

Әмма үзенең һәр сүзендә һәм һәр адымында халыклар дуслыгын яклаган Җиңүче солдат фашистларның бу кыргый планнарын, гаять зур чыдамлык белән һәм бик күп көч куеп, җимерде, юкка чыгарды. Кайбер фронтларда, әйтик, мәсәлән, Новороссийск янындагы «Үлем Үзәнлегендә», шул солдатның өстенә бер тоннадан артык снаряд һәм бомба яудырылган чаклар да булганы билгеле. Ләкин шундый дошман да халыклар дуслыгы көче белән бергә кушылган совет коралы көченә каршы тора алмады. Хәзер ирексездән шуны уйлыйсың: Берләшкән милләтләр оешмасы уставына: «халыклар бергә, үзара дус булып, яхшы күршеләр кебек яшәргә тиешләр» дигән юллар нәкъ шул чакта, Ватан сугышы фронтларында, безнең утлы пулялар ялтыравы белән, бомба чокырлары тезмәсе белән язылгандыр кебек!

Җиңүче солдат, фронт вәкиле буларак, башта, әлбәттә, илебез башкаласы Мәскәүгә кайтты һәм анда Владимир Ильич Ленин Мавзолееның алдына дошман кулыннан тартып алынган байракларны ташлады. Фронтның иң алгы сызыкларында үзенең батыр һәм күңелле юлдашы Василий Тёркин белән бергә йөргән кыю шагыйрь Александр Твардовскийның ихтирам сүзләре аңа, Ватан исеменнән, бәлки нәкъ шул чакны юллангандыр да:

**Синең солдатың — Ватаны өчен**
**Кан һәм тир түккән яклаучың кайтты.**
**Дүрт ел йөрде ул зур походларда,**
**Янган чакта да хәтәр утларда**
**«Яшәргә телим!» дип кенә әйтте.**
**Үтәде солдат изге бурычын**
**Синең мәңгелек байрак хакына.**

**Синең хактан да кемнең хакы зур**
**Кумәргә аны сөю — ялкынга!**

Үзенең тантаналы салюты һәм сүзе белән, залпы белән сугышка соңгы ноктаны шулай куйганда Җиңүче солдатның нәрсә уйлап, нәрсә теләгәнен күз алдына китерүе һич кыен түгел: моннан соң җирдә минем Ватаным бары тик тынычлык фронтында гына һөҗүм алып барсын һәм ул һөҗүмнең төп лозунгысы менә нинди булырга тиеш: «Тынычлык телисең икән — тынычлык политикасы өчен көрәш!»

Шулай, һичшиксез шулай әйткән Җиңүче солдат.

Һәм менә инде ул — тыныч хезмәт фронты көрәшчесе. Рус шагыйре Михаил Луконин сугыштан аның буш җан белән кайтканчы, буш җиң белән кайтуы яхшырак дип язган иде. Юк, Җиңүче солдат фронттан кешеләргә һәм хезмәткә — димәк, тагын батырлык эшләргә! — мәхәббәт ташып тулган җан белән кайтты. Чөнки, шул ук Луконин әйткәнчә, яуда көрәшкән өчен медаль дә, хезмәт җиңүе медале дә бер ук металлдан коела бит. Безнең хәзерге яшь буынга эштә батыр, тормышта матур булырга менә нинди остаздан өйрәнергә кирәк!

...Сугыш турында моңарчы язылган әсәрләребездә сурәтләнгән, хәзер исә тормышта сугыштан соңгы буын белән янәшә басып бер сафта атлаган Җиңүче солдатның җыелма образы әнә шундый гади һәм шундый якты, әнә шундый күптөсле һәм күпкырлы. Аның бүгенге көн белән рухи элемтәсе шундый нык һәм шундый сокландыргыч! Кайчандыр күпләп күтәргән сугыш йөкләренең авырлыгын гүя хәзер дә җилкәсендә тоеп, ул ерак киләчәккә атлый. Батырлыгы аның яшьләр йөрәгенә дәртялкын өсти. «Дошманның ут ноктасына күкрәге белән капланып аны сүндерде...» Александр Матросовның комсомол билетына язылган бу сүзләр дистәләп еллар узгач Анатолий Мерзлов билетына «Авыл хуҗалыгы техникасын һәм 1972 ел уңышын коткарганда һәлак булды» дип язылган сүзләр белән аваздаш яңгырый.

Бу турыда уйланулар киләчәктә безгә сугыш батырларының характер сызыкларын тагын да яктырак буяулар белән, тагын да калкурак итеп күрсәтергә ярдәм итәчәк.

Әдәбиятта магистраль темаларның берсе саналган бу тема әле бик күп яктыртылырга тиеш һәм яңадан-яңа әсәрләр туктаусыз языльр да. Алар идея-тематик яктан да, жанр төрлелеге белән дә, тормыш дәреслеген раслау осталыгы белән дә баерак була барырлар. Чөнки сугышның тарихи сабакларын әле кабатламаган, кулланышта булмаган сәнгатьчә алымнар белән сурәтләргә, батырлык чыганаклары һәм үрнәкләренең моңарчы күрелмәгәннәрен эзләргә һәм табарга кирәк. Бу бит батырлар даны алдында баш ию өчен генә түгел, ә замандашларыбыз тормышта үзләре кылган эшләрне Ватанга хезмәт итүнең иң югары үрнәкләре белән чагыштырып бәяләсеннәр өчен кирәк.

Әдәби хезмәтнең иң төп күрсәткече булганы өчен, сыйфат сүзе бирелә дә «иң яхшы» дигән эпитет белән генә бәяләнергә тиеш. Чөнки ашыгып, эзләнмичә, теләсә каян яки теләсә кемнән «прокатка» алган алымнар белән язганда теләсә нинди яхшы теләкнең дә юкка гына чыгуы мөмкин. Ә соңгы елларда алымнар охшашлыгы — бигрәк тә поэзиядә — күзгә бәрелеп тора башлады.

«Мин Ржев янында үлдем...» дип исемле Александр Твардовский үзенең сугыш елларындагы бер шигырен. Анда һөҗүмдә һәлак булган кеше үз үлемсезлеге турында үзе сөйли. Бөтенесе солдатча конкрет: бернинди артык сүз, декларация һәм эндәш билгеле шапырынулар юк. Шуңа да аның герое, аның авторы кебек үк, шигырь туган көннән башлап ук үлемсезгә әйләнде. Бераз икенчерәк тавыш биреп, әмма шулай ук истә калырлык үзенчәлек белән Грузиянең зур шагыйре Ираклий Абашидзе бер шигырендә капитан Бухаидзеның шундый ук үлемсезлеген сурәтли. Кавказ тауларында дошман пулясы еккач, әлеге капитан, әгәр терелә алсам:

> **Һөҗүмнәрдә тагын бирер идем**
> **Йөрәгемне туган ил өчен.**
> **Үлләр идем инде мине күптән**
> **Каплап торган шушы җир өчен,—**

дигән сүзләрен әйтә. Аннары без әрмән каләмдәшебез Ашот Грашиның кыска, әмма зур эчтәлек салынган шигъри этюдында тормышчан һәм күңел тәтрәткеч юлларны укыдык:

**Мин төш күрдем: төнлә ишегемне**
**Яуда үлгән дуслар кактылар.**
**...Блиндажымны — бар да иелеп керде,**
**Мылтыкларын кысып күкрәккә.**
**«Менә,— диләр,— хәзер безнең Җиңү**
**Дөнья күген ничек күкрәтә!**
**Юк, җырлама үлем хакында, дус!**
**Кара гүрдә күптән черсәк тә,—**
**Безнең учтан үсеп чыга үлән**
**Язгы-җәйге матур бер чакта...»**

Ә менә хәзер үзләре сугышны күрмәгән күп кенә яшь авторларның шигырьләре дулкын арты дулкын булып укучы өстенә ябырыла башлады. Җиңел — һәм инде үтелгән! — юл, җиңел алым сайланганлыгы күренеп тора. Ә бит охшашлыклар һәм кабатлаулар — кипкән бер елганың ике яры ул.

Хәрби темага язу, үзеннән-үзе аңлашылганча, вакыты белән бары тик яшьләр эше булачак.

**Солдат идем. Күземә сугыш керде:**
**Янгын итеп күрәм ал таңны.**
**Күк күкрәве исә хәтерләтә**
**Фронтларда туплар атканны.**

Яшьләребез әнә шулай дип, фронтовик шагыйрь Михаил Дудинча итеп, беренче заттан, әлбәттә, яза алмаслар. Алар инде икенчел материал җирлегендә эшләргә, сугышта катнашучыларның истәлегенә, архив материалларына мөрәҗәгать итәргә тиеш булалар. Ә моңа исә бик бирелеп өйрәнергә кирәк.

Һәм, ниһаять, сугышчы турындагы китапларның елмаюлы-көлүле булуларын яклап та берничә сүз әйтмичә булмый. Күңелле булу, шаяра белү — совет кешеләре характерының бер сыйфаты бит ул. Хәрби прозабызның иң яхшы үрнәкләре, нинди генә кыен шартларда да аптырап, сагышланып калмаган, киресенчә, нинди дә булса мәзәк сөйләп, тапкыр сүз, урынлы кулланылган фольклор уклары яудырып көрәштәшләре күңелен һәр вакыт күтәргән солдат Василий Тёркинның һәм җыелма, һәм классик образы, шулай ук фронтларда татар телендә чыккан газеталарда Хуҗа Насретдинны сөйләтеп бирелгән көлке һәм үткен материаллар моңа ачык мисал. Без, партизаннар, мәсәлән, белорус телендә чыгарылган «Фашист-еланны таптап изик!» дигән сатирик газета материалларының бөтенесен диярлек ятлый һәм халыкка сөйләп йөри торган идек. Алар дошманга нәфрәт һәм үч хисен үстерде.

Быел нәшриятыбыз чыгарган «Кыска җырлар» китабында да (төзүчесе Илбарис Надиров) халыкның Ватан сугышы елларындагы елмаюлы һәм чәнечкеле иҗатыннан менә дигән шәп үрнәкләр бар. Мисалга ике генә җыр китерсәк тә җитәр кебек:

**Сукыр Гитлер сука сөрә,**
**Утырып елый межага.**
**Безгә нужа күрсәтәм дип,**
**Үзе калды нужага.**

**Килгән чакта немец килде**
**Ике аягы белән.**
**Кире сыптыралар хәзер**
**Култык таягы белән.**

Сугыш турында акыллы да, күңелле дә булган яңа китаплар белән очрашуны без барыбыз да зарыгып көтәбез!

Безнең армиябез, Максим Горький әйткәнчә, бары тик хәрби көч кенә түгел, ул һәр вакытта культура көче дә булды һәм булачак. Чын сугышчы ул үзе дә күңеле белән шагыйрь һәм иҗатчы. Аның батырлыгын әсәрдән-әсәргә тирәнрәк һәм киңрәк сурәтләп яхшы китап язу — бу үзе дә героика, бу үзе дә батырлык. Җиңүче солдат портретына штрих, аның турында гимнга өстәр өчен, хәрбиләрчә әйткәндә, мишеньнең нәкъ уртасындагы «алмага» тия торган иң көчле сүзләр эзләү фронтындагы җиңүләребез күп булсын!

# ШАГЫЙРЬ МАКТАР ИДЕ АНЫ...

Совет Армиясендә озак еллар хезмәт итү дәверендә солдатлардан, сержантлардан, офицерлардан ... мин бик күп гүзәл кешеләрне очраттым. Барысы турында да дип әйтмим, шулай да мин аларның күбесе турында күңел түрендә хәзергәчә якты истәлек саклыйм. Шулар арасыннан сержант Царевны мин бервакытта да онытмаячакмын. Әле дә булса, егерме елдан соң да, ул минем өчен чагыштырып карау, үлчәү билгесе, эшләүче барлык кешеләрнең эталоны булып калды.

Царев безнең В. В. Куйбышев исемендәге Хәрби-инженерлык академиясенең өйрәнү полигонында 1953—1954 елларда хезмәт итте. Аның исемен хәтеремдә саклый алмаганлыгым өчен укучыларым алдында гафу үтенәм, мин аңа күңелемнән хәрбиләрчә ике сүз белән дәшәм: сержант Царев!

Татарстаннан килгән бу егетнең тормышы — даими хезмәт, яшәү мәгънәсе — хезмәтнең зарурилыгын тою иде. Нинди генә авыр эшкә тотынмасын, ул аны җиңмичә һәм, һичшиксез, җиренә җиткермичә туктауны белми, хәзергечә әйтсәк, сыйфат билгесенә лаек булырлык итмичә башкармый торып тынычланмый иде. Һәм башкарылган эшенең аяк астында ялтырап ятуын күргәч, ул канәгать булуыннан күңеле килеп, бер елмаеп куяр иде дә шундук яңа эшкә керешер иде. Мондый минутларда аның шатлык бөркеп торган күзләренә, яктырып киткән йөзенә караулары ничек рәхәт булуларын белсәгез икән!

Царев атланып йөрергә өйрәтергә алып чыгылган кырыкмышны иярләгән җайдакка охшый иде. Ул белә: нинди генә четрекле эш булмасын, тай аңа барыбер буйсыначак, буйсынырга тиешле! Әгәр дә инде эше үзе теләгәнчә генә бармаса, ул танып булмаслык хәлгә килеп үзгәрә, кыюлана, тәвәккәлләнә, «хәтәргә» әйләнә. Куллары җитезләнә, коралларны очырып кына йөртә, әллә нинди хәйләле яңа алымнар уйлап чыгара. Царевны эш өстендә күргәннәрдән берәү, бу хәлгә сокланып, «аның куллары да уйлый» дигән иде. Бик тә урынлы, таман әйтелгән сүзләр иде болар, чөнки чыннан да сержант нинди дер бер гап-гади эш башкармый, бәлки иҗат итә, көрәшә һәм шул көрәштә, шул иҗатта үзе теләгәнгә ирешә, җиңә.

Ул уртачадан калкурак буйлы, киң җилкәле, нык бәдәнле татар егете-керәшен иде. Аз сүзле, тәмәке тартмас, эштә «перекур»ларны танымас булды. Аның кыскычлардай зур, һәрнәрсәгә чытырдап ябышучан куллары һәрчак нинди дә булса шөгыль эзләр. Эшсез утыра алмас ул, ялкау утырып та арый, дип санар.

Үзенә генә хас бер дусларча елмаю белән башкаларга да булышыр:

— Бир, әйдә, мин... яле, эшләп карыйм әле, — дияр.

Күбесе аның соравына күнәр, ә кайберәүләр, аның иркенә буйсынмаска теләп, карышып та маташыр иде. Андыйларга да ул сүз әрәм итеп тормас, бәлки тыныч кына кысрыклар һәм барыбер эшне үз кулына алыр иде. Үзенчә эшләр, карап торучылар аның эш рәтен белүенә сокланмый калмас һәм, шул үрнәккә буйсынып, яңа дәрт белән уртак хезмәткә кушылыр иде.

Аның хезмәт сөючәнлеге башкаларга да күчүен күзәтеп торырга ярата идем мин. Царев янында кешеләрнең йомылып, яшерелеп яткан иҗади энергияләре кузгала сыман иде.

Менә ул утын яра. Өлгер хәрәкәтләр белән, матур итеп яра. Балтаны баш өстенә күтәрми, ә ике кулы белән дә яннан китереп уң иңбашы тирәсендә борып ала да, бөтен гәүдәсе белән һәм ничектер сызгыртып дигәндәй, аны калын агач кисентесенә китереп ямый. Күкрәгеннән «ха-х» дигән аваз бәреп чыга һәм теләсә нинди ботакларың чәлпәрәмә килеп ярыла.

Ә җирне куллары белән генә түгел, ә бәлки бөтен гәүдәсе белән казып ташлый. Җир астыннан казып барганда ул алдан беренче кеше урынын берәүгә дә бирми. Кечкенә көрәк белән баштан асны кимерә, эчкә үтә, аннары аста калам дип өрекми, катлам җимерелеп төшкәнче шулай итә.

Беркөнне төшке аш вакытында, барлык подразделениеләр ял иткәндә, мин Царевның күрше отделениенең эш урынында кәсләрне сүтеп яңабаштан тезгәнен күреп алдым. Ул тырыша-тырыша чокырчакырны тигезли, сыйпый, сылый, ягъни шапшак эшне сыйфатлы итеп ята иде.

— Нигә сез ял итмисез һәм кеше участогында маташасыз? — дип сорадым аңардан.

— Матурлык һәр җирдә кирәк, — дип җавап бирде ул, — ә бирedә кәсләр, кайчандыр әтием әйткәнчә, «миннән киткәнче, иясенә җиткәнче» дип кенә түшәлгәннәр.

Сержант Царев отделениесен мин ике мәртәбә хәлиткеч участокка — комлы забойга куйдым. Агып торган комда эшләр өчен кулланма сыйфатында без беренче мәртәбә яңа алымны сынап карарга булган идек. Шул сынауны тапшырдым мин Царев егетләренә.

Сержант Царев отделениесе бирелгән норманы өч мәртәбә арттырып үтәде. Бу безнең өчен шул чаклы мөһим уңыш иде, мин аны бүләкләргә карар кылдым. Чөнки ул үзенең иптәшләре белән бергәләп яңа механизациягә юл ачты. Эшләнгән эшләргә йомгак ясап, бөтен ротага мактау сүзе әйткәннән соң мин Царевны сафтан чакырып чыгардым да, мөгаен, устав таләп иткәнчә булмагандыр да, үз итеп:

— Иптәш сержант, сезгә шәхсән командир рәхмәте белдерергә телим. Бергәләп башкарган иҗади эшебез истәлеге итеп менә шушы кул сәгатен кабул кылуыгызны үтенәм, — дидем.

Ләкин аңа таба сузылган кулым һавада эленеп калды. Царев сәгатькә үрелми иде.

— Алмыйм... — диде ул әкрен генә, күз карашын читкә күчереп.

— Нигә соң? Безнең арада бит чын мәгънәсендә иҗади хезмәттәшлек көчле.

— Алмыйм, — дип кабатлады ул үҗәтләнеп. — Күзгә күренеп торган түбән норма билгеләдегез. Сез сәгатенә ярты метр бирдегез, ә минемчә, ике метрны үтәргә дә була!

Сафтагылар катып, сүзсез калдылар. Царев уйланып куйды, аннан болай диде:

— Ләкин мин метр ярым гына бирдем. Бу машина янында уйларга кулларым өйрәнеп җитмәгән әле...

Бу сүзләрне ишетеп, рота шаулап көлеп алды. Ихлас күңелдән, бер нәрсәне әйтә-әйтә көлделәр:

— ...куллар уйлый! ...Бер ярым аз! . . .куллар белән ничек уйларга! Менә әйтте ичмасам!..

Шунда мин бар тавышым белән:

— Чөяргә аны, егетләр, бүләкне алырга ризалатканчы чөяргә үзен!

Барысы да йөгерешеп килеп, Царевны күтәреп алдылар да һавага чөяргә керештеләр.

— Өч... дүрт... Аласыңмы? Алмыйсың? Өч... дүрт...

Мин моңа күңелем тулып карап тордым. Ә башымда әле генә аңардан ишетелгән сүзләр яңгырап тора иде: «Кулларым уйларга өйрәнеп җитмәгән әле...» Һәм миңа үз эшенә гашыйк хәрби кеше әйткән әлеге гади сүзләрдә искиткеч зур мәгънә бар сыман тоелды. Чыннан да, күнегелгән куллар аң катнашыннан башка да хезмәт башкара алалар. Ә мин Царевка, аның егетләренә яңа машинада эшләүне беренче генә мәртәбә тапшыруым иде. Царев алдында чыннан да мин гаепле — аңа тулы көченә эшләргә әле мөмкинлек тудырмавым белән гаепле була язганмын икән бит.

Һавага биш-алты тапкыр чөелеп-очып төшкәч, Царев килеште:

— Ала-а-ам! — дип бирелде.

Кыш үтте. Яңа иҗади эзләнүләр белән тулы булды ул. Һәм менә без Беренче Май демонстрациясенә чыгарга җыенабыз. Колоннага баскач, Царев, күз карашы белән һәм башын селкеп, лаборант кызларыбыздан берсе кулындагы транспарантка ымлады. Мин шуны аңлап алдым: Царевның куллары буш булмаска тиеш, алар монда да эшләргә тиеш бит! Без транспарантны аңа тапшырдык. Ул моңа шатланды, елмаеп кына үзенең рәхмәтен белдерде.

Сержант Царев белән без күп нәрсәләр турында сөйләштек. Әмма иң кызыклысы «уйлый белүче куллар» турында булды. Чыннан да куллар «уйлый» килеп чыга бит. Кеше күңел салып, зиһенен биреп, эзлекле төстә эшләгәндә әкренләп уйлар кулга күчә бара. Күп тапкыр күнегүләрдән соң алар эш барышындагы һәр операцияне «сукыр килеш» тә җиренә җиткереп башкара башлый. Үзенә бер төрле стереотип барлыкка килә, димәк. Музыкант, мәсәлән, уйлары концерт залыннан еракта килеш катлаулы әйберләрне башкара ала. Әйтик, слесарь бер үк вакытта деталь эшкәртә һәм шәкертләре белән гәпләшә... Ә машинисткалар арасында клавишларга карамыйча басучылар азмыни?

Царев отделениесе, яңа механизация белән эшләп, чыннан да норманы ике метрга җиткерде. Командир үз егетләрен аларның да куллары «уйлый» башлаганчы өйрәтте.

... Сержант Царевны күптән күргәнем юк. Ул хәзер унынчы бишьеллык төзелешләренең берсендә эшли булыр. Әмма минем хәтергә ул үзенең хезмәте, эшче таланты белән кереп калган. Армия аның бу талантын тагын да үстереп җибәрде.

Яраткан сержантымны мин еш искә алам, бүгенге яшь солдатларга аны үрнәк итеп куям. Аны уйлаганда һәр чак бөек Шиллерның: «Кешенең гүзәллеге һәм гасырларны кичәр намусы кулы эшләгәннең бәһасын йөрәге белән тоюында», дигән сүзләре хәтеремдә яңара. Безнең сержант Царев кебекләр турында әйтелгән шагыйрьнең бу сүзләре.

В. КАБАНОВ,
полковник-инженер, техник фәннәр кандидаты, доцент.
Мәскәү.

**Мәгъсүм Гәрәев**

# ҖИҢЕЛМӘС КАПИТАН

## Кереш сүз урынына



Гайнан Сәетхуҗинның исеме дөньяда велосипед спорты тарихы сәхифәләренә җуелмас хәрефләр белән язылды. Ун тапкыр СССР чемпионы, Рим Олимпиадасы һәм дөнья беренчелеге призеры, күп кенә халыкара ярышларның «алтын лауреаты», атказанган спорт мастеры Гайнан Сәетхуҗин, үзенең «ике аяклы атын» иярләп, планетабызның бик күп илләрен гизде, дөньяны җилдән җитез тизлеге, гадилеге, ярдәмчел һәм нык характерлы капитан булуы белән таң калдырды. Атаклы спортчы СССР җыелма командасын халыкара аренага ун ел рәттән капитан буларак алып чыкты. Моңа кадәр спортның бер генә төре дә андый озын гомерле капитанны белми иде әле.

Гайнанның спорт биографиясе белән танышуны мин Сочида, аның кечерәк кенә бер музейны хәтерләткән бүлмәсендә башладым. Алтын, көмеш, хрусталь кубоклар һәм призларның, зиннәтле бүләкләр, төрле медальләрнең һәркайсына күренекле велосипедчының исеме, фамилиясе алтын хәрефләр белән язылган. Аларны кайсы илдә, нинди ярышларда алуы күренеп тора. Һәр призның үз тарихы, үз шатлыгы, үз борчулары бар. Гайнаннан күпме көч, осталык, түземлек, йокысыз төннәр таләп иткән алар. Моны фәкать чемпион үзе һәм тренеры гына белә. Призлар Гайнан Сәетхуҗинның планета буйлап сәяхәтен күз алдына китереп бастыралар. «Велосипед иярендә» ул 330 мең километр юл үткән. Призларның һәркайсы кызыклы бер новеллага тиң. Алар безгә велосипед спорты «академия»сенең серләрен көннән-көн тулырак ачалар.

Авылда үскән гади бер малай бала чагыннан ук велосипедка «гашыйк» була. Зур спортның нәрсә икәнен күз алдына да китермәгән егет, соңыннан үзенең ихтыяр көчен, тырышлыгын җигеп, совет спортын данга күмә, аны яңа баскычларга күтәрә.

Велосипед спортына җаны-тәне белән бирелгән талантның тормыш юлы мавыктыргыч һәм кызыклы эпизодларга бай. Шуларның кайберләре турында сөйлик.

«Интернациональ» отеленең зур бүлмәсендә ул бер ялгызы. Ачык тәрәзәләрдән бүлмә эченә язгы җылы җил белән бергә гүзәл Прага урамнарыннан агып кергән гүләү Гайнанга фикерләрен тупларга ирек бирми... Менә алты этап инде артта калды. Җиңү кәнәнә багышлап уздырылган велосипед марафоныньң алты кыен көне булды бу этаплар. Шәхси һәм команда беренчелегендә элеккечә үк голландиялеләр алда бара. Дөрес, безнең команда бүген икенче урынга чыкты. Әмма аны бельгиялеләр, поляклар, немецлар кысрыклый. Нәрсә булса да эшлисе һәм, һич тә кичектермичә, нәкъ менә иртәгә эшлисе иде. Иртәгә Гайнан белән бер үк мизгелдә алҗуның ни икәнен белмәүче голландияле Нийдам, полякларның тәҗрибәле пары Газда-Форнальчик, тынгысыз немец Амплер һәм тагын уннарча шундый көчле спортчы алгы сызыкка ташланачак. Бу минутта бәлки алар да иртәгә буласы хәлиткеч ярыш турында уйлана торганнардыр.

Көтмәгәндә ишек шакыдылар.

Гайнан: «Керегез!» дип җавап кайтаруга, бусагада хат ташучы күренде. Аның кулында дүрткә бөкләнгән телеграмма кәгазе иде.

Гайнан яткан урыныннан сикереп торды да кабаланып телеграмманы алды. «Узышларның барышын игътибар белән күзәтәбез. Кайнар сәлам җибәреп, җиңү телибез. Урал характерыңны күрсәт әле үзләренә! Заводтагы дусларың»,— дигән сүзләр язылган иде анда.

Гайнанның йөзе яктырып китте. Уйлары белән ул үзендә спортка мәхәббәт уяткан Чиләбесенә, эшче дуслары янына очып кайткандай булды.

Гайнан телеграмманы саклык белән генә өстәлгә куйды. Аның уйлары яңадан ярышларга барып тоташты...

Ул дөньядагы иң популяр бу ярышларга ике ел рәттән запас узышчы булып килеп тә ярыш кискенлеген татый алмыйча кире кайтып киткән иде. Ниһаять, 1960 елда тауга күтәрелгәндә биш тапкыр җиңеп, туган илебезгә ул берьюлы ике приз — «Активлык өчен» һәм «Таулар короле» призларын алып кайтты. Бер елдан аны СССР җыелма командасы капитаны итеп сайладылар. Ул елны безнең җыелма команда беренче урынны алды, шәхси беренчелектә Юрий Мелихов җиңде. Шул чакта велосипедчыларыбызның шатлыклары эчләренә сыймаган иде. Капитаннары Гайнанны алар һавага чөйделәр. Ә ул, капитан буларак, үзенең шәхси үрнәге белән егетләрен тагын да рухландырырга кирәклеген яхшы аңлады...

Менә алар яңадан стартта. Алда, җилләрне узып, Юрий Мелихов үзенең ике көпчәкле «машинасын» куа. Гайнан бераз арттарак калып бара. Аның үкчәсенә баса-баса француз, поляк һәм швед велосипедчылары килә. Бераз хәл җыеп алу өчен, Гайнан аларны уздырып җибәрә. Аннары кабат үзе алга чыга. Үнда «90» саны язылган багана күренә. Димәк, туксан километр ара узылган. Бу — бүгенге юлның яртысы диярлек.

Берсеннән-берсе биек таулар башлана. Көтмәгәндә Гайнанны румын Мойчану куып җитә.

— Тауларда синнән башка кыен, әйдә, кызурак юырт! — ди ул аңа.

Йөз дә илле икенче километрда алар Юрий Мелиховны куып җитәләр. Юра белән Гайнан бер-берсенә карашып алалар. Шуннан артыгы кирәкми. Көчне хәтта елмаюга да әрәм итмәскә — күп көн-



Гайнан Сәетхуҗин.

лек ярышларда катнашучы велосипедчыларның законы шундый. Гайнан, Юраның киң иңнәренә ышыкланып, икенче булып бара.

Менә Брноның кызыл кирпечтән салынган йортлары күренә. Стадионга юл сорап торасы юк кебек. Урамның ике ягына тезелгән меңнәрчә кешеләрнең җанлы коридоры үзе шунда илтә. Ләкин стадион капкалары алдында Юра, юлны ялгыштырып, читкә тайпыла. Медьерди белән Мойчану алга уза. Мелихов өченче булып килә.

Ике йөз егерме ике километр озынлыктагы кыен юл артта калды. Берничә сәгатьтән велосипедчылар кунак йортында чираттагы летучкага җыелдылар. СССРның җыелма командасы тренеры Леонид Шелешнев егетләренә ярыш беркетмәләрен таратты. Җиде көн дәвамында шәкертләре аның елмаюын беренче тапкыр шунда күрделәр. Беркетмәдә совет командасы беренче урынга язылган, ә шәхси ярышта Гайнан Сәетхуҗин алга чыккан иде.

Брнодан Готвальдовка кадәр йөз утыз җиде километр. Чагыштырмача артык озын булмаган бу этапта безнең команда Германия Демократик Республикасы велосипедчыларын җиде минутка отты. Гайнан Сәетхуҗин үзе бу юлы да беренчелекне бирмәде. Шушы җиңүдән соң аның командасы да, ул үзе дә калган бер этапта да оттырмадылар. 1962 елда Җиңү көненә багышланып үткәрелә торган халыкара традицион ярышларның унбишенчесе СССР командасының тулы җиңүе белән тәмамланды.

...Варшава стадионы. Әле моннан ничә ел гына элек Совет командасының запас велосипедчысы Гайнан Сәетхуҗин нәкъ менә шушыннан, ярышларда катнашу бәхетенә ирешә алмыйча, кайтып киткән иде. Ә бүген монда ул узышларның икеләтә герое — командасы да, шәхси беренчелектә дә чемпион. Авыр юлдан соң ул битеннән тирләрен дә сөртергә өлгермәде, дуслары Юрий Мелихов, Алексей Петров, Виктор Капитонов, Анатолий Черепович, Станислав Москвин ГДР, Чехословакия, Польша территориясендә 2413 километрга сузылган озын юлда үзләрен җиңүгә рухландырган капитаннары Гайнанны берәм-берәм кочарга керештеләр.

— Мондый капитан белән югалмаячакбыз, — диләр алар.

«Җиңү әләмнәре өчәү һәм алар сары, зәңгәр, шәмәхә төстә була. Бу төсләр бөтенесе дә безнекеләр кулында», дип язды ул чагында «Советский спорт» газетасы журналисты С. Токарев. Әйе, ул елны төп призларның өчесе дә безнең велосипедчыларда иде.

...Гайнан Сәетхуҗинның спорт трофейлары «музее»нда бик күп телеграммалар саклана. Менә аларның кайберләре:

«Җиңү көненә багышлап уздырыла торган ярышларның унбишенчесендә откан команданың барлык членнарын да зур уңышлары белән котлыйбыз. Чиләбе металлургия заводы эшчесе Гайнан Сәетхуҗинның җиңүе белән аеруча горурланабыз. Спортта яңа уңышлар телибез. Чиләбе металлургия заводы директоры Вяткин, партком секретаре Нефедов, завком председателе Дегтярев, комсомол комитеты секретаре Показов».

«Горурланам. Кулыңны каты итеп кысам, Гайнан,— дип яза Көньяк Уралның танылган корыч коючысы, РСФСР Верховный Советы депутаты Василий Мокронский. — Сиңа һәм синең командаңа чын күңелдән яңа уңышлар телим».



Берлин. Ярышлар алдыннан.



«Кадерле Гайнан,— дип котлый аны Чехословакиядән унбиш яшьлек укучы Ян Билек,— мин спортны бик яратам. Сез һәм сезнең барлык иптәшләрегез миңа бик ошый. Телевизор экранында мин Сезнең Готвальдов стадионына ук кебек атылып килеп керүегезне күрдем. Моны һич онытасым юк».

Телеграммалар күп. Магаданнан һәм Тбилисидан, Норильскидан һәм Таҗикстаннан, Франциядән һәм Мексикадан, Бельгиядән һәм Италиядән... Әмма Гайнан өчен аларның үзенең туган ягыннан — Чиләбедән килгәннәреннән дә кадерлерәкләре юктыр...

## «Беренче бүләгем әтигә»

Рәхмәтулла абзый — шактый кырыс кеше. Гайнанга велосипед «җене» кагылу аның күңеленә бер дә хуш килми. Улының өйгә соңга калып, ачыгып, тәмам арып кайтуын ошатмый ул. Өстәвенә, өстебашы пычранып беткән була. Сеңелләре Маһирә белән Сәгыйдә боларны әтиләренә белгертмәскә тырышалар. Гайнан капканы ачып керүгә, җылы су алып, аны юындырырга чыгалар. Өйдә исә Рәхмәтулла тамагын кыра-кыра: «Нигә юк-бар нәрсә белән азапланасың? Ташла, егет, бу эшеңне,— дип Гайнанны әрләп каршылый.— Татар халкына көрәш хас. Мин, синең урыныңда булсам, сөлге тотып мәйданга чыгар идем»,— ди.

Гайнан дәшми. Гаиләдә шундый тәртип: олыларга каршы сүз әйтеш юк. Шулай булмаганда, спорт белән хушлашуыңны көт тә тор. Ә инде Сәгыйдә дә Гайнан юлыннан киткәч, Рәхмәтулла абзыйның кәефе тагын да бозыла төшә, шулай да ул балаларының юлына киртә булырга теләми. Сәгыйдә, абыйсы белән бергә, заводның спорт секциясенә йөри. Эштән соң алар һәр көн саен икәүләп велосипедта күнегүләр ясыйлар.

Гайнанга һаман бер уй тынгылык бирми: кайчан соң ул зур ярышларда приз алыр да аны әтисенә бүләк итәр икән?.. Ә бу көн өллә ни ерак булмый инде. Ул, завод чемпионатында беренче разряд

нормасын үтәп, предприятиенең җыелма командасы составына кертелә.

Беренче җиңүдән соң спортчыны нигәдер уңышсызлыклар эзәрлекли торган була. Гайнан да нәкъ шундый җәфаны кичерә. Ул кышның-кыш буена чаңгы һәм тимераякта шуа, төп игътибарын физик әзерлеккә бирә. Ә яз җиттеме — оттыра: стартка зур өметләр белән чыкса да, финиш сызыгын һич кенә дә беренче булып үтә алмый. Бу хәл Сәетхуҗинны үчектергәннән-үчектерә һәм ул күнегүләргә вакытны тагын да күбрәк бирә башлый.

Көннәрнең берендә заводның велосипед спорты секциясенә Чиләбенең иң тәҗрибәле тренерларыннан берсе Борис Садовников килә. Гайнан аның кул астында укый, өйрәнә, характерын чыныктыра. Әмма «фәннәр» кыен, зур түземлек, көч һәм чыдамлык таләп итә. Шулай да ул кыенлыклар алдында каушап калмый. Күнегүләрнең берсендә аның велосипедының тәгәрмәч сугымы сына. Шәһәргә әле ун километрдан артыграк ара калган була. Ул велосипедын иңбашына күтәрә дә җәяүләп атлый. Шушы вакыйгадан соң атна буена секциягә барырга кыймый йөри. Ләкин спортны ярату үзенекен итә...

1955 ел Гайнанга уңышлар китерә: ул берсеннән-берсе матур нәтиҗәләргә ирешә, ярышларда җиңү артыннан җиңү яулый.

Нальчик шәһәре. Гайнан өчен беренче зур старт шунда була. Ярышларда илебезнең велосипед спорты «йолдызлары» катнаша. Аның белән янәшәдә Колумбет, Бебенин, Крючков, Чижиков, Матвеев, Плотицын... Советлар Союзының үзе бер җыелма командасы!

Төне буе йокы керми аның күзләренә. Шундый күренекле спортчылар белән узышка чыгачагына ул әле ышанып та җитә алмый... Бу старт аның өчен велосипед спортының үзенчәлекле бер университетына әверелә. Гайнан анда илебезнең иң көчле велосипед спортчылары белән очраша, аларның ярыш алымнарын өйрәнә, чемпионат аңа гыйбрәтле сабак була.

Тренерлар, яшь егетнең тырышлыгын күреп алып, аны Мәскәү — Минск — Киев — Харьков — Мәскәү маршруты буйлап күп көнлек ярышларга чакыралар. Бу шатлыклы хәбәрне аңа завод секциясендәге дусты Вадим Стешин җиткерә.

— Җыен, Гайнан, җыен! — дип кычкыра ул Сәетхуҗиннарның бусагасыннан атлап кергәч.— Сине «Металлург»ның иң көчле велосипедчылары күнегүләренә дәшәләр. Аннан — күп көнлек узышлар.

Менә стартлар көне килеп җитә. Беренчелекне алу өчен бөтен көчләрен туплаган велосипедчылар колоннасы ил буйлап чаба. Смоленск, Орша, Минск, Бобруйск шәһәрләре инде артта кала. Велосипедчыларны һәр этапта меңнәрчә тамашачылар каршылый һәм озатып кала.

Башта эшләр әйбәт кенә бара. Беренче этапны ул шактый җиңел үтә. Аннары икенчесен, өченчесен уза. Озакламый кыен һәм авыр юллар башлана. Гомельга якынлашканда салкын, зәһәр җил велосипедчыларның йөзләренә китереп бәрә һәм кәрванны тузгыта башлый. Баруы чиктән тыш кыенлаша. Куллар күшегә, аяклар кургаш итек кигәндәй авырая. Шул чак Чиләбе вокзалы перронында озатып калган дуслары күз алдына килеп баса Гайнанның... Томан эчендә тренерның йөзе күренеп киткәндәй була.

Чернигов — Киев этабы тәмамланганнан соң, лидерларны куып җиту өчен нәрсә эшләргә кирәк икән дип баш ватып утырган минутларын һич онытасы юк аның. Армия спорт клубы велосипедчылары белән ярышу уен түгел. Илебезнең җыелма командасы тулысы белән диярлек шулардан тора бит!

— Егетләр! — дип сүз башлый шунда Виктор Лобанков.— Иртәгә Гайнанның туган көне! Аңа егерме яшь тула!

Дуслары, елмаеп, Гайнанга борылалар.

Арадан берсе җитди генә итеп әйтеп куя:

— Этапны җиңсәк, бергәләшеп бәйрәм итәбез.

— Дөрес,— дип аны куәтли Юрий Макаров.— Болай булгач, син, Гайнан, Лубныга беренче булып барып җитәргә тиеш. Үзеңә Немытовны яки тагын кемне дә булса иярт тә туп-туры финишка элдерт!

Этапны оту — һәр узышчының хыялы. Һәм ул тәвәккәлләргә була. Киевта старт алу белән лидерлар рәтенә чыга. Алда «Динамо» егете Кацинскийның сары чәчле башы күренеп китә. Миша Курбатов туп кебек алга оча... Узышучылар төркеме бөтенләй бутала. Кече финиш якынайган саен тәҗрибәле осталар ярсый-ярсый һөҗүм итәләр. Гайнан да, бөтен көчен җыеп, соңгы тапкыр алга ыргыла. Асфальт юл кыскарганнан-кыскара бара. Менә ак тасма көпчәкләр астына шуып килеп керә. Гайнанның башыннан яшен тизлеге белән уй йөгереп уза: «Оттым!»

Киев — Лубны дистанциясендә җиңүе өчен аны кул сәгате белән бүләклиләр. Танылган спортчылар белән ярышта җиңеп алган зур бүләк — кул сәгате — аның беренче призы.

Ярышлардан кулына сәгать кенә түгел, күкрәгенә «Спорт мастеры» значогын да тагып кайта ул. Вокзалда аны якын дуслары Борис Садовников, Геннадий Чурбаков, Вадим Стешин, Виктор Андреев, бертуган Володкиннар, сеңелесе Сәгыйдә һәм әтисе Рәхмәтулла абзый каршылый. Рәхмәтулла абзый, кулындагы газетасын селки-селки, улына сүз ката:

— Күрче, күрче, кем кайткан! Чемпион! Рәхмәтулла малае, спорт мастеры Гайнан!

Ә Гайнан сумкасыннан «Победа» сәгатен алып әтисенә суза.

Гайнанның туган көнендә, аңа егерме яшь тулган көнне була бу истәлекле вакыйга.

## Пирамидалар илендә

Совет велосипедчылары, Прага, Цюрих, Афина аэропортларында тукталыш ясаганнан соң, ниһаять, Каһирәгә килеп җитәләр. Мисыр халкы һәм күп көнлек узышларны оештыручылар пирамидалар иленә беренче тапкыр аяк баскан безнең спортчыларны җылы каршылый.

Булачак узышлар һәм совет спортчылары турында Каһирә матбугаты күп яза. Газеталарның берсендә безнең велосипедчылар менә мондый юлларны укыйлар: «Совет спортчылары Мисыр буйлап узышта беренче тапкыр катнаша. Аларга әле трасса таныш түгел, команда халыкара ярышларда тәҗрибәсе булмаган велосипедчылардан төзелгән. Әмма алар башка командалар белән тигез көрәшәчәкләр һәм русларның җиңүе шик тудырмый».

...Менә велосипедчылар утырган поезд старт бирелергә тиешле Луксорга килеп җитә. Тугыз илдән килгән кырык биш велосипедчыны борынгы милли киемнәр кигән егетләр һәм Мисыр велосипед спорты федерациясе президенты Исмәгыйль Таһир котлый. Шуннан соң велосипедчылар кәрваны 221 километр озынлыктагы юлга кузгала. Юлның беренче өлешен барысы да диярлек бер үк тизлектә үтә. 130 нчы километрда Болгария һәм Румыния командаларыннан

кешәр, ГДРдан бер узышчы алга чыга. А. Олизаренко, Г. Сәетхуҗин һәм команда капитаны А. Черепович алардан калышмаска тырышалар. Сохагтагы финишка 10 километрдан кимрәк ара калып бара. Шушы араны узганда Болгария велосипедчысы Б. Коцев, румын К. Мойчану, ГДРдан Г. Штользе, безнең егетләрдән Г. Сәетхуҗин төп группадан алга чыгалар. Б. Коцев финишка — беренче, Гайнан өченче булып килә. Дистанция алты сәгать унбиш минут илле ике секундта узылган. Бу — уртача тизлек сәгатенә 35 километрга якын дигән сүз. Эсселек утыз градуска җиткән кызу көндә һәм комлы юлда уздырылган ярыш өчен начар нәтиҗә түгел!

Ләкин бу әле озын һәм ялыктыргыч юлның башы гына. Алда — яңадан 1700 километр... Сохаг — Асьют этабы Гайнаннар командасы өчен, мөгаен, иң күңелсез булгандыр. Стартта тузан өермәсе күтәрелә. Безнең велосипедчылар венгр Г. Торокның алга узып китүен абайламый калалар. Г. Торок йөз унбиш километрлы дистанцияне баш группадагы алты велосипедчы арасында Асьютка беренче булып килеп кергән А. Петровка караганда ике минут унтугыз секундка элегрәк тәмамлый. Шулай да ике этап нәтиҗәсе буенча СССР командасы төп көндәшләрдән өч минутка алда була әле.

Этап артыннан этап. Чиратта — Порт-Сәет.

— Менә шушы этапта җиңсәң иде,— дигән уй Гайнанның башыннан бер минутка да чыкмый. Аның күңеленә ут салгандай, Сүәештән киткәндә шаян малайлар Гайнан Сәетхуҗинга: «Сәет! Сәет!» — дип кычкырып калалар. Тизлек арткannан-арта бара. Утызынчы километрларда Болгария велосипедчысы Д. Колев, аның артыннан А. Олизаренко, А. Петров, ГДРдан Х. Каппель һәм Румыниядән В. Добреску алга ыргылалар. Төп группадан тагын бер велосипедчы — Гайнан Сәетхуҗин аерылып китә. Лидерлар арасында безнекеләр өчәү, җиңү өчен иң уңай чак. Тактик көрәш нәкъ менә шушында башлана да. Алда юлны ремонтлыйлар, тагын сулга борылырга кирәк. Бу хәл велосипедчыларны бөтенләй саташтыра, комлы юлдан узышу тәмам хәлдән тайдыра. Сәетхуҗин, тешләрен кысып, бөтен көченә педальләргә баса. Ләкин башкаларның да бирелергә исәбе юк. Чөнки шәһәр янәшәдә генә. Биш, өч, ике, ниһаять, соңгы километр. Велосипедчылар, финишка җиткәндә, гадәттәгечә, торналар шикелле, бер-бер артлы тезеләләр. Көндәшләре җай эзләгән арада буй-буй сызыклы ак күлмәк кигән берәү сулдан алдырып узып та китә. Гайнан, Гайнан Сәетхуҗин ич бу! Молодец, Гайнан! Менә сиңа Сүәеш малайлары озатып калган «Сәет!»

Гайнанны финиш сызыгына чакыралар. Аның уң кырына Петров килеп баса. Аларны Порт-Сәет губернаторы Мөхәммәд Риад тәбрикли. Бу этапта җиңгән Гайнан Сәетхуҗинның муенына ул чын чәчәкләрдән үрелгән таҗ кидерә.

СССР велосипедчылары бу узышларда команда беренчелегендә дә җиңеп чыгалар. Моның өчен Гайнанга тагын бер приз бирелә. Ә команда Мисыр президенты Җамал Габделнасыйрның көмеш кубогы белән бүләкләнә.

## Рим Олимпиадасында

Спорт тормышы көтелмәгән вакыйгаларга искиткеч бай. Бүген син чемпион, ә иртәгә финишка соңгы кеше булып килүең мөмкин. Олимпия уеннарына, дөнья чемпионатларына барырга хокук алганчы нинди генә хәлләр татымый спортка гашыйк кешеләр. Гайнан кебек

күпне күргән, күпне кичергән һәм җиңү шатлыгы күргән егетләрне велосипед спорты әлегә белми. Рим Олимпиадасына әзерләнгән вакытта булган бик гыйбрәтле бер очрак турында искә төшереп узасы килә. Велосипедчылар, Минскида старт алып, Балтик буе республикалары аша үтәләр. Аннары юл Мәскәүгә борыла. Мәскәүдә ул көнне тантана — В. И. Ленин исемендәге Үзәк стадионда СССР халыкларының икенче җәйге спартакиадасы ачылуга багышланган спорт бәйрәме бара. Шундый тантаналы көндә стадионга кемнең генә беренче булып атылып керәсе килмәсен! Финиш инде кул сузымы гына җирдә диярлек. Сәетхуҗин, төп группадан аерылып, Горький урамына чыга. Шул вакыт чиләкләп яңгыр коя башлый. Ләкин Гайнанны туктатырлык бернинди көч тә юк инде. Дөньясын, барлык көндәшләрен онытып, ул алга чаба. Стадион капкаларына хәтле нибары 100 метр ара калып бара. «Велосипед поезды»н озата килүче мотоциклчылар, узышучыларга юл биреп, читкә тайпылалар. Сәетхуҗин да алар артыннан иярә. Шунда ук кинәт кемнеңдер: «Кире борыл, ялгыштың!» — дигән сүзләрен ишетә. Егетнең коты оча, маңгаена салкын тир бәреп чыга. Юлдан кире борылып, капкадан килеп кергәндә, Горький егете Александр Ючковның стадион буйлап әлдерткәне күзенә ташлана.

Гайнанга ачы сабак була бу.

1960 ел — Рим Олимпиадасы елы. Италия җирендә булачак стартларга планетабызның төрле почмакларында әзерләнәләр. СССРның велосипед спорты федерациясе дә күнегүләрнең махсус программасын төзи. Җиңү көненә багышланган традицион халыкара ярышларда иң яшьләрне сынап карарга булалар. Яңа команда төзелә. Аның составында Горькийдан Александр Ючков, эстон егете Антс Вяравас, харьковлы Михаил Курбатов һәм Гайнан Сәетхуҗин кертелә. Капитан итеп Павел Востряковны сайлыйлар.

Узышларга Чехословакиянең башкаласы Прага шәһәрендә старт бирелә. Прага урамы буйлап алга ыргылучы чуар колоннада күпләргә әле бөтенләй таныш булмаган совет спортчысы татар егете Гайнан да бар. Аның янәшәсендә немецлар, чехлар, поляклар, венгрлар, бельгиялеләр, шведлар, тунислылар, болгарлар, норвегиялеләр... Һәркайсының максаты — беренче дистанцияне оту. Сынатырга ярамый. «Сиңа да һөҗүмгә күчәргә вакыт», — ди Гайнан үз-үзенә. Уңай моментны туры китереп, сөзәк юл кырыннан түбәнгә ташлана. Көндәшләре моны хәтта сизми дә калалар бугай. Кече финишка ул беренче булып үтә.

Ләкин куанырга әле иртәрәк шул. Бу — ике мең километр озынлыктагы дистанциянең кыска бер этабы гына. Гайнан алда торган авыр маршрутны хәтта күз алдына да китерә алмый. Безнең команда рәттән ике дистанциядә оттыра.

Өченче этап аның хәтерендә бүгенгедәй ачык саклана. Братиславадан Готвальдовка кадәр — 195 километр. Яңа дистанциядә совет велосипедчыларының эшләре җайлы гына бара. Немецларның көрәшне артык кискенләштерәселәре килми. Поляклар көчләрен Варшавага саклыйлар. Шулай булгач, тәвәккәлләргә кирәк. Таулы урыннар Гайнан өчен бигрәк тә кулай. Тауларда ул үзен аеруча әйбәт күрсәтә. Безнекеләр арасында аның «Таулар короле» дигән кушаматы тикмәгә түгел бит!

— Алга ыргыл! — дип кычкыра аңа Павел Востряков. — Үргә менгәнче лидерларны ничек тә куып җит...

Капитан әмерен үтәргә кирәк. Һәм ул лидерларны куып җитә. Тау бүләген алу өчен 20 километр юл үтәсе бар. Югарыга алып менгән юл куе урман эченә керә. Бераздан яңгыр, аннары ишеп-ишеп



Прага, 1962 ел. Җиңү көнөнә багышлап үткәреле торган Халыкара ярышта беренчелекне алган совет командасы спортчылары.

кар ява башлый. Барысы да арыган. Карлы сөзәк юлдан Гайнан алга ыргый һәм Готвальдов стадионына беренче булып килеп керә. Чехословакия җирендә аңа беренче призны тапшыралар. Бу бүләк командага бер минут ташлама ясый. Монысы әйбәт, бик әйбәт.

Җиңү көне ярышларын Сәетхуҗин уңышлы тәмамлый: бу ярышларның ул елгы чемпионы, ГДР спортчысы Эрих Хагеннан барлык этаплар суммасы буенча дүрт минут чамасы гына калыша. Командалар арасында совет спортчылары өченче урынга чыга. Сәетхуҗин туган илебезгә «Таулар короле» призын алып кайта. Моннан тыш Гайнан дистанцияләрдәге егерме алты кече финишның үндүртендә беренче булып килә һәм Рим Олимпиадасына бару өчен ышанычлы адым ясый.

Туган илебездә Сәетхуҗинны тагын бер җитди имтихан көтә. Римга бару өчен дүрт кеше инде путевка алган. Ә бишенчесе әлегә билгесез.

— Бишенчесе Сочидагы узышларда җиңгән кеше булачак, — ди велосипедчыларга СССР җыелма командасы тренеры Леонид Шелешнев. Гайнан тренерга биргән сүзендә тора һәм беренчелекне яулап ала. Гайнан Сәетхуҗинны Олимпия командасы составына кертәләр.

...Рим олимпиячеләрне каршылый. Храмнар, кинотеатрлар, кибет витриналары, хәтта борынгы һәйкәлләр Олимпиада эмблемалары белән бизәлгән. Бу эмблемалар биш континент спортчыларының дуслыгын чагылдыра. Римлылар үзләре дә, олимпиячеләргә охшатып, ак, кызыл, яшел, зәңгәр, сары костюмнар һәм эшләпәләр кигәннәр. Бөтенесе Олимпиада ачылу тантанасын көтә.

Олимпия авылында спортчыларга урын — түрдән, хуҗалар аларны ачык йөз белән каршылый. Гайнан ГДРдан, Польша, Япония,

Бельгия, Норвегиядән килгән велосипедчы танышларын чәй эчәргә чакыра. Үзе дә аларга кунакка йөри. Менә нинди ул Олимпиада! Барлык илләрнең егетләрен һәм кызларын бер-берләренә якынлаштыра, аларның дуслыкларын ныгыта.

Олимпиада каникуллары эш көннәре белән алышына. Велосипедчылар программасының беренче эш көне — командалар узышы. Гайнан бу ярышларда катнашмый. Ул тамашачы гына...

Узышны итальяннар башлый. Алар, үзләрен чын хуҗаларча тотып, әйләнештән-әйләнешкә отыш секундларын җыялар. Немецларның да квартеты менә дигән. Әнә безнекеләр. Алар да әйбәт бара.

Тик менә Алексей Петровның гына эше көйсезләнеп бара кебек. Ул бер велосипедчыны үзеннән алга уздыра да артка кала. Аның каравы, Капитонов бөтенләй арымаган кебек. Ә Петровка нәрсә булды икән?

Финиш. Итальяннар — беренче, немецлар — икенче, совет командасы өченче урында. Юра Мелихов һәм Евгений Клевцов хәлсезләнгән Петровны култыклап киләләр. Ул көч-хәл белән генә сулыш ала.

— Врач чакырыгыз! — дип кул изи Капитонов.

Массаж ясаучы йөгереп килә.

— Эссе суккан, — ди ул.

Алексейга массаж ясыйлар. Тәненә салкын су коялар. Ниһаять, ул күзен ача. Беренче сүзе итеп, дусларыннан сорый:

— Ничәнчеләр?

— Бронза медальләр алдык, — дип тынычландыра аны Капитонов.

Гайнанга да чират килеп җитә. Италия башкаласы буйлап группалы ярышлар башлана. Катнашмаучы спортчыларның барысы да трассага чыга. Алар чиләкләр, кружкалар сатып алалар.

— Без сезгә Мәскәү һавасы ясыйбыз, — дип шаярта безнең спортчылар, ярыштагы иптәшләренә су биреп һәм су сибеп торырга әзерләнәләр.

Дистанциянең икенче өлешендә Виктор Капитонов белән итальян Ливио Траппе төп группадан аерылып китә. Бик күпләр моңа гадәти нәрсә итеп кенә карый. Финишка чаклы берничә әйләнеш калгач, башта немецлар алга ыргыла, Тэвэ Шур бик кызу куалый. Ван ден Бергын да Бельгиягә Олимпиада медален алып кайтмакчы. Безнекеләрдән Капитонов алда.

Соңгы километрлар аеруча озын, ялыктыргыч булып тоела. Капитонов һич икеләнмичә җиңүгә бара. Рим узышында ул моңа ирешә дә. Велосипед спорты буенча, әле беренче тапкыр буларак, илебезгә Олимпия медален алып кайта.

Оркестр, Италия башкаласын яңгыратып, Советлар Союзы Гимнын уйный. Бу тантананың сәбәпчесе Виктор Капитонов, мәһабәт көйне тыңлап, мактау пьедесталының иң өске баскычында горур тора. Икенче көнне Римда чыга торган барлык газеталар Виктор Капитонов җиңүе турында язалар. «Рус егете — Олимпиада чемпионы!» Виктор итальяннарның иң яраткан спортчысы Ливио Траппены узды! Рим тып-тын булып калды. Хәтта ирләрнең дә күзләреннән яшь бөртекләре тәгәри. Гайнан, фиништан соң, Ливио Траппеның балаларча үксүен бик озак карап тора. Нишлисең бит, спорт шундый нәрсә инде ул: җиңәсең дә, оттырырга да туры килә...

Тагын дүрт елдан соң унсигезенче Олимпия уеннарына Японияга Гайнан СССР велосипедчылары командасы капитаны булып барды.

— Без тәгәрмәчләр өстендә яшибез, — дип сөйләргә яраталар велосипедчылар. Бу сүзләрдә зур хаклык бар.

Кичә генә Гайнан Сәетхуҗин командасы Җиңү көне ярышларыннан алтын медаль отып кайтты. Бу җиңү аларга аеруча кадерле иде. Ярышлар кызып барганда гына совет велосипедчыларыннан берсенең аягы имгәнә. Безнең командада биш кенә кеше кала. Әмма башка командалардан бер кешегә ким булса да, бу авыр көрәштә совет командасы җиңеп чыга алды.

...Гайнан кулында бүген тагын яңа телеграмма. Парижга Франция коммунистлары газетасы «Юманите» призына ярышларга чакыралар.

Совет спортчылары Парижның таныш урамнары буйлап атлыйлар, истәлекле урыннарга тукталалар. Франция хезмәт ияләре һәркайда «Юманите» газетасы бәйрәменә әзерләнә. Менә Монмартр һәм Мәхәббәт бульвары. Моннан берничә сәгать кенә элек эш киемнәрен салып, бәйрәм костюмнарын кигән эшчеләр «Юманите» газетасы саталар.

Александр Кулибин иптәшләренә бер тәкъдим ясый:

— Әйдәгез, егетләр, без дә сатышыйк!

Велосипедчылар, куллары белән ишарәләп, эшчеләргә үзләренең теләкләрен белдерәләр.

Гайнан французча берничә сүз дә белә икән. Ул сүзләр, спорт терминнары гына булсалар да, парижлылар белән уртак тел табуга ярдәм итәләр. Гайнан Сәетхуҗин янына шунда ук зур чират тезелә.

Кичен Гайнанны һәм аның командасын Франция Коммунистлар партиясенең сугышчан органы «Юманите» редакциясенә чакыралар. Безнең егетләр редакция сотрудниклары белән танышалар, газетаның киләсе санында басылып чыгачак үз рәсемнәрен карыйлар.

Иртән — старт...

Гайнан узган ел Парижда булган вакыйгаларны исенә төшерә. Совет велосипедчылары күп көнлек «Тур де Лавенир» ярышларына килгәннәр иде. Профессиональ велосипедчылар ярышы иде ул. Моны инде Җиңү көне узышлары, яисә «Юманите» газетасы призына ярышлар белән һич чагыштырып булмый. Соңгы икесе спортчыларны үзара дуслаштыра, алга таба югары нәтиҗәләргә ирешү өчен ярдәм итә. «Тур де Лавенир»ны оештыручы буржуаз эшкуарлар һәвәскәр велосипедчыларны: «Моның өчен сезгә күпме түлиләр?» «Табышыгыз күпме?» дигән сораулар белән йөдәтеп бетерәләр. Безнең егетләр суыткычлар өчен двигатель һәм запас частьлар сатучы фирма вәкиленә тап була. Бу әрсез француз танылган профессиональ велосипедчы Жак Анкетиль аша Алексей Петровтан стартка күлмәгенә шушы фирманың эмблемасын тагып чыгуын сорый. Алексей аның тәкъдимен көлеп кире каккач, француз тәмам аптырашта кала. Совет кешеләренең спорт белән кәсеп итү өчен шөгыльләнмәүләрен эшкуар французга аңлатып бирүе бик кыен була. Профессиональ спорт турында уйланганда Гайнан немец дусты, менә дигән спортчы, Магдебург шәһәре металлисты Густав Адольф Шурны искә төшерә. Алар беренче тапкыр 1960 елда Җиңү көне ярышларында очрашканнар. Шуннан бирле дуслыклары ныгыганнан-ныгый бара. Шурның спорт даны Җир шарының барлык континентларында шаулый. Аны Германия Демократик Республикасы Халык палатасы депутаты итеп

сайлыйлар. Ул яраткан эшенә, туган иленә бирелгәнлеге белән безнең велосипедчыларга һәр вакыт үрнәк булып тора. Ике тапкыр дөнья чемпионына Көнбатыш Германиянең профессиональ велосипедчылары оешмалары акылга сыймаслык зур суммага контракт төзергә тәкъдим ясагач, Шурның моңа җен ачулары чыга һәм ул болай дип җавап бирә:

— Мин Германия Демократик Республикасы гражданины һәм шулай булып калачакмын да.

Гайнан менә ГДРдагы дусты Густав Адольф Шур белән «Юманите» газетасы призына ярышка чыга. Икесенең дә кулында «Юманите» эмблемасы төшерелгән кызыл әләм. Франциянең хезмәт халкы аларны котлап кул чаба, җиңүгә рухландыра. Кыен, бик кыен була бу ярыш. Көн буена сузылган авыр көрәштә Гайнан Сәетхуҗин җиңә, икенче ел рәттән «Юманите» призын ота.

Бөтен дөньяда танылган Гайнан Сәетхуҗин спортта әнә шундый катлаулы юллар аша берсеннән-берсе җаваплырак ярышларда җиңү яулый. Беренче рәсми ярышын педале сынган велосипедта завод чемпионы булып башлаган Гайнан зур спортта җиңелмәс капитан булып ирешә. Канада, Англия, Бельгия, Норвегия, Төркия, Голландия юлларында җиңелүне белми. Польшада аны «ук» дип йөртәләр, чехлар «җиңелмәс капитан» дип атыйлар. 1971 елны Гайнан Мәскәү педагогия институтын тәмамлый, шул ук елда СССР халыкларының V җәйге спартакиадасында, РСФСР җыелма командасы капитаны буларак, тагын бер алтын медаль ота. «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнә. Хәзер Гайнан Сәетхуҗин Мәскәүдә яши. Ул — РСФСР җыелма командасы тренеры. Велосипед спортының дөньядагы иң танылган вәкилләре белән бер сафта атлый.

## Фәнис Яруллин

### *Туган ягы кирәк кешегә*

Читтә йөргән чакта сагындырып
Керер өчен төнлә төшенә —
Зәңгәр таңлы, сайрар сандугачлы
Туган ягы кирәк кешегә.

Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә —
Шатлыкларын ишеттерер өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Сайлап алган юлы ялгыш булып,
Юлыкканда бәла ишегә —
Арып-талып кайтып егылыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Уй-фикерне нидер тупаслатса,
Тузан кунса яшьлек хисенә,
Күңелләрне сафландырыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

### *Җитми*

Кешегә гел нидер җитми,
Гомер буе шулай.
Бар нәрсәсе җиткән кеше
Сирәк була бугай.

Сабый чакта акыл җитми,
Яки җитми көчең.
Ярты юлда туктап кала
Бик күп кенә эшең.

Үскәч сине алып китсә
Юллар ерак-ерак,
Җитми башлый ялан аяк
Йөгереп үскән сукмак.

Җитми бодай басулары,
Җитми тургай җыры.
Җитми дуслар елмаюы,
Җитми җанга җылы.

Кеше комсыз түгел, ләкин
Җитми бик күп нәрсә:
Батырлык җитми кайвакыт
Ир булсаң да гәрчә.

Сабырлыклар җитми безгә
Иң-иң кирәк чакта:
Ашыгып изге хисләрне
Тапшырабыз ятка.

Кайвакыт җитми тугрылык,
Я усаллык җитми.
Җанны майдай эретерлек
Йомшаклык та җитми.

Җитми бәхет, җитми дөнья —
Җитми әлләниләр.
... Бар нәрсәне җиткерергә
Гомер җитми диләр.

## *Син әйтәсең*

Син әйтәсең: «Мә, ал бер кулымны,
Ирләр өчен бер кул зур нәрсә.
Бер кул белән йөзне каплап була,
Көтмәгәндә йөзгә җил бәрсә.

Бер кул — сыңар канат кына түгел,
Бер кулда бит анда биш бармак.
Бармакларны дошманыңа каршы
Йодрык итеп була йомарлап.

Ә дусларның кулын кыскан чакта
Бер кул була инде ике кул.
Ике кулда көч һәм кодрәт чиксез —
Бер куш йодрык кына түгел ул»...

Син әйтәсең: «Мә, ал бер аякны,
Икеләнми бирәм гомергә.
Йөгереп булмаса да йөреп була,
Сиңа кирәк бик күп йөрергә.

Кичекмичә ерак юлларга чык,
Юлда гына олы ачышлар.
Юллар алар хыялларны чынга
Тоташтыра торган баскычлар.

Хыялларың синең шундый матур,
Баскычларың илтер биеккә...
Мә, ал, — дисең, — ярты саулыгымны,
Мин яшәрмен, — дисең, — ничек тә»...

Нәрсә әйтим мондый сүзләреңә:
Күңелкәең синең киң дә соң!
Болай да бит җаның-тәнең белән,
Бөтенләең белән миндә син.

●

Табигать бүген эшләгән
Сәер хата:
Яшел яфраклар өстендә
Ак кар ята.

Агачлар бу кызык хәлгә
Ышанмыйча
Гаҗәпләнеп карап тора,
Кымшанмыйча.

Бу әле һич чын түгелдер
Дигән сыман —
Ямь-яшел күзләргә ап-ак
Өмет тулган.

Агачларның бу хәлләре
Миңа таныш:
Гаҗиз итә көтмәгәндә
Килгән сагыш.

## *Үзебез теләп*

Кар ява. Йомшак, җылы кар.
Җиргә ап-ак иннек кунган.
Өстең салып аунасаң да,
Өшемәслек җылы сыман.

Салам шунда бүрегемне,
Изүләрем ычкындырам:
Үзем теләп куеныма
Кар тутырам, кар тутырам.

Карлар үбә иренемнән,
Кар кытыклый муенымны;
Чиркәнсәм дә көләм генә —
Дәвам итәм уенымны.

Куанамын сабыйларча,
Миңа рәхәт, миңа кызык.
Кар куенда эрегәч кенә
Тәннәремә йөгерә суык.

... Гел шулай бит тормышта да —
Үзең теләп алданасың.
Эчеңә салкын төшкәч кенә
Уфтанасың, зарланасың!..

Су буенда үскән малай мин,
Елгаларның холкын беләмен:
Агымсулар белән көрәшеп
Ныгыгандыр бәлки беләгем.

Бик хәтәр дә була елгалар,
Хәйләкәр дә була елгалар:
Тын ага дип керсәң кайвакыт,
Йомшак тотып каты егалар.

Ә шулай да иң-иң хәтәре,
Миңа калса, урта төшендә —
Елгаларның үтсәң уртасын,
Ышанычың арта эчеңдә.

Каршы ярлар сине тартамы,
Күкрәгеңдә көчең артамы —
Сулышларың тигезләнәләр,
Колачларың җитезләнәләр.

Су буенда үскән малай мин,
Елгаларның беләм гадәтен:
Үтеп җиткәч кенә уртасын,
Артка карап бераз алам тын.

**В. Иванов,**
Татарстан мәгариф министры,
тарих фәннәре докторы

# МӘГЪРИФӘТЛЕ КАЗАН

Моннан нәкъ җитмеш ел элек «Пар ат» шигырендә Габдулла Тукай, үзен Казанга талпындырган уй-хисләрен белдереп: «Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур»,— дип язды. Мәгърифәт, гыйрфан — белем, культура дигән мәгънәле сүзләр. Бөек шагыйрь хаклы иде, чөнки безнең автономияле республиканың хәзерге башкаласы Казан элек-электән мәгърифәт, мәдәният үзәкләреннән берсе булып килде.

Дөнья күләмендә кыйммәтле ачышлар ясаган Н. И. Лобачевский, А. М. Бутлеров, М. Н. Зинин, татар халкының бөек уллары К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов һәм башка бик күпләрнең эшчәнлеге безнең Казанда барды. Химиклар һәм математикларның, физиклар һәм механикларның, астрономнар һәм медикларның Казан мәктәпләре революциягә кадәр үк ил һәм дөнья фәнендә мәртәбәле иде.

Рус халкының җирле халыкка дустанә карашлы укымышлылары тирәсендә Тукайның яктәшларыннан да фәннең төрле өлкәләрендә гыйльми көчләр үсеп чыга алды. Ләкин Октябрь революциясенә кадәр татар халкы вәкилләре фәнни эш белән шөгыльләнергә тулы мөмкинлек ала алмый килделәр. Чөнки төп халыкның киң катламнарына, фәнгә димибез инде, хәтта белемгә дә юл ябык иде.

Бөек Октябрь фән һәм мәгариф үсеше өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ачты. Совет властеның беренче көннәреннән үк яңа мәгариф системасын төзү, мәктәпләрнең уку-укыту базасын ныгыту, мәгариф эше кадрларын әзерләү, наданлыкны бетерү юнәлешендә зур эш башланды. Өлкәннәр ул елларны яхшы хәтерлиләр булыр: ил хуҗалыгында таркаулык, җимереклек иде. Идел буена килгән афәт-ачлык безнең якларда тормыш хәлләрен тагын да кыенлаштырды. Шундый шартларда да халкыбыз социалистик төзелешкә бирелеп җигелде, шул исәптән үзенең караңгылыгын җиңә барды. Октябрьның унъеллыгына инде мәктәпләр саны ишәйде, аларда татар укучылары күбәйде һәм 1928 елда укучылар арасында татарлар өлеше 37 процентка җитте. Сугыш алдыннан Казанда йөзгә якын мәктәп бар иде.

Совет мәктәбенең, шул исәптән милли мәктәпләрнең дә үсеш юлы җәмгыятебезнең социализмга, хәзер исә коммунизмга таба үсеш ихтыяҗлары белән тыгыз бәйләнгән. Бүгенге көндә гомуми урта белем алуга күчү тормышка ашырыла. 1975 елда Казан мәктәпләренең сигезенче классларын тәмамлаган укучыларның барысы да урта уку йортларында белем алуларын дәвам иттерәләр иде.

Хәзер Казанда гомуми һәм махсус белем мәктәпләренең саны 140 ка җитте. Тугызынчы бишьеллыкта гына унбиш яңа мәктәп салынды. Барлык мәктәпләр диярлек типовой биналар, ашханә, буфетлар белән тәэмин ителгән, ә кабинетлар һәм лабораторияләр өр-яңа техник җиһазлар белән җиһазланган.

Соңгы арада шәһәрнең өч районында укыту-производство комбинатлары төзел-

де. Аларда җиде меңләп өлкән класс укучысы шөгыльләнә. Бередәге кабинетларда иң яңа приборлар, инструментлар, сызымнар, белешмә һәм техник әдәбият, кыскасы, кирәкле һәр җиһаз җитәрлек. Бу кабинетларда яшьләр электрон-хисаплау машиналары операторы, электр җиһазларын монтажлаучы булырга, радио-электроника өлкәсендәге һөнәрләргә — барлыгы ун төрле һөнәрнең берсенә өйрәнә. Аңлашылса кирәк, болай иткәндә укучыларга үзләренә гомерлек һөнәр сайлау җиңелләшә, аларда хезмәткә коммунистик мөнәсәбәт тәрбияләү мөмкинлекләре арта, мәктәп белән промышленность предприятиеләре арасында нәтиҗәле бәйләнешләр ныгый төшә.

Яшь буынны тәрбияле һәм белемле итү эшенә шәһәрдә алты меңнән артык педагог көч куя. Аларның күбесе — үз хезмәтенең чын остасы. Менә, мәсәлән, Г. З. Зарифовны алыйк. Инде утыз биш елдан бирле ул укучыларына физика фәненең гаҗәеп дөньясын ачып килә. Кайбер мәктәпләрдә табигать белеме фәннәреннән: физика, математика, биология һәм башкалардан өлгереш түбәнрәк булып кала биргәндә, Габдрахман Зарифов укучылары физиканы «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләренә укый. Алар бу фәнне үз итәләр, яраталар, аңа гашыйклар. Г. Зарифов — РСФСРның атказанган укытучысы, Социалистик Хезмәт Герое.

Мәгълүм хакыйкатьтер: укытучы үзе укудан өзелмәскә тиешле. Моны аңардан тормышыбыз, фән, техника һәм социаль алга барыш темплары таләп итә. һәм укытучыга профессиональ яктан үсәргә шартлар Казан кебек шәһәрдә чагыштырмача яхшы булып килде, тагын да әйбәтләнә бара.

Казан — профессиональ-техник белем бирү үзәге дә. Соңгы өч бишьеллык чорында гына училищеларның саны егерме бердән кырык җидегә җитте. Аларда егерме меңгә якын яшь кеше белем, һөнәр ала, тормыш итәргә әзерләнә. Узган бишьеллыкта гына училищеларны йөз дә ун төрле белгечлек буенча илле мең егет һәм кыз тәмамлады.

Белем бирүнең бу системасы шулай ук туктаусыз үсештә. Әйтик, авиация заводы нигезендә 1940 елдан бирле училище эшләп килә. Ул уналты меңнән артык эшче-белгеч әзерләде. Шулар арасыннан Социалистик Хезмәт Герое, СССР Верховный Советы депутаты фрезерчы Г. Әсхәдуллин кебек хезмәт осталары, дәүләт эшлеклеләре өлгереп җитеште. Алар исә нигездә һөнәр алып чыкканнар иде, хәзер инде училище урта белем дә бирә торган уку йорты итеп үзгәртелде. Шуңа бәйләнешле рәвештә анда укытуның техник базасы яхшыртылды, педагоглар коллективы көчәйтелде. Монда тәрбияләнгән яшьләр эшче коллективларга җиңелрәк керәләр, хезмәтләрен уңышлырак башкаралар, җәмәгать эшләренә теләбрәк катнашалар.

Урта белем бирүче училищеларның киләчәге зур. Хәзер үк инде Казанда гына алар унау санала, ә бу бишьеллыкта барысы да диярлек шундый итеп үзгәртеләчәк. Әйтергә җиңел булса да, чынбарлыкта бу эш бер селтәнү белән генә хәл ителә алмый. Сүз укыту-тәрбия эшенең сыйфатын яхшырту турында бара, моның өчен исә тиешле техник база, инженер-педагог кадрлар булдырырга кирәк.

Махсус урта уку йортлары да шәһәрдә зур үсеш юлы үтте. Әле гражданнар сугышы тәмамлануга Казанда техникумнар ачыла башлады. Шуларның берсе — яшелчә-бакчачылык техникумының эшләп китүе В. И. Ленин исеме белән бәйләнгән. Швейцариягә сувенирлар сатудан керемнең бер өлеше юлбашчы күрсәтмәсе белән шушы максатка тоту өчен бүленгән. Казанда махсус уку йортлары ачу шулай башланып, Совет властеның унъеллыгына аларның саны егерме икегә җитте. Аларда биш меңләп яшь кеше белем алса, шуларның өчтән ике өлешеннән күбрәге эшчеләр, крестьяннар булып, яртысы татарлар иде.

Беренче бишьеллыклар чорында махсус урта белемле белгечләр әзерләү темплары тагын да тизләште. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1928 елгы июль һәм ноябрь Пленумыннан соң, аның күрсәтмәләрен тормышка ашыру йөзеннән, Казанда финанс-экономика, автоюл, төзелеш, мехчылар, авиация һәм элемтә техникумнары бер-бер артлы эшли башлады.

Бөек Ватан сугышы алдыннан Казанда илле махсус урта уку йорты бар иде. Аларның читтән торып белем алу бүлекләрендә өч меңнән артык эшче, колхозчы һәм хезмәткәр укыды. Дөрес, сугыш елларында уку йортларының да, укучыларның да саны кимеде. Сугыштан соңгы чорда халык хуҗалыгы үсеше ихтыяҗлары бу

өлкәдә яңа күтәрелеш тудырды. 1970 елда шәһәрдәге техникумнарда, махсус училищеларда 24 мең кыз һәм егет 70 төрле белгечлек буенча әзерләнә иде.

Фән һәм техниканың кызу темплар белән алга барышы тудырган ихтыяҗларны искә алып, КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы махсус карарында белгечләр әзерләүне яхшыртуга юнәлдерелгән зур бурычлар билгеләде. Хәзер алар тормышка ашырыла: укыту-тәрбия эшләренең эчтәлеге һәм формалары яхшыртыла, укытучы-инженер кадрларның әзерлек дәрәҗәсе күтәрелә, укытуның заманча чаралары кулланууга алына. Узган бишьеллыкта шәһәрдә илле меңнән күбрәк урта буын белгечләре әзерләнде.

Бөек Октябрьдан соң югары мәктәпне тамырыннан үзгәртеп кору башланган иде. Әле 1918 елда ук эшче һәм крестьяннарны вузларга әзерләүче курслар эшли башлады. 1919 елның ноябренда университетның эшчеләр факультеты, тагын бер елдан татар рабфагы ачылды. Шуларда әзерлек үткән хезмәт иясе татарлар соңыннан Мәскәү, Ленинград, Казан һәм башка шәһәр университетларын, институтларын тәмамладылар.

Югары уку йортлары һәм фән учреждениеләре челтәре туктаусыз киңәя барды. 1920 елда ачылган ГИДУВ — Врачларның белемен күтәрү дәүләт институты тиз арада эре гыйльми һәм педагогик үзәк булып өлгерде. 1922 елда авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты, шулай ук татар коммунистик университеты ачылды. Аларда Татарстан һәм күрше республикалар өчен кадрлар әзерләнә башлады. Белгечләрнең күбесе эшче, крестьян һәм хезмәт интеллигенциясе арасыннан үстерелде.

Шәһәрдә илнең иң эре уку йортларыннан берсе — университет. 1925 елның июнендә аңа В. И. Ульянов-Ленин исеме бирелде. Ул чакта университетта ике мең студент, 44 профессор, тугыз доцент, йөздән артык ассистент эшли иде. Фәнни-педагогик кадрларның көчле һәм ишле булуы аңа үзеннән яңа уку йортлары аерып чыгарырга мөмкинлек бирде. Аның нигезендә медицина, финанс-экономика, юридик һәм башка институтлар ачылды, 1930 елда университетның һәм политехник институтның химия факультетлары нигезендә химия-технология институты эшли башлады, ике елдан соң авиация институты төзелде.

Утызынчы елларда вузларда укыту-тәрбия бирү эшләрен камилләштерү, аларның производство белән бәйләнешен ныгыту юнәлешендә күп эш эшләнде. 1932 елда Казанда югары һәм урта уку йортларының беренче конференциясе булды. Аларның кайберләре ил күләмендә алдынгы урыннарга чыкты, университет икенче урынны алды.

Партия һәм Совет хөкүмәте милли өлкәләрнең хуҗалык һәм культура ягыннан үсеше өчен зур тырышлык куйдылар. Бу кайгыртучанлыкның җимешләре Казан вузлары эшендә дә чагылды: аларның матди нигезе ныгыды, профессор-укытучылар составы көчәйде. Сугыш алдыннан аларда бер академик, 132 профессор, 231 доцент, сигез йөзләп өлкән һәм кече фәнни хезмәткәр булып, шулардан 65 профессор һәм доцент татар милләтеннән иде. Алар арасында М. Фазлуллин, Б. Кондратский, Х. Мөштәри, Х. Шәмсетдинов кебек галимнәр эшләде.

Казан югары уку йортларында Бөек Ватан сугышы елларында да белгечләр әзерләү буенча киеренке эш барды. Нәкъ шул авыр чорда университетта татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды. Сугыш беткән елны Татарстанда консерватория эшли башлады. Сугыштан соңгы елларда югары мәктәп зур үсеш юлы үтте. Яңа вузлар ачылды. Яңа факультетлар, кафедралар һәм бүлекләр барлыкка килде. 1946 елда төзүче инженерлар институты яңадан эшли башлады. Университет юристлар һәм журналистлар әзерләргә кереште. Ветеринария, педагогия һәм авыл хуҗалыгы институтларында яңа белгечлекләр буенча кадрлар укыту гамәлгә кертелде.

Югары уку йортларының укыту-тәрбия, торак шартлары яхшыртыла торды. 1968 елда университетның физика факультеты төзелешенә нигез салынды. Хәзер тагын күп катлы бер бина калкып чыкты. Бүгенге университет үзе бер фән шәһәрчегенә әверелде.

Казанда югары уку йортлары ишәя бара. Культура институты, физик тәрбия институтының филиалы үсеп килә. Вузларның промышленность предприятиеләре белән иҗади бәйләнеше ныгый. Алар хәзер халык хуҗалыгы өчен йөздән артык белгечлек буенча кадрлар әзерләп чыгаралар.

Хәзерге этапта югары белем бирүнең үсеше коммунизм төзелешендәге бурычлар зурая баруы, фән-техника һәм иҗтимагый прогресс үсеше ихтыяҗлары белән тыгыз бәйләнгән. Уку йортлары хәзер яңа уку планнары нигезендә эшли. Аларда исә студентларның фәнни һәм махсус әзерлеген күтәрүгә, укытуны фәнни-тикшеренү эшләре белән тыгыз бәйләүгә, практика белән якынайтуга зур әһәмият бирелә.

Халык хуҗалыгын фән һәм производствоның яңа тармаклары буенча белгечләр белән тәэмин итү максатларыннан чыгып, авиация, химия-технология, медицина институтларында өстәмә факультетлар ачылды. Казанда тугызынчы бишьеллыкта энергетика, тирә-юнь мохитны саклау, вакуум техникасы һәм башка төр белгечлекләр буенча кадрлар әзерләнә башлады. Шул елларда гына 50 мең, ягъни сигезенче бишьеллыктагыга караганда ун меңгә артык, белгеч чыгарылды.

Казан югары уку йортларының зур темплар белән үсешен университет үрнәгендә күрәбез. 1974 елда аның 170 еллыгы билгеләп үтелде. 1976 елга аны 45 мең кеше тәмамлаган, аларның 35 меңе Совет власте елларына туры килә. Казан университеты шәһәребезнең генә түгел, илебезнең иң дәрәҗәле уку йортларыннан берсе санала. 1974 елда ук аның сигез факультетында ун меңгә якын студент белем ала иде. Университет бүген ике фәнни-тикшеренү институтын, астрономия обсерваториясен, гаять бай гыйльми китапханәне, хисаплау үзәген, проблемалар буенча тугыз лабораторияне эченә ала. Бирелгә 65 кафедрада йөздән артык профессор һәм фән докторы, ярты меңнән күбрәк доцент һәм фән кандидаты җитмешкә якын белгечлек буенча яшьләргә белем бирә.

Моннан җитмеш ел элек Тукай: «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» — дип өметләнеп кайткан Казан ул чорда ук, шагыйрь бик дөрес әйткәнчә, мәгърифәт үзәге булса, хәзер исә Советлар иленең иң эре югары уку йортлары үзәкләреннән берсенә әверелде. Бирелә 11 вуз һәм өч филиалда 50 меңнән артык студент укый! Студентларның тугандаш гаиләсендә кырыктан күбрәк милләт вәкилләре, шул исәптән егерме биш меңнән артык татар яшьләре, белем һәм тәрбия ала. Галим-укытучылар сафында йөздән артык фән докторы, өч меңнән күбрәк фән кандидаты бар. Шуларның сигез йөзгә якынын татарлар тәшкил итә.

Фәннең үсеш юлын күздән кичергәндә шунысын да искә алырга тиешбез: фәнни традицияләр Казанда революциягә кадәр үк салынган иде. Әмма ул чорның иҗтимагый шартлары, изүчеләр строе хакимлеге фән прогрессын тоткарлап килде. Бөек Октябрь җиңүе генә хезмәт кешесенә фәнгә юл ачты, кешелек цивилизациясе тарихында беренче мәртәбә буларак фән-техника казанышларын халык казанышына әйләндерде.

Әле егерменче елларда ук Казанда, гыйльми кадрлар әзерләүнең төп формасы буларак, аспирантура үсеш алды. Ул чактагы аспирантларның күбесе гражданнар сугышы мәктәбен үткән, хезмәт чыныгуы алган сәләтле яшьләр арасыннан иде. Шундый аспирантларның берсе Гыйлем Камай булды. Соңрак ул күренекле химик, РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, СССР Дәүләт премиясе лауреаты булып җитлекте. Идел ярында йөк ташучы улы, яшьлегендә үзе йөкче егет Гыйлем ата-анасы кушкан исемен революциядән соң гына аклый алды: 30 яшендә татарлардан беренчеләр рәтендә профессор, зур гыйлемле галим булды. Аның мышьяк һәм фосфорорганик кушылмалар белән бәйләнгән ачышлары фәнне баетты.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институты, вузлардагы иҗтимагый фәннәр кафедралары гуманитар фән проблемаларын тикшеренү үзәге булып тора. Филиал галимнәре, шул исәптән алты фән докторы һәм 50 фән кандидаты, татар халкының тарихын һәм культурасын, Идел һәм Урал буе халыклары милли культураларының үзара тәэсир итешү һәм баетышуына бәйле мөһим проблемаларны өйрәнү өлкәсендә нәтиҗәле эш алып бара. Институт эшендә Татарстанда һәм күрше автономияле республикаларда, өлкәләрдә социалистик һәм коммунистик төзелеш мәсьәләләрен өйрәнү зур урын алып тора. Аларның гыйльми эзләнүләре зур бәягә лаеклы.

Шулай үсә безнең борынгы Казан, мәгърифәт һәм фән шәһәре. Тукай сүзләре аның бүгенгесенә һәм киләчәгенә бигрәк тә туры килә төшә: «И Казан!.. Нурлы Казан!»

# КӨРӘШКӘ БИРЕЛГӘН ТОРМЫШ

...Гани абзый ишегалдында йөгереп уйнап йөргән малае Хөсәенне чакырып алды да, келәт янында әлсерәп утырган зур сары этне күрсәтеп:

— Бар, Сарбайны юарга кибеттән сабын алып кайт! — дип, Хөсәенгә акча тоттырды.

Акчаны җәһәт кенә алган малай авыл буйлап кибет ягына таба чапты.

Бу — Гани абзыйның 6 яшьлек Хөсәенне беренче сынавы иде. Максаты — малайның сәүдә эшенә сәләтен чамалап карау. Ул Хөсәенне дә үзе кебек сәүдәгәр булыр дип өмет итә иде. Әмма бүгенге сынау икесе өчен дә бик күңелсез бетте. Сарбайны юарга кибеттән иң арзан, хуҗалык сабыны алып кайтыр дип өмет итеп торганда, Хөсәен иң кыйммәтле, ялтыравык матур кәгазьләр белән төрелгән сабын күтәреп кайткач, Гани абзый түзмәде, беренче мәртәбә Хөсәенне үзенең авыр йодрыклары белән таныштырды...

Бу хәл Хөсәеннең туган авылы — элекке Пенза губернасы Татар Юнигы авылында булып уза. Авыл мәдрәсәсендә берникадәр белем алгач, әтисе аны Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга бирә. Ләкин мәдрәсәдәге иске тәртипләр аны һич тә канәгатьләндермиләр, берничә айдан соң ук Хөсәен аны ташлап чыга. Малаеның русча өйрәнергә теләге булуын искә алып, шулай ук элекке хыялларын да фикердә тотып, Гани абзый Хөсәенне Мәскәү сәүдә мәктәбенә укырга бирә. Мәктәпне бик уңышлы бетерүе сәләтле һәм тырыш малайга белемен Мәскәүдә башта коммерция училищесында, ә аны тәмамлагач — институтында укырга мөмкинлек ача...

Россия эшче-крестьяннарының көннән-көн көчәя барган революцион көрәше, большевикларның зур аңлату һәм оештыру эшләре студент Тарпищевның дөньяга карашы формалашуына зур йогынты ясый. Ул сәүдәгәр карьерасыннан кискен рәвештә баш тарта һәм Бөек Октябрь социалистик революциясен көрәшчеләр сафында каршы ала.

Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң, Россиянең төрле почмакларында совет властен урнаштыру өчен зур көрәш башлана. Илебез өчен шушы җаваплы көннәрдә Хөсәен Тарпищев хезмәт ияләре яулап алган яңа тормышны урнаштыруда үзенең беренче рәттә барырга тиешлеген аңлый. 1918 елның июнендә, 6 айлык кандидатлык стажы үткәннән соң, ул большевиклар партиясе сафына керә һәм шушы көннән башлап коммунистлар партиясе сафында аның актив эшчәнлеге башлана.

Менә Хөсәен Ганиевич — Урта Азиядә. Монда ул партия, Совет эше алып бара, Кәттә-Курган өязе эшче һәм крестьян депутатлары Советы президиумы члены итеп сайлана. Мәгариф эшләрен торгызу юлында күп эшли.

Ләкин аңа монда озак эшләргә туры килми. Ул Кызыл Армия сафларына баса, атаман Дутов бандаларына каршы көрәшчеләр сафында Актүбә фронтына китә. Кызыл Армия сафларында аның оештыру һәм хәрби таланты ачыла, пропагандист

булырак осталыгы үсә: Хөсәен Ганиевич гади кызылармеецтан Кызыл Армиянең күренекле политработнигы булып җитлегә.

Берникадәр вакыттан соң, Оренбург фронтында хәрәкәт иткән Беренче революцион армиядә Хөсәен Ганиевич армия политотделы начальнигының ярдәмчесе вазифаларын үти. Соңыннан, 1919 елның июлендә, Үзәк Мөселман хәрби коллегиясенең карары белән Х. Г. Тарпищев Беренче Татар бригадасына хәрби-политик эшкә җибәрелә. Монда ул, Йосыф Ибраһимов, Шамил Усманов, Бәкер Белоусов, Нигъмәт Еникеев, Якуб Чанышев кебек күренекле татар хәрби эшлеклеләре белән кулга-кул тотынып, кызылармеецларны хәрби-политик яктан тәрбияләү өстендә эшли. Ә 1920 елда Идел буе хәрби округы төзелгәч, Хөсәен Тарпищев округ политбүлегенә җитәкче работник итеп җибәрелә.

Коммунист буларак, Хөсәен Ганиевич кызылармеецлар белән эшләгәндә большевиклар партиясе линиясен тайпылышсыз үткәрә, хәрби дисциплинаны ныгыту чараларын күрә. Эшче-крестьян дәүләтен аңлы рәвештә яклау кирәклеген, илебез халыклары арасындагы мөнәсәбәттә пролетар интернационализм принциплары нигезендә эш итүнең мөһимлеген армый-талмый аңлата.

Хөсәен Тарпищевның партия политикасын тормышка ашырудагы принципиальлеге Совет һәм хәрби органнар тарафыннан югары бәяләнә һәм аңа еш кына зур җаваплы эшләр тапшырыла. Мәсәлән, 1920 елда Идел буе хәрби округыннан Мәскәүгә җибәрелгән бер донесениедә Башкортстанда буржуаз-милләтчеләргә каршы алып барылган көрәш һәм бу эштәге кыенлыклар турында языла. Күрелгән чаралар рәтендә анда «...мөселманнар арасыннан иң яхшы политработник, политуправление начальнигы ярдәмчесе иптәш Тарпищев һәм аның белән берничә сотрудникның» җибәрелүе әйтелә (САУДА, ф. 9, тасвирлама 21, эш 1). Тапшырылган һәр эштә ул үзенә күрсәтелгән ышанычны аклап чыга.

1920 елның ахырында Реввоенсовет карары белән Үзәк Мөселман хәрби коллегиясе үзгәртелеп корыла һәм ул Реввоенсовет Политуправлениесенең Көнчыгыш бүлеге дип йөртелә башлый. Озакламый Хөсәен Ганиевич Тарпищевның бу бүлекнең җитәкчесе итеп билгеләнүе аңа партия күрсәткән зур ышаныч турында раслаучы тагын бер мисал булып тора.

Совет властеның беренче елларында ук коммунистлар партиясе рус булмаган халыклар арасында партия һәм совет эшләренең куелышына зур игътибар бирде. Совет властеның асылын аларга үз ана телләрендә җиткерергә кирәк иде. Шушы максат белән 1917—18 елларны Милләтләр эше буенча халык комиссариаты янында милли комиссариатлар һәм РКП(б) Үзәк Комитеты янында милли секцияләр төзелә. Тиздән аларның урыннардагы органнары да булдырыла. 1918 елның ахырында РКП(б) ҮК янында Көнчыгыш халыклары арасында эшләү өчен махсус секция оештырыла. Соңыннан ул РКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы дип йөртелә һәм аның урыннардагы секцияләре дә төзелә. Кызыл Армия сафларында хезмәт итү дәверендә Хөсәен Ганиевичка Казанда, Самарада, Оренбургта һәм башка шәһәрләрдә булырга туры килә. Монда ул губерна партия комитетлары янында мөселман секцияләренең эшендә дә актив катнаша. Мәсәлән, 1920 елның башында Казан губкомының мөселман бюросы составына Хөсәен Тарпищев та сайлана. 1919 елның ноябрендә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының икенче съезды җыела. Хөсәен Ганиевич съездны хәзерләү комиссиясендә эшли. һәм нәкъ менә шушы көннәрдә аңа беренче мәртәбә В. И. Ленин белән очрашырга туры килә.

Бу — 1919 елның 21 ноябрь көне була. Съезд ачылыр алдыннан В. И. Ленин бер группа делегатлар белән РКП(б) Үзәк Комитетының киңәшмәсен уздыра. Киңәшмәгә килгән Хөсәен Тарпищевны, Шәймәрдән Ибраһимовны, Кадыйр Габдрахмановны, Кәрим Хәкимовны, Халик Садриевны һ. б. В. И. Ленин бик җылы каршы ала һәм аның председательлегендә җитди киңәшмә башланып китә. Бу вакытта милли политикада иң актуаль проблемаларның берсе — Идел буе халыклары өчен милли Совет автономияләре төзү иде. Башкорт Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелгән иде инде. Чиратта Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү тора. Бу киңәшмәдә катнашкан карт большевик Кадыйр Габдрахманов үзенең истә-

лекләрендә күрсәткәнчә, Хөсәен Тарпищев бер төркем делегатлар тапшыруы буенча ТАССР төзү турында алдан хәзерләнгән документ белән киңәшмәдәгеләрне кыскача таныштыра. Тикшерелә торган мәсьәләләр һәм шулай ук съездда каралачак сораулар буенча җанлы фикер алышу башлана.

В. И. Ленин Казан губернасы эшче-крестьяннарының көнкүреше һәм настроениесе турында җентекләп сораша. Ул шулай ук промышленность һәм авыл хуҗалыгының торышы, татар хәрби частьларын оештыру һәм татарлардан партия кадрларын хәзерләү мәсьәләләре белән кызыксына. Әңгәмә вакытында В. И. Ленин тикшерелгән мәсьәләләр буенча язмалар калдыра. Ул анда рус хезмәт ияләре белән тыгыз элемтә кирәклеген аеруча басым ясап әйтә. В. И. Ленин киңәшмәдә чыгыш ясаган ораторларның исемлеген яза. Бу язмалардан күренгәнчә, киңәшмәдә Хөсәен Ганиевич ике мәртәбә чыгыш ясый. (Кара: Ленинский сборник, XXIV. М., 1933, 194 бит.) Киңәшмә ахырында В. И. Ленин Татарстан республикасы төзү турында кайбер күрсәтмәләр бирә һәм илебез халыклары арасындагы дуслыкны ныгыту кирәклеге турында аеруча басым ясап әйтә. (Кара: В. И. Ленин. Полн. собр. соч., т. 39, 462 бит.)

Иртәгесен Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының икенче съезды ачыла. В. И. Ленин делегатлар алдында чыгыш ясый.

Хөсәен Ганиевич тын да алмыйча Ильичны тыңлый. Башка делегатлар кебек үк, ул да бөек юлбашчының һәр сүзен үзенә сеңдереп калдырырга тырыша.

Владимир Ильич үзенең чыгышында Совет Россиясенең халыкара империализмга каршы алып барган авыр көрәше турында сөйли. Империализм тарафыннан гасырлар буе изелеп килгән көнчыгыш халыкларының якын киләчәктә көрәшкә күтәреләчәкләрен әйтә. һәм шушы юлда көнчыгыш халыклары коммунистлары алдында торган бурычларның үзенчәлекләре турында сөйли.

В. И. Ленинның РКП(б) ҮК янындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының икенче съездындагы чыгышы бу халыклар арасында эшләүче коммунистларга, шул исәптән Хөсәен Ганиевич Тарпищев өчен дә, директив документ булып хезмәт итте.

Гражданнар сугышы тәмамлангач, коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте алдында сугыш вакытында коточкыч җимерелгән халык хуҗалыгын торгызу мәсьәләләре килеп баса.

Илебезнең ташкүмер промышленносте үзәге Донбассны мөмкин кадәр тизрәк торгызырга, заводларны, фабрикаларны, транспортны ташкүмер белән тәэмин итәргә кирәк иде.

Донбасс шахтерларының интернациональ отрядында татар эшчеләре дә аз түгел иде. Украина тикшеренүчесе Ю. Римаренконың күрсәтүенчә, 1921 елда Украина территориясендә 90 мең тирәсе татарлар яши. Шуларның яртысыннан артыгы Донбасска туры килә. Шуның өстенә 1921 елда монда көн саен 100 дән артык татар эшчесе килеп тора. Менә ни өчен коммунистлар партиясе Донбасстагы татар эшчеләре арасында партия эшен оештыруга зур әһәмият бирә. һәм алар арасында политик эш алып бару өчен партия Хөсәен Ганиевич Тарпищевны җибәрә.

РКП(б)ның Донецк губкомы янында татар-башкорт коммунистлары секциясе оештырыла һәм аның җитәкчесе итеп Хөсәен Тарпищев куела. Секция шахтерлар арасында агитация һәм пропаганда, культура-агарту эшләрен киң җәеп җибәрә. Партиянең Донецк губкомының турыдан-туры ярдәме белән ул татар телендә «Эшче тавышы» дигән газета чыгара башлый. Аның битләрендә марксизм-ленинизм идеяләре, халыклар дуслыгын ныгыту мәсьәләләре пропагандалана.

Шул ук вакытта татарлардан идея-теоретик яктан тиешле дәрәҗәдә коралланган җитәкче кадрлар хәзерләү буенча чаралар күрелә. Шушы максат белән Украинада уку-укыту эшләре татар телендә алып барыла торган партия-совет мәктәпләре ачыла. Хөсәен Ганиевич бу мәктәпләргә булдыклы һәм партия эшенә бирелгән кадрларны тарту өчен зур эш башкара. Ул үзе дә бу мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшләре алып бара. Хөсәен Тарпищев җитәкчелегендә татар-башкорт коммунистлары секциясе татар һәм башкортлар өчен культура-агарту учреждениеләре, мәктәпләр ачуга да күп көч куя.

Донбасста өч ел эшләгәч, 1924 елның апрель аенда Хөсәен Ганиевич Мәскәүгә, РКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Татар-Башкорт секциясе Президиумы члены һәм инструкторы итеп күчерелә. Бу органның төп вазифасы — Башкортстан һәм Татарстан АССРлар төзелгәннән соң, автономияле республикаларга керми калган Идел һәм Урал буе татар, башкорт халыклары арасында партия эше алып бару була. Ул турыдан-туры коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты җитәкчелегендә эшли. Хөсәен Ганиевич ил буйлап күп йөри, хезмәт ияләре арасында оештыру һәм аңлату эшләре алып бара. Шушы ук чорда аның Мәскәүдә чыга торган «Эшче» газетасында мәкаләләрен дә күрергә була.

Партиябез илне индустрияләштерү мәсьәләсен куйгач, 1925 елның сентябрендә Хөсәен Ганиевич Татарстанга җибәрелә һәм аның экономикасын күтәрү өстендә актив эшли башлый.

Башта ул Дәүләт банкының Казан конторасы управляющие урынбасары була. Бер ук вакытта аңа башка җаваплы хуҗалык эшләренә дә җитәкчелек итәргә туры килә. Хуҗалык эшләрен партия кушканча, игътибар белән өйрәнү үзенең нәтиҗәләрен бирә. Тиздән Хөсәен Тарпищев үзен хуҗалык эшләре буенча да тәҗрибәле белгеч итеп таныта. 1930 елның 11 январенда Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы карары белән Хөсәен Ганиевич Тарпищев Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы хөкүмәтенең финанс эшләре буенча халык комиссары итеп билгеләнә. Бу елларны Хөсәен Ганиевич даими рәвештә республиканың партия һәм җитәкче органнарына сайланып килә. Ул партиянең өлкә комитеты җибәрүе буенча республика районнарында еш була, икмәк хәзерләү, колхозлар оештыру эшендә турыдан-туры катнаша.

Илдә социалистик төзелешнең яңа этабына хәзерләү өчен, перспективалы халык хуҗалык работнигы буларак, Хөсәен Ганиевич Промышленность академиясенә укырга җибәрелә. Моннан соң аңа Татарстанга кайтырга туры килми, ләкин кайда гына эшләсә дә, ул үзенең бөтен көчен социализм төзүгә бирде.

**РИФ ХӘЙРЕТДИНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ТАТАР ДРАМА ТЕАТРЫ
# ҺӘМ ОПЕРА СӘНГАТЕБЕЗ

Музыка элек-электән татар совет театрының иң көчле якларыннан берсе булып килде. Театр белән музыка арасында бәйләнеш бик табигый күренеш буларак кабул ителә. Мондый бердәмлек кайчан һәм ничек башланган соң? Мәгълүм булуынча, революциягә кадәрге чорда музыка тәнәфес вакытларында, спектакль алдыннан һәм аннан соң яңгыраган, халык уен кораллары ансамбле яисә оркестрда халык көйләре, биюләр, маршлар, увертюралар башкарылган. Әмма озак та үтми, музыка драма спектакльләренең эченә үтеп керә, персонажларның хис-кичерешләрен гәүдәләндерүгә хезмәт итә башлый. Бөек Октябрь революциясе чорында ук М. Фәйзинең «Галиябану»ы, Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә»се һәм башка музыкаль драмалар сәхнәгә менә.

Егерменче елларның башыннан Салих Сәйдәшев музыкасы белән татар музыкаль драмасында яңа чор ачыла. Мәгълүм бер мәгънәдә без С. Сәйдәшевне татар театрында музыкаль драма жанрын тудыручы дип тә әйтә алабыз, чөнки ул моңа кадәр башлыча халык көйләренә нигезләнгән музыкаль спектакльләрне ныклы профессиональ музыка җирлегенә куя.

Әйтергә кирәк, күп кенә милли республикаларның театр һәм музыка сәнгате дә Октябрь революциясеннән соң шундый ук үсеш баскычлары аша үтте. Җырлар һәм оркестр белән башкарыла торган аерым эпизодлар рәвешендә музыка драма спектакленең эчке тукымасына үтеп керә. Шушындый «синтетик» спектакль соңга табарак музыкаль драма исемен ала. Егерменче һәм утызынчы елларда бу форма татар театрында мөстәкыйль әдәби-музыкаль жанр булып үсеп китә. Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Таҗи Гыйззәт һ. б. драматурглар үз әсәрләрен С. Сәйдәшев музыкасына исәп тотып, композитор белән иҗатташлыкта язалар. «Красная Татария» газетасында басылган мәкаләләренең берсендә[1] С. Сәйдәшевнең музыкаль драмалар өлкәсендәге иҗатын бәяләп, Г. Кутуй, мәсәлән, болай дип яза:

«Музыкаль драма театр репертуарына 1916 елда керде. Анда драматик уен элементлары татар халык көйләре белән аралаша. Музыкаль оформление өчен театр яшь композитор Салих Сәйдәшевкә бурычлы. Аның пьесалары татар операларын тудыруга юл ачты».

К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар» әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә С. Сәйдәшев татар халык көйләреннән киң файдалана. һәм алар композитор үзе иҗат иткән оригиналь әсәрләр — арияләр, дуэтләр,

---

[1] «Татарский театр» исемле мәкалә, 1930 ел, 12 февраль саны.

хор һәм балет номерлары белән бергә үрелеп бара. Ул әсәрләр татар музыкасының милли рухын, колоритын гаять нечкә тоеп язылганнар һәм эстетик кыйммәтен югалтмыйча, көй-аһәңнәренең матурлыгы, фикер һәм хискә байлыгы белән безне куандырып, бүген дә яши бирәләр. «Зәңгәр шәл» музыкаль драмасыннан Булат һәм Мәйсәрә җырлары, качкыннар хоры (1926 ел), Т. Гыйззәтнең «Наемщик» әсәреннән Батыржан, Гөлйөзем җырлары һәм арияләре (1928 ел), К. Тинчуринның «Ил», «Кандыр буе»нда спектакльләреннән «Ал чәчәкләр» җыры, Фәридә ариясе (1929 һәм 1932 еллар) һ. б. күп әсәрләр музыка классикабыз хәзинәсендә мактаулы урынны алдылар.

С. Сәйдәшев арияләре форма һәм стиле белән татар халык җырларына якын тора, алар халык җырының образлылык үзенчәлекләрен, тирән мәгънәлелеген, мелодик байлыгын үзләренә сеңдергәннәр.

Шуның белән бергә, аларны опера арияләренә хас билгеләр дә аерып тора. «Наемщик» музыкаль драмасыннан Гөлйөземнең беренче ариясен мисалга алыйк. Нечкә лирик хискә нигезләнгән ул ария киң сулыш белән башкарыла, тойгы-кичереш тасвирләренә бай. Кисәкләре арасындагы контрастлылык ике кисәкле озын көйләрне хәтерләтә. Беренче өлеше халыкның озын көйләрендәге кебек иркен һәм талгын яңгырый, ул импровизациялелеге, интонацияләренең тәгәлләнгәнлеге белән аерыла. Көйнең икенче өлеше исә җитезлеге, кыска көйләрдән килә торган җиңел-җыйнаклыгы белән әсир итә. Күп арияләрнең лад төзелешләре дә халык көе принципларына нигезләнгән. Шул ук вакытта алар анык бер максатка, сәхнә персонажларының эчке халәтен ачуга, герой һәм героиняларның музыкаль образын тудыруга хезмәт итәләр.

Салих Сәйдәшев музыкаль драмаларга увертюра, биюләр, интермедияләр кертә. Алар спектакльләргә өр-яңа рух өсти, тамашачыны опера музыкасын тыңлауга күнектерүгә ярдәм итә. Инструменталь музыка әсәрләре театр сәхнәсендә генә калмыйча, эстрадага күчә, радиода яңгырый башлый. Татар симфоник музыкасының беренче үсентеләре шулай мәйданга килә.

С. Сәйдәшев музыкасы спектакльләрнең сюжет сызыгына һәм эчке рухына бик табигый ятыша, вакыйганы, әсәр эчтәлеген баета һәм җанландыра. Спектакльнең драматургиясендә ул еш кына үзәк урынны ала, көнкүреш картиналарын, образларның төп сыйфатларын калкурак гәүдәләндерергә ярдәм итә.

Салих Сәйдәшевнең музыкаль драмалары, шулай итеп, татар операсының әлгәресе булдылар. Аларда булачак татар операларының мөһим чаралары туплана килә, милли профессиональ музыка теле һәм стиле формалаша башлый.

Профессиональ музыкабыз үсешенең башлангыч дәверендә аның төрле жанрлары да бертигез дәрәҗәдә үсеп китә алмый. Егерменче елларда, әле профессиональ музыка беренче адымнарын гына атлаган, симфония һәм симфоник концертлар, ораторияләр әле юк чагында, музыкаль драма һәм опера кебек сәхнәдә башкарыла торган демократик жанрлар музыка сәнгатебезнең әйдәп баручы төрләре булып әверелә.

Беренче татар операсы «Сания» 1925 елда туа. Аның интернациональ авторлар коллективы тарафыннан язылуы да очраклы күренеш түгел иде. Беренче татар музыкантларыннан берсе композитор Солтан Габәши, Башкортстанның халык артисты, җырчы, халык җырларын җыючы Газиз Әлмөхәммәтов белән берлектә, опера өчен ария, дуэт, хор һәм инструменталь партияләрнең көйләрен яза. С. Габәши — Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк һәм егерменче еллар башында төрле әдәби-музыкаль кичәләрдә якыннан торып катнашып килгән, драма спектакльләренә музыка язу өлкәсендә дә беркадәр тәҗрибә туплаган, Татарстан һәм Башкортстан районнарында музыка фольклорын җыю белән дә шөгыльләнгән киң колачлы музыкант. Операның өченче авторы, композитор, скрипкачы һәм педагог Василий Иванович Виноградов та татар музыкасы өлкәсендә шактый еллар эшләгән була. Ул операның мелодик материалын эшкәртү белән шөгыльләнә, аны гармонияләштерә һәм оркестрга сала. Опера өстендә эшләү иҗат индивидуальлекләре, музыкаль хәзерлекләре төрле булган бу өч шәхестән гаять киеренке хезмәт һәм тырышлык таләп итә.

«Сания» операсы 1925 елның 25 июнендә Татарстан автономияле республикасы оештырылуга биш ел тулган көнне Казанда куела. Спектакльдә Казан шәрык музыка техникумы хоры һәм оркестры, Татар дәүләт драма театры артистлары катнаша. Хор һәм оркестрга күренекле музыкант, музыка техникумы директоры Александр Александрович Литвинов җитәкчелек итә. Рольләрне Зөһрә Бәйрәшева, Сара Садыйкова, Ситдыйк Айдаров, Әшрәф Синяева, Сара Байкина, Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши һ. б. башкара[1].

Драма театры актерлары бер үк вакытта опера җырчылары ролендә чыгыш ясыйлар. Драма театрында опера жанрының үз сурәт чаралары, компонентлары гына формалашып калмый, драма актерлары арасыннан Сара Садыйкова, Галия Кайбицкая кебек беренче опера җырчылары да үсеп чыга.

Табигый ки, татар профессиональ музыкасы аякка яңа басып килгән елларда опера бик үк камил дәрәҗәдә була алмый иде әле. Әмма шулай да операның мәйданга чыгуы сәнгать тормышында зур вакыйга, «гадәттән тыш бер нәрсә булып күренә»[2]. Октябрь революциясенә кадәр профессиональ музыка сәнгате дә формалашып җитмәгән халыкның егерменче еллар уртасында ук инде опера масштабындагы әсәрне сәхнәгә күтәрә алу факты үзе бик күпләрне таңга калдыра. «Сания» операсы белән кызыксынуны бермә-бер арттыра. Милли музыка культурасының ярым профессиональ характердагы садә музыкаль пьесалар һәм ялгыз җырдан музыкаль драмалар һәм опера дәрәҗәсендә сикереш ясавы чыннан да искиткеч күренеш булып тоела. Опера хакында матбугатта чыккан мәкаләләрнең күпчелегендә әнә шул хәл билгеләп үтелә. Мәсәлән, «Кызыл Татарстан» газетасы «Тагын «Сания» операсы турында» дигән мәкаләдә болай дип яза: «Сания» операсы татар сәнгатенең бөтен дөнья хәрефләре (нота) белән, музыканың бөтен дөнья телендә язылган. Ләкин, шуның белән бергә, үзенең бертөрлелеген, татар музыкасының төп хасиятләрен югалтмаган, чын мәгънәсе белән... татар колориты бирә торган бердәнбер мәдәни әйбер».

Этнограф, Шәрык халыкларын өйрәнү фәнни җәмгыяте члены профессор В. Бороздин, «Сания» спектакльләренең реалистик характерда булуын, анда халыкның тормыш-көнкүреше, җыр-биюләре, уеннары шактый тулы чагылуын күрсәтеп үтә. «Бу операда татар музыкасының опера композициясе төсендә оешу дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгәнлеге күренде»,— ди ул[3].

Беренче татар операсы куелу хәбәре чит илләргә, Германия һәм Италиягә барып җитә. Берлинда чыга торган музыкаль атналык басмасының 1925 ел, 51—52 саннарында беренче татар операсы хакында мәкалә басыла, операдан нота материаллары, авторларның һәм башкаручыларның фоторәсемнәре бирелә. Италиянең башкаласы Рим шәһәрендә урнашкан Европа шәркый институты 1925 елның 30 октябрендә институт журналында татар музыкасына, шул исәптән «Сания» операсына да багышлап зур мәкалә бастыра[4].

Әмма шатлык авазлары арасында аек тәнкыйть фикерләре дә булмый түгел. Мәсәлән, драматург К. Тинчурин «Сания» операсы турында» дигән мәкаләсендә шундый фикерләр әйтә:

«Сания» операсында татар моңы, аһәңе ураган бер килеп, бер бөтен берлек юк. Монда башкорт моңы да бар, ...татар моңы да бар, төркестан дәрвишләренең мөнәҗәтләре дә очрый... Монда калфак, кәләпүш киертелгән Европа музыкасы да яңгырый»[5].

Китерелгән өзектән күренгәнчә, операның кимчелекләрен, стиль бердәмлеге җитмәвен К. Тинчурин яхшы тойган. Чыннан да, операның Г. Әлмөхәммәтов язган либреттосы ук шартлылыктан азат булмый, анда сюжет динамикасы, вакыйга үсешендә киеренкелек җитенкерәми[6]. Әсәрнең сюжетында социаль мотивлар ятуына

---

[1] Бу хакта кара: Ш. Рахманкулов һәм Х. Терегулова. «Татар совет музыкасы утыз ел эчендә». Казан, 1950 ел.

[2] Тагын «Сания» операсы турында. «Кызыл Татарстан», 1925 ел, 21 июль.

[3] В. Бороздин. Татар телендә беренче опера «Сания». «Кызыл Татарстан», 1925 ел, 9 июль.

[4] Бу хакта кара: «Кызыл Татарстан», 1925 ел, 31 декабрь саны.

[5] «Сания» операсы турында. «Кызыл Татарстан», 1925 ел, 9 июль саны.

[6] Әсәрнең эчтәлеге, берничә сүз белән әйткәндә, шуннан гыйбарәт: бай сәүдәгәр кызы Сания ярлы егет Зыяны ярата. Кызның әтисе яшьләрнең бәхетенә каршы төшә һәм кызын бай кияүгә бирергә тели. Ике гашыйк, барлык киртәләрне җиңеп, үз теләкләренә ирешәләр.

да карамастан, анық музыкаль драматургиясе сүлпән үстерелә, конфликты йомшак, вакыйгалар тышкы иллюстрация булудан узмыйлар диярлек. Үзәк героиня образы тик бер яссылыкта, лирик планда гына ачыла, драматизм, хисләрнең эчке киеренкелеге җитми.

Г. Әлмөхәммәтов, В. Виноградов һәм С. Габәши беренче татар операсын милли фольклор традицияләре рухында иҗат итәргә омтылалар. Алар халык музыкасының аерым жанрларын үрнәк итеп алалар, бигрәк тә кыска көй, озын лирик көй интонацияләре, авыл һәм уен көйләре ачык сизелеп тора. Шуның белән бергә, марш, вальс, бишек җыры кебек классик музыка жанрларына хас билгеләр дә очрый. Бер очракта хор һәм бию күренешләре халыкның үз җырларына (мәсәлән, «Сания», «Алмагачлары», «Уфа әпипәсе») нигезләнсә, башка кайбер хор һәм арияләрдә халык көйләренең аерым өлешләре, «микроцитаталар» файдаланыла. Өченче бер җирдә исә, хор номерлары һәм ариозалар озын һәм кыска көй, авыл көйләре калыбында, шулар өчен характерлы булган үзенчәлекләр йогынтысында языла. Шушындый алымнарны куллану нәтиҗәсендә операга халыкның үзендә яшәгән һәм күнегелгән интонацияләр килеп керә. Опера жанры белән таныш булмаган тамашачыны җитди музыкага якынайту, сәнгатьнең яңа төрен үзләштерүне җиңеләйтү өчен моның зур әһәмияте була. «Сания» авторларының беренче иҗат тәҗрибәсен тәкъдир итеп, шуны әйтергә кирәк: операның мелодикасы өлкәсендә алар милли стильне саклауга ирешәләр. Төп геройлардан Сания белән Зыяның музыкаль характеристикасы аеруча уңышлы чыккан. Аларның арияләре операның иң яхшы лирик сәхифәләрен тәшкил итә.

Әсәрнең гармоник теле исә тигез һәм бердәм түгел. Бер очракта гармония бик гади чаралар ярдәмендә гәүдәләнсә, башка очракта Европа классик операсы чаралары белән мавыгу сизелә, ә ул пентатоник көй агышы белән һәр вакыт табигый рәвештә ярашмый. Тональ-гармоник сферада сурәтләү чараларын эзләнү чоры әле яңа башланган вакыт өчен гармония чуарлыгы, стиль бөтенлеге җитмәве табигый нәрсә була, әлбәттә.

Күренешләрнең композициясендә, эчке үсештән бигрәк, материалны күрсәтү һәм сөйләп чыгу өстенлек ала, дөресрәге, әсәр төрле характердагы күренешләр белән чуарланып китә, мәсәлән, беренче пәрдәдәге масса күренешендә эчке эзлеклелек булмавы бигрәк тә ачык күренә.

«Сания» операсы татар профессиональ музыка сәнгате әле беренче адымнарын гына атлаган, операның үз милли стиле, музыкаль сурәтләү чаралары әле табылып өлгермәгән елларда мәйданга чыга. Драматургия кануннарын тирәнтен үзләштерүгә нигезләнмәве, көй белән фактура-гармония чараларының стилистик бердәмлеге табылмау аркасында ул репертуарда тотрыклы урын ала алмый.

Шул кимчелекләренә дә карамастан, ул өзлексез яңгырашлы мелодик материалга корылган, арияләр, хор, дуэт һәм ансамбльләре бер үзәккә оештырылган беренче опера иде. Аңарда халык көнкүреше картиналары күркәм чагылыш тапты, лирик көйләр өлкәсендәге эзләнүләр һәм табышлар да нәтиҗәсез калмады. «Сания» операсы тарихи яктан җитди әһәмияткә ия: опера жанрында тәүге сынау булу белән бергә, ул — киләчәк татар операларының элгәресе дә.

Г. Әлмөхәммәтов, В. Виноградов, С. Габәши иҗат иткән икенче опера — «Эшче» — татар пролетариатының тууы, 1905 ел революциясе шартларында аның сыйнфый аңы үсеше темасына багышлана. Опера М. Гафуриның 1920 елларда язылган шул ук исемдәге поэмасына нигезләнгән. Анда сыйнфый көрәш күренешләре, татар крестьянының аңлы эшчегә әверелүе процессы чагыла. Опера 1930 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә башкарыла. Спектакльдә Газиз Әлмөхәммәтов, Ситдыйк Айдаров, Наилә Рәхмәтуллина, Әхәт Хисамов h. б. җырчылар катнаша. Әсәрне сәхнәгә С. Валеев-Сульва куя. А. Литвинов дирижерлык итә.

Татар операсының революцион темага мөрәҗәгать итүе утызынчы елларда ил күләмендә яңгыраш ала. Шул рәвешчә, «Эшче» — тарихи-героик жанрдагы татар операсын тудыруда беренче тәҗрибә дә була. Ул 1930 елда Мәскәүдә Милли театрларның бөтенсоюз Олимпиадасында күрсәтелә һәм темасының актуальлеге, аерым отышлы яклары белән башкала матбугатының игътибарын җәлеп итә.

«Правда» газетасының 1930 ел, 8 июль санында «Беренче адым» дип исемләнгән мәкалә басылып чыга. «Опера музыкасы,— диелә анда,— татар халык җырларын файдаланып язылган, ләкин йомшак, тәҗрибәсез кул белән язылган. Анда авыл җырының иң яхшы үрнәкләренә якын килгән байтак көйләр бар, әмма үзләренең мелодик фикерләрен сәнгать ягыннан билгеле бер юнәлештә үстерүдә композиторларның көчсезлеге сизелә. Оркестр өлеше сүлпән, урыны-урыны белән килешсез эшләнгән, оркестр хәрәкәтне биреп җиткерми... Шуңа да карамастан, операда сәламәт һәм яшәүгә сәләтле орлык бар. Эшче тормышын-көнкүрешен күрсәтү нык һәм төгәл ритмнарда алып барылырга тиеш, сентиментальлек һәм музыкаль фактураның тоныклыгы моңа комачаулый; халык җырларына таянып, әмма аларны операга бөтен килеш кертмичә авторлар бик дөрес эшләгәннәр».

Югарыда әйтелгән кимчелекләр яңа эпоханы чагылдыру бурычын куйган башка күп кенә музыка әсәрләренә дә хас иде.

«Сания» операсы белән чагыштырганда, бу яңа әсәрдә халык көйләреннән файдалану баерак һәм кызыклырак форма ала. Монда «Казан сөлгесе», «Тамчы тама», «Тәфтиләү» кебек озын көйләрне һәм башкорт халык җырларын хәтерләтүче моңнар ишетелә. Көйләр гармониясе күбесенчә гади һәм табигый, пентатоник характердагы халык җырларының көй төзелеше үзенчәлекләре исәпкә алынып эшләнә.

Халык җыры «Эшче» операсында музыка драматургиясенең мөһим өлешен тәшкил итә. Мәсәлән, «Казан сөлгесе» җырында Хәмидә образының сыйфатлары, «Тамчы тама» көендә халыкның аһ-зарлары, нәфрәте һәм көрәше чагылыш таба һ. б.

Беренче операдагы кебек үк, авторлар характеры белән татар халык җырына якын торган оригиналь хор һәм арияләр иҗат итәләр. Крестьян кызы Сәлимә партиясендә озын көйләргә хас бизәк-орнаментларга бай лирик көй ишетелә. Ә өченче пәрдәдәге эшчеләр хоры кыска көйләр һәм такмакларны хәтерләтүче ритмга корыла. «Эшче»нең авторлары музыкаль-интонацион чыганак сыйфатында башкорт халык мелосыннан да иркен файдаланалар.

Бу опера революцион эпоха белән аваздаш булган яңа опера телен табу өлкәсендә җитди эзләнү үрнәге иде. Һәм аңарда пролетар гимннар, эшче җырлары рухы да чагылмый калмый. Эшчеләр хоры, кайбер ялгыз номерлар революцион җырлар рухында язылган, аларда халык җырының колориты да саклана.

«Эшче» операсы да беренче опера әсәренә хас кимчелекләрдән азат булып җитә алмый. Картиналар һәм күренешләр арасында эчке бердәмлек җитми, әсәр вак эпизодлар белән чуарлана. Алар фикер үсешен чагылдырудан бигрәк, иллюстрация булып кына калалар, кисәкләрне берләштерүче реприз моментлар җитешми. Опера авторлары стилистик чуарлыктан да котыла алмаганнар.

Ничек кенә булмасын, икенче татар операсының сәхнәгә күтәрелүе культурабыз тормышында уңай күренеш иде. Аның авторлары шул заман тормышына нигезләнгән опера иҗат итүгә омтылыш ясыйлар, эшчеләрнең чын тормыш картиналарын һәм революцион көрәшен җанландыралар. Икенче операның мәйданга чыгуы татар профессиональ музыка сәнгатенең куәтле рәвештә үсеп килүен, аның төрле жанрларда милли әсәрләр тудыруга сәләтле икәнлеген раслады.

Татар музыка сәнгатенең сурәтләү чараларын баету һәм үстерү эшен утызынчы елларда драма театрында С. Сәйдәшев дәвам иттерә. Театр сәхнәсендә аның музыкасы белән барган «Кандыр буе» (К. Тинчурин әсәре), «Бишбүләк» (Т. Гыйззәт әсәре), «Күзләр» (Х. Фәтхуллин әсәре) һ. б. спектакльләр зур уңыш казана. Композиторның иҗаты мелодик образлар һәм темалар палитрасын баета, музыкада күп тавышлылык элементлары көчәя, татар көенең ритмик нигезе, гармония чаралары киңәйтелә.

Татар музыка культурасының тизлек белән үсә, киңәя баруы милли опера һәм балет театрын булдыру бурычын көн тәртибенә куя. Хөкүмәтебез карары белән 1934 елда Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе ачыла. Яшь татар композиторлары һәм музыкантлары С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, җырчылардан С. Садыйкова, Г. Кайбицкая, М. Рахманкулова, А. Измайлова, Ф. Насретдинов, С. Айдаров, У. Әлмиев һәм башкалар студиягә укырга җибәрелә.

Утызынчы елларда татар профессиональ музыкасында талантлы композиторларның зур бер төркеме күтәрелеп чыга. М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин һ. б. композиторлар күп төрле жанрларда яңадан-яңа әсәрләрен иҗат итәләр.

1939 елның 17 июнендә Н. Җиһановның «Качкын» операсы (Ә. Фәйзи либреттосы) белән Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла. Ә аннан соң Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, Х. Вәлиуллин, Җ. Фәйзи опера иҗаты өлкәсендә җиң сызганып эшлиләр. Опера театры сәхнәсендә Н. Җиһановның «Ирек», «Алтынчәч», «Илдар», «Түләк», «Шагыйрь», «Намус», «Җәлил», М. Мозаффаровның «Галиябану», Х. Вәлиуллинның «Самат», «Дим буенда», Җ. Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» исемле опералары куела.

Нәҗип Җиһанов опералары татар операсы жанрында яңа үсеш этабы ача, үзенә хас стиль бөтенлеге һәм драматургиясе булган, халык традицияләре, рус һәм дөнья музыкасы классикасына нигезләнгән опера жанры өлгереп җитә. «Алтынчәч» һәм «Җәлил» опералары халкыбызның музыка классикасы фондына керә.

Күргәнебезчә, татар дәүләт драма театры опера сәнгатебезнең тууы һәм үсешендә мөһим роль уйный. Сәхнәдә барган музыкаль спектакльләр операның мәйданга күтәрелүендә зарури бер баскыч булалар, сәхнә уенын вокаль номерлар, җырлар, арияләр, дуэтлар белән бергә алып баручы актерлар арасыннан беренче опера җырчылары үсә, ә музыкаль драманың үз эчендә акрынлап киләчәк татар операларының милли стиле нигезләре һәм мөһим сыйфатлары формалаша.

**МАРГАРИТА ФӘЙЗУЛЛАЕВА.**

# ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘР ЮЛГА ЧЫГА

Роберт Миңнуллин һәм Фәннур Сафин... Ике шагыйрь, ике дус. Мин аларның икесен дә яхшы беләм — икесендә ике төрле характер. Үзләренең холык-фигыльләре белән аларның әсәрләрендә туган образларны, лирик геройларының характер сыйфатларын чагыштырып карыйм, шәхес һәм лирик герой мөнәсәбәте хакында уйлыйм. Туры киләме алар?.. (Кайчакларда, кызганычка каршы, тормышта бер төрле яшәп, бөтенләй икенче төрле язарга өйрәнгән кешеләр дә очрый бит. Мондый очракта шәхес белән герой конфликтка керә. Бу исә әсәрләрнең эмоциональ тәэсир көченә зыян китерә.)

Сүзне Роберт Миңнуллин шигырьләреннән башлыйк.

**Теләсәң, шаулап була,**
**Исемнәр яулап була,**
**Урыннар даулап була.**
**...Дивана түгел заман,**
**Барсын да аңлый заман.**
**Шау-шуларга ышанырга,**
**Узган бит андый заман.**
**Теләгәннәр шауласыннар,**
**Дауласыннар,**
**Яуласыннар...**

Минемчә, бу — программа характерындагы шигырь, шагыйрьнең дә, лирик геройның да кемлеген, асылын, ниһаять, яшәү принципларын ачык күрсәтә торган шигырь. Р. Миңнуллин, белүемчә, үзе дә шулай яши — терсәкләр белән түгел, табигый сәләте, тырышлыгы ярдәмендә эшли. Вакытлы матбугатта чыгып килгән шигырьләре дә, әле күптән түгел басылып чыккан «Бәхетле булыгыз» дигән җыентыгы да — шул тырышлык нәтиҗәсе. «Ояла-ояла гына Тукай яшен узып барган» яшь шагыйрьнең дөньяга карашы, үз эшенә, хезмәтенә мөнәсәбәте лирик геройның да характер сыйфатларын, яшәү нормаларын билгели. Һәр китапка, бигрәк тә беренче җыентыкка, бөтен җәһәттән коеп куелган, ювелирларча эшләнгән әсәрләр генә керү мөмкин түгелдер. Шунысын да истән чыгармаска кирәк: кем өчендер шәп тоелган әсәрне икенче берәүнең бөтенләй кабул итмәве дә ихтимал бит әле. Һәр бәядә — күңел халәте, зәвык үсеше, шәхси мөнәсәбәт — субъективлык моменты бар. Бәхәстә критерий — поэзиянең бүгенге үсеш дәрәҗәсе. Ул инде шәхси теләкләр белән, әлбәттә, исәпләшми.

Р. Миңнуллин китабында да кемдер кабул итмәслек, кире бәя бирерлек, яки чынлап та эшләнеп, табылып бетмәгән шигырьләр юк түгел. Шундыйлар рәтенә мин «Шамун Фидаигә», «Икмәккә мәдхия», «Имин булыр илләр», «Татар хатыннары», «Кунакчыллык» дигән риторик шигырьләрне кертер идем. Болардан тыш, тагын ачыклап бетерәсе аерым строфалар һәм юлларны табарга мөмкин. «Булмас иде һич куркыныч, кем кулында бит ул кылыч?!» дигән икеюллыкта, мәсәлән, мәгънәне рифма җиңгәндәйрәк тәэсир кала. «Төнге пейзаж» шигырендәге: «Кемдер аяз күк йөзенә чиләкләп энҗе сипкән. Юк, Зөһрә-кыз, кич утырып, зәңгәр кулъяу-

лык чиккән» — дигән юлларга да бәйләнеп була. Чиләклап яңгыр койса — табигый хәл. Ә чиләклап күккә энҗе сибү сәеррәк яңгырый. Күкнең (кулъяулыкның) зәңгәрлеге дә тәнлә күзгә бик ташланмый бит. Бәхеткә каршы, мондый юллар күп түгел. Киресенчә, бирелеп, сокланып укырлык, самими язылган, саф тойгылы шигырьләр өстенлек итә:

Керфегеңдә, чәчләреңдә
Җылы кар, яңа кар.
Әллә соң кызлар урамга
Чәчкәнме чулпылар!!
Бер-берсенә орынсалар,
Валлаһи, чылтырар
Көмештәй чулпылар.

Бу кар чулпыларда табигатьнең матурлыгы да, хатын-кызның сафлыгы да, яшәүнең яктылыгы, гүзәллеге дә чылтырый кебек. Мондый шигырьләрне укыганда, синең күңелгә дә дөньяны сабыйларча ярату хисе йога, күңел ничектер тынычланып, яңарып китә, кичерешләр салмаклана, тигезләнә.

Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,
Сөн суында юган иң элек...

Яки

...Без әнкәйнең биш кайгысы булдык,
Биш шатлыгы булдык кайчакта,

— дигән юллар күңелне (әйдә без аны, гадәттәгечә, кыллы инструмент итеп күз алдына китерик) яшәү матурлыгына, балаларча яратуга — дөрес яңгырашка көйләмимени?

Җир бәхеттән оеп ята —
Ак әкият, тылсым инде!
Бу аклыкка, кулы барып,
Кем яманлык кылсын инде!

Табигать аклыгы шагыйрьнең, кешенең саф хисләре белән берләшә. Туган җир сурәте, бала чак, яшьлек хатирәләре тантаналы тынычлык булып гәүдәләнә. Кешене гел борчып, ярсытып кына торырга димәгән, аның җанына матурлык элексиры сирпеп, ял да бирергә, яшәүгә яңа көч өстәргә дә кирәк ләбаса! Р. Миңнуллинның үзенә дә, шигырьләренә дә шундый сыйфат бирелгән. Ул артык борчылмаса да, барыбер уйлана, кичерә, ләкин матур хатирәләрнең кадерен, тәмен дә белә.

Хатирәләрнең шигырьгә әверелүе — иң табигый хәл һәм, әйтер идем, шагыйрьгә җиңелрәк бирелә торган, күпмедер дәрәҗәдә җайлырак хәл итела торган нәрсә. Ә менә бүгенге хәлләрне күреп, туа гына башлаган тойгыларны тәртипкә китереп, аларны риторикага, өстән-өстән генә язылa торган тасвирламаларга кайтарып калдырмау өчен тәмам җитлеккән шагыйрьгә дә гаять күп көч түгәргә, газап кичерергә туры килә. Бүгенге көн күренешләрен чын сәнгать фактына әверелдерә алу табигый сәләт, профессиональ өлгергәнлек хакында сөйли. Мәсәлән, Робертның Әрмәнстанга бару тәэсирендә язылган шигырьләре шул хакта уйларга мәҗбүр итә. Алар — публицистика түгел, эскизлар да түгел, чын, тирән шигырьләр:

Ирләр кебек — эндәшмиләр таулар,
Аларда да ирләр холкы бар.

«Мартирос Сарьян» шигырендә хәтта бөтен Әрмән иле сурәтен күрәбез.

Таулар иле бәйрәм көткән кебек —
Нинди матурланган, ясанган.
Әйтерсең лә Әрмәнстан үзе
Сарьян кулы белән ясалган!!

Шагыйрьнең профессиональ яктан үсешен, ә лирик геройның гражданин буларак өлгергәнлеген расларлык юлларның барысын да санап чыгу мөмкин түгел. Шунлыктан кайберләренең исемнәрен генә атау белән чикләнергә туры килә: «И изге йорт», «Ахак учак», «Базыда бозлар ага» (соңгы строфасын сызып), «Малайлар», «Элекке «Англетер» гостиницасында», «Клараға», «Көз инде», «Ярый әле» һ. б.

Билгеле булганча, язу манерасы, стиль ахыр чиктә шулай ук характер сыйфатларына килеп тоташа. Р. Миңнуллинда стиль алымнары төрле, ә күзгә нык ташланганы — афоризмга охшашлык. «Яхшылыкка тик яхшылык», «Беребез дә алдан белә алмый», «Дөнья бит ул», «Мәхәббәт» кебек шигырьләре шундыйлар рәтенә керә. Алар халыкчанлык, гадилек белән аерылып торалар.

Шагыйрь халык, ил, җир хакында заман проблемалары зурлыгын тоеп фикер йөртә. Ул шигырьләрне укып чыккач, якты хисле, тыныч холыклы тыйнак кеше образы күңелдә кала.

**Аптырыйсыз. Әйтерсең лә**
**Андыйлар бер без генә.**
**Әйбәтме, әйбәт түгелме —**
**Шундый инде без менә.**

Минемчә, андый булу әйбәт. Кирәгеннән артык дәгъвалы кешеләр күбәйгән вакытта тыйнакларның кадере бермә-бер арта.

Аерым юллар, строфалар, бөтен шигырьләрнең дәрәҗәсен күтәрә алырлык: «Берәүләрне Алып итә, тик барыбер алып китә — дөнья бит ул», «Сагышыннан сары чәчәк аткан каберендәге сәрби куагы», «Уйланырга куркып басып торам» (Есенин үлгән гостиницада), шулай ук тайларның кояшны тешләмәкче булып ыргылулары һәм башка шундый кызыклы тәгъбирләр, язу осталыгы хакында сөйләү белән бергә, яхшы күңелле, сизгер, эшлекле лирик геройның — совет кешесенең матур сыйфатлары булып та гәүдәләнәләр.

Андый сыйфатлар Фәннур Сафин әсәрләренә дә хас. Аның шигырьләрен укыганда да шагыйрьнең кеше буларак үз холкы-фигыленә тугры икәнлеге сизелеп тора.

Әйе, авторның үз тормышы белән аның лирик героен бер итеп күрәсе килә. Лирика — тойгылар хәрәкәте, фикерләр үсеше, җан яшәеше. Күңелдәгенең барын да яшермичә, үзеңнән, бигрәк тә башкалардан курыкмыйча, йомшаклыгыңнан оялмыйча, халәтеңне дөньяга табигый көенчә әйтеп бирә белсәң, шәхес белән лирик герой бер-берсеннән аерылмыйлар, һич югы, конфликтка кермиләр.

Фәннур Сафинның беренче шигырьләрен укыганда ук күңелдә якты, җылы тойгылар кала. Сәбәп өлеге шул — хакыйкать, дөреслек тойгысы, авторның эчкерсезлеге булса кирәк. Укыйсың, күз алдына Кама яклары, андагы тын авыллар, шаулы калалар, төзелешләр килә. Шагыйрь шул конкрет җирлектән юлга чыга. Шагыйрь зәңгәрсу томаннар аша балкып торган еллардан, ата-аналар, кардәш-ырулар гомер иткән, яхшылык-миһербанлыкка күнегелгән, шул ук вакытта үз-үзеңне кызганып елауның ярамаган эш икәнен, кешеләр хакында гына кайгыртып еларга мөмкин булуын аңлаткан җирдән юлга чыга.

Бу җир — туган җир.

Бу җир — башка шагыйрьләрнең дә ватанына охшаш. Бәлки аны бөтенебез дә бертөрле яратабыздыр, ләкин төрлечә күрәбездер. Һәркем аны үзенчә күргән хәлдә, үзенчә җырлый. Бүтәнчә ярамый. Шулай тиеш. Фәннур да мәхәббәтен кабатланмаганча, яңача әйтеп бирә белә. Бу җирләрдә көннәр мәхәббәт белән җылытылган, ә төннәренең «нигәдер күзе дымлы...»

Конкрет җир шигъри дөньяга әверелә башлый һәм ул дөньяда лирик герой яши.

**Авыр чакта ил барыбер**
**Үз моңына сыенып...**

Лирик герой сурәте халык сурәте белән берләшә.

Шагыйрьләренең кадерен белми башлаган халык — кыска гомерле. Ә халык кадерен белмәгән шагыйрь — икеләтә кызганыч. Андыйлар булмый, булмаска тиеш. Илсез-йортсыз кешене сукбай дип атыйлар. Юлга чыккан шагыйрь халык тормышыннан чыгып китми — мәңгелеккә шунда кала.

Лирик геройның якташлары үзләренчә яшәгән кебек, үзләренчә сөйләшәләр дә. Шуның бер билгесе — «з» авазы урынына «д» әйтү, «җ»ларны күбәйтебрәк сөйләшү. Герой бу яклап та индивидуальләшә. Аның уйлап кына чыгарылган «мин» түгеллегенә ышанасың.

Конкрет төбәге булган кебек, ул яшәгән вакытның да реаль галәмәтләре бар: потлап-потлап сөт тапшыра торган якташларының кайчак төннәре «тарткан җәя кебек киеренке». Алар җирнең, халыкның иминлеген кайгырталар. Грузовикларга төялеп далаларга юнәлгән яшьләрнең палаткалар янында өмет утларында җылынып утыруларыннан да заман билгеләрен танырга мөмкин.

Дөньяда юллар — мәңгелек. Ләкин һәр заман аңа үз сыйфатларын бирә. Чулман-Кама юллары да нык үзгәрде. Анда хәзер, икенче дәвердән, әкиятләрдән килсә дә, Алыплар да манаралы кранга «Вира!» дип кычкырыр иде.

Лирик герой — Канкайлар оныгы.

Лирик герой — яңа тормышны төзүче.

Кыйммәтлесе шунда, сәнгать фактларына әйләнгән бу детальләр Фәннурның үз биографиясе белән дә раслана. Ул Казан университетына Түбән Кама төзелешеннән килә. Шагыйрь булып өлгергәч тә аның бу темадан китә алмавы, шул хакта яңадан-яңа шигырьләр язып торуы бер дә юкка гына түгелдер. Менә шунда инде шәхес белән лирик геройның (гәрчә гел тәңгәл кую дөрес үк булып бетмәсә дә) аерылгысыз икәнен тагын бер кат күрәсең.

Хәтта характер бердәмлеге дә сизелә. Мин белгән Фәннур — ягымлы, күзләре һаман көлеп тора. Шигырьләрендә дә шундый булып кала.

Фәннурда да, Робертта да җитди лирикага өш кына җорлык, җиңеллек килеп керә. Ләкин җиңел уйлау түгел. Алар шаярганда, синең дә күңелең күтәрелеп, дөньяң яктырып китә. Ә шул ук вакытта кайдадыр елга буенда, тезләрен кочаклап, яшьлек моңаеп утыра...

Мин Фәннурның бу образына да ышанам, күз алдына китерә алам.

Шагыйрь үзен кемнеңдер ышанычы итеп, кемнеңдер дәвамы итеп тоя. Шуңа күрә аның батырлары да моңая белә, Алыплары да елый белә...

Аның герое өчен хакыйкать — күкрәк баласы. Аны якларга, сакларга кирәк. Минемчә, мондый тойгыларны чын геройлар гына кичерә ала һәм чын шагыйрьләр генә яза ала.

Р. Миңнуллинның бер шигырендә тайлар билгесезлеккә атлыгалар:

> Карт ат кына гаҗәпләнеп
> Карап тора тайларга.

Нишләтик, андый «карт атлар» кешеләр арасында да юк түгелдер. Әмма яшьлек шуның өчен дә яшьлек бит инде ул — гаҗәпләнү, өнәмәүләргә карамыйча, күз дә салмыйча ары чаба.

Андый тайлар Фәннурда да бар.

Шагыйрьләр зур өметләр белән юлга чыга. Якты юлга чыга.

Шулай икәнлегенә ышанып, мин аларга:

— Хәерле юл! — дим.

Аларның бездән арырак китсен, ераграк заманнарга җитсен белеп, кул болгап калам.

ӘХСӘН БАЯНОВ

IIIIIIIIIIIIIII

Самат Шакир

# ИЛЕМ ӨЧЕН, ҖЫРЫМ ӨЧЕН...

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубына кергәндә, уң як стенада ак мәрмәрдән эшләнгән истәлек тактасы тора. Ул тактага Бөек Ватан сугышы елларында батырларча һәлак булган язучыларның исемнәре теркәлгән. Алтын хәрефләр белән язылган изге исемнәр арасында Лотфи Вәли дә бар.

Бик күп укучылар Лотфи Вәлинең тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксыналар. Язучылар союзына, редакцияләргә аның турында сорашып хатлар килә. Бу мәкалә шул сорауларга җавап рәвешендә язылды.

Лотфи Вәли (Лотфи Вәлимөхәммәт улы Вәлимөхәммәтов) 1910 елда тугандаш Башкортстан республикасының Кушнаренко районы, Илек авылында туа. Лотфига бер яшь тулганда аның әнисе вафат була. Берникадәр вакыттан соң, әтисе өйләнеп, булачак шагыйрь үги әни тәрбиясендә кала. Үз әнисенең ягымлы сүзләреннән, җылы карашыннан мәхрүм булган балага бик яшьли авыр эшләр башкарырга туры килә. Унбиш яше дә тулмаган килеш, авылын ташлап, ул Бөре шәһәренә чыгып китә, анда төрле урыннарда хезмәт итә.

1929 елда Лотфи, башкалабыз Мәскәүгә күчеп, шундагы заводларның берсенә эшкә керә, кичләрен укып, үзенең белемен күтәрә. Бу — беренче бишьеллыклар, коллектив хуҗалыклар төзү башланган чор, халык хуҗалыгының барлык тармакларында хезмәт энтузиазмы киң җәелгән бер чак була. Нәкъ шул елларда завод-фабрикалардан, төзелеш мәйданнарыннан, колхоз кырларыннан әдәбият мәйданына бик күп яшьләр килә. Лотфи Вәли — шуларның берсе.

Аның әдәбиятка килеп керүендә герой-шагыйребез Муса Җәлилнең роле зур. Мәскәү шәһәрендәге заводларда һәм төзелешләрдә эшләгәндә, ул М. Җәлил тарафыннан оештырылган әдәби түгәрәккә йөри, башкалада яшәүче шагыйрьләр белән очраша, алардан киңәшләр ала. Лотфиның беренче шигырьләре һәм мәкаләләре ул елларда Мәскәүдә татар телендә чыгып килгән «Коммунист», «Эшче» газеталарында, «Октябрь баласы» журналында басыла.

Инде әйтелгәнчә, Лотфи Вәлигә иске тормышның авырлыгын бик кечкенәдән үз җилкәсендә татырга туры килә. Шуңа да аның шигырьләрендә әнә шул авыр тормышка ләгънәт уку, байларга һәм алпавытларга ачу һәм нәфрәт белдерү, аларга каршы көрәш мотивлары калку итеп күрсәтелә. Шагыйрьнең семья архивыннан табылган «Җәбер, золым күрдек без» дигән шигырендә, мәсәлән, мондый юллар бар:

**Җәбер, золым күрдек без,**
**Иске бишмәт кидек без.**
**Байлар өчен эшләсәк тә,**
**Хәер сорап йөрдек без.**

Лотфи Вәлинең беренче шигырьләре сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан шактый зәгыйфь була. Ләкин шунысы характерлы, алардан шул чорның сулышы бөркелеп тора, ул шигырьләрдә хезмәтнең дан эше, мактау эше икәнлеге шактый калку итеп, пафос белән әйтеп бирелгән. Менә аның Ибраһим Гази һәм Мирсәй Әмир төзегән «Каләмле ударниклар» альманахында басылган «Туган цехлар аккорды» шигыренең беренче юллары:

**Ул цехларның кайнар төзү чоры**
**Җырлап үтелмәгән үтүен.**
**Туар җырлар кебек,**
**Без аларның**
**Сагынып көттек ходка китүен...**

Яшь шагыйрь шахтерлар, метро төзүчеләр, чуен коючылар турында күп яза. Аның «Забойлар төбеннән», «Колчеданнар җыры турында», «Даешь, металл!» шигырьләрендә хезмәт эчендә кайнаган эшче шагыйрьнең уй-кичерешләре белән очрашабыз.

Ибраһим Гази белән Мирсәй Әмир эшче шагыйрьнең беренче шигырьләренә уңай бәя бирәләр: «Иптәшләрнең күпчелеге производствоның эчендә торып, үзләренең әдәби хезмәтләрен конкрет бер производствоның көндәлек практик бурычларына бәйләп алып бара беләләр,— диләр алар.— Мәсәлән, Мөхәммәт Садри, Лотфи Вәли һ. б. тагын бик күп иптәшләрнең шигырьләре үзләре эшли торган производствоның көндәлек мәсьәләләренә карата язылган. Шуның белән бергә, бу шигырьләр конкрет алынып язылган бер производство өчен генә яраклы булмыйча, гомумән, бөтен производстволардагы кимчелекләр белән көрәшү өчен үткен корал була алалар һәм совет әдәбияты өчен алар шул яклары белән кыйммәтле дә...»

Лотфи Вәлинең иҗат колачы елдан-ел киңәя, зурая бара. Ул япон самурайларына каршы шигырьләр яза («Кыйнадык һәм тагын кыйнарбыз»), төньяк Котыпны үзләштерүчеләрне тәбрикли. Аның бөек В. И. Ленинга багышланган шигырьләре байтак. Үзе оригинал шигырьләр язу белән бергә, ул башка милләт шагыйрьләренең юлбашчы турындагы күп кенә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Мәскәүдә эшләгәндә Лотфи Вәли нәшриятта аерым китап итеп чыгару өчен үз шигырьләреннән бер җыентык төзегән. Аңа шагыйрь Мансур Крымов эчке рецензия язган. Бу турыда М. Крымовның хаты бар:

«Лотфи Вәли!

Саумы? Мин 5 гыйнвардан 2 февральгә кадәр командировкада булдым. Шуңа күрә синең язган хатларыңа җавап бирә алмадым. Әле 2 февральдә генә Мәскәүгә кайттым. Һәрхәлдә, синең сораган сорауларыңа җавап бирәмен.

Мәскәүдә китап бастыра торган урын юк. Аны Свердловскига җибәрсәң шәп булыр.

Аннан соң, мин сүз башы язарга булган идем, командировкага китү аркасында эшли алмадым. Синең китап-шигырьләр Муса Җәлилдә ята.

Мин, аны тиз арада алып, берәр чарасын күрермен.

Хәзергә сау бул.

Дуслык сәламе белән: **М. Крымов.**

2/II — 1934 ел.»

Күпме тырышсак та, хәзергә бу җыентыкның язмышын ачыклый алмадык. Шагыйрьнең үз архивында да, Муса Җәлил белән Мансур Крымов архивларында да әлеге кульязма табылмады.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан, Лотфи Вәли берничә тапкыр Казанга килеп, Язучылар союзы каршындагы әдәби консультация бюросына үзенең шигырьләрен калдырган. Шигырьләрен тикшергәннәр, иң уңышлыларын сайлап алып, шул елларда чыккан төрле җыентыкларга керткәннәр. Мәсәлән, 1939 елда чыккан «Туган ил» альманахында бер шигыре бар. Анда сүз данлы совет иле турында бара. Шагыйрь шул илнең гражданины булуы белән горурлана. Шигырен ул зур шатлык

һәм рухлану, шундый илең булуга горурлану хисләре белән, пафослы һәм тантаналы итеп тәмамлый:

**Тик бер синдә генә яшәү — шатлык,**
**Яшәү — бәхет, яшәү — күңелле!**
**Шуңа күрә сөям, илем, синең**
**Җирең, суың, зәңгәр күгеңне!**

Лотфи Вәли үзенең җыентыкларын бастырып чыгарырга өлгерми кала — Бөек Ватан сугышы башлана. Шагыйрь, кулына корал алып, немец илбасарларына каршы сугышка китә. Фронтта ул батыр разведчикларның берсе була, зур һәм җаваплы заданиеләр үти, часть командирыннан рәхмәтләр ала. Каты бәрелешләрдән соңгы кыска ял сәгатьләрендә, юл капчыгыннан кәгазь, карандаш алып, шигырьләр, очерклар яза, көндәлекләр алып бара. Ул Казан һәм Мәскәү белән, язучылар һәм газета-журнал редакцияләре белән тыгыз элемтәдә була. Яңа шигырьләрен «Совет әдәбияты» журналына җибәреп тора. Менә аның «Совет әдәбияты» журналының 1942 елгы апрель санында басылып чыккан «Йөрәк тавышы» дигән шигыре:

**Суксам тимер өзәр чагым минем,**
**Йөрәгем көчле, үчле, ялкынлы.**
**Илем өчен, җырым, әнкәм өчен**
**Кабатлыйм мин изге антымны!**
**Кабатлыйм мин аны чын күңелдән,**
**Кабатлыйм мин халкым алдында.**
**Кабатлыйм мин: бөтен илбасарны**
**Тар-мар итү өчен барын да!**

Шагыйрь һәм солдат Лотфи Вәли, алда әйтелгәнчә, Төньяк-Көнбатыш фронтта башта минометчы, аннан соң разведчик, сапер булып сугыша. Берничә тапкыр яралана, ләкин алгы сызыктан китми. «Чигенмим мин» дигән шигыре безгә аның фронт тормышы турында сөйли:

**...Көрәш кырын ташлап, бу хәлемдә**
**Артка чикмим, иптәш санитар.**
**Ярам өчен тагын үч алам мин,**
**Кемлегемне аңа танытам!**

**...Ә бу ярам минем тирән түгел,**
**Әле көрәшерлек хәлем бар.**
**Үз аягым белән бер адым да**
**Чигенмәм мин, иптәш санитар!**

Сугыш кырында ул шигырьләр генә түгел, чәчмә әсәрләр дә яза. Аның окопта язган «Ертылган хат» дигән очеркы бар. Әсәрдә Әхәт Әхмәтҗанов дигән снайперның кыюлыгы, тапкырлыгы җанлы, йөгерек тел белән, истә калырлык итеп сурәтләнә.

Бөек Ватан сугышы елларында Лотфи Вәлинең иҗаты тагын да үсә төшә, әдәби осталыгы камилләшә. Ул, хәрби осталыкка өйрәнү белән бергә, иҗат активлыгын да арттыра. Шигырьләре, очерклары, мәкаләләре фронт газеталарында һәм Татарстандагы газета-журналларда басылып бара. Лотфи Вәли хезмәт иткән дивизия, фашист офицерларын һәм солдатларын кырып, бик күп әсирләр алып, шәһәрләрне һәм авылларны азат итә. «Без зур адымнар белән алга барабыз! Без фашист илбасарларны җиңәчәкбез!» — дип яза ул хатларында.

Төньяк-Көнбатыш фронт сугышчылары дәүләт чикләренә якынлашалар. Гвардияче полклар сафында Лотфи Вәли дә алга юл яра. Бер биеклек өчен барган сугышта немец илбасарлары безнең гаскәрләргә бик нык каршылык күрсәтәләр. Өч тәүлектән соң гына биеклек совет сугышчылары кулына күчә. Җир асты ныгытмаларыннан, землянкалардан, блиндажлардан төркем-төркем булып немец солдатлары һәм офи-

церлары чыга, кулларын күтәреп әсир төшәләр. Арада бик күп илләрне талаган, совет халкына бәла-казалар, үлем һәм дар агачлары алып килгән «СС» дивизиясе солдатлары да була. Алар хәзер мескен булып кыланалар. «Гитлер капут, Берлин капут!» дип, дер-дер калтырап, совет сугышчылары алдына басканнар. Бу күренешне күзәткән Лотфи Вәли «Пленный илбасар» дигән шигырь яза һәм Казанга җибәрә. Әсәрдә ерткыч Гитлер солдатын ул болай сурәтли:

**Ул, күтәргән килеш ике кулын,**
**Шәфкать сорый — яшьле күз белән.**
**Ерткычлыкның бөтен зәһәр агуы**
**Аңкып тора аның үзеннән.**
**Бөтен ачуымны бергә җыеп**
**Карап торам шушы кулларга.**
**Канга баткан шыксыз бармакларын**
**Өлгермәгән, явыз, юарга.**
**Шушы инде безнең аналарны,**
**Газиз балаларны буган кул.**
**Күз яшьләре белән шәфкать сорый...**
**Карагыз, ничек мескен булган ул!**

Лотфи Вәли сугыш кырыннан өч-дүрт дәфтәр шигырьләр җибәрә. Ләкин алар янгын вакытында юкка чыгалар. Фронттан язган хатлары да, фоторәсемнәре дә янып көлгә әйләнә. Архивының бик аз өлеше генә сакланып калган...

1943 елның кышы. Окопларга кар сырышкан. Көчле җил күз ачарга да ирек бирми. Тирә-якта артиллерия канонадасы. Баш өстеннән безнең самолетлар очып уза. «Катюша»лар дошманга ут ташкыны яудыра. Көчле «ура» тавышлары яңгырый. Немецларның атаклы дивизияләрен сытып-җимереп, совет сугышчылары алга ыргыла. Атакага күтәрелүче солдатлар арасында бер сугышчы мина ярчыгы тиеп җиргә егыла. Аның күкрәгеннән кан саркый. Ул полкташлары кулында килеш соңгы сүзләрен әйтә:

— Хатыныма, балаларыма хат языгыз... Кыр сумкасында шигырьләрем бар, аларны Казанга, «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә җибәрегез...

Батыр сугышчы дөнья белән мәңгелеккә бәхилләшә.

«Совет әдәбияты» журналының 1944 елгы 2—3 саннарында Лотфи Вәлинең фронттан җибәрелгән соңгы шигырьләре басылып чыга.

Исхак Зәбиров,

филология фәннәре кандидаты

# МУСА ҖӘЛИЛ ИҖАТЫНДА ЛЕНИН

*«...Владимир Ильич кебек бөек фигураны бөтен колачы белән, тулаем алып сурәтләүнең аерыча читен мәсьәлә икәнлеген танырга туры килә. Зур һәм кыен бурыч бу. Ясалып бетмәгән портретны, күрәсең, киләчәк гасырлар төгәлләр».*

*Г. М. Кржижановский.*

Муса Җәлилнең легендага әверелгән тормышы — данлы ленинчыл идеология мәктәбендә тәрбияләнгән, зур рухи куәткә, рухи гүзәллеккә ия булган шәхес биографиясе ул. М. Җәлил царизм тарафыннан җәберләнгән, ә хәзер, совет чынбарлыгы шартларында, талантлары чәчәк ату өчен бөтен мөмкинлекләр алган татар халкының улы иде. Һәм ул үз шигърияте белән генә түгел, көрәшче-гражданин булуы белән дә үзен үстергән халыкның данын бөтен дөньяга таратты. Хәтта аның үлеме дә яңа дөнья кешесенә гимн булып яңгырады.

«Исең китәрлек бит: без — французлар, атып үтерелгән Гарсиа Лорка исемен ишетеп тетрәнгән, атып үтерелгән Жак Декурның соңгы сүзләрен яисә нацистлар тарафыннан асып үтерелгән Юлиус Фучикның төрмәдә язган китабын тын да алмыйча укыган кешеләр, бу совет шагыйренең хәтта исемен дә белми идек. Оят эш бу. Ул кеше Казан һәм Новосибирск, Одесса һәм Сәмәрканд, Владивосток һәм Ленинград, Тбилиси һәм Ригада яшәүче барлык туганнары өчен һәлак булган. Ул үзенең гомерен шулай ук без — французлар яисә чехлар өчен дә корбан иткән...» — дип яза атаклы француз язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Луи Арагон.

Һәр батырлыкның тамырлары еракларга китә. Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең бөтен гомер юлы: ялкынлы яшьлегендә салган беренче сукмаклары, белемен күтәрү, уку, чыныгу чоры, партиянең ару-талуны белмәс яшь һәм дәртле көрәшчесе булып өлгереп җитүе, киң колачлы иҗаты һәм җегәрле эшчәнлеге, ниһаять, Бөек Ватан сугышы елларындагы тиңсез батырлыгы — боларны бүген җир шарының төрле почмакларында яшәүче бик күп кешеләр белә.

Оренбург шәһәреннән туган авылы Мостафага кайту белән үк яшүсмер Муса партия ячейкасы ярдәмендә авыл балалары арасында оештыру эшен башлап җибәрә, Оренбург ягы авылларында беренче дип әйтерлек пионер оешмасы шулай туа. Балаларга ул Бөек Октябрь революциясе, барлык изелгән халыкларның юлбашчысы

Ленин хакында сөйли. Яңа тормыш төзү, илгә күбрәк файда китерү өчен бик күп укырга, белем тупларга кирәклеген яшь Муса яхшы аңлый. Егерменче елларның башларында ул Казанга килә, рабфакка укырга керә. Казанда ул зур шигърият дөньясы белән очраша, татар әдәбиятының Кави Нәҗми, Фәтхи Бурнаш, Һади Такташ кебек күренекле вәкилләре белән таныша, үзе дә якыннан торып иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Шушы ук чорда яшь шагыйрь беренче тапкыр шигырьдә Ленин образына мөрәҗәгать итә һәм «Ленин туды» дигән шигырен яза. Бу шигырь әйтерсең «Авыру комсомолец» поэмасының туачагына алдан хәбәр биреп куя.

В. И. Ленинның вафатын яшь Муса тирәнтен кичерә, «бик яшь көе аннан ятим калып» яшәү шагыйрьгә бик авыр, чөнки «безнең телләр «Корьән» сүзе түгел, Ленин сүзе белән ачылган». «В. И. Ленин» шигырендә ул яшьләргә мөрәҗәгать итә, алар өчен юлбашчы сүзенең, ул калдырган васыятьнең гаять зур куәткә ия булуын раслый. Көннәрне Ленинсыз үткәрү җиңел булмаса да, яшь эшче һәм көрәшче йомшап, өркеп калмас, ул гаҗизлек хисеннән өстен тора, чөнки ул — ленинчы, яңа социалистик җәмгыять төзүдә юлбашчы планнарын тормышка ашыручы. Бу хис-фикерләр «Ленин туды» исемле шигырьдә тагын да киңрәк гәүдәләнә. Үлем турында түгел, ә юлбашчының тууы, барлык изелгән, кыерсытылган юксыллар өчен бу көннең нинди әһәмияткә ия булуы хакында яза М. Җәлил. Ленинның тууы — хезмәт кешеләре өчен, чыннан да, зур бәхет, шул ук вакытта ул бер очраклылык кына түгел, ә тарих өчен зарури күренеш.

**Бөкре әткәемнең шахтасыннан,**
**Икмәк сүзе белән ялганып,**
**Яңрап чыккан чүкеч авазы,**
**Әнкәемнең тире заводыннан,**
**Түккән күз яшенә алланып,**
**Җиргә төшкән әрнеш карашы**
**Тудырдылар аны.**

М. Җәлил бу шигырендә Ленинны «миллионнарча әтием-әниләремнең углы» дип атый, үзе исә, шул ук образ ассоциациясе буенча, аңа «әтием» дип эндәшә. Коллык һәм эксплуатация дөньясының җимерелүе, Россия халыкларының азатлык яулап алуын, кешелекнең яңа эрасы башлануын яшь шагыйрь үзенең шәхси язмышы аша күз алдына бастыра, әнә шул сурәт чаралары белән тасвирлый.

М. Җәлил Ленин образын һәрчак күңелендә йөртә, шигырьләрендә дә аңа каткат әйләнеп кайта. В. И. Ленин әле исән чакта ук Муса илнең иҗтимагый тормышында кайный, яңа тормыш өчен көрәшүчеләрнең алгы сафларында булырга тырыша. Хак эшнең тантанасы өчен актык сулышкача көрәшү — егерменче елларда ук инде шагыйрьнең девизы әнә шундый. Бөек Октябрь һәм Ленин, ленинчыларның тормыштагы тарихи роле М. Җәлил иҗатында гражданин-шагыйрь күзлегеннән гәүдәләндереләләр, ул үзен марксизм-ленинизм идеяләренең ялкынлы пропагандисты итеп күрә.

**Без туганбыз Октябрьда,**
**Без — Октябрь баласы.**
**Октябрьда туганнарның**
**Ленин була бабасы.**

Сугыш алды елларында, башлангыч классларда укыганда, шушы җырны җырлап йөрүебез әле дә хәтердә. Ул җыр минем шикелле меңнәрчә пионерларның күңелендә Ленин һәм Октябрьга мәхәббәт орлыклары чәчеп үстергән.

В. И. Ленинның характер байлыгы, образының тирән һәм күпьяклылыгы шагыйрь алдында зур мөмкинлекләр ача. М. Җәлил дә шигырьләрендә юлбашчы образының әле бер, әле икенче сыйфатына мөрәҗәгать итә, аның тирән акылы һәм ихтыяр көчен, юмор һәм ирониясен аерым алып сурәтли.

Муса Җәлил яшьләр тормышын аеруча яхшы белә, аның хезмәт фронтында күрсәткән батырлыкларын, тормышны үзгәртеп кору романтикасын лаеклы сурәт-

ләргә омтыла. Ул үзе дә бу көрәштә турыдан-туры катнаша, әзлекле рәвештә беләмен күтәрә һәм барлык сәләтен практик эшкә бирә.

**Ленин сукмагыннан киң эз белән**
**Үтүче ил!**
**Синең каршыга**
**Сыналырга килдем.**
**Мин — яшь егет.**
**Мин туганмын көчү таңында,**
**Укыганмын көрәш мәктәбендә,**
**Тикшергәнмен Ленин сабагын.**
**Бәһаңны куй —**
**Менә синең алда**
**Сабагымнан сынау ясадым.**

Комсомол яшьләр темасы — шагыйрьнең иң яраткан темаларыннан берсе. Яңа җәмгыятьне төзүчеләрнең образларын ул һаман тирәнрәк ачуга ирешә, алар җәмгыять алдында торган бөек бурычлардан аерылгысыз итеп сурәтләнәләр, коммунизм тантанасы өчен үз-үзеңне корбан итәргә әзер булу — алар өчен бик табигый халәт.

1924 елның көзендә М. Җәлил «Авыру комсомолец» («Үткән юллар») исемле поэмасын яза. Әсәрдә Ленин образы күренекле урын тота, ул монда шагыйрь һәм аның яшьтәшләренең үз тормыш тәҗрибәсе күзлегеннән сурәтләнә. Поэмасы белән Җәлил, асылда, Ленин темасын гәүдәләндерүдә әдәбият алдына яңа бурычлар куя. Әсәр үзәгендә революция эше өчен үзен корбан итүче фидакарь көрәшче образы тора. Яшь герой Ленинны үзенең йөрәгендә саклый, ленинчы булу аның өчен чын горурлык һәм чиксез бәхет. Поэма 1925 елда М. Җәлилнең «Барабыз» исемле җыентыгында басылып чыга. Шагыйрь бу әсәрен комсомоллар алдында еш укый һәм зур уңыш казана.

**Күңел нидер көтә.**
**Кинәт**
**Трибунада ул үзе...**
**Ленин...**
**Баскан.**
**Безгә сәлам укый,**
**Йөрәкләргә үтә һәр сүзе:**
**«Комсомолец — бөек исем.**
**Ләкин**
**Көч исемдә түгел, эшендә».**

М. Җәлил юлбашчының комсомол съезды трибунасыннан речь сөйләвен сурәтли, аның эчке психологик портретын гәүдәләндерүгә, кешелек сыйфатларына үтеп керергә омтылыш ясый. Поэманың яшь герое Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романындагы Павел Корчагинга бик якын тора. «Батырлык көрәштә туа. Батырлык кыенлыкларга һәр көн каршы торып, алар белән аяусыз көрәштә тәрбияләнә» — Н. Островскийның бу сүзләре М. Җәлил поэмасы героена да бик туры килә. Ул да, өметсез авыру хәлендә урында яткан килеш тә, көрәшче булып кала. Ул, Павка Корчагин кебек үк,— батырлык, рухи ныклык үрнәге.

Муса Җәлил шигырьләрендә без һәрвакыт авторның үзен дә күрәбез, ул үзе сурәтләгән вакыйгаларның шаһиты гына түгел, аларда шагыйрь үзе якыннан торып катнаша, тормышны алга әйдәп бара. «Батрак ана» шигыре нәкъ әнә шундый әсәрләрнең берсе.

**Бишле лампа кайчак сәке буйлап**
**Түргә ташлый тонык шәүләсен.**
**Анда мүкле калын стенада**
**Басып тора Ленин гәүдәсе.**

Батрак ана улын сагынганда
Карап куя шушы суратка.
Хәтерендә: аны әлгән чакта
Ярсып әйтте улы йөрәктән:
— Әнкәй, бу — Ленин бу!
Барыбызга да
Юл күрсәткән Ленин бабай бу!
Син сакла аны, яме!
Ә мин инде
Менә шушы Ленин сабакларын
Укырга дип иртән барамын...

Шигырьдәге яшь герой һәм аның батрак әнисе шагыйрь белән бергә тормышта үз урыннарын ныклы тоеп яшиләр, алар Ленин һәм Октябрь алып килгән тарихи хакыйкатьне беләләр.

Октябрь революциясе М. Җәлил алдында аң-белемгә, зур иҗатка юл ачты. Студентлык елларында ул К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әсәрләрен тирәнтен үзләштерә, рус, татар, Көнбатыш Европа, Шәрык поэзиясен өйрәнә. М. Горький һәм В. Маяковскийның Ленин образын гәүдәләндерү тәҗрибәләре дә яшь шагыйрьне күп нәрсәгә өйрәтә. Еллар үткән саен М. Җәлилнең шигъри таланты үсә, тирәнәя бара.

В. И. Ленинның үлүенә ун ел тулганда үзәк нәшриятта «Ленин СССР халыклары җырларында» дигән җыентык басылып чыга. Җыентыкта М. Җәлилнең дә «Ленин турында җыр»ы урнаштырыла. Бу җырга композитор Латыйф Хәмиди музыка яза. Сүзләрен русчага С. Болотин тәрҗемә итә. Авторлар юлбашчының шигъри һәм музыкаль образын чагылдырырга омтылалар.

Пионеры! Ленин умер.
Болью в сердце скорбь стучит.
Храбро биться за коммуну
Вождь наш Ленин нас учил.

Ленин һәм партия темасы, комсомол яшьләр образлары Муса Җәлилнең «Партиягә», «Съезддан», «Комсомолларга», «Туган ил», «Авыл советына», «Безнең авыл», «Иптәшкә» һ. б. күп шигырь һәм җырларында үстерелә.

Муса Җәлилнең күп кенә тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик чыгышлары да ленинчыл фикер йөртү стиле белән аерылып тора. «Югары сыйфат өчен көрәшкәндә», «Съездның көн тәртибенә», «Интернационал» тәрҗемәләре өстендә» һ. б. хезмәтләрендә ул әдәбиятта Ленин һәм тугрылыклы ленинчылар образларын тудыруны җитди бурыч итеп куя. Җәлил публицистикасы ул заманның яшь буын каләмнәренә әдәби иҗатта партиялелек һәм халыкчанлык принципларын үзләштерергә, гражданлык позицияләрен табарга ярдәм итә. Аның «Югары сыйфат өчен көрәшкәндә» исемле чыгышы бу яктан аеруча характерлы. 1940 елның 7 декабрендә М. Җәлил әнә шул темага Татарстан язучыларының гомуми җыелышында доклад ясый. Доклад тиздән «Совет әдәбияты» журналы (1941 ел, 1—2 саннар) битләрендә мәкалә булып басылып та чыга. Автор анда Бөек Ватан сугышы алды елларында татар әдәбияты барышына тәпле анализ ясый һәм әдипләр алдына тулы бер иҗат программасы куя. Әдәбиятта дөнья пролетариаты юлбашчысы В. И. Ленин образын күрсәтүне М. Җәлил идея эчтәлеген үстерүдәге «иң куанычлы һәм иң мөһим күренеш» итеп санавын әйтә. Ленин темасына багышланган әсәрләр өстендә эшләү югары гражданлык, чын иҗат атмосферасы, үзара бердәмлек һәм ярдәмләшү булганда гына уңышлы алып барылырга мөмкин. Докладчы үз алдына әнә шундый максатларны куя да. Ленин темасына язылган әсәрләр арасында ул Р. Ишморат белән Х. Фәтхуллинның «Ялкынлы яшьлек» исемле пьесасын бәяләп үтә. «В. И. Ленинның студентлык дәверен эченә алган һәм аның Казан университетындагы беренче революцион чыгышын чагылдырган бу пьеса, Ленин образын эшләүдәге һәм драматургик сюжетны корудагы зур гына җитешсезлекләренә карамастан,

безнең әдәбияттагы зур җиңешләрнең берсе булып тора», дип яза М. Җәлил һәм уңышның нигезен тарихи материалга һәм Володя Ульянов образын тудыруга авторларның иҗади якын килүләрендә күрә. М. Җәлил әдәбиятта М. Вахитов, Х. Ямашев, К. Якупов кебек күренекле татар революционерларының образларын сурәтләүне мөһим бурыч итеп куя. «Зур тарихи вакыйгалар фонында бу эре эшлеклеләрнең көчле, ачык художестволы образларын тудыру хезмәт ияләре массасын коммунизм рухында тәрбияләүдә зур җитди хезмәт булачак»,— ди ул.

«Съездның көн тәртибенә» исемле мәкалә дә әдәби әсәрләрдә көрәшче большевик образын сурәтләү, аларны тулы канлы, җанлы характерлар итеп бирү мәсьәләсенә багышланган. Ул бу өлкәдәге кимчелекләрнең сәбәпләрен эзли, социалистик реализм әдәбиятына лаек иҗат уңышларына китерерлек алым һәм чаралар хакында уйлана. М. Җәлилнең «Интернационал» тәрҗемәләре өстендә», «Драматургиябез алдындагы бурычлар» һ. б. күп мәкаләләре дә нәкъ әнә шундый югары таләпчәнлек рухы белән сугарылган.

Муса Җәлил иҗади яшьләрнең кайгыртучан һәм игътибарлы дусты, киңәшчесе иде. Эшчәнлегенең бу ягы белән дә ул үзен көрәшче-ленинчы, чын мәгънәсендәге коммунист итеп танытты. Ленин һәм партия, туган ил һәм хезмәт кешеләре темасы аның барлык әсәрләренең һәр күзәнәгенә үтеп кергән. Бары тик Ленин мәктәбен узган, ленинчыл чыныгу алган кеше генә фашист төрмәсендә үлем көтеп ятканда да югары сәнгать хасиятләренә ия булган, җиңүгә какшамас ышаныч белән сугарылган шигырьләр иҗат итә ала иде. М. Җәлил шигъриятенең сәнгать көче — аның югары партиялелегендә. Ленин һәм партияне сурәтләгән әсәрләре белән ул бөек максатларга хезмәт итүче мөһим миссияне — социализм, интернационализм һәм хезмәт ияләре бердәмлеген пропагандалау миссиясен үтәүгә өлеш кертте.

# ИҖАТ ЯШЬЛЕГЕ

Үзган ел Татарстан китап нәшрияты күренекле татар совет язучысы Афзал Шамовның «Сайланма әсәрләр»ен[1] басып чыгарды. «Бер мәхәббәт турында» исемле ул җыентыкка авторның нигездә егерменче-утызынчы елларда иҗат ителгән хикәяләре һәм повестьлары тупланган.

Афзал Шамов — яңа туып килгән әдәбиятның, татар совет әдәбиятының беренче сафларында торган әдипләрнең берсе. Гражданнар сугышы фронтларыннан ул әдәбиятка татар авылын, тагын да киңрәк итеп алганда, татар халкы тормышын социалистик үзгәртеп кору идеяләрен алып килә.

Язучының беренче хикәяләре матбугат битләрендә 1919 елда күренә башлый. Шул чордан алып, прозаик, публицист, тәрҗемәче, республиканың иҗат көчләрен оештыручы буларак, ул өзлексез тестә татар әдәбиятына хезмәт итеп килә. Мемуарчы һәм татар әдәбияты классикларының томнарын төзүче буларак та аның роле бәяләп бетергесез зур.

Тематик яктан нихәтле генә чуар булып күренмәсен, «Бер мәхәббәт турында» китабы эчке бөтенлеге белән аерылып тора. Ул әсәрләрдә революциядән соңгы еллардагы авыл һәм шәһәр тормышы, гражданнар сугышы вакыйгалары, авторның сугышчан яшьлеге чагыла. «Бер мәхәббәт турында», «Днепр буенда», «Очрашу» повестьлары А. Шамов үзе дә актив катнашкан гражданнар сугышын сурәтләүгә багышланган. Әдипне шулай ук совет властеның беренче елларындагы авыл тормышы да үзенә тарта. «Рәүфә» повесте һәм «Налог» хикәясе шуны раслый. Җыентыкка кергән хикәя-повестьларның байтагы моңарчы кат-кат басылган әсәрләр. Бу үзе үк аларның заман сынауларын уңышлы узган булулары хакында сөйли. Ул әсәрләрне укып, бүгенге яшьләр җәмгыятьне революцион юл белән үзгәртеп кору чорындагы вакыйгалар белән, егерменче һәм утызынчы еллардагы тормыш белән таныша алалар.

А. Шамов китабының тагын бер үзенчәлекле сыйфатын билгеләп үтәргә кирәк: аның геройлары төрле милләт кешеләре, һәм алар бергәләп яңа тормыш төзү өчен көрәшәләр. Китап битләреннән безнең алга шул заман кешеләренең тере образлары килеп баса. «Рәүфә» исемле повестьтан бәхеткә, яңа тормышка омтылучы Рәүфә, авыл егете, соңыннан Кызыл Армиянең яшь сугышчысы Насыйх («Очрашу» повесте), яшь комсомолка Рабига Салихова («Бер мәхәббәт турында» повесте) — әнә шундыйлар. А. Шамов әсәрләрендәге бу һәм башка персонажлар тормышчан, хис һәм фикерләренең чын булулары белән аерылып торалар. Персонажларын тасвирлаганда язучы үзен әдәби характерлар коюю остасы итеп таныта. Аның әсәрләрендә пейзаж сәнгатьчә тасвирның мөһим бер чарасы булып тора, ул органик төстә әсәрнең сәнгатьчә тукымасына килеп керә, үз геройларының рухи халәтен бирү өчен автор аңардан ифрат оста файдалана. Әйтик, «Рәүфә» повестеның башындагы язгы табигать күренеше беренче юллардан ук авторның идея-эмоциональ максатын аңларга булыша. Тагын А. Шамов әсәрләренең лексик байлыгын билгеләп үтәсе килә. Ул бүген дә матурлыкларын, афористик характерларын югалтмаган халык тәгъбирләрен, мәкаль-әйтемнәрне мул һәм оста куллана. А. Шамовның образлы, тирән мәгънәле теле күп кенә яшь һәм башлап язучылар өчен үрнәк була ала. Беркемгә дә

---

[1] А. Шамов. Сайланма әсәрләр. Бер мәхәббәт турында. Казан, 1976 ел.

сер түгел, кайбер яшь язучыларның теле төссез, ярлы һәм коточкыч дәрәҗәдә бертөсле.

Әсәрнең композициясен кора, мавыктыргыч фабула төзи белүне дә язучының осталыгы хакында сөйләүче бер сыйфат дип санарга кирәк. Бу яктан бигрәк тә «Туйда» әсәре аерылып тора. Анда асылда повесть эченә повесть сыйган, өстәвенә язучы үзенә кирәкле идеяне кызыклы формада җиткерә алган (Туры Хикмәтнең хикәясе). А. Шамовның хикәя-повестьлары сурәтләнгән чынбарлыкка автор мөнәсәбәтен белдерүнең эмоциональ төсмерләре ягыннан да күп төрле: «Рәүфә» повестендагы кебек, без лирик-драматик сөйләү алымы белән дә очрашабыз, «Туйда» повестендагы, «Кыз урлау», «Юлда» хикәяләрендәге кебек, җылы юмор белән өртелгән хикәяләү алымы да күзгә ташлана. Яшьләр һәм бер яшьләр генә түгел, башка укучылар да ул әсәрләрне зур кызыксыну белән укырлар дип ышанам. Чөнки алар безнең үткәнебез, хорафатка ышану, караңгылык, хәерчелек күренешләре тулып яткан иске тормыш турында хәбәр бирәләр. Җыентыктагы «Ана» һәм «Госпитальдә» хикәяләре бу җәһәттән бераз аерылып тора. Ана темасы, тормышның үзе кебек үк, мәңгелек тема. «Днепр буенда» исемле хикәядә хатын-кыз азатлыгы күтәрелә, бу яңа тема түгел, әмма актуаль тема.

А. Шамов иҗатының тагын бер кызыклы сыйфатын билгеләп үтәсе килә. Аның рецензияләнә торган җыентыктагы хикәя һәм повестьларын укыганда аларда тормыштагы үзенә яхшы таныш кешеләр, вакыйгалар турында ашыкмый гына, тәфсилләп сөйләүче авторның иркен сулышын тоясың. Әдипнең язу алымы әйбәт традицияләрдән, төрки әдәбиятларындагы прозаның милли үзенчәлегеннән килә — мөһим нәрсәләр хакында ашыкмый, кабаланмый сөйләргә кирәк. Әмма шактый салмак, детальләргә мул бу алым әсәрне кабул итәргә комачауламый гына түгел, киресенчә, әсәрдә сурәтләнгән кешеләрнең рухи дөньясын яхшырак аңларга булыша. Һәртөрле мактауга һәм хуплауга лаек әлеге алымны, кызганычка каршы, татар язучыларының хәзерге буыны онытып бара. Салмак хикәяләү алымы турында сөйләгәндә без һич тә буш фәлсәфәдән торган озын-озын бүлекләрне түгел, ә тормышны сәнгатьчә сурәтләү алымын күздә тотабыз. Татар әдәбиятында һәм башка төрки әдәбиятларда хикәяләүнең салмак алымы күпчелек очракта язмада, бигрәк тә диалогларда «диде» сүзе белән белдерелә. Беренче карашка, күп тапкырлар кабатлана торгач, салмак, эпик «диде» сүзе сүлпәнлеккә, бертөрлелеккә алып килә төсле. Әмма татар телендә «диде» формасы органик төстә сәнгатьчә сурәтләү чаралары составына керә.

Фикерне түгәрәкләп шуны әйтәсе килә: А. Шамовның повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы кызыклы, мәгънәле булып чыккан. Китаптагы барлык әсәрләрнең эчтәлеген сөйләп чыгуның хаҗәте юк, безнең фикерләрнең дөреслегенә ышану өчен, җыентыкның үзе белән танышырга кирәк.

**ГАЛИЯ ХАНТЕМИРОВА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

## Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә апа балаларына язган шигъри васыять-хат

Бик нык авырдым, балам,
Үлсәм куралмый калам.
Зарланып бер хат язам, —
Уйлап карагыз, балам.

Бик сагындым сезләрне,
Бигрәк тә кызларны.
Иртә торсам да кө̂тәм,
Кичен ятсам да көтәм,
Сезнең өчен ут йотам, —
Уйлап карагыз, балам.

Ана күңеле — балада,
Бала күңеле — далада,
Шул сүз әле чамада,—
Уйлап карагыз, балам!

Төштә күреп уянам,
Шуны сөйләп куанам,
Кайтырлар дип юанам,—
Уйлап карагыз, балам.

Чит җирләрдә үзегез,
Хатта килә сүзегез.
Үзәгемне өздегез,—
Уйлап карагыз, балам.

Көн дә иртә торамын,
Хатыгызны көтәмен,
Юксынып аһ итәмен,—
Уйлап карагыз, балам.

Казаннарда да булдым,
Оренбурда да тордым,
Ахыр аерылып калдым,—
Уйлап карагыз, балам.

Кече кызым Хәдичә,
Йөзләреннән нур чәчә.
Никадәр үкенсәм дә,
Үлмәм микән күрмичә?

Ибраһим балакаем,
Тыңлагыз әйткәнемне.
Мине искә алганда
Онытма әткәеңне.

Зәйнәп белән Хәдичә,
Сезгә кайгы көннәре.
Сезнең өчен януым
Көйдерәчәк гөлләрне.

Муса улым, сиңайтәм,
Туганнарыңны кара.
Үләр вакытым җитте, —
Кылып булмый бер чара.

Ни тилмереп көтсәм дә,
Киләлмисез каршыма.
Нинди бәхетсезлек бу
Минем моңлы башыма?

Ибраһим, Муса, Хәдичә,
Зәйнәп, хуш-сау булыгыз...
Исән чакта дөньяда
Бергә матур торыгыз [1].

---

[1] Башкортстан АССРның Стәрлебаш районы Кызыл Яр авылында Әминә Хәбибуллинадан (1923 елда туган) язып алынды. Ул бу әсәрне Оренбург якларыннан ишетеп-язып алып кайттым дип сөйли.

Искәрмә: Муса Җәлилнең әнисе Рәхимә апа 20 нче елларда балаларына язган шигъри хат бу. Безнең кулда янә дә Башкортстанның Миякә, Әлшәй районнарында Башкорт дәүләт университеты студентлары 1974 һәм 1975 елларда язып алган өлеге шигъри васыятьләр саклана. Мин үзем дә 1962 елда Оренбург өлкәсе Орск шәһәрендә Мусаны һәм аның әнисен якыннан белгән кешеләрдән шушы ук хатны язып алган идем.

Биредә васыять-хат, фикер кабатлаудан котылу өчен, кыскартып бирелә.

**РИФ МӨХӘММӘТҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты,**
**Уфа университетының өлкән укытучысы.**

# РӨСТӘМ БАШКУРОВ

**(1927—1967)**

16 майда Рөстәм Башкуровның тууына 50 ел тулды.

Рөстәм Шакир улы Башкуров әдәбият мәйданына илленче елларның башында килә һәм тиз арада үзен үткен каләмле тәнкыйтьче, сәләтле әдәбият галиме итеп танытып өлгерә. Әдәбият галиме буларак, ул сөекле шагыйребез Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүгә аеруча күп көч куя. Аның 1958 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Тукай һәм рус әдәбияты» исемле монографиясен әдәби җәмәгатьчелек тә, киң катлау укучылар массасы да җылы каршылый. Моннан тыш Р. Башкуров 1960 елда Казанда, 1965 елда Мәскәүдә рус телендә чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы»н язуда якыннан катнаша.

Берничә ел элек Мәскәүнең «Наука» нәшриятында «Күп милләтле совет әдәбияты тарихы» («История многонациональной советской литературы») дигән коллектив хезмәтнең соңгы томнары чыгып бетте. Билгеле булганча, алты томлык бу зур хезмәтнең һәр томында безнең татар әдәбиятына да киң урын бирелгән. Томнардагы «Утызынчы елларда татар совет поэзиясе», «Ватан сугышы чорында татар поэзиясе» дигән бүлекләрне Рөстәм Башкуров язган.

Республика газета-журналларының 50—60 нчы елларда чыккан саннарында Р. Башкуров каләме белән язылган тәнкыйть мәкаләләре, әдәби рецензияләр күп очрый. Аларда ул язучылар коллективы алдында торган актуаль мәсьәләләрне кузгата, теге яки бу язучы иҗатына караган кызыклы фикерләре белән уртаклаша. Тәнкыйтьченең Ш. Маннур, Ш. Мөдәррис, З. Мансур, М. Крымов кебек шагыйрьләр иҗаты турындагы мәкаләләре бүген дә зур кызыксыну белән укыла.

Тирән белемле, югары әдәби зәвыклы каләмдәш дустыбыз башлаган хезмәтләрен тәмамларга, уйлаган эшләрен эшләргә өлгерә алмый калды. Шәфкатьсез үлем кырык яше дә тулып җитмәгән килеш аны безнең арадан алып китте.

# ОСТАЗЛАРНЫҢ ӨЙРӘНЧЕГЕ БУЛА

Халыкка аң-белем бирүдә, әдәбият һәм сәнгатьне үстерү эшендә тел белгечләренең дә роле ифрат зур. Грамматик төзелеше яхшылап өйрәнелгән, әдәби яктан ныклы эшкәртелгән милли телләрдә генә югары художестволы әсәрләр, фәнни хезмәтләр туарга мөмкин.

Татар теленең беренче грамматика китабы дөньяга килүгә тиздән 200 ел тула. Бу чор эчендә телебезне өйрәнүдә, эшкәртүдә, аның грамматика, лексикология, стилистика, диалектология һәм башка тармакларын фән буларак үстерүдә дистәләрчә күренекле белгечләр эшләделәр.



Революциядән соң татар телен өйрәнүдә, аның орфографиясен юлга салуда, әдәби телне үстерүдә, шуның белән бергә халкыбыз арасында культура революциясен тормышка ашыруда тел белгечләре ифрат зур эшләр башкарды. Татар тел белеменең үзенең мәктәбе барлыкка килде. Хәзер аның бай тәҗрибәсе, буыннан-буынга күчеп килгән уңай традициясе бар.

Бүген татар тел белеме өлкәсендә илледән артык фән кандидаты, дистәгә якын фән докторы эшли. Алар тюркологиядә һәм гомум тел белемендә мөһим проблемаларны хәл итүдә катнашалар.

Шуларның арасында — филология фәннәре докторы, профессор Габделхәй Әхәтов та бар.

Әхәтов — сугыштан соңгы елларда күренекле филологлар М. А. Фазлуллин, Л. Җәләй, Ш. Рамазанов, Р. Хәкимова, В. Хангилдин, М. Гайнуллин кебек белгечләр җитәкчелегендә укыган һәм эшләгән, соңрак инде фәнни эстафетаны алар кулыннан кабул иткән кеше.

Актаныш районының Пучы урта мәктәбен тәмамлап, комсомолда җитәкче эшләрдә үзен сынаганнан соң, ул Казан педагогия институтына укырга керә. Студент елларында ук фәнне, җәмәгать эшен яратканлыгын танытып өлгерә.

Институтны уңышлы тәмамлаган тырыш егетне шунда ук аспирантурага калдыралар һәм ул, аспирантура срогы тулганчы кандидатлык диссертациясен яклап, фәнни дәрәҗә алуга ирешә. «Татар телендә фразеологик әйтелмәләр» дигән бу хезмәт җанлы сөйләмдә һәм матур әдәбиятта образлылык тудыру чараларының кызыклы бер төренә багышланган.

Остазларының гыйльми традицияләрен эстафета төсендә дәвам итеп, яшь белгеч үзе дә яңа кадрлар хәзерләргә, югары уку йортларында эшләргә керешә. Мәгълүм ки, татар теле, әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендә эшләү өчен кадрлар күптән инде башка өлкәләрдә дә хәзерләнелә. Әхәтов, вуз тәмамлаган бер төркем алдынгы яшьләр белән, Себердәге Тобол педагогия институтына килә, институт каршында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оештыра, аның мөдире булып эшли. Өлкә күләмендә чыга торган татар телендәге газета эшендә, татар драма түгәрәге чыгышларында актив катнаша, булачак докторлык хезмәтенә материаллар туплау өстендә эшли.

Аның эшчәнлегенә күренекле тюрколог Җ. Г. Киекбаев игътибар итә һәм Әхәтовны 1958 елда Башкорт дәүләт университетына эшкә чакыра. Монда ул докторлык диссертациясе яклый, профессор дәрәҗәсенә күтәрелә һәм менә 13 ел инде татар теле һәм әдәбияты кафедрасының мөдире булып эшли.

Яхшы остазның өйрәнчекләре була, шул вакытта гына ул ил һәм халык ихтирамын казана. Әхәтов әле яшь белгеч вакытында ук фән өчен яңа кадрларны актив әзерләшә. Бүген аның җитәкчелегендә ике дистәдән артык яшь белгеч фән кандидатлары булдылар, берничә кеше докторлык эшләрен язды.

Профессор Әхәтовның Мәскәүдә, Казанда, Уфада, Алма-Атада, Тоболда, Свердловскида һ. б. шәһәрләрдә йөздән артык фәнни хезмәтләре басылып чыкты. Алар татар лексикологиясе, фразеологиясе, диалектологиясе һәм стилистикасына багышланган. «Хәзерге татар теле лексикасы», «Диалект шартларында тел укыту мәсьәләләре», «Көнбатыш Себер татарлары диалекты», «Татар фразеологиясенең кайбер мәсьәләләре» кебек хезмәтләре тюркологиядә һәм совет лингвистикасында да югары бәя алды.

Галим һәм педагогның остазлары һәм шәкертләре аңардан яңа хезмәтләр көтәләр.

**ХӘЛӘФ ГАРДАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# УЛ БҮГЕН ДӘ, КИЛӘЧӘКТӘ ДӘ БАР

Татар совет балаларының иң сөекле шагыйрьләреннән берсе, үзенең тылсымлы шигырьләре белән балалар поэзиясендә аерылып торган гаять үзенчәлекле һәм талантлы шагыйрь Бари Рәхмәтнең тууына 80 ел тулды.

Ул 1897 елның 29 маенда элекке Урал губернасы Гурьев өязе Жилая Коса поселогында хезмәткәр гаиләсендә туа. Башлангыч белемне шул поселоктагы мәдрәсәдә ала. Кечкенәдән Тукай шигырьләрен яратып укый. 1914 елда Казанда чыга торган «Ак юл» исемле балалар журналында аның «Бәйрәм котлы булсын» дигән беренче шигыре басылып чыга. Шуннан башлап газета-журналларда күп кенә шигырьләр белән катнаша. 1918 елда Кызыл Армия сафларына алына. 1920—1921 елларда Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гали белән бергә «Кызыл Армия» газетасы редакциясендә әдәби сотрудник булып эшли.

Аның бу башлангыч чор иҗатына караган шигырьләре революцион көрәш пафосы белән сугарылганнар:

**Шатланмам, сөенмәм**
**Мин чын таң атмыйча,**
**Дошманны юк итеп**
**Азатлык тапмыйча.**

**(«Ямь тапмыйм». 1918.)**

Шагыйрь революция тудырган күренешләрне самимилегендә, гадилегендә кабул итә, ихлас күңелдән бирелеп җырлый.

Әнә шундый «туры сызыклы», күбрәк тезеп-сөйләп чыгуга корылган шигырьләре белән беррәттән, Б. Рәхмәтнең Тукай шигырьләренә тартым, гаять халыкчан янгырашлы үткен сатирик әсәрләре дә күренеп китә:

**Юк идек, безне бар кылды,**
**Тән яратты, җан бирде.**
**Балчык белән әвәләп**
**Адәм ясап куйдыя.**
**Түшәк бирде җәяргә,**
**Юрган бирде ябынырга,**
**Ахыры заман җиткәнче**
**Йокларсыз дип тидия.**

**(«Күрең кадир кодрәтен». 1920.)**

Аның «Татар бае Колчакны көткәндә» (1919) шигыре дә әнә шундый рухлы.

1932 елда Б. Рәхмәт Казанга күчеп килә һәм төзү трестында бухгалтер булып эшли. Озак еллар язмый торганнан соң 1939 елда кабат «Чаян», «Совет әдәбияты» журналларында үзенең яңа лирик һәм сатирик шигырьләрен бастыра башлый.

1942 елда фронтка китә. Хәрәкәттәге армия сафларында Украина, Молдавия, Болгария, Венгриядә барган сугышларда катнаша. 1945 елның февралендә яралана. Госпитальдән соң 3 нче Украина фронты газетасы «Совет сугышчысы»нда эшли.

Шагыйрьнең сугыш чоры лирикасы яңа сыйфатлар белән байый: сөйләп тасвирлау урынына ул картиналы итеп язарга керешә, шигырьгә юмористик рух үтеп керә:

> — Сугыш бетәр анысы, үзең бетмә.
> — Исән булсак, бәлки бетмәбез.
> Ялтырашып иске бер тиендәй,
> Бер кайтырбыз туган йортка без.
>
> («Исән булсак, бетмәбез». 1943.)

Никадәр җитди тема һәм әлеге юлларга күпме җан җылысы өртелгән. Шуңа күрә шигырь гади шаяру булып кына калмый. Ул хисләрне тирәнгәрәк алып төшә, аның төбендә зур югалтулар авырлыгы ятуын сизгәндәй буласың.

Шагыйрьнең бу чор шигырьләренә тукталып, З. Мәҗитов түбәндәгеләрне язды: «Аның сугыш елларында иҗат ителгән кайсы гына әсәрен алып карасак та, нәкъ шушы сыйфатны — халык иҗатына аваздаш яңгыраган лиризмга юмористик бизәкләр кушып сурәтләүне күрербез:

> Фронтларда байтак
> Нужа күрдем, Майтап, картайдым,
> Хәзер сине күрү,
> Суырып-суырып үбү бар кайгым.
> Җитен чәчләр белән,
> Көмеш кашлар белән кайтам мин.
> Әйтмәссең бит кайткач,
> «Кайттыңмыни, картлач шайтан», дип.
>
> («Без кайтырга чыктык». 1945.)

Буш юллар түгел... драматик кичереш дәрәҗәсенә якынлашкан лиризм» [1]. Әмма, күренгәнчә, юмор Б. Рәхмәт өчен бизәк кенә түгел, ул аның эчке үз табигате, дөньяны сиземләве һәм фикерләү үзенчәлеге, җырчыларның трагик кичерешләрне көлеп җырлаганы шикелле, монда да юмор әсәрнең җитдилеген бетерми генә түгел, киресенчә, сугышның тетрәндерерлек бер картинасын бөтен каршылыгы белән ачып сала.

> Рәхәтләнеп, көпшәләрен сузып,
> Ял иттеләр герой пушкалар,
> «Катюша»ларга да бүгеннән соң
> Шау-шу куптармаска куштылар.
>
> («Сугыш беткәч». 1945.)

Бер караганда җиңелчә тонда язылган ярым шаяру төсмере алган гади юллар. Ә бит «пушкаларның рәхәтләнеп ял итүләрен» үз тәнең белән тойгандай буласың... «Шау-шу куптармау»ның фәлсәфи мәгънәсен аңлап... тирәнлегенә гаҗәпләнәсең...

> Киткән чакта еладың «китәсең» дип,
> Инде «ник кайттың» дип елыймсың!
> Нигә елыйсың!
>
> («Сугыш беткәч». 1945.)

Монысы да гади шаяру түгел. Әлегә һәр ике елауның аерымлыгын һәм уртаклыгын лирик герой үзе дә бик яхшы белә. Әмма бит ул җиңеп кайткан кеше. Үзендә шаярырлык көч тә табарга тиеш...

Сугыштан соң Б. Рәхмәт олылар өчен матур-матур юмористик һәм сатирик әсәрләр язды. Аның «Бармагыңа акча түлим» (1946), «Әби белән бабушка» (1949),

[1] «Казан утлары», 1975 ел, 4 сан.

«Тәмәкене ничек ташларга» (1955), «Бабай белән дедушка» (1956), «Чынлап үпмәдем» (1956), «Мактады да сукте» (1956) һ. б. шигырьләре татар укучысының яраткан әсәрләренә әверелде.

Революция, гражданнар сугышы утларын, Бөек Ватан сугышы утларын кичеп чыныккан, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган өлкән шагыйрь тыныч төзелеш елларында үзенең бөтен шигъри дәртен, көчен яшь буынны — балаларны тәрбияләүгә бирә.

1949 елда Б. Рәхмәтнең балалар өчен язылган «Кем көчле», «Укыйсым килә» исемле беренче китаплары басылып чыга. Шуннан соң аның иҗаты активлашып китә. Кыска гына вакыт эчендә ул «Зәңгәр күл» (1950), «Нәниләр китабы» (1953), «Сабан туенда» (1953), «Бакчада күңелле» (1954), «Безнең җәй» (1955), «Ялкау, иренчәк һәм кире» (1956), «Кыш бабай ёлкада» (1956) исемле китапларын язды. Тиз арада балаларның сөекле шагыйре булып танылды. Китаплары республика буенча уздырылган балалар әдәбияты конкурсларында югары бәя алды.

«Балалар язучысы булып туарга кирәк», дигән В. Г. Белинский. Б. Рәхмәт моны бөтен иҗаты белән исбат иткән зур талант,— дип язды балалар язучысы Җ. Тәрҗеманов.— Аның әле революциягә кадәр язылган беренче шигырьләрендә үк менә мондый сабыйларча ачышлар бар иде.

**Эш күп икәнлеген белгән кук,**
**Җәй көне таң ата төннән үк.**

**[«Кадерле вакыт», 1916.]»**

Кайда монда «сабыйларча ачыш»?

Балалар фикерләвенең үзенчәлекле характерын исәпкә алмый торып, күрәсең, әлеге сорауга җавап табу мөмкин түгелдер. Чөнки балаларның үз үлчәме, үз логикасы, «үз аршины» бар. Шуңа да аларның фикерләве безгә я артык беркатлы, мәгънәсез сыман тоела, я ул көлке тудыра, я философларча хикмәтле булып күренә. Ләкин аларның иң мәгънәсез дигәннәренең дә төбендә дөньяны аңларга тырышу, табигать, тормыш күренешләре арасында уртаклык, бәйләнеш табарга омтылу ята. Балалар аңында әйберләрнең теләсә нинди очраклы билгесе буенча да ныклы ассоциацияләр туарга мөмкин. Аларның кайберләре янәшәлек юлы белән, кайберләре охшашлыкка һәм аерымлыкка нигезләнеп барлыкка килә. Кайвакыт әлеге бәйләнешләр бик үк дөрес тә булып чыкмыйлар. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре дә буталып киткәли. Тик зарар юк. Иң әһәмиятлесе — бала үзе уйлый, «ни өчен?» дигән сорауга җавапны үзе эзли. Хаталар тормыш практикасында акрынлап бетәр, ә баланың фикерләү алымы, аның аерым фактлардан ниндидер уртаклык табып алуы, нәтиҗә-сәбәплелек ассоциацияләре нигезендә тормыш күренешләренең үзара мөнәсәбәт-бәйләнешен ачыкларга тырышуы гомер буена калачак.

Менә шушы күзлектән чыгып карaганда, Б. Рәхмәтнең «Кадерле вакыт» шигырендәге «сабыйларча ачышын» күрү, таңның иртә атуын эш күплеккә бәйләп аңлатуның ни дәрәҗәдә реаль булуы һәм шигърилеге үзеннән-үзе аңлашыла.

Шагыйрьнең 1937 елда язылган «Яз килә» шигырендә дә нәкъ балаларча шигъри итеп уйлый белүне күрәбез:

**Яз килә! Яз килә! Матур яз килә.**
**Түбәләрдән тама тамчылар,**
**Каталарын сөйрәп ләштер-лештер,**
**Китеп бара мескен кыш елап.**

Җитди генә, азрак лирик планда башланып киткән беренче юллардан соң шигырьгә әнә шулай, «каталарын ләштер-ләштер сөйрәп», көтелмәгән һәм төп фикер үсешеннән читтәрәк торган, әһәмиятсезрәк булып тоелган, әмма детальләре аермачык күзгә бәрелеп торган җанлы картина тудырган тасвир элементы килеп керә. Фикер һәм хис логикасы шунда ук үзгәрә, күңел башка тонга көйләнә.

Б. Рәхмәтнең сугыш чорында язылган «Сәлам хат» (1943) шигыренә дә балалар битараф кала алмыйлар.

**Безнең хәлне сорап баксагыз,**
**Бик исән-сау гына ятабыз.**
**Кулда мылтык, билдә граната,**
**«Фашист» дигән кошлар атабыз.**

Көрәсең, биредә кечкенәләр күзалларлык динамик картина тудырылган.

Б. Рәхмәтнең күп кенә шигырьләре эшкә өндәү, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләүгә багышланган. Ләкин ул бервакытта да коры дидактик формада язмый. Һәр очрак өчен яңача чишелеш, яңача яңгыраш табарга тырыша. Әйтик, «Сара — уңган кыз» шигырендә ул бу максатка хезмәт матурлыгын күрсәтеп бирү ярдәмендә ирешсә, «Сара — врач» шигырендә хезмәт темасы олылар үрнәгендә профессия сайлап уйнау рәвешендә яктыртыла. Өченче бер шигырьдә хезмәт кешене салкыннан саклый («Кыш һәм кеше»). Дүртенче очракта хезмәткә мәхәббәт бөтенләй көтелмәгән яктан... ялкаулык аша... аны фаш итү ярдәмендә тудырыла. («Шундый ялкау ул».)

Шагыйрь туган ил, туган җир табигате турында яратып яза. Ул гына да түгел, тарихи үткәннәргә кайтып, иҗтимагый гомумиләштерүләр ясый. Социаль вакыйгалар турында балага беренче төшенчәләрне бирүгә ирешә:

**Патша булган заманда**
**Торсалар да Казанда,**
**Белмәгән дә балалар**
**Зәңгәр күл барын анда.**

**(«Зәңгәр күл».)**

Б. Рәхмәтнең ел фасыллары, төрле кош-корт, җәнлекләр тормышыннан алып язган шигырьләре аеруча җанлы, аеруча җылы тәэсир тудыра:

**Киң безнең күңелебез,**
**Бик иркен илебез.**
**Унарлап,**
**Йөзәрләп,**
**Меңәрләп килегез!**

**(«Сыерчыктан телеграмма».)**

Инде шагыйрь иҗатындагы юмор үзенчәлекләрен карап үтик. Аның тулаем юморга корылган шигырьләре күп түгел. Менә шуларның кайберләре.

**Вакыт белән Якуп**
**Ярыша бервакыт.**
**Вакыт алга чаба,**
**Якуп артка чаба.**
**Үзе алда бара...**
**Арттан караганда.**

**(«Якуп белән вакыт».)**

Бу — балаларның «үз» юморы, үз күзаллавы. Әлеге шигырьдә без сатирик элементларны да очратабыз:

**Сәгать мескен туктый.**
**— Туктасам да ярый,**
**Минем дәресем юк,— ди.**

«Әхмәтнең укыйсы килә», «Яңа ел килгәч» дигән шигырьләр дә шулай елмаеп язылган.

**Ә мин былтыр яткан идем,**
**Быел тордым йокыдан.**

**(«Яңа ел килгәч».)**

Гомумән алганда, Б. Рәхмәтнең юморы көлкеле вакыйгалар, мәзәк хәлләр, сәер гадәтләргә корылган «кычкырып торган» юмор түгел. Аның юморы мөлаем — эчтән,

тирәннән килә, ул яктылык, нур, җылылык итеп әретелгән. Күрәсең, шагыйрьнең самимилегеннән, аның дөньяга сабыйларча сөенеп каравыннан туадыр. Ни турында гына язмасын, аңа шагыйрь күңеленең җан җылысы иңә. Аның күле дә «бит урта-сын уеп көлеп, елмаеп куйган кебек», кояшы да, «су өстен ялт иттереп», матур итеп күзен кысып, «күлдә су эчеп ята» («Зәңгәр күл»). Әйе, ул дөньяга балаларча, якты күз белән карый. Балалар шагыйре Ш. Галиев, Б. Рәхмәт күңеленең әлеге иң матур, иң характерлы үзенчәлеген тотып алып, аның «Сөенеч» (1972) исемле китабына язган сүз башында болай ди:

«Үзем очраткан кешеләрне ике төрлегә бүлеп карар идем мин: кояшлы кешеләргә һәм болытлы кешеләргә. Кояшлы кешеләрнең күзләреннән елмаю яктысы сибелә, күзләрендәге чаткыны тергезеп, нурлар үрләтеп яшиләр алар. Андыйлар турында «сабыйлар акылы чыкмаган» дип тә әйткәлиләр. Әйе, аларның бала чак бәйрәмнәре һәрчак үзләре белән. Тормышка ихлас сокланып һәм гаҗәпләнеп карый беләләр алар. Юлларында очраган салкын бозларны шаян сүз, мөлаем елмаю белән эретәләр. Бөтен дөньяның гел яктыра барасын, кояшлы киләчәктә тапкыр сүзле, киң күңелле кешеләр яшәячәген беләләр алар. Бари Рәхмәт әнә шундый Кояшлы Кеше иде».

Аның шигырьләре дә, «кояш куяннары» кебек, күңелгә уйнаклап үтәләр. Шагыйрь нинди генә темага язмасын — бала өчен ул яңалык, бала танып-белү шатлыгын кабат-кабат кичерә:

**— Шуны белмәскә!**
**Беләм ич,— дидем.**
**Чыгарасың ич**
**Безгә мич,— дидем.**

Б. Рәхмәтнең әйләнә-тирәдәге әйберләрне, табигатьне җанландырып, кешеләштереп, телгә китереп күрсәтүе, шуның белән аларны кеше күңеленә тагын да якынайтуы шулай ук әйтелгәннәр уңае белән зур шатлык, әчкерсезлек, үз итү, дус булу, ярату хисе уята. Бала рухи рәхәтлек ала, эмоциональ дулкынлану, эстетик ләззәт кичерә.

**— Сыерчыгым, нигә китәсең!**
**Сагынырмын сине киткәчтен.**

**— Көз җитте бит инде, мин туңам,**
**Килгән идем җәйге костюмнан.**

**(«Кошлар киткәндә».)**

Әлеге күренеш-алым белән без халык иҗаты һәм Тукай шигырьләрендә дә («Карлыгач», «Бала белән күбәләк», «Ялкау маэмай» һ. б.) очрашабыз. Б. Рәхмәт бу матур традицияне дәвам иттерә.

Балалар психологиясе үзенчәлекләрен исәпкә алып, Б. Рәхмәт үзенең әсәрләрен еш кына «уен» итеп тә оештыра. Уен аша балага үз фикерен уздыруы, эмоциональ тәэсир итүе, эстетик һәм мораль тәрбия бирә алуы, аларда җанлылык уятуы — шулай ук шагыйрьнең зур уңышы итеп саналырга тиеш. «Кадерле тәс» музыкаль уены, «Кыш бабай елкада» инсценировкалары әнә шундый көчкә ия.

Б. Рәхмәт берсеннән-берсе матуррак әнә шундый шигырьләр язып калдырды. Ул нәкъ балаларча дәртләнеп иҗат иткәндә, шигъри осталыгы тәмам ачылып җиткәндә, 1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы барган көннәрдә сәхнәгә чыгып, ил халкы алдында гаять зур уңыш белән үзенең шигырьләрен сөйләгән чакта — поэзиябезнең тугрылыклы солдаты булып постта торганда арабыздан мәңгегә китте.

Аның биографиясе зур, язган шигырьләре күп, эшен кыю тесте дәвам итүчеләре бар, әмма ул мәңге картаюны белмәс мөлаем йөзле сабый бала; аның бүгенгесе һәм киләчәге генә бар. Бу бүген дә, киләчәктә дә шулай.

**РАВИЛ КУКУШКИН.**

# СЕКТАН[1] БЕЛӘН ЙОЛДЫЗЛАР ҮЛЧӘРГӘ...

Моннан бернична ел элек Аккош күлендә өлкән язучылар белән сөйләшеп утырганда башка бер уй килде: «Менә бу өлкәннәрнең иҗат портретларын язып калдырырга иде. Берсеннән-берсе кызыклы, берсеннән-берсе үзенчәлекле, кабатланмас характерлы шәхесләр: Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Сибгат Хәким һәм башкалар, һәм башкалар».

Шул чак әсәрләрен үзем яратып укып килгән тагын бер автор турында уйлап куйдым: «Дөньяның кайсыдыр бер почмагында Миргазиян Юныс дигән үзенчәлекле тагын бер язучы бар бит әле. Җитмәсә, ифрат кызык биографияле язучы. Язганы — әллә ниткән мәрҗән атаулары, Өмет борыннары, энҗе эзләүчеләр, пассат җилләре турында... Дөнья күреп, ил гизеп йөргән диңгезче — үзе татар язучысы!»

Аның белән күптән танышасы килеп йөри иде. Минем өлкән диңгезчеләрне байтак күргәнем бар: аларны, кая гына бармасыннар, ихтирам белән «диңгез бүресе», «бабай», «карт» кебек исемнәр белән атап йөртәләр. Өлкән диңгезчеләр, үз дәрәҗәләрен үзләре белеп, вәкарь саклап кына йөриләр, алар адмирал Нахимовка охшатып кирәк кадәр сакал үстерәләр, «Алтын руно» яки «Капитанский» дигән хуш исле тәмәке тарталар, алар вакланмыйлар, дөньяның ыгы-зыгысына өстән, елмаеп кына карый беләләр... Ихтирамга бик лаек, батыр һәм киң күңелле кешеләр алар.

Менә шулай, үзен күрмәгән көе генә мин Миргазиян Юнысның портретын күңелдән яза да башладым. Әмма үзен күрергә һич җай чыкмады.

1972 елның җәе иде, язучыларның Коктебельдәге иҗат йортына минем исемгә калын гына бер хат килеп төште. Карыйм — Миргазиян Юнысовтан дип куелган. Шул елны «Казан утлары»нда минем «Фронтовиклар» дигән әсәрем чыккан иде. Җиде битлек хатта әлеге диңгезче шул әсәрем турында фикер йөртә, минем белән бәхәсләшә, кайбер урыннарын мактый, яманлый, шатлана һәм дулый иде.

Хатлар аша безнең арада юл салынды. Коктебельгә адресланган соңгы хатында ул болай дип язган иде:

— Казанга кайтышлый телеграмма сук, Курск вокзалында үзем каршы алырмын, танышырбыз, Казан вокзалына озатып куярмын.

Телеграмма суктым... 1972 ел җәенең коры, сөремле көннәреннән берсе, Мәскәү тирәсендә торфлар яна, вокзалда күз ачыта, саргылт кояш вокзал шпиленә элә геп икегә аерылган. Вагоннан бөтен кеше чыгып бетте, кочаклашу, чемодан күтәрер алдыннан «чуп» итеп үбешүләр башланды, әмма мин көткән диңгезче күренмәде. «Алтын руно» тәмәкесенең хуш исе урынына перронда көек исе. Шатура торфы исе иде.

Минем кәеф китте, шунда кыска җиңле күлмәк, бишенчеме-алтынчымы рост чалбар кигән әзмәвер кадәр бер егеттән сорый куйдым:

— Казан вокзалына багаж илтә торган йөк таксие кай тирәдә икән?

— Ә сез Казаннанмыни? — диде егет әтәләнеп йөргән хуттан озын кулларын, озын аякларын җыеп бетерә алмыйча.

Сорауга сорау белән җавап бирүчеләрне җенем сөйми, мондый чакта минем тыным кысыла, өрлек буе бу егеткә, башны шактый күтәреп, ачу катыш түбәннән

---

[1] Секстан — йолдызлар белән диңгез өсте яссылыгы арасындагы почмакны үлчәү өчен кулланыла торган инструмент.

карадым. Әмма егет ачуланышырга җыенмый иде, һәм ул, елмаеп, саф татарчага күчте:

— Ялгышмасам, мин сезне каршы алам бугай, тик мин телеграмманы өйдә калдырганмын, вагон номерын хәтерләмим. Мин — Юнысов,— дип метрлы кулын сузды.

Тормышта алданулар, ялгышулар шактый булганы бар, әмма мондый ук хәлгә калганны бер дә хәтерләмим. Машинада барганда күп нәрсә ачыкланды: ул инде әллә ничә еллардан бирле Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев, Хәсән Туфан, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллиннар белән таныш һәм алар белән күрешкәләп яши икән. Мин дә инде, ачуым килмәгәе, бер хыялый...

Казан вокзалы урынына ул мине үзенең өенә алып китте. Мин әле перрондагы уңайсыз хәлдән айнып бетә алмаган идем. Күрмәгән кешенең хыялдагы портреты белән чынбарлыктагы кыяфәте арасындагы аерманың моңарчы беркайчан да мине болай ук кыен хәлгә куйганы юк иде. Ләкин бу әле ялгышуларның баласы гына булган, анасы аның мичтә калган икән...

Сигезенче Соколиная урамында таксист белән Миргазиян арасында кызу әңгәмә башланды:

— Юк, монысы түгел,— ди таксист. Алга таба хут бирә, газга баса.

— Уздык, уздык,— дип әтәләнә Миргазиян.— Артка чигер. Я булмаса, борыл. Ә-әнә тегеннән.

— Юк, узмадык,— ди таксист.— Син бит миңа җиденче йорт, дидең. Әнә җиденче — алда...

Әмма, бәхәсләшә торгач, шофер да шикләнә калды. Көпә-көндез машина белән ишегалларында әнә шулай килеп сугып йөрдек.

— Йортыгыз бик кечкенәме әллә? — дип сүзгә мин дә кушылдым.

— Юк, өч йөз квартиралы. Тугыз катлы.

— Кичә генә күчендегезмени?

— Юк, инде дүрт ел яшибез.

Шофер да, мин дә шуннан ары дәшмәдек.

Миргазиян Юнысның биографиясе минем өчен әнә шуннан — аның үз йортын үзе эзләвеннән башланды.

— Һи-и, исегез киткән икән,— диде Миргазиянның хатыны Рәисә ханым, мең бәла белән йортны табып квартираларына килеп кергәч.— Көн саен шулай ул. Исегез киткән икән. Аның хезмәт хакын да юньләп алып кайтып бирә алганы юк...

Шунда мин икенче һәм иң зур хатамны эшләдем:

— Нәрсә, теге якка йомшакмыни? — дип ияк астына чиртеп халыкара бер билге күрсәттем.

— Ю-у-уж,— дип көлде хатыны рәхәтләнеп.— Авызына да алмый. Бөтенләйгә. Тик аның бер гадәте бар: хезмәт хакы алган көнне язу машинкалары сата торган кибеткә керә.

— Шуннан?

— Шуннан шул: ай саен бер машинка ала. Я «Националь», я «Репортер», я «Эрика»...

— Алай икән... Кая җыясыз соң аны?

— Җыймыйбыз. Ике-өчкә тулгач, әлегрәк алганын комиссионныйга илтеп бирә тора.

Һәм мин, ниһаять, моннан соң алар өенә эз бастырмаслык итеп, өченче ялгышымны ясадым.

— Файда беләндер инде, күрәсең...

Ну, бу мокытлыкны!

— Ие, файда белән,— дип көлде хатыны.— Йөз сиксәнгә ала, йөзгә сата. Беркөнне шул магазинда кассирның сдачасы булмаган, акча тапшырган икән, хезмәт хакының илле сумын калдырып чыгып киткән. Аннан оныткан. Бер атнадан бардым, ул кассир, ял алып, китеп барган...

Таныштык, белештек, сүзләр күп булды. Вәгъдә буенча ул мине Казан вокзалына озатып куйды. Юлда үзенең иҗат планнарын, «Тозлы җил» исемендә трилогия язарга җыенуын, исән булса, Хәсән Туфан турында иҗади портрет тудырачагын әйтте, алдагы җәйдә рюкзак асып Татарстан буйлап — Тукай, Мәрҗани, Курсави,

Галиәсгар Камал әзләре буенча җәяүләп узарга уйлаганын, тагын әллә нинәр, әллә нинәр сөйләде.

— Шуларны эшләгәч, тагын диңгезгә китәм, хәзер бик нык сәламәтлегемне ныгытам. Измаил паркында көн саен иртән ун-унбиш чакрым йөгерәм, йоглар системасы «Хатха-йога»ны өйрәнәм,— диде.

Шуннан соңгы очрашуларда мин Миргазиян белән күпне күрдем...

— Мона монда гына ул,— дип, Миргазиян Мәскәү урамыннан сине җәяүләп бер алып китмәсен. Аның «монда гына» дигәне, беренчедән, кимендә алты-җиде чакрым ара була. Анысы әле ярый, әдәбият, диңгез турында сөйли-сөйли атлый торгач, әнә шул «мондагы»ны өч-дүрт чакрым узып та киткән буласың.

— Ах, шайтан, узганбыз икән,— дип ул бераздан кире борыла. Шәһәр транспортын ул яратмый.

Озак еллар буе океан киңлекләрен гизгән кешенең шәһәр трамваена, җир асты юлларына керәсе килмәве, әлбәттә, табигый. Эш сәгате бетеп өйгә кайтышлый, ул башкала урамнарыннан җәяүләп уза. Көн саен диярлек берәр музейга, күргәзмә залына кермичә калмый. Бүген кайда нинди күргәзмә ачылган, анда нинди яңалыклар булуы мөмкин — әллә ничек кенә барысын да алдан белеп тора.

— Мона монда гына кереп чыгыйк әле,— дип, бервакыт ул мине сәнгать музеена алып керде. Кердек, мәрмәр баскычтан менүгә Пикассоның «Карт яһүд» дигән картинасы янына килеп басты да бик озак карап торды. Баксаң, бу музейга ул гел керә икән.

— Пикассоны яратам, һәр полотносы — бер китап,— диде ахырдан.

Беренче очрашкан вакытта яшен чамалауда мин ялгышкан кебек, күпләр аның белемен, әзерлеген чамалаганда да ялгышалар. Я, ярар инде, йөзгән, ил-җир күргән, Мадагаскар янында су коенган, Кызыл диңгездә чумып үз кулы белән мәрҗән алып менгән. Коломбо портында мәһабәт кокос пальмалары арасында йөргән, төрек кызларының тау буенда чикләвек җыйганнарын карап утырган, безнең ил белән сәүдә итүче бер төрекнең бакчасында кунак булган — ялкында кыздырылган сарык ите ашаганнар. Аннан Неапольдә ремонтта торганнар, Бомбейда бодай бушатканнар.

— Ә менә без язучылар, филологлар болай уйлыйбыз,— дип сүз башлап аңа, гап-гади бер диңгезчегә, әдәбият-сәнгать гыйлеменең нечкәлеген аңлатырга тотынган кеше харап була.

— Поль Верленның «Көзге җыр» шигыре искә төште әле,— дип тотына үз чиратында Миргазиян.— Франсуа Вийон белән Поль Верленга кадәр яшәгән бөтен француз шагыйрьләренең китапларын үземдә булдырасым килә...

Яңа таныш белеп бетерми, әлеге гади диңгезче моннан уналты ел элек Мәскәү дәүләт университетының филология факультетын тәмамлаган. Я, ярый, Вийон, Теофиль Готье, Экзюпериларны яхшы белгән «Мәскәү татарына» бераз үзебезнең татар әдәбияты буенча мәгълүмат бирергә кирәк... дип сүз башлаган кеше дә ялгыша. Чөнки бу юнәлештәге әңгәмәнең бер-ике җөмләсеннән үк аңлашыла: татар әдәбияты тарихын да яхшы белә бит әлеге «диңгез бүресе». Баксаң, Мәскәү университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасы каршында «Һади Такташ иҗатының башкорт совет поэзиясенә йогынтысы» дигән темага диплом яклаган икән.

Эшләгән урынында русча, өендә кызы белән инглизчә, Казаннар килеп чыкса — алар белән татарча, Одессадагы элеккеге дуслары — диңгез бүреләре кунакка килсә, алар белән итальянча да сөйләшә икән.

Тукта әле, кем соң бу, кайларда туган, кайларда укыган, яшәгән соң бу егет? Биографиясе — гади дә, түгел дә. 1927 елда Бәүлы районы Исергәп авылында туган, шунда урта белем алган, ат җигеп урман чыгарган, көлтә керткән, икмәк заданиесе илткән, аулак өйләргә йөргән. Әнисе актык акчасына аңа гармун алып биргән... (Кулына тальян керсә, Миргазиян әле дә булса мәскәүлеген онытып исергәпләнә дә бетә.) Аннары яше җитәр-җитмәс военкомат юлын таптый башлый, яшьтәшләреннән ярты ел алда үзе ялынып-үтенеп армиягә (ул вакытта — сугышка!) китеп бара. Аларны ашыгыч рәвештә радист-һава укчысы итеп әзерләп чыгаралар һәм фронтка озаталар. Әмма Германия аэродромнарының берсенә килеп төшкәндә мәгълүм була: сугыш беткән.

Исергәп егете үзен авиациягә багышлый. 1950 елда ул экстерн рәвешендә штурманнар хәзерли торган училищены тәмамлый. Авариягә очрап имгәнгәнче, хәрби самолетларда оча. Аннан Мәскәү университетына килеп керә. Әмма Исергәп басуларыннан ат белән көлтә ташыгандагы яшьлек хыялларыннан берсе аңа тынгылык бирми: бу дөнья бик зур, бик киң. Ул шундый киң — зәңгәр күк гөмбәзендә хәрби самолет кабинасыннан күренгән кадәр генә дә түгел. Кичәге һава штурманы, бүгенге филология факультеты студенты Миргазиян Юнысовның күңелен еракларгы сихри утраулар, ул әлегә күрмәгән мәһабәт пальмалар, экватор өстендәге тыгыз кара күктәге эре йолдызлар, пассат җилләре үзенә тарта. Бала чактан колагына кереп калган бер исем аңа тынгылык бирми: Занзибар... Бу исем берөзлексез аның хисен кузгатып тора, ул исем, ничектер, мәңгелек яшьлек, матурлык, сафлык символы буларак, берөзлексез сихри аһәң булып аның йөрәк кылларына чиртеп тора: Занзибар... Ул таумы, диңгезме, атаумы? Әмма ул, шиксез, зәңгәр. Ул кайдадыр, ә-ә-нә тегендә, ерак якта, ул — бер дә шиксез зәңгәр диңгезләр, зәңгәр болытлар артында. Һәм яшьлек романтикасы белән күңеле тулган егет, читтән торып укуга күчеп, зәңгәр Занзибарны эзләп сәфәргә чыга. Илебезнең диңгез капкасы булган мәшһүр Одесса портының причаллары тирәсендә шул көннәрдә күлмәк җиңнәрен сызганган, гади чалбар, җиде таңкәлек ботинка кигән озын буйлы бер егет күренә. Аның сагышлы моңсу күзләре порт каршындагы Решилье һәйкәле яныннан еракка — диңгез артына текәлгән...

Җаны теләгән — елан ите ашаган, ди халык.

Миргазиян күмер ташый торган иске бер судногa табак-савыт юучы булып керә. Бераздан — мореходкада (диңгезчеләр хәзерли торган училищены шулай дип атыйлар), аннан штурманнар хәзерли торган курста. Һәм, ниһаять, Миргазиян малай вакытында көлтә ташыганда үзе хыялланган Занзибарга барып чыга. Әйе, йөрәге аны алдамаган, Занзибар зәңгәр болытлар артында икән. Шуннан китә ил гизү. Океан судносында айлар буе, әгәр ул судно берәр чит ил тарафыннан фрахтовать ителгән булса (ул илнең йөген ташырга ялланган булса), яртышар ел су өстендә. Александрия — Сингапур, Марсель — Аден, Стамбул — Бомбей, Гданьск — Коломбо... Азмы дөньяның портлары!

Миргазиян йөзгән «Чулым» теплоходы Иракның Басра портына килеп швартов биргәч, пальмалар арасындагы асфальттан портка ап-ак «Мерседес» килеп туктый. Бу нинди генә гарәп чиновнигы булды тагын, дип, теплоход бортына күз салса, — юк, гарәп чиновнигы түгел, ә Миргазиянның бертуган энесе, Тышкы мөнәсәбәтләр институтын тәмамлаган Вахит икән. Ул Азия, Африка илләрендә безнең дәүләтнең сәүдә вәкиле сыйфатында экономик киңәшче булып эшли. Исергәп малайлары капитанның беренче ярдәмчесе каютасында Көнчыгышның затлы җимешләрен ашап кофе эчәләр, еракта калган әниләрен, үзләре таптап йөргән камыл басуларын, кырау төшкәч бары тик безнең якларда гына тарала торган бәрәңге сабагы исен хәтергә алалар...

Миргазиянның булачак хикәяләре, повестьлары, кульъязмалары — барысы да океан киңлекләрендә, төнге вахта, ял сәгатьләрендә языла. Ул әсәрләрдән шуңа күрә галәм киңлекләрен, планета сулышын, бөтен кешелек җәмгыятенең йөрәк тибешен сизгәндәй буласың.

Сезнең караңгы тропик төнендә океан, күк йөзе белән япа-ялгыз калганыгыз бармы? Галәмнең сулышын әнә шунда тоясың, яшәү мәгънәсен шунда тирәнрәк аңлыйсың. Борынгы заманның бөек акыл ияләре һәм шагыйрьләре тикмәгә генә биек тау, ком чүле яки диңгез, океан бишекләреннән килеп чыкмаганнар... Синең баш өстеңдә теп-тере эре йолдызлары белән кара күк гөмбәзе, ә корабыңның корыч тәненә планетаның иң дәһшәтле куәт чыганагы — тыгыз су массасы килеп бәрелә. Су дөньясы үзенең әсиәзенә чит масса кагылганны гафу итми, ул шундук аңа каршылык күрсәтә. Аның куәте каршында син йомычка, син тузан, молекула... Әмма әнә шул дәһшәтле көч кочагына ташланган адәм баласы дөньяда мөмкин булган шөгыльләрнең иң изгесен башкара: кайсыдыр илдә ач балалар синең судноң трюмындагы меңләгән тонна бодайны көтәләр, кайсыдыр халыклар өчен синең судноңа төяп җибәреләчәк әфлисун, чәй, лимонны озату зур әһәмияткә ия, кайсыдыр ил белән кайсыдыр илләрнең экономик үсеше, димәк, кешеләр язмышы — синең суд-

ноңдагы бакыр рудасы яки тюклаган мамык, тирене вакытында илтеп җиткерүгә, алып кайтуга бәйләнгән. Әнә шулар бәрабәренә кеше табигатьнең дәһшәтле куәтенә корыч тавы белән ерып керә һәм океан белән уртак тел таба.

Төнге вахталарда әнә шуларны тойган хәлдә, Миргазиянның «Тимер фил», «Занзибар зәңгәр болытлар артында» кебек китаплары языла. Хәер, алар гына түгел, «Тозлы җил» дә, «Торна тавышы» да шунда языла башлый. Миргазиян аларны диңгездән кайткач төзәтә, редакцияли генә.

Миргазиянның яраткан язучылары бар. Сөйләшкәндә, әгәр син ул язучыларның әсәрләрен укымаган булсаң, аның кәефе китә. Алар — Э. Хемингуэй, В. Быков, Ю. Трифонов, Ф. Абрамов, В. Распутин, В. Конецкий. Соңгысын ул телгә алмыйча калмый. Чөнки Виктор Конецкий бүгенге иң күренекле язучы-маринист. Ул берәүне дә кабатламыйча әсәр яза белә. Аның китапларында — авторның уйланулары, хыяллары. Ул Сиднейдан торып та, Марсельдән дә, Нагасакидан да, Калькуттадан да, Одесса портыннан торып та кеше язмышы, планета язмышы турында уйлана, үзе күргән илләр-җирләр турында кызык-кызык хикәяләр тудыра. Төрле халыкларның мифларын телгә ала, алар булып уйлый, океан рифларына утырган судноларны кешеләрне коткаруда катнаша... Әйтергә кирәк, Виктор Конецкийның бер китабы «Мифлар һәм рифлар арасында» дип атала. Миргазиян Юнысның тормыш юлына, иҗат эшчәнлегенә күз салсаң, аның тормышы һәм иҗатына нәкъ шундый характеристика биреп булыр иде: ул гомере буе мифлар һәм рифлар арасында. Иҗат эшендә ул шактый кыенлыклар кичерә — язасы темалар күп, күргән-белгән күп, капитан ярдәмчесе каютасында төннәр буе алып барган көндәлекләр, язмалар аның кулы тигәнне көтә. Казаннан еракта яшәү дә үзен сиздерә: нәшриятлар, редакцияләрдәге иптәшләр белән ул бик сирәк күрешә, сөйләшүләр күбрәк почта аша алып барыла. «Наука и религия» журналында бүлек мөдире булып эшләү белән берррәттән, ул шәһәрнең җәмәгать эшендә актив катнаша. Мәскәүдә ул Марксизм-ленинизм кичке университетында укый, Иҗтимагый фәннәр академиясе каршындагы социологлар курсын тәмамлый. Шәһәр предприятиеләрендә, завод цехларында лекцияләр укый.

Үзенең мифлар дөньясы — язмалары белән ул бары тик төн уртасында гына өстәл янында очраша. Көндәлек ыгы-зыгыдан азат булып, үзенең язу өстәле янында утырганда ул рифларны хәвефсез узып тулы хут белән алга барган корабны хәтерләтә... Ә аның язасылары күп әле. Бик күп...

...Дөнья кичкән диңгезченең шүрлегендә, Тукай, Ибраһимов, Дәрмәнд әсәрләре белән бергә, «Справочник капитана дальнего плавания» дигән калын китап тора. Язу өстәле турысында диварда — экзотикалы көнчыгыш илләреннән океаннар аша хуш исле чәй ташучы клипер макеты. Кием шкафының өске шүрлегендә кара-каршы флаглы, якорьлы капитан фуражкасы...

Юк, шәһәр урамнарында эре-эре атлап озак йөрмәс, барыбер океанга — рифлар һәм мифлар арасына, мәрҗән атауларына китәр бу. «Тозлы җил» трилогиясенең соңгы өлешен эшкәртеп бетергәнче генә коры җирдә яши ул. Зәңгәр болытлар артындагы ерак илләргә, океаннар өстендә чайкалырга барыбер китәр бу, Мәскәүнең язу машинкалары сата торган кибетенең план үтәлешенә зыян килсә-килер, китәр бу...

Рифлар, мифлар дөньясын бераз әйкагач, укучыларын сагынып да, яңа әсәр язар өчен, кабат безнең арага кайтыр. Тик ул йөзәчәк судно да, язачак әсәрләре дә рифларны әйләнеп узсын иде.

...Миргазиян әшыга, язасы темалары аңа тынгылык бирми. Вакыт җитмәүгә борчылып ул кайвакытта чәчелеп китә, төрле жанрларга ташлана — мәкалә, притча, рецензия яза, ә әлеге зур тема — диңгез темасы туктап тора. Ул вакытта Миргазиянның тормышы аның фикерләре белән каршылыкка керә. Табигать биргән байлыгын тиешсез урынга әрәм итүчеләр турында ул үзе:

— Секстан белән чикләвек ваталар бит,— дип әйтергә ярата.

Секстан — йолдызлар белән диңгез өсте яссылыгы арасындагы почмакларны үлчәү өчен.

Капитан ярдәмчесе Миргазиян Юнысов коры җирдә вакытта моны үзе дә исеннән чыгармасын иде. Аңа әле нибары илле яшь — хәтернең шәп вакыты.

**МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ.**

## КАВИ ЛАТЫЙПКА 50 ЯШЬ

*Шагыйрь һәм прозаик Кави Латыйпка 50 яшь тулды. Бөек Ватан сугышында катнашкан, аннары озак еллар буе чик буенда хәрби хезмәттә булган һәм бүгенге көндә тыныч хезмәттә иҗади дәрт белән янып яшәгән шагыйрьнең татар телендә «Солдат эзләре» (1960), «Умырзая» (1966), «Ак карлар» (1970), чуваш телендә «Шигырьләр» (1964) һәм русча «Тормыш бизәкләре» («Краски жизни», 1973, «Советский писатель») китаплары басылып чыкты. Космонавт Андриан Николаевка багышланган «Йолдыз тапкан егет» повесте да татар һәм чуваш телләрендә басылды. Шулай ук Кави Латыйпның «Мизгел» исемле хикәяләр китабы һәм «Бәхетле язмыш» дигән очеркы аерым басма итеп чыгарылды.*

*Без бу санда укучыларыбызга аның берничә яңа шигырен тәкъдим итәбез.*



# ӨМЕТ БЕЛӘН КАРЫЙМ ДӨНЬЯГА МИН

### Алай гына түгел...

Өмет белән карыйм дөньяга мин,
Өмет минем гомер юлдашым.
Алай гына түгел, тагын зуррак —
Өмет минем тормыш кояшым.

Яшәп була нинди газапта да,
Күңелеңдә өмет сүнмәсә.
Алай гына түгел, тагын зуррак —
Мөмкин икән хәтта үлмәскә!

### Улымның әйтелмәгән васыяте

Дөнья куйсам егет чакта,
Яшегезне түкмәгез.
Бер сүзем бар: «Рәсемемне,
Зинһар, ятим итмәгез!»

## *Бик сагынам...*

Күңел елый... Ләкин сиздермисең
Берәүгә дә — дошманмы, дусмы.
Һәркемнең бар үзе генә белгән
Җәрәхәте,
Хиросимасы...
Үземә генә килгән хәсрәтем бар, —
Шул бәйләде ике кулымны.
Янып-көеп яшим көне-төне,
Бик сагынам газиз улымны!..

## *Фронтта*

Укалы калфак кигән кыз
Баскан танк өстенә.
Һич ышанмыйм үз-үземә,
Күрәммәллә төшемдә?..

Моңлы көйгә сузып-сузып
Татар кызы җырлады.
Әйтерсең лә бөтен фронт
«Тәфтиләү»не тыңлады.

## *Йөрәге сакта*

Йоклый алмый төнен ана,
Киеренке бит заман.
Ил чигендә улы белән
Йөрәге сакта һаман...

## *Сагыш*

Канәфер орлыгы сыман
Сибелгәннәр язмышлар.
Хәтта илебез Гимнында
Без кичергән сагыш бар...

## *Күпер*

Син әйтәсең: чал төс кергән
Кара чәчеңә.
Ә сиңа бит җитмеш түгел,
Илле яшь кенә...

Әйе, дустым, илледә дә
Күп юл үтелгән.
Яшьлегемә кире кайтмам, —
Күпер сүтелгән!

## *Бөеклек*

Тауга карап тора карт инвалид,
Искә ала Ватан сугышын.
Тау башында ята аның улы, —
Тоя кебек хәтта сулышын.

Ә тау — ташлы, текә, биек... Ләкин
Чал атаның килә менәсе.
Улы бөеклеген горур солдат
Биеклектән күрә киләсе...

## Энҗе Мөэминова

### Буяштым

Мин койма буяштым
Беркөнне яшелгә.
Мактады әни дә,
Мактады әти дә.
Карыйлар да миңа,
Көләләр үзләре:
«Буялмый калган, дип,
Яшелгә күзләре!»
Килдем дә тиз генә,
Карадым көзгегә:
Көзгедә бар җирем
Ямь-яшел күренә.

Буялганмы әллә
Яшелгә көзге дә?!

### Пешердек!

— Кесәлнеме, кесәлне,
Кем яратмый кесәлне!
Үзе ачы аз гына,
Үзе төче аз гына,
Тәме — шикәр, бал гына!
— Кесәлнеме, кесәлне,
Кем дә пешерә аны!
Он гына булсын бары!
Үзе пешә тиз генә,
Сал да бута, из генә!
— Пешереп карыйкмы?
— Әйдә!..
— Әниләр дә күрсеннәр,
«Булдыргансыз!» — дисеннәр.
Ашасыннар туйганчы.
«Олы телдән үтмәде,
Кече телгә җитмәде», —
Дип әйтерлек булмасын.

Чиләк ярым су китте...
Пакетларда он бетте...
Бу ни хәл соң? Бу ни бу?! —
Нигә кесәл булмый бу?!

## Заһирә Гомәрова

### Зәңгәр чәчәк

Бик тырыш малай Әнис:
Көн буе һаман дәрес...
Беркайда китеп йөрми,
Ә эше күп... өлгерми.

Ризыкның тәме бетте,
Йокысы качып китте.
Әмма бер көн энисе
Кызык итте Әнисне.

— Болынга, — ди, — барыйк без,
Зәңгәр чәчәк табыйк без.
Ул чәчәк шундый серле,
Өзәргә кирәк берне.

Алар болынга китте,
Кичкә чак кайтып җитте.
Әби карый чәчәкне:
— Тапкансың — ди, — әй, шәпне!

Куйыйк мендәр астыңа,
Йокың килер ятуга.
... Чыннан да серле икән,
Әнисе дөрес әйткән.

Йокы аңа бу юлы
Шундый тәмле тоелды.
Көлә-көлә уянды,
Көчем күп дип куанды.

### Зәйни

Авызын һич тә буш тотмый,
Эшләтеп тора Зәйни:
Я бармагын суыра ул,
Я шоколад умыра ул,
Я исә сагыз чәйни.

Белим диме кәчләрен,
Көрәштерә тешләрен.
Карандаш башларының да
Ныклыгын сынап карый.
Чәйнәп бетерә алмый.

Китап актарган чагында
Күзәтегез Зәйнине:
Анда да авыз кыймылдый,
Хәрефләрне чәйниме?

Чакырсалар ашарга,
Тырыша ул качарга.
Иптәшләре сөйлиләр:
— Үзе гел чәйни, — диләр, —
Ашамас Зәйни, — диләр.

Шул гадәтен ташлатырга
Нинди дару табасы,
Докторгамы барасы?
Бу шигырьне укучы
Әйтер бәлки чарасын?

## Юл куючы Бари

Әбисе ашын китерә,
Кашык, тәлинкә ташый.
Ничек җитешсен әбисе,
Тышта самавар ташый.

Аптырагач, оныгына:
— Булышсана, улым, — ди, —
Унлап эшне башкарырга
Җитми ике кулым, — ди.

Тик безнең Габделбари
Җавапка аптырамый:

— Зурлар эшен тартып алу
Нәниләргә килешми.
Без һәркайда өлкәннәргә
Юл куярга тиеш, — ди.

# САТИРА —
# ҺӨҖҮМ КОРАЛЫ

*Журналыбызның 1975 һәм 1976 елгы бишенче саннарында без, Бөек Ватан сугышы елларында елмаюлы һәм көлүле әсәрләрнең дошманга каршы көчле корал булып көрәшкәнен исбатлап, сугыш еллары фольклорыннан шактый күп үрнәкләр бастырган идек. Укучыларыбыз игътибарына төрле илләрдән һәм төрле телләрдән җыеп тәрҗемә ителгән тагын бер туплама тәкъдим итәбез.*

I

## БЕЗНЕҢ УКЛАР

### КУЛ КҮТӘРМӘДЕ

Бервакыт Гитлер, үзен озата йөргән офицерлары белән, юләрләр йортына бара. Анда дәваланып ятучыларның барысын да бер рәткә тезәләр һәм фюрерны сәламләп кул күтәрергә мәҗбүр итәләр. Арадан бары тик берәү генә кулын күтәрми. Гитлер аңардан:

— Син ник сәлам бирмисең? — дип сорый.

Ә теге исә аңа:

— Мин юләр түгел, мин биредә эшлим генә бит, — ди.

### НИЧЕК МӨМКИН БУЛДЫ

— Совет снайперы пулясыннан ничектер сакланып кала алды бит Карл.

— Ничек шулай мөмкин булды икән?

— Гап-гади мөмкинлек: партизан минасына эләгеп дөмекте.

### АЯК СУЗДЫ

— Мурманскины алуы бик җиңел — аңа бары тик кул гына сузарга кирәк, — дигән иде майор Фон Криккен.

— Ә хәзер кайда соң ул майор?

— Аякларын сузды.

### ДИВИЗИЯ КАЯ КИТТЕ!

— Син белмисеңме, Ганс, безнең күршебездәге дивизия кая китте икән?

— Аны кичә безнең күршедәге бер ротаны тулыландырырга җибәргәннәр.

## ГАЕБЕ ЮК

— Лейтенант Драпфуль, сез үз ротагыз белән ут сызыгыннан качып чигенүдә гаепләнәсез. Шул гаепне таныйсызмы?

— Юк, танымыйм. Чөнки ротаның яртысы гына качты, ә икенче яртысын исә мин шуларны тотарга җибәрдем, ә үзем икенче ярты артыннан чаптым — чөнки аны беренче ярты белән бергә качырмаска кирәк иде.

## ӘГӘР ТОЛ КАЛСА...

— Беләсеңме, Фриц, бүген Геринг әфәнденең хатыны туган көн. Бәлки безнең эскадра исеменнән котлау җибәрергә кирәктер?

— Әгәр ул инде тол калган булса, мин аны, әлбәттә, бик рәхәтләнеп тәбрикләр идем.

## ТЕЛӘК

Ике немец солдаты сөйләшә:

— Янәшәңдә совет бомбасы ярылган минутта син нинди соңгы теләк теләр идең?

— Янымда Гитлерның басып торуын...

## НИК ЕЛЫЙ

— Ник елыйсыз, фрау Энзель? Сезнең ирегезне генерал иткәннәр бит.

— Әй, әйтмәгез лә шуны! Генералдан тол калганчы, полковник хатыны булуым яхшырак иде.

## КАКШАУ

— Геббельсның немец солдаты нервысы турында мәкаләсен укыдыңмы, Фриц?

— Юк. Минем нервларым шул кадәр какшады инде хәзер, Геббельсны гомумән укый алмаслык булдым!

## МӘКТӘПТӘ

— Ганс, «чабу» дигән фигыльне төрләндер әле?
— Мин чабам, ул чаба, без чабабыз...
— Ә алар?
— Ә алар һөҗүм итәләр, укытучы әфәндем.

## КУРКУНЫҢ ЧИГЕ

Разведкадан кайткан бер солдат хәбәр итә:
— Әле җимерелмәгән бер күпер калган.
— Танклар узарлыкмы?
— Узарлык.
— Атлы гаскәр?
— Минемчә, уза алырга тиеш.

— Алайса, пехота да уза алачак?
— Пехота уза алмастыр кебек, капитан!
— Ничек инде ул алай, танклар уза, атлы гаскәр уза, ә пехота юк?
— Чөнки күпер башына бик усал эт бәйләнгән.

## АРТТА КАЛГАН

— Син, Фриц, нишләп монда буталып йөрисең?
— Полкымнан артта калдым.
— Ә полкың кайда?
— Каберлектә.

## ҖЫР БЕЛӘН ҖИҢҮ

Даладагы иң өстен биеклек фашистлар кулында. Алар анда бик күбәү. Безнең көчләр кирәгенчә тупланып җитмәгән һәм ул биеклекне алу әле мөмкин түгел. Шуның якынында гына, снаряд төшеп ярылган бер чокырда, безнең разведчигыбыз — бер грузин егете ята. Ул өши, аңа күңелсез, аны куркыныч та шактый интектерә...

Нәкъ менә шул моңсу минутта ул үзенең туган телендә «Сулико» җырын көйли башлый. Мавыгып китеп, гүя тирә-юньдәге бар нәрсәне дә оныта һәм торган саен катырак кычкырып җырлый башлый.

Үрдәге фашистлар аларның борын төбендә үк шулай кычкырып кем дә булса берәүнең генә җырлавын күз алларына китерә алмаганнар булса кирәк — каушый-курка калалар һәм, кинәт кубып, биеклекне ташлап китәләр. Анда безнекеләр менеп урнаша.

Взвод командирының рапорт кәгазенә кыска гына бер җөмлә языла: «Н. биеклеген «Сулико» белән тулысынча яуладык!»

## ҖИР БЕЛӘН БЕРГӘ

— Чын ариец беркайчан да калтырамаска тиеш.
— Ә мин калтырамыйм да бит әле. Җир үзе шулай, ничек селкенергә белмичә, руслар утыннан калтырый, мин исә ул селкенгәннән генә селкенәм.

## ЯЛГАН СҮЗ

— Курт Пепке, сез фронтта безнең полк бик күп сугышчыларын югалтты дигән гайбәт таратасыз икән.
— Моны миңа бүген икенче батальон солдатлары әйтте, һерр оберлейтенант!
— Менә болай дип сез икеләтә ялганлыйсыз инде! Икенче батальон солдатларыннан сез бернәрсә дә ишетә алмадыгыз һәм ишетә алмыйсыз, чөнки ул батальонны кичә руслар тулысынча юк иттеләр, кырып бетерделәр бит!

## АЛДАН УЙЛАП ЧАМАЛАУ

— Менә шулай, штаб начальнигы: «Бөек Германия» полкы оборона тота, «Адольф Гитлер» полкы «Бөек Германия» полкының фронттан качмавын күзәтә, ә «Рейхсмаршал Геринг» полкы «Адольф Гитлер» полкы чигенә башласа, аны киртәләп ут ачарга әзер...

## АЛДЫЙ ЯЗДЫ

Немец ефрейторы Генрих Хлюст фронттан хат яза: «Рус җирендәге салкын кышлар безгә ул хәтле үк куркыныч түгел. Менә землянкада утырабыз, ул җып-җылы...» Шул сүзләрдән соң нокта куяр өчен хатны кабат укып чыккач үзе дә сизмәстән өсти ул: «Хәзер карандашка күчтем, чөнки савыттагы язу карасы туңган һәм аны берни белән дә җылыту мөмкин түгел».



## БӘХӘСТӘ ОТУ

Икенче фронт ачылгач, Гитлер гаскәренең ике солдаты «Безнең бердәмлек кайда көчлерәк?» дигән бәхәс куптара: янәсе, Көнчыгыш фронттамы, әллә Көнбатыштамы?

— Дускаем минем, безнең яктагыдай бердәмлек хәзер һичкайда юк ул. Әйтик, мәсәлән, солдат ике көнлек ялга китте ди. Ә фронтка ул яңадан килгәндә аны каршылап бөтен гаскәр Көнбатышка чаба.

## НӘРСӘ КАЛДЫ!

— Әйт әле, Курт, безнең җиңелмәслектән нәрсә генә калды хәзер?

— Бер генә нәрсә калды дияр идем мин: ул да булса, тизрәк әсирлеккә биреләсе иде дигән җиңелмәс теләк.

## ҖӘЗА

— Миңа яңа костюм тегәр өчен нинди материал килешлерәк булыр диярсең?

— Сезгә, фюререм минем, челтәрле-шакмаклы тукыма иң яхшыдан булыр.

Гитлерга шундый җавап биргәне өчен империя башлыклары кием тегүче останы үлем җәзасына хөкем итәләр.

## ТИЗ ХӘЛ КЫЛУ

Дранкен һәм Гендегокер исемле ике солдатны разведкага юллыйлар.

— Язмышларыгыз үз кулыгызда икәнен бер минутка да онытмагыз! Сак һәм күзәтчән булырга, теләсә нинди мәсьәләне бик тиз хәл кыла белергә кирәк, — ди офицер аларны эш башкарырга озатканда.

Немец разведчикларының юлын бәзнекеләр, совет солдатлары, бүлдерә һәм «Хенде хох!» дигән команда бирелә.

Шул чакны Гендегокер үз юлдашы Дранкенга ашыгып пышылдый икән:

— Отто дустым, язмышларыбыз үз кулыбызда бит безнең!

Һәм алар икесе дә бик ашыгып кулларын күтәрәләр.

## ТИЗЛЕК

— Син фронтта күпме вакыт булдың, Фриц?

— Һич әйтә алмыйм шул, сәгатькә карап өлгерә алмадым.

### КҮРӘСЕ КИЛҮ

— Вилли Шемпене бик күрәселәрем килде.
— Ничек күрәсең ди? Ул бит руслар әсире хәзер...
— Нәкъ менә шул әсир икәнен күрәсем килә дә.

### ҖИҢҮЛЕ КОРАЛ

— Полковник әфәнде! Безнең туптан атып большевиклар офицеры безнең бөтен пулеметларны кырып ташлады.
— Безнең коралның җиңүе турында штабка ашыгыч хәбәр итегез.

### КАРАП БУЛМАДЫ

— Совет кавалериясе белән очрашу сездә нинди тәэсир калдырды?
— Берни дә әйтә алмыйм, чөнки җайдакларга карап торып булмады, без алардан качып чаптык.

### ЫШАНДЫРЫП КИРЕ КАГУ

— Син белмисеңме, Ганс, кичә советларның нинди полкы безнең дивизияне шулай тетеп салды?
— Аның кырылып ташлануы турында безгә Геббельс июль аенда ук хәбәр иткән иде бит инде. Нәкъ менә шушы полк дип бел!

### АВЫЛГА ТАНКИСТ КАЙТКАЧ

— Нәрсә, малай, борыныңны болай салындырып бик моңаясың әле?
— Чөнки мине менә, синең шикелле танкист итеп, армиягә һаман алмыйлар.
— Үсеп җиткәч — алырбыз.
— Көт син аны! Мин үсеп җиткәнче сез анда бөтен гитлерчыларны кырып бетерәчәксез бит.

II

## ЧЕХ ҺӘМ СЛОВАК МӘЗӘКЛӘРЕ

### НИЕМӘ КИРӘК УЛ ТЕЛ!

— Немец телен өйрәнәсеңме син? — дип сорыйлар бер словактан.
— Ниемә кирәге бар аның?! Гитлерчылар «соңгы солдаткача сугышачакбыз» диләр бит. Шулар бөтенесе дөмеккәч, кем белән немецчә сөйләшергә кала?

### ДӨРЕС СҮЗГӘ ҖАВАП ЮК

Словакиягә басып кергән Италия армиясе офицеры, җирле халыкның фашистларга карата нинди мөнәсәбәттә булуын белергә теләп, берәүне урамда туктата да аңа сораулар яудыра башлый:

— Син инглизләргә хезмәт итәр идеңме?
— Юк.
— Ә Совет Армиясенә?
— Юк.
— Ә безнең бөек дуче гаскәрләренә?
— Мена аңа булышыр өчен көне-төне эшләр идем!
— Молодец икәнсең. Афәрин! Ә һөнәрең буенча кем буласың соң син?
— Табутлар ясыйм.

## СӘЛАМНЕҢ СЕРЕ

— Рядовой Попер, офицерларга ничек сәлам бирергә кирәк?
— Немец офицерына бер кулны, ә советныкына ике кулны күтәреп.

## ИКЕ ӘСИР СӨЙЛӘШӘ

— Рус пулясыннан мин башымны кулларым белән сакладым.
— Синең кулларың калкан түгелдер бит?
— Юк... Мин кулларымны баштан өскә күтәрдем.

## НИЧӘ КЕШЕ КАЛДЫ!

— Минем ротадан ничә кеше калды, солдат?
— Сез ялгызыгыз гына!
— Ә син?
— Мин дә бер үзем, ләкин бүтән ротадан.

## ЯТИМ БУЛЫРГА ТЕЛӘҮ

— Фриц, чын немец өчен фюрер партиясе кем?
— Ана кебек була ул, обер-лейтенант әфәнде!
— Дөрес! Ә фюрер үзе?
— Ул исә ата була!
— Дөрес әйтәсең. Ә син үзең кем булырга теләр идең?
— Мин шыр ятим булырга телим, обер-лейтенант әфәнде!

## МӘСКӘҮ ПЛАНЫ

— План буенча чигенүебезгә ышанасыңмы, Фриц?
— Ышанам. Ләкин ул план бит Берлинда түгел, ә Мәскәүдә эшләнгән.

## ИШЕТҮЛӘРЕ КҮҢЕЛЛЕ

Газета киоскысына берәү килә дә: «Дас райх» бармы? — дип сорый.
— Юк, «Дас райх» инде юк.
Әлеге кеше киоск артына барып тора да бераздан тагын килеп сорый:
— «Дас райх» бармы?

— Юк. «Дас райх» инде бетте.

Шул ук кеше, өченче кат килеп, тагын «Дас райх» сорагач, сатучы аңа ачуланып кычкыра:

— «Дас райх» бетте дип ике мәртәбә әйттем бит инде!

— Ах, пани, гафу итегез, миңа шул «Бетте!» дигән сүзне ишетүе бик күңелле.

## АЧКЫЧ ТАБЫЛМЫЙ КАЛА

Швейк Гитлер белән сөйләшә.

— Җиңәчәгебезгә ышаныч зур безнең, — ди Гитлер. — Җиңүгә беренче ачкычыбыз — ул Италия, икенчесе — Япония һәм өченчесе — безнең җиңелмәс армиябез.

— Жижкова урамында мин бер панины беләидем, — дип тезеп китә Швейк. — Аның бер бәйләм ачкычы бар иде. Бервакыт ул бәдрәфкә кермәкче икән, әмма кирәкле ачкычын тапканчы инде соң була...

## ЯҢА КОРАЛ

Геббельс речь сөйли:

— Безнең яңа төр коралыбыз бар! Шуны ходка җибәрсәк, сугышның очына тиз чыгачакбыз.

— Ә нинди корал соң? — дип сорый ул сөйләп бетергәч аның якыннарыннан берәү.

— Ак флаг.

## ҖӘЗАДАН СОҢ

Гавличек исемле артистны немецлар алдында чыгыш ясарга мәҗбүр итәләр. Сәхнәгә ул, Гитлер кыланышына ишарәләп, уң кулын югары күтәргән кыяфәттә чыгып баса. Көчле алкышлар тынгач исә әйтә:

— Мин театрдан кайтканда минем этем нәкъ шундый югарылыкка сикерә.

Моның өчен аны бер айга төрмәгә утырталар. Җәзадан соң исә ул сәхнәгә кулын тагын да югарырак күтәреп чыга. Тагын да көчлерәк алкышлар шаулый һәм артистның тагын бер яңа сүзе әйтелә:

— Мин төрмәдән чыккач, минем этем нәкъ менә шундый югарылыкка сикерде!

## КИРӘКЛЕ КОЙМАЛАР

Гитлер солдатлары Прага урамнарында теләсә ничек азып-тузып, чехларның котын гына түгел, хәтта гомерләрен алып йөри башлагач, шәһәр идарәсе аеруча куркыныч урыннарда тротуарларны тимер рәшәткә белән киртәләргә була.

Шул койманы кора башлаучылардан сорый икән бер узгынчы:

— Нәмәстә эшләгән буласыз әле сез шулай?

— Ничек нәмәстә! — ди бер эшче, усал елмаеп.— Прагага атлы казаклар килгәч, аларның юрткакларын бәйләп торырга койма кирәк булачак ич!

III

# НЕМЕЦ АНЕКДОТЛАРЫ

## ГЛОБУССЫЗ ГИТЛЕР

Бер авыл карчыгы 1941 елның декабре азагында үзләрендә укыткан мөгаллим өенә керә һәм шунда гомерендә беренче тапкыр глобус күрә.

— Франциянең кайда икәнен күрсәтегез әле миңа, укытучы әфәнде?

Укытучы глобуста Францияне күрсәтә.

— Шактый зур икән, — ди карчык. — Ә Америка Кушма Штатлары кайда була инде?

— Менә биредә, әбекәй.

— Күр син аны, алары тагын да зуррак икән! Ә Советлар кайда?

Укытучы бармак төртеп күрсәтә.

— Инде килеп без үзебез кайда булабыз?

Укытучы бармагы Германия буйлап шуыша.

Авыл карчыгы исләре китеп карап тора-тора да әйтә:

— И хода, безнең фюрерга кем дә булса ник шундый бер глобус бүләк итми икән?

## ГИТЛЕР ҺӘМ ВРАЧ

— Майн фюрер, сезнең нервыларыгыз какшый башлаган бит.

— Нервылар? Монысы әле әллә ни түгел. Яшь чагымда мине врачлар син шашкан дип куркыта торганнар иде.

— Сез бит әле, майн фюрер, хәзер дә ул хәтле үк карт түгелсез.

## ДӨРЕС НӘТИҖӘ

Үз һәлакәтен сизеп, Гитлер дөрес нәтиҗәгә килә:

— Штык ярдәмендә дөнья белән идарә итүләре җиңел, әмма штыкка утырсаң — ай-һай, авырттыра икән.

IV

# ФРАНЦУЗЧА ЕЛМАЮЛАР[1]

## КЫЮ КИБЕТЧЕ

Бер китап кибетчесе, барча коммерсантлар да шулай эшләргә тиеш булганга, витринага сатлык җан маршал Петэнның һәм аның ярдәмчесе Лавальның портретларын куярга тиеш була. Әмма ике сурәт астына ул ике төрле язу да ябыштыра: берсе — «арзанайтылган бәягә сатыла», икенчесе — «инде сатылды». Французлар витрина каршында туктап шаркылдашып көләләр, ә кибетче бик тиз арада төрмәгә ябыла.

## КЕМ БЕЛӘН КЕМ!

Урам буйлап узучы немец солдаты каршысына бер малай килә дә:

— Сезнең бил каешыгыз каптыргычына нәрсә язылган? — дип сорый.

— Готт Нит Унс,— дип аңлата солдат,— ягъни «тәңре безнең белән» дигән сүз.


— Алай икән,— ди малай.— Ә безнең белән — руслар!

[1] Франциядә чыккан «Тагын сөйлә әле!» (Эмиль Серван-Шрейбер) һәм «Фәлән-фәләннәр белән очрашу» (Жюль Мош) исемле китаплардан.

## Әмирхан Еники

# ЧИКЕРТКӘ

ӘБДЕРӘХИМ КОДА ӘКИЯТЕ



Сез белмәгән, ә без күрмәгән борын заманда иске авыл мәдрәсәсендә ата-анасыз бер ятим малай укып яткан. Барыр-торыр җире булмагач, ятим шәкерт үзенең хәлфәсенә самавар куеп, аш пешереп, җаен-кышын шул мәдрәсәдә яши биргән. Хәлфә янында үз тамагы да ач булмаган моның. Аннары атна кичләрен авыл малайлары боларга сәдака итеп әз-мәз онын, ярмасын, йомыркасын, сөтен дә китергәлиләр икән. Шулай ук хәлфә үзе дә аш мәҗлесләренә барган җиреннән ятим шәкертенә бәлеш төпләре кыстырып кайткалый торган булган. Сирәк эләксә дә ярап куйган бәлеш төбе!.. Әмма шулай да үсеп барган малайга ашау асла җитмәгән, буйга һаман үскән, ә тәненә бер дә ит кунмаган, сыйраклары да бик нечкә булып калган. Шуңадыр инде, шәкертләр аңа «Чикерткә» дигән ләкаб[1] тә биргәннәр. Ятимнең моңа әллә ни ачуы килмәгән — болай да ул аз сүзле, сабыр холыклы малай булган.

Тора-бара моның чын исеме онытылган, бары шул «Чикерткә» дигән ләкабе генә торып калган.

Менә бер заман озын кыш та үтеп китә, җылы язлар да килеп җитә, шәкертләр дә өйләренә таралышып бетәләр. Хәлфә дә, елдагы гадәте буенча, корьән укып, сәдака җыеп йөрер өчен җәй башыннан ук авыллар арасына чыгып китә. Мәдрәсәдә ятим шәкерт ялгыз үзе генә торып кала.

Ләкин бу юлы моның хәлфәсе авыллар арасында ни сәбәптер озак йөргән. Ул калдырып киткән азык та бетә башлаган, атна кичләрен сәдака итеп онын, ярмасын китерүчеләр дә юк бит инде, шулай итеп ялгыз малай бик аптырауга төшкән. Нәрсә ашарга, кайдан алырга? Ачлык — убырлы карчык, җилегеңне суыра ул! Ахырда, уйлана торгач, Чикерткә тәки бер хәйләсен тапкан бит! Мәдрәсә мичендә кыштан калган шактый көл өелеп ята икән, менә шул көлне иләктән үткәреп, бер кечерәк капчыкка тутырган да күрше авыл базарына күтәреп киткән шәкерт... Базарга барып җиткән бу, сатучылар рәтеннән урын табып, капчыгының авызын ачып җиргә куйган — инде килеп сораучыларны гына көтәсе калган.

---

[1] Ләкаб — кушамат.

Базар әкренләп зурая, халык артканнан-арта, менә әле берсе, әле икенчесе килеп, капчыгы янында утырган Чикерткәдән сорый икән:

— Улым, ни бу, нәрсә сатасың?

— Абзый кеше, бу күсе үтерә торган дару, шәп дару, алып җибәр әле булмаса! — ди Чикерткә сәүдәгәрләрчә өлгер генә.

Ә күсе даруы авыл халкына бик кирәк нәрсә икән ул. Агайлар шунда ук моның көлен учлап-учлап ала да башлыйлар. Чикерткәнең капчыгы бик тиз бушап кала, шактый гына акча да төшерә, шул акчага үзенә җитәрлек азык-төлек ала да, базарда озак буталмыйча, тизрәк авылына таба сыптыра.

Ә агайлар, базарчылар өенә җыелышкач, бер-берсеннән сорыйлар икән: бу даруны күсегә каршы ничек кулланырга соң?.. Ләкин берсе дә белми, имеш, берсенең дә малайдан сорарга уена килмәгән. Эх, ачык авызлар дип үзләрен тиргиләр икән агайлар. Шуннан бер өлкәне яшьрәкләрнең берсенә әйткән:

— Бар, ат менеп базарга чап, малайдан сорашып кайт! — дигән.

Егет ат менеп чапкан, ләкин базарда малай утырган җирдән җилләр генә исә икән. Шулай да, сораша торгач, бер адәм егеткә капчык аскан малайның кайсы якка таба чыгып киткәнен күрсәткән. Егет шул якка таба чаптырып киткән. Ахырда малайны куып җиткән. Җиткән дә туктатып сораган:

— Карале, энекәш, син безгә күсе даруы саттың да бит, ә менә ничек итеп кулланырга кирәклеген әйтмәдең... Яле, тиз генә шуны әйтеп бир, юньсез! — дигән.

Чикерткә бер дә каушамыйча гына егеткә болай дип аңлаткан:

— Бик ансат эшләнә ул, кем, абый кеше! Күсене тоткач, шул даруны аның күзенә сибәргә кирәк. Шуннан күсе тәгәри дә үлә, — дигән. — Аңладыңмы инде?

— Аңладым! — дигән егет, атын борган да тизрәк авылдашлары янына чапкан.

Ә Чикерткә исән-имин генә авылына кайтып җиткән. Азык кайгысы күпмедер вакытка онтылган, ятим шәкерт буш мәдрәсәдә артык ваем чикмичә генә тора биргән.

Менә бер заман югалган хәлфәсе дә кайтып төшә моның... Былтыргы шикелле җәяүләп, әлсерәп түгел, ә шәп ат җиккән таза тарантаста кайтып керә бу... Чикерткә хәлфәсен каршыларга йөгереп чыга. Сәлам алышып, кул бирешеп күрешәләр. Бик куана шәкерт хәлфәсенең, ниһаять, кайтып керүенә. Тиз генә эләктереп самаварын да куя, чәй урнысын да әзерли, хәлфә астына йомшак юрган да җәя, таянырга мендәр дә ташлый.

Хәлфә, атын тугарып, юынып-сөртенеп кергәч, күчтәнәчләрен ашъяулык өстенә чәчеп сала да үзе йомшак юрганга аяк бөкләп утыра. Кул күтәреп, бер дога кылалар, шуннан соң ашыкмыйча тәмләп кенә ашый-эчә башлыйлар. Ә ашъяулык өстендә төче күмәч, бавырсак, кызыл эремчек, калай савытта бал белән май — Чикерткәнең тәмам күзләре яна. Мондый сыйны аның әле беренче күрүе икән.

Хәлфәнең дә кәефе бик әйбәт була. Бу юлы сәфәре уңышлы чыккан икән. Шактый күп сәдака төшергән, шуның өстенә бер байдан карызга[1] да алып торган, менә шул акчаларга җигүле ат та сатып алган. Боларны сөйләп бетергәч, хәлфә шәкертенә әйтә:

— Безгә бу хәерче авыл мәдрәсәсен ташларга кирәк, — ди, — монда ачка киселеп ятудан мәгънә чыкмас. Әнә моннан көн тараф-

---

[1] Карызга — бурычка.

тагы кыргыз далаларында кәрван үтә торган юллар бар — безгә дә менә шул тарафларга күчәргә кирәк. Ул юллардан мал төягән кәрваннар өзлексез үтеп йөриләр. Кәрван хуҗалары — бай сәүдәгәрләр, сәдаканы да алар мул тамыза. Әмма безгә хәер эстәүче генә булырга ярамый. Без изге затлардан булырга тиешбез. Менә мин сине, шәкерт, ишан итәм, ә үзем синең мөриден булырмын, ийе, аллага тапшырып!.. Төшенәсеңме?.. Без кәрван юлыннан ерак түгел бер хозур гына урында чатыр корып җибәрербез. Мин инде ишан хәзрәтләре торырлык, җефәктән тегелгән чатыр да сатып алдым, — дип сүзен бетерә хәлфә.

Чикерткә хәлфәсенең бу сүзләреннән бик аптырап кала, ни диеп әйтергә дә белми. Әллә мине шаярта гына микән дип тә уйлый, ләкин үзе шиген әйтергә дә курка. Хәлфәсе шуны сизгәндәй моңардан сорый:

— Я, ник дәшмисең? Ни уйлыйсың?

— Хәлфә абзый, сез мине ишан итмәкче буласыз да бит, әмма миннән, ай-һай, ишан чыгар микән соң? — ди Чикерткә, түбән карап кына.

— Чыгар, боерган булса! — ди хәлфә, бер дә исе китмичә.— Син зиһенле шәкерт, корьән сүрәләрен дә яттан беләсең, буең-сының да килгән — менә дигән ишан ясап чыгарам мин син сасыктан, алла бирсә!..

Хәлфәсенең сүзе — боерык, күңеле бик үк тартмаса да риза була шәкерт. Шул көннән хәлфә аны ишан кыланышларына өйрәтә дә башлый: ничек итеп йөрергә, ничек итеп утырырга, кешеләр белән ничегрәк сөйләшергә, доганы ничегрәк итеп кылырга — әлхасил, барысын да күрсәтеп бирә хәлфә. Чикерткә боларның һәммәсен дә шактый тиз отып ала.

Ә бер атнадан инде болар юлга да җыеналар. Туры атны әйбәтләп җигәләр, юрган-мендәрләрен, кечкенә сандыкларын, кургашын белән ямаган таз-комганнарын тарантаска чыгарып салалар, үзләре әгузе-бисмиллаларын әйтеп, иплэп кенә менеп утыралар да аллага тапшырып, кыйбла тарафка карап чыгып та китәләр. Бер көн баралар, өч көн, биш көн баралар, җиденче көн дигәндә, ниһаять, кыргыз даласына барып җитәләр. Далада буталып йөри торгач, кәрван үтә торган юлны да эзләп табалар. Инде туктар өчен әйбәт кенә урын сайларга кирәк. Ахырда болар тип-тигез далада көзгедәй ялтырап яткан бер түгәрәк күл буена килеп чыгалар да шуның янында туктарга булалар. Бик ямьле, бик хозур җир икән... Шулай да хәлфә чатырны күлдән читтәрәк, юлдан ераграк калку бер урынга мендереп коруны мәслихәт таба, чөнки калкулык өстеннән карап, ике яктан да килеп яткан кәрваннарны әллә каян ук күреп булачак. Шулай ук чатыр үзе дә ерактан ук күренеп торачак. Моның әһәмиятен Чикерткә аңлап бетермәсә дә, хәлфә үзе бик яхшы аңлаган.

Шулай итеп чатырны калкулык өстенә коралар, чатыр башына ишанның яшел әләме дә кадап куела. Бу эш беткәч, чатыр эченә киез-паласларын кертеп җәяләр, йомшак юрганны буйга бөкләп, сузып салалар, шуның өстенә берничә колакчын мендәр дә ташлыйлар. Аннары нәкъ урта бер җиргә тәбәнәк кенә өстәл куеп, аның өстенә зур-зур, калын-калын китапларны өяләр. (Берсен урта бер җиреннән ачып та куялар.) Бу эшләр дә беткәч, хәлфә Чикерткәне киендерә башлый. Иң элек ул аңа тезенә хәтле үк төшеп торган ак күлмәк белән иләмсез киң ак ыштан кидерә, шулар өстеннән яшел-сары буйлы ефәк чапан кидерә, ә башына егерме аршин ак бәстән, Бохара түбәтәе тирәли, шавадан да зуррак чалма урап куя. Шуннан соң әйтә Чикерткәгә:

— Тәкъсир, синең эшең менә шушы өстәл янында башыңны бөгеп, изге китап моталага кылып утыру... арсаң, әнә мендәргә таянырсың... Ә калганы минем эшем, — ди.

Тәмам урнашып беткәч, болар башта тәмле күл суыннан чәй кайнатып эчәләр, аннары хәлфә, атка атланып, тирә-якны карап кайтмакчы булып, чыгып китә. Чикерткә тәбәнәк өстәл янында аяк бөкләп, изге китап «моталага» кылып кала. Хәлфә дала буйлап шактый озак йөри, ләкин бер җирдә дә бернинди адәм заты яки җан иясе очратмый. Кәрван юлы да буш, тын, бер атлы, бер җәяүленең килгәне яки китеп барганы күренми. Әллә ташландык юл микән бу, дип шиккә дә төшә хәлфә, әмма шулай да өметен өзми. Дөрестән дә, бер калку урыннан тирә-якка әйләнгәләп карана торгач, бик еракта, офык читендә үк нәрсәдер селкенгән шикелле күренә моңа... Көтә хәлфә сабыр гына, көтә, инде кояш баерга да күп калмаган була һәм, көтә торгач, теге селкенгән нәрсә әкрен генә килеп яткан озын бер кәрван булып чыга. Моны күрү белән хәлфә атын борып, җан-фәрман чатырына таба чаба. Кайтып керсә, ни күрсен — Чикерткә чалма-чапанын салып ташлап, мендәрләргә батып, сабыйдай изрәп йоклап ята, имеш!

— Әй, син, хәшәп, тор тизрәк! — дип кычкыра хәлфә. — Тапкансың вакыт, әнә кәрван килә ятыр! Чалма-чапаныңны ки дә өстәлең янына утыр. Кәрван кешеләре безгә сугылмыйча калмас, әзер булып тор!

Үзе шунда ук кире чыгып та китә. Кәрван, дөяләр адымы белән генә килсә дә, шактый ук инде якынлашкан була. Калкулык өстендәге чатырны да күрәләр, ахрысы, менә ике җайдак, кәрваннан аерылып, болай таба чаптырып килә дә башлый. Озак та үтми, килеп тә җитәләр. Атларыннан төшәләр, хәлфәгә сәлам бирәләр. Хәлфә дә, түбәнчелек белән башын иеп, сәламнәрен ала, аннары чүгәләп бер дога кылалар. Шуннан килүчеләр җайлап кына: әйтсәгезче, кардәш, бу кем чатыры була, кем тора анда? дип сорыйлар. Хәлфә үз нәүбәтендә зур бер серне ачкандай итеп, бу — бөтен әтрафта дан тоткан фәлән ишанның чатыры була, дип җавап бирә. Нишли соң ул монда, дип сорыйлар тегеләр. Ишан хәзрәтләре, ди хәлфә җавабында, аллаһы тәгаләгә якын торыр өчен адәмнәр арасыннан китеп, ошбу тын сәхрәдә ялгызы көн вә төн изге гыйбадәттә утыра!.. Алай икән, диләр килүчеләр тыйнак кына, ә син үзең кем буласың?.. Мин изге ишанның мөбарәк кулын тоткан мөриде булам, ди хәлфә, һәм бер мәлгә аптырабрак-уйланыбрак калган җайдаклардан үзе сораша башлый: сез кемнәр буласыз, бу кәрван кайдан, кайсы якларга китеп бара? Без кәрван озатучылар булабыз, диләр тегеләр, фәлән җирләрдән фәлән илгә мал төяп барабыз... Юлыгыз уң булсын, ходай бәла-казалардан сакласын, ди хәлфә, кара сакалын сыпырып. Җайдаклар кулларын күкрәкләренә куеп рәхмәтләрен белдерәләр, аннары монда изге ишан торганын хуҗаларына кайтып әйтер өчен тиз генә китеп тә баралар.

Хәлфә шунда ук борылып чатырга керә.

— Ә, утырасыңмы? — ди ул Чикерткәгә. — Шулай кирәк, тәкъсир. Тик чалмаңны батырыбрак ки, авып төшмәсен... Тиздән кәрван хуҗалары килергә тиеш. Алар синең догаңны алыр өчен янына керерләр. Китаптан башыңны күтәрмә, сүзеңне кыска тот, ә догаңны озак итеп укы, аңладыңмы?

Чикерткә башын гына кага. Ул инде тәбәнәк өстәл янында утыра-утыра алҗып беткән була, һавага чыгасы, далада рәхәтләнеп йөрисе килә, әмма булмый — түзәргә кирәк, түзмичә ярамый, хәлфәнең талканы коры, ишан дип тормас, бөкләп ишкән тастымалы мендәр астында гына...

Хәлфә чатырдан чыкканда кәрван туктаган яктан ике кеше җәяүләп кенә бу якка таба килә иде инде. Өс-башларына карaганда, болар, һичшиксез, кәрван хуҗалары булырга тиеш. Хәлфә бер таш өстенә утырып, аларны сабыр гына көтеп ала. Менә килеп җитәләр, сәлам бирәләр, утырып дога кылалар, аннары әйтәләр:

— Әфәндем, бу ерак чатырда ишан хәзрәтләренең изге гыйбадәттә утыруын белеп, без бик хәйран вә шат булдык. Инде безгә дә олы зат үзенең хәер-фатихасын бирмәсме икән? Хозурына кереп, тезләнәсебез килгән иде.

— Мәрхәбә, изге ният белән килгәнсез икән, — ди хәлфә торып. — Әмма башта үзем кереп, ишан хәзрәтнең рөхсәтен алышым кирәк. Аз гына көтегез.

Кергәч, шыпырт кына:

— Килделәр! — ди. — Каушама. Һаман мөгрәнеп кенә укыган бул, ара-тирә кычкырып та куйгала, ишетеп торсыннар! Мин аларны азрак тота төшәрмен.

Чыккач, тегеләргә әйтә:

— Ишан хәзрәтләре изге китап моталага кылып утыра, бераз сабыр итәргә кирәк булыр, әфәнделәр! — ди.

Кәрван хуҗалары сабыр гына көтәләр, мөридтән ишанның исәнсаулыгын, хәл-әхвәлен сорашалар. Ә бераздан хәлфә чатыр эченә башын тыгып карый да: «Инде, кардәшләр, керсәгез дә ярый, тик озак тормасагыз иде, ишан хәзрәт көне буе гыйбадәттә утырып, бик арды булса кирәк»,— ди... Тегеләр чүәкләрен салып чатыр эченә керү белән лып итеп тезләнәләр, тез өстендә генә мүкәйләп ишан хәзрәтнең алдына баралар һәм йөзләрен җиргә оралар. Шул рәвешчә, бик түбәнчелек белән изге ишаннан фатиха бирүен сорыйлар. Чикерткә, чалмалы башын игән килеш кенә, тәсбих аскан кулын күтәреп, әкрен генә селкенә-селкенә бик озак итеп дога кыла. Маңгаеннан алып ияк очына кадәр битен сыйпаганнан соң, мөсафирлардан сәфәрләре турында сораша, сәүдә итеп йөрүнең саваплы эш булуы турында корьәннән берничә аять тә китерә, пәйгамбәремез Мөхәммәт саллалаһегаләйһивәссәләмнең дә сәүдәгәр булуын исләренә төшерә. Мөсафирлар алларына карап, оеп кына утыралар, ишан хәзрәт сүзен бетергәч, кесәләреннән чыгарып аның алдына сәдакаларын салалар һәм мөбарәк кулына иреннәрен тидереп алалар. Ишан хәзрәт сәүдәләренә уңыш, малларына бәрәкәт, үзләренә иминлек теләп тагын бер озын гына итеп дога кыла. Шуннан соң кәрван хуҗалары ишанга кат-кат баш иеп, тезләре өстендә генә чигенеп, чатырдан чыгып китәләр.

Мөсафирларны озаткач та хәлфә ашыгып Чикерткә янына керә.

— Я, ничек? — ди ул, түземсезләнеп.

Чикерткә учын ачып күрсәтә: ике зур алтын тәңкә!.. Хәлфә айгыр кешнәгәндәй көлеп җибәрә:

— И-ха-ха!.. Менә күрдеңме, сасык!.. Кәрван юлы — хәерче татар авылы түгел шул!.. Мәшә алла иншалла, эшләр ходка китә болай булгач... Ә син, шәкерт, ишанлыкны шәп очлап чыктың, афәрин!.. Шулай кирәк, корьәннән дә, хәдистән дә телеңә килгәнне сип тә утыр!.. Ул хәсисләр барысы да туң күчән, ни әйтсәң дә бата үзләренә... Тик син вәкарь сакла, изгеләрчә тот үзеңне, хикмәт менә шунда гына!..

Тышта кеше авазлары ишетелгәндәй була, хәлфә ашыгып чатырдан чыга. Чыкса, ни күрсен, биш-алты кеше, чатырга якынаерга курыккандай, бер читтәрәк таптанып торалар. Хәлфәне күрү белән аңа иелә-бөгелә сәлам бирәләр һәм без дә ишан хәзрәтнең догасын алырга килгән идек диләр. Хәлфә ялт итеп чатыр эченә керә дә Чикерткәгә: «Тагын бер төркем килгәннәр, төзек кенә утыр, хәзер

кертә башлыйм. Ә тәңкәләреңне яшер, соңыннан санап алырмын», дип әйтә. Шуннан кире чыгып, кәрван кешеләрен берәмләп кенә чатыр эченә уздыра башлый. Тегеләрнең һәркайсы керә дә лып итеп тезләнә, мүкәйләп кенә барып, ишанның мөбарәк кулына авызын тидереп ала, акчасын чыгарып сала һәм ишанга ияреп дога кыла да артын-артын гына ишеккә таба чигенә.

Шулай итеп, ул кичне кәрван озатучыларның барысы да килеп, ишанның догасын алып, кулын үбеп китәләр. Чикерткәнең киндердән махсус теккән чапан астындагы тирән кесәсенә алтын тәңкәләр шактый ук җыелып кала.

Бу «изге эшләрдән» котылгач та хәлфә, билгеле, ишан кесәсен бушатып, тәңкәләрне санап ала да үз сандыгына бикләп куя. Аннары таганда пешергән умачин кертә, икәүләп шуны тәмләп кенә ашыйлар, артыннан баллап чәй дә эчәләр. Шуннан соң «ишан хәзрәтләре» чалма-чапанын салып ташлый да, мендәрләре өстенә сузылып, утын ярып аргандай, гырылдап йоклап та китә.

Ләкин хәлфә тиз генә йокларга ятмый әле. Бер бәйләнчек уй аның башына кереп утыра. Кәрванчыларга ишанның берәр могҗизасын да күрсәтәсе иде бит — менә шул хакта һаман баш вата ул... Могҗиза кирәк, могҗиза күрсәтсә, ишанның даны әллә кайларга таралачак. Ләкин ничек итеп, нинди могҗиза табарга соң?

Ниһаять, бик еракка китеп кояш та бата, дала өстенә бик тиз караңгылык иңә, ә күктә, төнгелеккә бер җиргәрәк җыелган кыргыз малларыдай, бихисап йолдызлар калка. Ә ай юк, айның соңгы көннәре, тиз генә чыкмаячак, шуңа күрә төне дә дөм-караңгы.

Хәлфә, чатырдан чыгып, кәрван туктаган якка колак салып тора. Анда да тынлык, шылт иткән тавыш та юк — юлчылар ишанның хәер-фатихасын алганнан соң бик тынычлап йоклыйлар, күрәсең. Шулай да хәлфә ашыкмый, яртытөн җиткәнне көтә төшә, чөнки белә ул — бу вакытта кешеләрнең йокылары каты була.

Менә бер вакыт далада шундый тирән тынлык урнаша ки, әйтерсең дөнья яратылганнан бирле килә бу гаҗәеп, серле тынлык!.. Инде аллага тапшырып кузгалырга да ярый торгандыр... Хәлфә кәрван яткан күл буена сак кына төшеп китә. Аның күзләре, мәче күзе кебек, дөм-караңгыда да тирә-юньне аера ала. Бер дә адашмыйча кәрванчылар янына туры гына барып та җитә... Кәрван йоклый, тик җиргә чүккән дөяләрнең күшәве, атларның солы кетердәтүе генә ишетелеп куйгалый. Хәлфә башта туктап тирә-ягын бераз күзәтә, аннары мыштым гына шул дөяләр, атлар арасына керә. Әзрәк караштырып йөргәннән соң, ялгыз чатыр артына бәйләп куйган ике бик шәп, бик сылу атларны чишеп ала да әкрен-әкрен, сак-сак кына кәрван яткан җирдән чыгып китә. Төн, тынлык, сызылып кына йолдыз атылып китә, әмма кәрванчылардан селкенгән кеше дә булмый.

Хәлфә бары таң алдыннан гына үзләренең чатырына кайтып керә. Ул шунда ук «ишан хәзрәтләрен» төрткәләп уята.

— Әй, син, хәшәп, тор! Тор диләр сиңа!.. Арт саныңны онытып йоклыйсың да йоклыйсың... Килешми ул ишанга! Бар, әнә тышка чыгып кер дә, чалма-чапаныңны киеп, өстәлең янына утыр. Бик мөһим сүзем бар сиңа.

Чикерткә торып, хәлфәсе кушканча, тиз генә чатыр артына чыгып керә дә, чапанына чорналып, чалмасын башына батырып, тәбәнәк өстәл янына аякларын бөкләп утыра.

— Инде яхшылап тыңла! — ди хәлфә. — Тиздән кәрван хуҗалары сиңа китап ачтырырга килерләр. Бүген төнлә аларның ике шәп атларын урлап киткәннәр. Менә син аларга шул атларны «табып» бирерсең.

— Ничек итеп?

— Китап ачып дим ич, миңгерәү!.. Башта тыңла! — Һәм хәлфә атларның ни төстә булуын, кай тарафка китүләрен, моннан ничә чакрымда, нинди урында торуларын сөйләп бирә дә аннары әйтә:

— Менә шуларны онытмыйча, китапка карап сөйләрсең... Ягъни мәсәлән, хак тәгаләнең әшкәртүе буенча изге китап сиңа боларның барысын да ачып бирә, аңладыңмы?..

— Аңладым аңлавын да, тик ул атлар сез әйткән җирдә булмаса? Сез дә бит, хәлфә абзый, күрәзә түгел.

— Мин өйрәткәнчә эшлә син, хәшәп! Төпченмә! Ату кара аны, ишан дип тормам! Алланың үзенә якын торучы, надан халык белмәгән серләрне белүче, могҗизалар кәшеф итүче — менә кем син, сасык!.. Башкасы сиңа кирәкми... Әнә алдыңдагы кара тышлы китапны моталага кылып утырган бул, ә кәрван хуҗалары килгәч, яшел тышлысын ачарсың.

Чикерткәне шулай боргычлап өйрәткәннән соң хәлфә, чатырдан чыгып, кәрван ягын күзәтергә тотына. Кәрван халкы инде торган була, анда ниндидер хәрәкәт башлана, шаулашкан тавышлар да ишетелә. Озак та үтми, кәрваннан аерылып, өч кешенең чатырга таба килгәне дә күренә.

Хәлфә, чатырның ишек япмасын аз гына ача төшеп, Чикерткәгә хәбәр итә:

— Киләләр!.. Казык шикелле утырма, бөгелеп утыр!.. Күзең китапта булсын!

Ниһаять, тегеләр килеп җитәләр, кычкырып сәлам бирәләр — хәлфә дә тәгазим белән сәламнәрен ала. Шуннан арадан бер тазамәһабәте, шәп киенгәне, дәрәҗәсен төшермичә, әдәп белән генә әйтә:

— Әфәндем, без ишан хәзрәтләре хозурына килгән идек, аңа гозеребез бар, кабул итүен үтенсәгез иде.

— Белмим шул, — ди хәлфә, уйланган булып. — Ишан хәзрәтнең бүген кәефе юграк иде, шулай да үтенечегезне кереп әйтим. Сез, әфәнделәр, аз гына сабыр итегез!

— Мәйле! Без көтәрбез.

Хәлфә кереп, Чикерткәнең өс-башын, алдын-артын дигәндәй күздән кичергәннән соң, тора төшеп, кире чыга да:

— Мөбарәк зат сезне кабул итәргә булды, рәхим итәсез! — ди.

Кәрван хуҗалары, чатыр эченә узып, шунда ук тезләнәләр һәм башларын keләмгә тидереп алалар. Ишан хәзрәт, уйлары белән бу гөнаһлы җирне ташлап, каядыр гарешкә ашкандай тәмам онытылып — оеп утыра, керүчеләрне гүя сизми дә, тик бераздан гына иләмсез зур чалмасы астыннан боларга бер карап ала. Аннары һич сүз әйтмәстән, озын тәсбих элгән кулын күтәреп, озак кына дога кыла, бары шуннан соң гына телгә килә:

— Алла бәндәләре, йөзегездән күрәм, сезне ниндидер кайгы минем хозурыма китергән булырга тиеш. Сөйләгез! — ди.

— Хак сүз, тәкъсир! — ди кәрван хуҗасы, бөгелеп. — Бүген төнлә ике иң шәп атыбыз юкка чыкты. Явыз адәмнәр угрылап киткәндер дигән шигебез бар, сездән, тәкъсир, шул хакта китап ачуыгызны түбәнчелек белән сорамакчы идек.

— Хак тәгалә әшкәртсә, изге китап алдамас,— ди дә ишан, өелеп торган китаплар арасыннан бер яшел тышлысын тартып ала. Аннары, әгузе-бисмилласын әйтеп, урта бер җиреннән ача да авыз эченнән генә мөгрәнеп укырга тотына. Әзрәк укыгач, тегеләрдән сорый:

— Атыгызның берсе тимер күк, икенчесе кызыл туры идеме?

— Шулай, тәкъсир, бик дөрес, тимер күк белән кызыл туры? — диләр кәрванчылар өметләнеп.

Ишан хәзрәт тагын китапка бөгелә, озак кына селкенә-селкенә укый, тынып күзләрен йомып тора, аннары тагын укый, ахырдан әйтә боларга:

— Изге китап миңа шуны ачты: атларыгызны бер угры таң алдыннан урлап киткән, Әмма ләкин көн яктыра башлагач, далада тотылудан куркып, атларны бер сай чокырдагы ялгыз агачка бәйләп калдырган. Угрының нияте караңгы төшкәч, яңадан килеп алу булса кирәк... Әгәр дә хәзер генә эзләп барсагыз, атларыгызны мотлака шунда табарсыз.

— Кай тарафтарак соң ул сай чокыр, тәкъсир?

— Мәгъриб тарафында... Чыккан кояшка аркагыз белән торып туры гына барсагыз, чокырның нәкъ өстенә барып чыгарсыз.

— Еракмы соң ул чокыр, шуны да әйтсәгезче, тәкъсир!

Чикерткә, ишетмәгәнгә салышып, бераз уйга кала: нәрсә дип әйтте әле хәлфә абзый? Әллә сигез, әллә унсигез чакрым диде инде шунда, мөртәт?.. Хәер, кем үлчәгән аны? Җитәр, китсеннәр тизрәк!

Тамак кыргалаган була да әйтә тегеләргә:

— Хәерле сәфәр сезгә, мөсафирлар! Хак тәгалә башка бәла-казадан сакласын, амин!

— Рәхмәт, тәкъсир, бик зур рәхмәт!.. Шулай була гына күрсен!.. Тик без әлеге ни... чокыр турында...

— Кызу чапсагыз, тиз барып җитәрсез! — ди ишан шактый дорфа итеп һәм ашыгып тәсбихенең «хөрмәләрен» тарта башлый.

Тегеләр, бердән авып, маңгайларын келәмгә тидереп алалар, сузылышып ишан хәзрәтнең алдына алтын тәңкәләрен салалар, шуннан соң Чикерткәгә ияреп дога кылалар да бик мәмнүн кыяфәттә ашыга-ашыга кәрваннарына китеп баралар. Ә бераздан инде өч-дүрт җайдакның «мәгъриб тарафына» чаптырып киткәнен хәлфә дә, Чикерткә дә күреп калалар.

Атларны табып кайтканнан соң, кәрван шул ук көнне күл буеннан кузгалып, үз юлы белән китеп тә бара. Бер-бер артлы тезелешкән дөяләрнең ике яклап салындырган йөкләре белән чайкала-чайкала салмак кына атлап барулары тигез далада әле шактый озак күренеп тора.

... Атларны табып биргән «могҗизадан» соң, калкулык өстендәге чатыр эчендә утырган яшь «ишан хәзрәтнең» даны бик тиз тирәякка тарала: менә кайда икән ул изге зат!.. Менә кемдә икән ул хикмәт!.. Вай-вай-вай!.. Аның өчен яшерен бер нәрсә дә юк икән ләбаса!.. Алла тәгалә үзе аңа барсын да әшкәртеп кенә тора икән шул!

Хәзер инде күл буеннан узучы кәрваннар чатыр турысына җиткәч туктамыйча калмыйлар. Мал хуҗалары, ялчылар, кәрван озатучылар һәммәсе тезелешеп калкулыкка менәләр, берәмләп кенә чатыр эченә кереп, лып итеп тезләнәләр, мүкәйләп барып, Чикерткәнең «мөбарәк» кулын үбәләр, учларындагы алтын яки көмеш тәңкәләрен тәбәнәк өстәлгә салалар. Ишанның, бөгелеп утыра торгач, авыр чалмадан нечкә муены арып бетә, дога кыла-кыла авызы кибә, куллары тала. Вакыт-вакыт аның хәтта сикереп торасы, тәбәнәк өстәлне тибеп очырасы, чалмасын сүтеп ыргытасы, ә бу «аңгыра сарыкларны» выжлатып куып чыгарасы да килеп китә. Әмма... хәлфә уяу, хәлфәнең күмердәй кара мут күзләре көйдереп алырга гына тора.

Ә көннәрдән бер көнне күл буена баштанаяк коралланган бишалты җайдак килеп чыга. Калкулык өстендәге чатырны күрү белән атларын тизрәк шунда таба боралар. Бу вакытта хәлфә тышта була. Чаптырып килгән кораллы кешеләрне күреп, ул «талаучылар

түгелме икән?» дип шактый шүрләп тә кала. Ләкин килеп җиткән җайдаклардан берсенең бик зиннәтле киемнәрдән булуын күргәч кенә азрак тынычлана.

Җайдакларның әнә шул шәп киенгәне ат өстеннән төшмичә генә сәлам бирә, хәлфә исә кул кушырып аның сәламен ала.

— Әйтегезче, изге ишанның чатыры шушы буламы? — дип сорый сәлам бирүче.

— Ийе, ишан хәзрәтләренең изге гыйбадәт урыны шушы була, — ди хәлфә. — Кем дип белик сезне, хөрмәтле юлчылар, кайсы илләрдән киләсез?

— Без фәлән патшалыктан илчеләр булып килдек, — ди юлчы. — Безгә ишан хәзрәтләренең үзен күрү кирәк, хозурына керергә рөхсәт итегез.

— Гозерегез ни соң? — дип сорый хәлфә сак кына.

— Без олуг падишамызның сәламен ишан хәзрәтләренә тапшырырга һәм мөбарәк затны үземез белән алып китәргә тиешмез.

— Алай икән, — ди хәлфә уйланып. — Ни өчен мөбарәк затны урыныннан кузгатырга телисез, әгәр белергә мөмкин булса?

— Падишамызның әмере шулай... Хафа булмагыз, ишан хәзрәтләренең иминлеген саклаячакмыз, ә барып җиткәч сарайда аңа тиешле кадер-хөрмәт күрсәтеләчәк.

— Яхшы, алайса, мин кереп ишан хәзрәтләренә бу мөһим хәбәрне җиткерим. Соңра сезне чакырырмын. Моңа кәефегез кырылмасын, чөнки ишан хәзрәтләре һәрдаим изге гыйбадәттә утыра һәм алдан хәбәр итмичә һичбер кемсәне кабул итми.

Шулай ди дә хәлфә, илчегә түбәнчелек белән баш иеп, чатыр эченә кереп китә. Кергәч, Чикерткә янына тезләнеп, аның колагына шыпырт кына әйтә:

— Бәхетең бар икән, шәкерт!.. Ерак патшалыктан сине алып китәр өчен илчеләр килде.

— Нинди, кайсы патшалыктан? — ди Чикерткә сискәнеп.— Юк, мин беркая да бармыйм, минем үзебезнең Тәпәрешкә кайтасым килә.

Ул инде кайнар яшьләрен агызып елый да башлый. Хәлфәнең моңа бик тә ачуы килә:

— Бу ниткән эш тагын?!. Син хәсискә патша кадәр патшадан махсус илчеләр чакыра килгәндә, бармыйм дип, авызыңны бияләйдәй җәеп шыңшып-елап торасың. Юк, барырсың!.. Хәерче татар авылына кайтырга кайчан да өлгерербез... Бел аны, бу чакыру тикмәгә генә түгел, димәк, син сасыкның даны чит мәмләкәткә дә барып җиткән дигән сүз. Ходай кушып, патшаның да ышанычын казана алсак, беләсеңме, муенныбыздан дәүләткә батачакбыз... Я җитәр! Яшьләреңне сөрт, борыныңны тартма!.. Хәзер илчене кертәм. Төзек кенә утыр. Ишанча... Күп сөйләмә, җавабыңны уйлап кына бир... Падишаһе әгъзам хәзрәтләренең чакыруын кире кага алмыйм диген... Менә шул... Кара аны!..

Хәлфә Чикерткәнең чалмасын төзәтеп, тәсбихен кулына тоттыра да ашыгып чыгып китә.

Ул да булмый, чатырга зиннәтле киемнәре өстеннән кәкре кылыч таккан илче кыю гына килеп керә. Сәлам бирә, туп-туры ишан алдына барып тезләнә, кул күтәреп бер дога кылалар. Шуннан соң илче, вәкарьлеген саклаган хәлдә, үзенең кайсы илдән, кем булуын әйтеп, патша хәзрәтләренең сәламен тапшырып, нинди максат белән килүен аңлатып бирә. Бик йончыган кыяфәттә бөрешеп кенә утырган «ишан» әкрен-сүлпән генә:

— Падишагыз хәзрәтләренә безгә күрсәткән игътибары өчен рәхмәт инде, — ди, — аллаһе тәгалә үзенә һәм дәүләтенә иминлек

китерсен, амин!.. Әмма аның безләргә гозере нидән гыйбарәт соң?

— Падишамыз хәзрәтләре хозурына баргач, ул үзе сезгә гозерен бәян кылыр, — ди илче, — безләргә исә сезне алып килү вазифасы гына йөкләтелде.

Ишан хәзрәтләре башын иеп, тәсбихен тартып, озак кына уйланып утыра, тик шуннан соң гына болай дип җавап бирә:

— Мин фани дөнья ыгы-зыгысыннан, ахирәтен оныткан бәндәләрдән читкә китеп, бары изге гыйбадәттә утыручы алланың бер зәгыйфь колымын, бер нинди сәбәп белән дә мин бу... ни... мәҗбүрән эшемне бүлмәс идем, әмма ерак җирдән махсус кешеләр җибәреп, безгә тәгазим күрсәткән, безне үзенең солтанатлы хозурына чакырган падишаһе әгъзам хәзрәтләренең үтенечен кире кагарга җөрьәт итә алмыйм. Әлхасил, кадерле илче, мин аллага тапшырып сезнең белән озын сәфәргә чыгарга ризалыгымны белдерәм. Инде, бер фатиха кылып, мөридемә тиешле боерыкларны бирергә рөхсәт итегез!..

Сүзен шулай тәмам иткәннән соң, ишан хәзрәтләре кулын күтәреп, күзләрен йомган килеш, озын итеп бер дога кыла. Илче дә, ишан хәзрәтне күндерүеннән бик канәгать булып, аңа ияреп дога кыла да, алдына бер янчык алтын тәңкәләр куеп, чатырдан чыгып китә.

Шунда ук ялт итеп хәлфә керә:

— Я, ничек булды?

— Булды инде, сез әйткәнчә булды, хәлфә абзый! — ди Чикерткә боек кына.

— Менә бик әйбәт, муладис!.. Җыендык, алайса! Ай-һай, мин әйтәм, эшләр кая китте — патша хозурына барабыз гой!

Тиз генә чатырны сүтәләр, әләмне таягына урыйлар, калын китапларны өеп бәйлиләр, шуннан соң барлык әйберләрен, мендәрюрганнарын тарантаска чыгарып төйиләр дә, атларын җигеп, әлеге җайдакларга ияреп, озын юлга чыгып та китәләр. Чикерткә өчен бу озын юлның газабы шунда иде ки, ул тарантас өстендә барганда да үзенең изге ишан икәнен бер генә минутка да онытмаска тиеш иде. Шуңа күрә еш кына атларны туктатып, су булган җирдә тәһарәт алып, су булмаган җирдә тәямим генә сугып, биш вакыт намазын калдырмыйча укып барырга мәҗбүр була. Шуның аркасында юл да озаккарак сузыла.

Чиксез даланы, даладан соң галәмәт эссе ком чүлен үтеп, болар сигезенче көн дигәндә, ниһаять, ерак патшалыкның пайтәхетенә барып җитәләр. Биек капусыннан керәләр, кәкре-бөкре урамнарыннан узып, чылтырап арыклар аккан бакча эчендәге әллә ни зур да түгел, әмма бик чибәр салынган бер өйнең ишеге төбенә килеп туктыйлар. Бу патша боерыгы белән ишан хәзрәтләре өчен махсус әзерләп куелган өй була.

Чикерткәне тарантастан култыклап кына төшерәләр һәм кыйммәтле келәмнәр, алтын кәндилләр белән зиннәтләнгән шул өй эченә алып керәләр. Монда аны атлас-ефәкләрдән генә киенгән яшь кенә егет-хадимнәр каршы алалар.

Алып кайткан илче ишан хәзрәткә әйтә:

— Тәкъсир, сез инде бүген шушында тәгам җыеп, авыр, озын юлдан соң әйбәт кенә истирахәт итегез... Падишаһ хәзрәтләре үз вакыты белән сезне хозурына чакыртып алыр, — ди.

Ул чыгып киткәч тә чибәр егетләр идәндәге келәмгә табын җәеп, төрле кош итләреннән кыздырылган кәбаблар, алтын-көмеш тәлинкәләрдә әлвән вә әлвән җимешләр, озын муенлы көмеш савытларда затлы шәрабләр һәм зур табак белән бик әгъла пешерелгән пылау

кертеп куялар. Чикерткә белән хәлфә бу сый-нигъмәтләргә исләре китсә дә, тыштан артык сиздермичә, ефәк мендәрләр өстенә утырып, җиңнәрен сызганып, иң элек әгъла пылауны куллары белән ашыкмыйча гына ура башлыйлар. Алар бүре шикелле ачыкканнар иде. Шулай да Чикерткә тыелып кына ашарга мәҗбүр, чөнки ул изге зат, тамак колы булу аңа ярамый — тәнендә җан сакларлык кына ашарга тиеш ул. Ә хәлфәгә ярый, хәлфә ул гөнаһлы бәндә, шуңа күрә олы табак пылауны берүзе диярлек ялтыратып та куя.

Пылаудан соң Чикерткә ширбәт, хәлфә шәраб эчкәләп, җимешләрнең төрлесеннән капкалап бераз хушлангач, теге хадимнәр табынны җыеп алалар да боларның икесен генә калдырып чыгып китәләр.

Икәү генә калгач, мендәрләренә таянып, корсакларын угалап бераз ятканнан соң хәлфә сүз башлый:

— Хуш, шәкерт, менә төшеңә дә кермәгән оҗмах нигъмәтләреннән авыз иттең... Менә ефәк мендәрләр өстендә шәһвәткә бирелеп ятасың... Бу бит синең башыңдагы егерме аршин бәздән ураган чалмаң өчен генә булмаска тиеш... Патша хәзрәтләре, мөгаен, сиңа бирәр бик четерекле мәсьәлә йөкләр һәм шуны чишүне таләп итәр. Я, шул чакта син ни эшләрсең, ни диеп җавап бирерсең, хәлбуки, янында акыл бирергә мин дә булмасам?..

— Белмим инде, хәлфә абзый!..

— «Белмим» — сүз түгел!.. Патшаның гозерен җавапсыз калдырырга һич тә ярамый, бел шуны!

— Ярамаса да нишлим соң? Җавап таба алмасам, патша хәзрәтләре, мин ишан түгел, диярмен.

— Әх, син, туң күчән, иштең ишәк чумарын! — дип кызып китә хәлфә. — Алай дисәң бит, сине шунда ук сарайдан чыгарып, беренче очраган тут агачына асып куячаклар... Юк, син ашыкмәле сыйракларыңны сузарга, аның өчен генә килмәдек әле без чүлләр кичеп, мин барын да онытма әле син, хәшәп!.. Ике колагың белән дә яхшылап тыңла: патша өчен дә син изге ишан булып каласың! Синең эшең корьән сүзләрен тезү, кул күтәреп дога кылу, фатиханы бирү — бары шул гына... Инде патша хәзрәтләре сиңа бирәр төрле чи төенне чишәргә кушса, түбәнчелек белән иплән кенә әйт: олуг падишам, диген, сезнең әмерегезне үтәр өчен без кайтып, изге китапны ачып карарга тиешбез, диген. Аңладыңмы? Бөтен нәрсәне изге китапка сылта... Ә монда кайткач, без инде икәүләп, менә шулай кырын ятып кына мәслихәтләшербез һәм, иншалла, патша биргән төенне дә чишәрбез. Моңарчы эшли белгән баш бу юлы да берәр әмәлен табар әле, боерган булса!

Шул арада ишек шакып, рөхсәт сорап кына әлеге илче дә килеп керә. Баш иеп сәлам биргәннән соң, ул ишан хәзрәтләрен патша сараена алып китәр өчен килгәнлеген белдерә. Чикерткәнең йөрәге жу-у итеп китә. Әмма хәлфә тыныч. Мөридләрчә өлгерлек белән ул Чикерткәне утырган җиреннән иплән кенә торгыза, өстенә озын чапанын кидерә, кулына тәсбихен тоттыра да култыклап кына урамга алып чыга. Чыгышлый колагына пышылдап кына: «Матри, нык бул, җебеп калма!» — дип әйтергә дә өлгерә.

Урамга чыккач, ишан хәзрәтләрен көмеш иярле, көмеш йөгәнле, муенына алтын шөлдерек таккан кечкенә ишәк өстенә күтәреп атландыралар. Шул рәвешчә, ике яклап атлы сакчылар озата барган хәлдә, аны сарайга алып та китәләр. Бу өйдә хәлфә үзе генә торып кала.

Барып җиткәч, ишанны, ишәк өстеннән төшереп, ике ягыннан култыклап, сарайның чит ил кунакларын гына кабул итә торган гаять тә бай, зиннәтле бер залына алып керәләр. Яшел бәрхет белән

тышланган, атлас мендәрле йомшак кәрсигә китереп утырталар. Шунда ук залның ике ягындагы ишектән патшаның вәзирләре һәм иң олы түрәләре кереп, үзләренә тәгаенләнгән урыннарга дәрәҗәләре буенча урнашалар. Озак та үтми, каяндыр быргылар уйнаткан тавыш ишетелә — залдагы кешеләр барысы да берьюлы аягүрә катып, бер мәлгә тып-тын булып калалар. Тик Чикерткә генә йомшак кәрсигә тәмам баткандай кузгалмыйча утырып кала. Менә бер заман түрдәге сырлап эшләнгән, алтын йөгерткән зур ишек гүя үзлегеннән тавышсыз гына ике якка ачыла һәм залга, өстендәге чапаны, башындагы таҗы белән елык-елык уйнаклап, патша хәзрәтләре үзе дә ап-ак сакаллы баш вәзирен ияртеп килеп керә. Зал уртасындагы атлас чатырлы алтын тәхетенә ашыкмыйча гына барып утыра. Шунда ук тәхетнең ике ягына гөрзиле сакчылар килеп баса.

Патша хәзрәтләре утыру белән башкалар да янәдән үз урыннарына утырышалар. Шуннан соң ишан хәзрәтләре тәсбих элгән кулын күтәреп, селкенә биреп, бик озын итеп дога кыла. Аның артыннан патша үзе дә, патшаның вәзирләре дә битләрен сыпырып куялар. Дога тәмам булгач, патша хәзрәтләре ишан хәзрәтләреннән исәнлек-саулыгын, озын сәфәрне ничегрәк кичерүен йомшак кына сораша, чакыруны кабул итеп, хозурына килүе өчен рәхмәтен белдерә һәм ахырдан нинди максат белән чакыртуын болай дип әйтеп бирә:

— Бәлки ишеткәнсездер дә инде, тәкъсир, билгесез угрылар сараема кереп, хәзинәмнән күп кенә асыл ташларымны, алтыннарымны урлап чыктылар. Шулар белән бергә атамнан мирас булып калган, минем өчен аеруча кадерле булган бер алтын балдак та югалды. Тирә әтрафтагы мәшһүр фалчыларны чакыртып, угрыларны фаш итүләрен сорасам да, алар миңа ярдәм итә алмадылар. Инде сезнең халык арасында даны таралган могҗизалар күрсәтүче бер изге зат булуыгызны ишеткәч, ниһаять, менә сезне үз хозурыма чакыртып алдым. Әгәр дә ки, ишеткәнемчә, сезнең шундый зат булуыгыз хак икән, сез миңа угрыларны һичшиксез фаш итеп бирерсез дип ышанам. Ул чагында мин сезне мәмләкәтемнең баш вәзире итеп куячакмын. Менә шулай... Инде дә мәгәр сез халыкны алдап йөрүче бер надан, ялган ишан булсагыз, бүтән чара юк, миңа сезнең мут, хәйләкәр башыгызны халык җыелган мәйданда чаптырырга туры киләчәк. Сезгә бу шаять аңлашыла торгандыр, тәкъсир?

— Әйе, аңлашыла,— ди Чикерткә әкрен генә.

Патша хәзрәтләренең сүзне бик мөлаем-йомшак башлап та, бу кадәр каты-куркыныч итеп бетерүе, әйтәсе дә түгел, Чикерткәне бик нык куркуга сала. «Бетте баш!» дип уйлый ул шунда ук эченнән, сикереп торып ишеккә дә ташланасы килә, әмма ләкин хәлфәнең биргән киңәшләрен исендә тотып, ничек кенә булса да сабырлыгын җуймаска тырыша. Патшаның сүзләренә артык исе китмәгәндәй тәсбихен тартып, фани дөнья уйларыннан киткәндәй күзләрен йомып, озак кына өнсез-сүзсез утыра. Бары шуннан соң гына ашыкмыйча тыныч кына әйтә:

— Олуг падишаһ, безгә күрсәткән игътибарыгыз вә мәрхәмәтегез өчен тәшәккердән гаҗизмен, әмма ләкин әйтергә тиешмен ки, мин күрәзәче дә, фал салучы да түгелмен. Мин гомеремне гыйбадәткә багышлаган тәңренең бер зәгыйфь колымын, хак тәгалә күңелемә ни салса, мин бары шуны гына изһар итә алам. Моның өчен миңа шәһәр ыгы-зыгысыннан китеп, этәч тавышы да ишетелми торган берәр аулак урында изге китап ачып карашым кирәк. Шул сәбәпле мин сез галиҗәнабтән без фәкыйрегезне әнә шундый аулак урынга күчерүегезне һәм өч көн мөддәт бирүегезне баш иеп сорыймын.

Иншалла, өч көн дәвамында хак тәгалә изге китап аша миңа ни дә булса әшкәртер дип ышанам.

Билгеле, Чикерткә мондый шартны аулак җирдән качып китеп булмасмы дигән бер өмет белән дә куя. Патша аның үтенечен кабул итә һәм вәзирләренә каладан читтә этәч тавышы да ишетелми торган берәр өй табып, хәзрәтне мөриде белән бергә шунда күчерергә куша.

Өй табыла, боларны шунда күчереп куялар. Бик мул итеп, өч көнгә җитәрлек азык-төлеген дә биреп калдыралар. Тик хадимнәр генә булмый, чөнки ишан хәзрәтләре аллаһе тәгалә белән аулакта ялгызы гына гәп алып барыр өчен хадимнәрдән баш тарта.

Икәү генә калгач, болар патшаның таләбен ничек итеп үтәү турында баш вата башлыйлар. Сарайдан алтыннарны чәлдергән ул мәлгунь каракларны кайдан табарга?.. Чикерткәгә бу эш бөтенләй өметсез булып күренә — мәшһүр фалчылар да фаш итә алмаган ич аларны! Хәер, ул башын артык ватмый да, чөнки өч көннән соң барыбер газиз башкайдан аерылырга туры киләчәк. Әнә хәлфә ватсын, баш аңа кирәгрәк, ник дисәң, аның мәдрәсә сандыгы Чикерткә җыеп биргән алтын тәңкәләр белән тула язды инде.

Ә хәлфә чынлап та уйлана, ашау-эчүен дә онытып уйлана. Башымны чабарлар дип тә курыкмый ул (аныкын түгел, ишанныкын тәгәрәтәчәкләр ич!), әмма ләкин шул «ишан» аркасында патшаның ышанычына кереп, сарай кешесе булып киту хыялы аңа бер генә дә тынгылык бирми... Моның өчен күп тә кирәкми ләса — каядыр посып яткан угрыларны фаш кына итәсе... Ахыр чиктә, түбәтәен бер салып, бер киеп уйлана торгач, хәлфә абзаң тәки хәйләсен таба. Ул тота да Чикерткәдән түбәндәге игъланны яздыра: «Падишаһигъзам хәзрәтләренең чакыруы буенча пайтәхеткә үзенең изгелеге вә күрәзәлеге белән бөтен мәшрикъка даны таралган ишан хәзрәтләре килде. Килүеннән максат шул ки, ишан хәзрәтләре, изге китап ачып, падишаһ хәзинәсен баскан угрыларны фаш итәчәк. Әгәр дә мәгәр угры үзе үз ихтыяры илән урлаган алтыннарын вә һәм падишаһ хәзрәтләренең атасыннан мирас булып калган мөһерле балдагын китерсә, ишан хәзрәтләре аның җанын саклап калуны өстенә алачак. Инде дә ки китермәсә, угры барыбер тотылачак һәм иң каты җәзага хөкем ителәчәк. Килү мөддәте ошбу игълан хәбәр ителгән көннең икенче тәүлегеннән дә соңга калмаска тиештер. И угры, изге ишан хозурына килеп, тез чүгәргә ашыгың!.. Ул сине мәрхәмәтеннән ташламас».

Игъланны тагын берничә нөсхә күчерткәннән соң, хәлфә, Чикерткәне ялгызын гына калдырып, үзе каланың базар мәйданнарына йөгерә-чаба диярлек китеп бара. Мәгълүм ки, бу илнең тәртибе буенча, мәйданнарда быргылар уйнатып җыйган халыкка патша фәрманын яки төрле мөһим хәбәрләрне кычкырып әйтүче көр тавышлы махсус адәмнәр була — хәлфәнең исәбе менә шул хәбәр салучылардан әлеге игъланны укыту иде. Һәм ул шулай эшли дә — зур каланың барлык мәйданнарында булып, үзенең игъланын халыкка кычкырып укыта.

Шул рәвешчә эшен бетереп, хәлфә, шактый арыган булуына да карамастан, кала читендәге аулак өйгә күтәренке кәеф белән кайтып керә. Ә Чикерткә нарасый баладай борынын әкрен генә сызгыртып йоклап ята. Хәлфә аны тибеп уята:

— Бу ниткән эш? Мин эт шикелле телемне салындырып чабам, ә син тук мачы кебек бөгәрләнәсең дә йоклыйсың! Тәмам аздың, малай!

— Хәсрәттән, хәлфә абзый, ачуланма, — ди Чикерткә, күзләрен уып.

— Нинди хәсрәттән?..

— Бетә бит, китә бит инде баш!.. Шуны онытып торсын дип яткан идем.

— Юк, син ашыкмәле башыңнан аерылырга! Ахмаграк булса да торсын әле ул үз урынында... Ни өчен чабам соң мин бу каланың кәкре-бөкре урамнарыннан? Менә быргылар уйнатылды, игъланны кычкырып укыдылар, мондагы такыр башларның колагына керде инде ул... Иншалла, моның бер нәтиҗәсе булмыйча калмас... Минем исәбемчә, карак та берәү генә булмас, икәү яки өчәү булырга тиеш алар... Игъланны ишеткәч, өчәүнең берсе килер, килмичә калмас... Беләм мин адәм баласын, иптәшен сатып булса да башын сакларга тырыша ул!..

— Ай-һай, хәлфә абзый, башы өчен курыккан кеше патша хәзинәсен басармы икән? Булмас, — ди Чикерткә сүлпән генә.

— Ни беләсең син, мәдрәсә чыпчыгы? Урлаганда бар да батыр, ә тотыла башлагач, һәркайсы шыр җибәрә. Батырлык белән куркаклык кешенең йөрәгендә гел алмашынып тора ул, тәкъсир! Менә көтеп карыйк, ут яктысына килгән күбәләк кебек берәрсе килмәсә, патша кызы миңа харам булсын!

Хәлфәнең бу гаҗәеп күрәзәлеге шул ук кичне раслана да. Иң әлек караклар чынлап та өчәү булып чыга. Билгеле, ишан хәзрәтләренең игъланын алар да ишетәләр һәм, билгеле инде, бу хәбәр аларны шактый хәвефкә сала. Үзара киңәш коралар: нишләргә? Малмы, башмы? Бер куркаграгы әйтә, алтыннарын ишан хәзрәткә тизрәк илтеп бирик, ди. Икенчесе — хәйләкәррәге — ашыкмаска куша: иң әлек белик, нинди ишан икән ул, ди. Китап ачып фаш итәм дигән. Ничегрәк итеп, кайсы битеннән ачып фаш итмәкче була ул безне, башта шуны күрәсе иде, ди. Ахырда өченче бер тәвәккәллесе төнлә ишан торган йортка барып, читтән генә хәзрәтне күзәтеп кайтмакчы була.

Базарлар таралып, кибетләр һәм кәрханәләр ябылып беткәч, шәһәр дә әкренләп тынгач, ишан йортын эзләп китә угры. Бара-бара, ниһаять, кала читендәге ялгыз йортны барып таба. Дөнья тын, төн караңгы, тик ишан тәрәзәсендә генә ут яна. Угры бик саклык белән, диварга елышып кына шул бердәнбер якты тәрәзәгә килә.

Ә бу вакытта хәлфә белән Чикерткә дә йоклап ятмыйлар. Берсе ишек төбендә, икенчесе бүлмәдә төнге кунакны көтәләр.

Угры диварга сылашып, бүлмә эченә үрелеп кенә карый һәм күрә: бүлмә уртасындагы тәбәнәк өстәл янында чалма-чапан кигән берәү әкрен генә селкенә-селкенә калын китап укып утыра. Ишан хәзрәтләре шушы үзе микәнни инде? Нәкъ шул чакта ишек артыннан хәлфә бер генә тапкыр «эһ-һем» дип тамак кырып куя, ләкин угры моны ишетми. Ә ишан хәзрәт китабыннан башын күтәрмичә нидер мыгырдана башлый, аннары кинәт кенә сикереп тора да: «Берсе килде, берсе килде!» — дип кычкырырга тотына.

Угры, моны ишетеп, бөтенләй коелып төшә: «Килгәнемне белде, китабына карап белде! Чукынган да ишан икән!» Ул шунда ук тәрәзә яныннан сыза. Ашыга-ашыга иптәшләре янына кайта да ишеткән-күргәннәрен түкми-чәчми аларга сөйләп бирә. Өч угрының икесе күп уйлап тормыйча, болай булгач, алтыннарны тизрәк илтергә кирәк, барыбер ул безне фаш итәчәк, диләр. Ләкин әлеге хәйләкәре, юк, ашыкмыйк, тагын бер сынап карыйк әле, ди. Ничек итепме?.. Менә икәү барып карыйк, икәүләп килгәнебезне белерме-юкмы?..

Шулай килешеп, угрыларның икесе яңадан ишан йортына китәләр. Барып җитәләр. Ишан тәрәзәсендә ут яна, ә үзе тәбәнәк өстәл янында һаман китабына төртелеп утыра. Бу юлы инде хәлфә ишек артыннан ике тапкыр әкрен генә тамак кырып куя. Угрылар исә тә-

рәзәнең ике ягына ышыкланып, ни булыр икән дип, тын да чыгармыйча карап торалар. Ишан хәзрәт, селкенә-селкенә бераз укыгач, шашынган шикелле кинәт кенә сикереп тора да, кул-аякларын болгап: «Икесе килде! Ике-сее!» — дип, бик яман акыра башлый... Угрылар тәрәзә яныннан җил өргәндәй юк булалар. Шактый чапканнан соң болар туктап, үзара сөйләшеп алалар:

— Алай, эш харап икән, ул тилергән ишаннан котылып булмас, хәзер үк патшаның алтыннарын китереп бирергә кирәк, баш кадерлерәк! — диләр.

Әмма кайтып җиткәч, теге хәйләкәр комсызы тагын әйтә: «Нигә алтынннарны илтергә, алтыннар калып торсын, балдакны гына илтик, патшага атасының балдагы кадерлерәк дигән ич ишан үзенең безгә язган хитабында», — ди.

Үзара озак кына тарткалашканнан соң, ахырда балдакны гына илтергә булалар. Бу юлы да ишанны сынап карыйсылары килә — алтыннарны таптырырмы, юкмы ул?

Шул ук төнне өчәүләшеп тагын ишан йортына китәләр. Ә тәрәзәдә һаман ут яна... Килеп җитүләре була, ишан хәзрәт бүлмәсендә котырына да башлый: «Өчесе дә килде. Өчесе дә, өчесе дә!..» Ул хәтта кызып китеп, киң ыштан балакларын җилфердәтә-җилфердәтә, чатлы-ботлы биергә дә тотына... Угрылар тәрәзәдән генә балдакны бүлмә уртасына ташлыйлар да үзләре, тасыр-тосыр чабып, төн эчендә эреп тә югалалар.

Шунда ук тыштан күзләрен елтыратып хәлфә килеп керә:

— Я ничек?

Чикерткә учына йомган балдакны ачып күрсәтә:

— Менә... ташлап киттеләр.

— Шәп, бик шәп! — ди хәлфә, кулларын угалап.

— Ә алтыннарны китермәгәннәр, — ди Чикерткә нәүмизләнеп.

— Алтыннарына төкер! Безгә бусы да җиткән.

— Ә патша таптырса?

— Таптырмас, патшаның болай да алтыны күп... Кая, бир әле монда балдакны. Ай-һай, авыр да икән соң, ләгънәт, ничә мыскал булыр бу?!

Ә Чикерткәнең һаман үз кайгысы:

— Угрыларны фаш итеп булмады бит, хәлфә абзый, патша хозурына баргач, мин нәрсә дип әйтермен?

— Я, җыларга тормале, чебеш!.. Мин барын онытма! Патша хәзрәтләрен шаккаттырачаксың әле син бу балдак белән!

— Ничек итеп?

— Анысын иртәгә белерсең... Ә хәзер сөтләп, йөземләп бер чәйләп җибәрик булмаса!

Төн уза, таң ата, Чикерткә ефәк юрган астында йоклап кала, ә хәлфә, балдакны эләктереп, иртән иртүк патша сараена китеп бара. Сарайның бик зур бакчасы була. Бакчада гаҗәеп агачлар, гаҗәеп гөлләр үсә, түгәрәк күлләр елтырап ята, чылтыр-чылтыр чишмәләр агып тора. Һәм шулай ук анда нинди генә кошлар да булмый!.. Баш бармак хәтлесеннән алып, бозау чаклысына кадәр!.. Аларның сайравыннан, кычкыруыннан бөтен бакча гөж килеп тора. Әмма ничек керергә соң бу җәннәттәй бакчага? Хәлфә биек диварлар буйлап йөри-йөри, ләкин бер дә керерлек тишек таба алмый. Ахырда йөри торгач, дивар астыннан агып чыккан бер арыкка туры килә. Күп уйлап тормыйча сикереп төшә дә, каты агымны ера-ера, дивар астыннан бакчага кереп тә китә. Кергәч, арыктан чыгып, чабуларын сыгып, бер юан агач артына ышыклана да бакчадагы кошларны күзәтә башлый. Күлдә йөзгән кошлар аңа кирәкми, җирдә йөргәннәре генә кирәк — аларның да тик иң зурлары гына...

Ахырда аның алдына салмак кына атлап берничә тәвә кошы килеп чыга. Арада берсе, шәрә башлысы, аеруча зур-таза була. Хәлфә теге балдакны кесәсеннән тиз генә чыгарып ипи йомшагына әйбәтләп төрә дә, тәвә кошының алдына иплән кенә ыргыта. Тәвә кошы аны шунда ук йотып та җибәрә. Хәлфәгә шул гына кирәк тә иде. Яңадан арыкка төшеп, бата-чума дивар астыннан чыга да уңга-сулга карамыйча өенә сыптыра.

Ә бу вакытта Чикерткә: «Тагын кая китеп олакты бу хәлфә абзый?» — дип, бүлмәсендә боегып утыра. Әллә ташлап качтымы дип бик борчылып, куркып та куя. Алай дисәң, тәңкә тулы сандыгы менә монда, мендәр астында гына... Алтыннарны ташлап качмас ул кеше!

Чынлап та, бераздан хәлфә үзе дә тирләп-пешеп кайтып керә. Керүе белән үк сорый:

— Сарайдан килмәделәрме әле?

— Юк, күренмиләр...

— Шөкер алайса, кайтып җиттем... Тиздән килерләр, әзер булып тор!

— Мин әзер, тик син генә әллә кайда йөрисең? — ди Чикерткә, үпкәсен белдереп.

— Синең башыңны саклап калыр өчен йөрим, сасык! Бүген патша хозурында җавап тотасың бар, белеп тор!

— Беләм. Тик син миңа балдакны биреп куй.

— Балдак юк.

— Ничек юк? — ди Чикерткә, коты алынып.

— Мин ул балдакны, — ди хәлфә, кара сакалын учлап, — аллага тапшырып, тәвә кошына йоттырдым.

— Алдыйсың, алдыйсың, — ди Чикерткә үрсәләнеп. — Яшергәнсең, үзеңә алып калмакчы буласың...

— Үкермә, хәсис!.. Могҗиза бу, аңлыйсыңмы? Изге ишан могҗизасы!.. Балдакны патшага чыгарып тоттырмыйсың, ә изге китап сүзе белән әйтеп бирәсең: атагыздан калган мөһерле балдак тәвә кошының карынында, дисең... Төшендеңме инде?

— Ниткән тәвә кошы, кайда соң ул?

— Патшаның сарай бакчасында. Син, Чикерткә, шуны гына бел: балдак кош карынында, вәссәләм!..

— Ә ышанмасалар?

— Ышанмасалар — суеп карарлар. Тик шуны онытма: тәвә кошлары анда берничәү... Шәрә башлысында диген, ягъни мәсәлән, таз башлысында, аңладыңмы?

— Аңладым, — диде Чикерткә мөгрәнеп кенә.

Ә бераздан ишан хәзрәтләрен алып китәр өчен сарай атлары җигелгән зиннәтле фаэтон килеп тә җитә. Чалма-чапаннарын киеп, әзерләнеп торган ишан хәзрәтләре яцел таягын алып, фаэтонга ашыкмыйча гына чыгып утыра. «Хуш, хәлфә абзый, күрешмәсәк, бәхил бул!» — ди Чикерткә, чак еламыйча. «Һи, шәкерт, — ди хәлфә, кәефлә генә елмаеп, — бу фаэтон мине дә алырга киләчәк әле, кайгырма!»

Атлар кузгалалар һәм Чикерткәне тибрәндереп кенә алып та китәләр.

Ә бу вакытта патша хәзрәтләре үз тирәсенә бөтен вәзирләрен җыеп, тәхетендә ишанны көтеп утыра. Менә бер заман ишек ачыла һәм ике сарай хадиме ишан хәзрәтләрен ике ягыннан култыклап, патша хозурына алып керәләр. Тәхет каршына китереп, кыйммәтле келәм каплаган бер калкурак урынга үзен иплән кенә утырталар. Ишан хәзрәтләре башта озак кына итеп дога кыла. Башкалар да аңа ияралар. Шуннан соң патша хәзрәтләре ишан хәзрәтләренә әйтә:

— Тәкъсир, сезгә бирелгән өч көн мөддәт үтеп китте. Шушы вакыт эчендә сез изге китап ачып, минем хәзинәмне талаучыларны фаш итәргә тиеш идегез. Шартын беләсез: я үлем җәзасы, я вәзирлек вазифасы!.. Я, ни әйтәсез?

Чикерткә җавап бирергә ашыкмый, күпмедер вакыт патшаның үзен дә, сүзен дә оныткандай күзләрен йомып, тәсбихен тартып утыра. Аннары кинәт кенә уянгандай башын күтәреп, патшага туптуры карый да һич каушау сиздермичә, тыныч кына сөйләп китә:

— Олуг падишаһ, хак тәгаләнең әшкәртүе буенча изге китаптан без фәкыйрегезгә шул мәгълүм булды: хәзинәгезне талаган угрылар өчәү булган, ләкин алар урлаган алтыннарын алып чит мәмләкәткә чыгып киткәннәр. Аларны шуннан гына эзләп табарга була... Әмма... (Чикерткә әз генә тынып тора.) Әмма атагыздан мирас булып калган кадерле балдакны табарга мөмкин, ул шушыннан, сарай ихатасыннан чыкмаган.

— Чыкмаган! — ди патша, алга омтылыбрак. — Кайдан табарга соң аны?

— Табуы читен булмас... Изге китап күрсәтүенчә, балдак бакчагыздагы тәвә кошының карынында!

Моны ишеткәч, патша ышанмыйча башын гына селкеп куя.

— Ай-һай, тәкъсир, изге китап сезне алдамый микән?!. Аннары тәвә кошлары минем бакчамда берәү генә түгел бит, кайсы юньсезнең карынында икән соң ул балдак?

— Таз башлысында! — ди Чикерткә.

— Таз башлы тәвә кошы юк минем бакчамда! — ди патша, ачулана биреп.

— Ягъни мәсәлән, йоны коелган шәрә башлысында, — ди Чикерткә һаман шулай тыныч кына.

— Андые бар шикелле, — ди патша ахыр килешеп. — Ләкин әйтегезче, тәкъсир, балдак аның карынына ничек итеп эләккән соң?.. Үзе сарайга кереп, сандыкны ачып йотмагандыр ич?!

Менә бу сорауга хәлфәдән бернинди дә сүз-киңәш булмаган иде. Ни диеп җавап бирергә? Чикерткә, тәсбихен тарткан булып, аз гына уйланып тора да бик гади генә итеп аңлатып бирә:

— Угрылар ашыгып бакча аша качканда балдакны төшереп калдырганнар. Ә тәвә кошы, мәхлук, шуны табып, таш урынына йоткан да җибәргән.

Патша рәхәтләнеп бер көлә, вәзирләр дә тыелып кына көлешеп алалар.

— Ярый, тәкъсир, — ди патша, көлеп туктагач, — сүзләреңнең хаклыгын хәзер белербез!

Шунда ук ул сарай хадимнәренә шәрә башлы тәвә кошын тотып китерергә һәм үзе алдында суярга да куша.

... Атланып чабарлык таза, мәһабәт кошны патша алдына тотып китерәләр, озын аякларын ныгытып бәйләп, кырын яткыралар да, әгузе-бисмилла әйтеп, чалып та җибәрәләр. Аннары эчен ярып карыйлар һәм менә патшаның күз алдында кош карыныннан әлеге балдак ялтырап килеп чыкмасынмы?! Бу тамашага бөтен сарай әһеле ис-акыллары китеп, тәмам хәйран вә вәйран булып калалар. Күпмедер вакыт бөтенләй телләренә килә алмыйча торалар. Патша хәзрәтләре балдакны кулына алып, авырлыгын белергә теләгәндәй, чөеп тә карый, бары шуннан соң гына аягүрә басып, Чикерткәгә әйтә:

— Афәрин, тәкъсир!.. Инде мин сезнең хак ишан булуыгызга тәмам ышандым, — ди.

Ә Чикерткә, һич исе китмәгән бер кыяфәт белән, тәсбихен тарткалап тик кенә утыра бирә.

— Ләкин, тәкъсир, — ди патша, сүзен дәвам итеп, — минем сезнең белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсем килә. Әйдәгез әле, булмаса, бакчага чыгыйк!

Патша тәхетеннән төшә, ишан урыныннан тора, башкалар барысы да аларга баш иеп калалар.

Бакчага чыккач, патша ишанны үзе дусларча култыклап, бераз аны-моны сөйләнеп барган була да аннары кинәт исенә нидер төшкәндәй тукталып кала.

— Тәкъсир, сез атлый торыгыз, мин хәзер артыгыздан җитәрмен, — ди ул ишанга.

Ишан моңа шактый гаҗәпләнә калса да, билгеле, атлый тора, ләкин артына борылып карарга курка. Ә арттарак калган патша хәзрәтләре шул арада җиргә чүгәләп нәрсәдер тотарга азаплана. Бер чүгәли, ике чүгәли, учы белән җиргә сугып та алгалый, аннары торып ишанны куып җитә дә, йомарлаган кулын сузып, аңардан сорый:

— Я, тәкъсир, әйтеп бирегез әле, минем шушы кулымда нәрсә?

Ишан ни әйтергә дә белмичә аптырап тора, ә патша аны отыры кыстый да кыстый:

— Я, әйтегез — әйт! Сез изге зат икәнсез, белергә тиешсез. Я, нәрсә минем учымда?..

Ниһаять, ишан хәзрәтләре аңлап ала: бу — сынау, патша хәзрәтләре тагын бер мәртәбә аны сынап карамакчы икән!.. Ләкин нәрсә әйтә алсын ул, учына патша нәрсә йомганын каян белсен ул? Хәлфә абзые да юк бит янында! Менә кайчан килеп җитте «изге ишанның» соңгы сәгате! Килә икән шул, күпме генә хитрит итсәң дә, барыбер килә икән!.. Беткән баш — беткән дигәндәй, малай-ишан ахырда бик ачынып үз-үзенә әйтә: «Әй, Чикерткә, Чикерткә! Бер сикердең — котылдың! Ике сикердең — котылдың! Өч сикердең — анысыннан да котылдың! Инде менә дүртенчесендә котыла алмадың — тотылдың!»

Моны ишетүгә патша хәзрәтләре шатлыгыннан хәтта кычкырып җибәрә:

— Ах, тәкъсир, белдең бит, белдең!.. Менә ходаның хикмәте! Һәм йомарлаган кулын ачып күрсәтә — учында яшел бер... чикерткә!

«Я хода, мең шөкер сиңа! — дип куя ишан да эченнән генә. — Дөньяда чикерткәләрең бер мин генә түгел шул синең!..»

— Синдә икән күрәзәлек, синдә икән зирәклек! — ди патша.— Дөрестән дә бит, мин бу бөҗәкне тотар өчен дүрт тапкыр чүгәләп, дүрт тапкыр учым белән җиргә сугарга мәҗбүр булдым. Инде минем бер шигем дә калмады, тәкъсир, син чын мәгънәсендә изге зат, олы акыл иясе икәнсең!.. Вәгъдә — иман, бүгеннән мин сине үземнең баш вәзирем итәм һәм, өстәвенә, сиңа бердәнбер кызымны да бирәм. Ризамы?

— Рәхмәт, патша абзый! — ди Чикерткә бичара аптыравыннан. — Мин инде сезнең теләккә каршы килә алмыйм. Тик бер шартым бар.

— Әйтегез, тәкъсир!

— Миңа һәр вакыт итәгать белән хезмәт иткән мөридемне миннән аермасагыз иде.

— Теге сезгә ияреп йөргән чандыр, кара хәлфәне әйтәсезме? Бик мут кешегә охшаган ул, әмма акыллы адәм булса кирәк. Ярый, мин риза, үз янызыгызда бер хадимегез итеп тотарсыз, ә киләчәктә бәлки аңа берәр төрле дәүләт эше дә бирербез, әгәр бик мутлашып китмәсә...

— Рәхмәт, падишам, рәхмәт! Тыныч булыгыз, мин аны үз кулымда нык тотармын.

Шул ук көнне патшаның боерыгы белән фаэтон җибәреп хәлфәне сарайга алып та киләләр. Озын кара казаки киеп, кырпу бүреген кырын салган хәлфә, кияү егетедәй, тәңкә тулы сандыгын култык астына кыстырып кына килеп төшә.

Икенче көнне инде патшаның бердәнбер кызын ишан хәзрәтләренә никахлап бирү турында бөтен илгә рәсми хәбәр дә таратыла. Патша сараенда туйга хәзерлек башлана. Шәһәрдәге бөтен йортларга бәйрәм флаглары эленә. Күрше дәүләтләрдән ханнар, шаһлар, шаһзадәләр кунак итеп чакырыла. Илдәге бөтен мәшһүр җырчылар һәм уенчылар сарайга җыела.

Никах укыласы көнне халык урамнарга, мәйданнарга агылып чыга. Бөтен җирдә — бәйрәм, шатлык, җыр-музыка... Алар өчен мәйданнарда зур-зур казаннар асыла. Әллә ничә йөз баш куй, тана, тәвәләр суела... Ә сарайдагы туй мәҗлесен инде әйткән дә юк — анда нинди генә кош итләреннән кәбаблар кыздырылмый да, нинди генә зат ашлар, җимешләр, шәрабләр табынга куелмый!

Никахтан соң безнең Чикерткә, чалма-чапаннарын салып ташлап, шаһзадәләрчә тоташ ефәктән җиңелчә генә киенеп, дөньяда тиңе булмаган сылулардан-сылу, гүзәлләрдән-гүзәл кыз янына кияү булып керә... Шул керүдән инде ул мөгътәбәр кунаклар янына бүтән чыкмый да — аның изге ишан да, шайтан да, беркем дә буласы килми, бары тик бәхеткә чумган яшь кияү генә булып каласы килә. Ә шаккатыргыч туй җиде көн, җиде төн дәвам итә. Хәлфә исә, «ишан хәзрәтләренең» бердәнбер якын кешесе буларак, мәҗлеснең иң түрендә утыра һәм үзенең зирәклеге, тапкыр сүзләре белән бик күпләрне авызына каратып та өлгерә. Чит ил кунаклары, исләре китеп: «Һай, бу нугай, кандай адәм бу?..» — диләр. Ә хәлфә, бөеренә таяна биреп: «Безме, без шундый адәм инде. Бөтен җирдә баш вәзир! Әшли дә, ярый да беләбез!» — дип кенә җибәрә.

Туйлар узгач, Чикерткә, баш вәзир сыйфатында, әкренләп дәүләт эшләрен үтәргә дә керешә. Хәлфә һәр вакыт аның янында була. Әйтергә кирәк, дәүләт эшләрен дә алар акыл белән бик оста йөртәләр. Патшага бик ошыйлар, патша алардан бик канәгать була.

Шул рәвешчә тату-тыныч кына шактый еллар бергә гомер кичерәләр. Ләкин патшаның ир баласы булмый, шул сәбәпле үзеннән соң илдә патшалык итүне рәсми фәрман белән киявенә тапшыра.

Менә көннәрдән бер көнне карт патша, ниһаять, үлеп китә. Гәүдәсен ак мәрмәрдән махсус эшләнгән төрбәгә бик олылап җирлиләр. Илдә бер атналык матәм көннәре игълан ителә. Шуннан соң, әлеге фәрман нигезендә, патшалык итү Чикерткәгә күчә. Тора-бара халык та аны ярата, чөнки кече яшьтән үк нужаны бик нык татыган безнең ятим Чикерткә үзен акыллы, гадел һәм миһербанлы патша итеп таныта. Үз урынына исә ул хәлфә абзыен баш вәзир итеп куя. Хәлфә дә инде олаеп бара, шуның өстенә өйләнмичә дә кала (сарайдагы җарияләр белән генә юана), әмма Чикерткәгә шул кадәр ияләшә — аңардан башка инде ул яши дә алмый...

Чикерткәнең биш баласы була — өчесе малай, икесе кыз. Хатыны бер дә картаймый. Бик тату, матур, бәхетле яши алар... Озак яшиләр... Инде Чикерткә вафат булганнан соң... Хәер, Чикерткәдән соң ниләр булганын без белмибез. Әкият шуның белән тәмам. Нокта куйдык! Бигайбә! Әкият ары, мин бире, аркасына чи тире!

Кода сөйләп беткәч, мин аңардан сорадым:

— Кемнән ишеткән идегез бу әкиятне?

— Беркемнән дә түгел, үзем... — диде кода, тыйнак кына елмаеп.

— Ничек «үзем?»

— Ну... үзем чыгарган әкият.

— Шулаймыни? — дидем мин, гаҗәпләнүемне бер дә яшермичә.

— Мин дә бит кайчандыр ятим шәкерт идем, — диде кода, акланырга теләгәндәй. — Хәллерәк шәкертләрдән әзрәк өлеш тимәсме дип, кичләрен мәдрәсә идәнендә тезелешеп яткан чакларда мин аларга озын-озын әкиятләр сөйли торган идем... Тамак кайгысы хыялны эшләткән, күрәсең...

— Алай икән... Интересно...

Мин, коданың чал башына карап, бераз уйланып тордым, аннары өйрәнелгән гадәт буенча әкият турында нидер әйтергә кирәк таптым. Билгеле, хәзерге заман күзлегеннән карап...

— Макташудан булмасын, кода, әкиятегез кызыклы, хәтта бик кызыклы. Тик менә ахыры әллә ничегрәк. Дөрес түгел кебек, минемчә.

— Нәрсәсе дөрес түгел?

— Сез үзегезнең Чикерткәгезне иң ахырда гына яхшы, гадел патша иткәнсез бит!..

— Нигә, ярамыймыни?

— Ярап бетмәс шул. Беләсезме, бик шәп фәкыйрь дә, баегач, бигрәк тә патша булып алгач, еш кына иң алама кешегә әйләнә дә куя... Ә сездә әйләнмәгән. Ни өчен?

— Юк, — диде кода, башын селкеп. — Элек бөтен әкиятләр дә шулай бетә торган иде, ник дисәң, халыкның һәр вакытта да яхшы патша күрәсе килгән.

Һәм ул моның бик күп мисалларын китерде. Кыскасы, ышандырды кода! Әкиятнең бер гаебе дә юк икән монда. Хикмәт исә халыкның өмет-хыялында икән. Бәс, шулай булгач, коданың бу әкиятен дә нәкъ үзе сөйләгәнчә калдырырга туры килә, иптәшләр! Әлеге ни... рациональ орлыгы өчен генә булса да...

## Кашфел Задә

### *Таяк турында*

Шагыйрь өендә шундый бер
Тамаша булган икән:
Таянып килгән таягын
Бер карт онытып киткән.

Мостай Кәрим.

Әллә ни зур вакыйга да түгел,
Кирәк идеме икән язарга?!
... Чал шагыйрьнең таягы тик... калган,
Онытылып калган — Нәҗәрда [1].
(Кунакханәдә бер, Казанда.)
Ниндидер мин мәгънә күрдем монда:
Шигъри мәгънә... Син дә искә ал! —
Шагыйрь энесенең сүзләреннән
Яшәргән бит, күрче, аксакал! —
Таянырга таяк кирәкмәгән,
Пегас канатында, күрәсең,
Кайтып киткән өенә. Бүген миңа
Шул таякны илтеп бирәсе.
Шул таякны... Ә бит үз җилкәмдә
Аксакалның авыр таягын
Күп татыдым. Еллар буе төшкәч
Кыйналуга күнеп барамын.
Әллә дим бер кулга эләккәч ул
Кемнедер соң үзем чүт кенә
Кыйнап карагамы? Күп бит яшьләр...
Ә кыйналу — шундый үстерә!
(Мин шаярам гына... кыйный алмам,
Гөнаһ ала алмам өстемә!)
Мин урамнан барам... Очам гүя,
Җиргә тидермим дә аякны.
Уйлап барам: «Аксакаллар — көчле,
Нигәме? Бит алар — таяклы...
Таяк саклый булыр талантны?»
Ашыгып атлыйм. Куркам: таяксыз соң,
Аксакалның көне узмаса? —
Янып язар җыры тумаса?!
... Мин дә язмас идем бу шигырьне,
Шул таякны оныттырган — Нәҗәр,
Ә оныткан — Туфан булмаса...

---

[1] Башкорт шагыйре Нәҗәр Нәҗми.

## Нури Арсланов

### Нурихан Фәттахка

*«Ерак гасырлар авазы»н укыгач*

«Кот»лау сиңа — кыю иргә — Нуриханга,
«Эт»тәй тугры, халык сөяр «Бүре» җанга!

Тузанын как, әйдә, иске заманнарның:
Борынгының сөйләт скиф, аланнарын...

Сыңар күзле Циклопларның күзен ач бер,
Элеккедәй дала гизсен әле Кашкыр.

Төшер тартып биек күктән «Таң-Ире»н дә, —
Рәхәтләнеп йөрсен әле «Эт-Ил»ендә.

Юкса, без гел «Каз» җирендә кала бирдек,
Кем ни әйтсә шуны чынга ала бирдек.

«Үзе юкның — күзе юктыр» дигән картлар:
Яле, үзең тарихларыңны ач — актар.

Абынсаң да гаеп түгел, тырыш-тырмаш, —
Олы юлга чыгарсың бер бара торгач.

## М. Әпкәли

# ПАРОДИЯЛӘР

### Кем кемне?..

«Малай-шалай чыгып чаба
Гөрләвекләр артыннан...»

«Шук малайлардай
Тамчылар чапты.
Гөрләвек чапты алар артыннан...»

Гәрәй Рәхим

Мыеклар, яллар җилферди җилдә,
Өзәнге бавы кылдай тартылган.
Кырмыска чапты куак тирәли,
Бер җайдак чапты аның артыннан.

Кычкырды алар берсе-берсенә —
Кычкырды алар: «Тот, тот, тотыгыз!»
Тузан туздырды шаян кырмыска,
Кылыч айкады җайдак туктаусыз.

И җайдак чапты, чапты шул чаклы!..
Аның артыннан кырмыска чапты.
Белеп булмады ләкин һич шуны —
Куак тирәли кем кемне куды?

## Саран бабай

«Күзләр үтте.
Инде мине
Икенче кыз бәхетле итте.
Ул бәхетне тапмас идем,
Ярый әле, ташлап киттең,
И чибәр кыз».

Р. Миннуллин

Кыярларым өлгерсен дә,
Берсен сиңа бирәм, дидең.
Мин ышанып көттем һаман,
Мин беркатлы,
Мин яшь идем,
Саран бабай...

Күзен әби
Бирде шалкан:
— Мә, тыгын,— дип,— елак шайтан...
Ә син кыяр биргән булсаң,
Ләкмәс иде бәлки шалкан,
Рәхмәт сиңа,
Саран бабай.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

8 һәм 9 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан язучыларының 1976 нчы әдәби ел йомгакларына багышланган зур җыелышы булып узды. Аны ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты.

Үткән елда чыккан шигъри җыентыкларда, «Казан утлары» журналы һәм башка күп төрле вакытлы матбугат органнары битләрендә басылган шигъри әсәрләр турында доклад белән күренекле шагыйребез Сибгат Хәким чыкты. Ул бүген актив иҗат итә торган дистәләрчә шагыйрьләребезнең иҗат җимешләрен анализлады, әсәрләргә хас үзенчәлекләр, күркәм сыйфатларны, заманның шигъри авазы булырлык уңышларны барлады, аерым кимчелекләрне күрсәтте. 1976 ел прозасына багышланган докладны тәнкыйтьче Флүн Мусин, драматургиябез турында докладны тәнкыйтьче Азат Әхмәдуллин сөйләде. Алар, бүгенге чор сулышын, аның рухын тирән чагылдырган повесть һәм романнарга, сәхнә әсәрләренә киң тукталып, прозаик һәм драматургларыбыз, театрларыбыз күтәргән мөһим проблемаларны гәүдәләндергән образларны күздән кичерделәр, әсәрләрнең көчле һәм йомшак якларын ачтылар. Җыелышта шулай ук Татарстанда иҗат итүче рус язучыларының иҗаты турында Рөстәм Кутуй, әдәби тәнкыйть һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган материаллар хакында яшь тәнкыйтьче Әмир Мәхмүдов, балалар әдә-



*Хөкүмәтебез бүләге журнал байрагында. Сулдан уңга: журналның баш редакторы шагыйрь Зәки Нури һәм җаваплы секретаре язучы Ләбибә Ихсанова.*

бияты турында шагыйрь Раил Вәлиев, тәржемә әсәрләре хакында тәржемәче Кыям Миңлебаев докладлары тыңланды.

Фикер алышуда язучылар Фатих Хөсни, Хәсән Сарьян, Аяз Гыйләҗев, Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, драматург Диас Вәлиев, Язучылар союзының Әлмәт бүлеге мөдире шагыйрь Әдип Маликов, язучы Нәби Дәүли, Язучылар союзының чуваш секциясе мөдире Василий Юдин, язучы Фаил Шәфигуллин һ. б. чыгыш ясап, әдәби хәрәкәтебезнең күп мәсьәләләрен күтәрделәр, бер ел эчендә иҗат ителгән проза, поэзия, драма әсәрләре, тәнкыйть хезмәтләре хакында үз фикерләре белән уртаклаштылар.

Җыелышка Гариф Ахунов йомгак ясады. Ул татар авторларының Мәскәү үзәк нәшриятларында басылган әсәрләренең саны елдан-ел арта баруын күрсәтеп үтте. Татар совет язучыларының иҗатына, аерым әсәрләргә багышланган мәкаләләр, рецензияләр дә ил эчендә һәм чит ил матбугатында күпләп басыла. 1976 елда аларның саны өч йөзгә җиткән. Г. Ахунов җыелышта яшь язучылар белән эшләү, оештыру чаралары хакында да сөйләде.



*Рәсемнәрдә: КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев журналга «Почет билгесе» орденын тапшыра. Уңда — язучы Мирсәй Әмир.*

Җыелыш ахырында КПСС өлкә комитеты секретаре М. В. Вәлиев «Казан утлары» журналына «Почет билгесе» ордены бирелүе уңае белән журнал редколлегиясен һәм барлык язучыларны партиябез өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән кайнар котлады, киләчәк тәрбия-иҗат эшендә, әдәби хәрәкәтне әйдәп алып баруда журналыбызның тәэсир көчен тагын да үстерүдә уңышлар теләде һәм хөкүмәтебезнең бүләгеп журнал байрагына беркетте. Журналның баш редакторы Зәки Нури рәхмәт сүзен әйтте, ул хөкүмәтебезне, партия өлкә комитетын «Казан утлары»ның киләчәктә дә заман байрагын югары тотачагына, халык белән бердәмлекне илһамлы хезмәттә раслау өчен көчне кызганмаячагына ышандырды.

## ТАГЫН «ХӘЗИНӘ» КИНОФИЛЬМЫ ТУРЫНДА

Республикабызның нефть районнарында язучы Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча Свердловск киностудиясендә эшләнгән киң экранлы нәфис һәм төсле фильм күрсәтелә башлавы хакында журналыбызның үткән санында хәбәр ителгән иде инде. Кинофильм иң элек Татарстан нефтенең бишеге — Әлмәттә, аннары Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләре һәм поселокларында, — барлыгы утызлап кинотеатрда демонстрацияләнде. 21 февраль көнне фильм Казан кинотеатрлары экраннарына чыкты. Бу премьераларда романның авторы Гариф Ахунов, фильмны куючы режиссер Ольгерт Воронцов, Свердловск киностудиясе директоры Юрий Асловский, рольләрне башкаручы артистлар А. Филиппенко, РСФСРның халык артисткасы Лариса Пашкова, Роман Громадский, РСФСРның халык артистлары Шәүкәт Биктимеров, Габдулла Шамуков, РСФСРның атказанган артисткасы Вера Минкина, Татарстанның халык артисты Делюс Ильясов, Татарстанның атказанган артисты Равил Шәрәфиев һәм башкалар меңнәрчә тамашачылар белән очрашып, әсәрнең геройлары һәм аларны экранда ничек гәүдәләндерүләре хакында сөйләделәр.

«Хәзинә» — Татарстан нефтьчеләренә багышланган беренче нәфис фильм. Бу әсәр өстендә эшләгәндә режиссер һәм төп рольләрдә уйнаучы актерлар берничә ай Әлмәт шәһәрендә, нефтьчеләр арасында яшиләр. Ә фильмның күп кадрлары бораулау мастеры Галимҗан Һадиев һәм скважиналарны җир астында ремонтлау мастеры Әхәт Гобәйдуллин бригадаларында төшерелә. «Хәзинә» романының авторы Гариф Ахунов фильмны төшерүнең барлык этапларында да консультант буларак ярдәм күрсәтә. Киноәсәрнең баш консультанты исә — «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры, Социалистик Хезмәт Герое А. В. Вәлиханов.

## ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНДА

Февральдә Татарстан Язучылар союзы, Казан театрлары, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе, Татарстан китап нәшрияты, кинотеатрлар һәм Казан циркы коммунистларының берләштерелгән җыелышы булып үтте. Җыелышта партиянең Казан шәһәре Бауман район комитетының иҗат оешмалары белән алып барган еллык эше турындагы отчеты тыңланды.

## УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

«Казан утлары»на хөкүмәтебезнең мактаулы бүләге бирелү уңае белән журналыбызның редколлегия членнары, авторлары һәм редакция хезмәткәрләре предприятиеләрдә һәм колхозларда, мәктәпләрдә һәм китапханәләрдә журнал укучылары белән күп кенә очрашулар үткәрделәр. Шундый берничә әдәби кичә февраль аенда Мари АССРның Бәрәңге районы авылларында уздырылды. Язучы Хәсән Сарьян һәм шагыйрь, журналның бүлек мөдире Рәдиф Гатауллин, яшь язучы Марсель Галиев игенчеләр һәм авыл интеллигенциясе вәкилләре алдында журнал эшчәнлеге, әдәбият яңалыклары хакында сөйләделәр, аларны «Казан утлары» битләрендә быел басыла торган әсәрләр һәм үзләренең иҗат үрнәкләре белән таныштырдылар.

* * *

«Казан утлары»ның баш редакторы шагыйрь Зәки Нури һәм язучы Рафаэль Мостафин Казанның исәп-кредит техникумы, 22 нче номерлы эшче яшьләр мәктәбе укучылары һәм 3 нче номерлы икмәк заводы эшчеләре белән очрашуда булдылар. Монда да сүз журналыбызның бүгенге торышы, аның әдәбият һәм заман белән бәйләнеше, анда дөнья күрәчәк яңа әсәрләр хакында барды. З. Нури һәм Р. Мостафин әдәбият сөючеләргә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, сорауларга җавап бирделәр.

* * *

Язучы Хәсән Сарьян, шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалимов Кукмара районында әдәбият сөючеләр белән шундый ук очрашу үткәреп, әдәби хәрәкәтебездә «Казан утлары»ның тоткан урыны, аның эше һәм планнары хакында сөйләделәр.

* * *

Матбугат тарату алдынгыларының Зеленодольск шәһәрендә үткәрелгән киңәшмәсендә журналның бүлек мөдире, шагыйрь Абдулла Сәләхетдинов катнашты. Ул редакциянең эше, планнары, быел басылачак әсәрләр турында сөйләде. «Казан утлары» журналын тарату эшендә зур активлык һәм өлгерлек күрсәткән Зәйнәп Галиуллина, Луиза Галиева, Рәшидә Гайнуллина иптәшләргә редколлегия исеменнән Мактау грамоталары тапшырылды.

* * *

Журналыбызның бүлек мөдире, журналист Хәмзә Зарипов Саба районында жур-

нал укучылары белән очрашты, аларга редакциянең бүгенге эшләре, тормыш белән бәйләнеше, алдагы планнары турында сөйләде.

* * *

Журнал укучылары белән очрашу өчен Алексеевский районына язучы Самат Шакир барды. Авыл хезмәт ияләре алдында ул «Казан утлары» һәм аның әдәбият-сәнгать тормышындагы урыны турында сөйләде. Очрашулар вакытында Урта Тигәнәле, Кыр Шонталасы, Олы Тигәнәле, Түбән Кондрата һәм башка авылларның игенче һәм терлекчеләре журналга өстәмә рәвештә язылу теләге белдерделәр.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘЛӘРЕ

Язучыларыбызның Г. Тукай исемендәге клубында күренекле татар совет язучысы Ибраһим Газиның тууына 70 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде. Әдипнең иҗаты турында әдәбият белгече Х. Хәйри кереш сүз әйтте. Язучыларыбыздан Г. Ахунов, Ф. Хөсни, Р. Ишморат һ. б. лар мәрхүм әдип хакында истәлекләр сөйләделәр. Ахырдан сәнгать осталары концерты булды, әдипнең әсәрләре укылды.

Казанның 10 нчы интернат мәктәбендә, язучының туган җире — Кама Тамагы районының Карамалы авылында да шундый ук кичәләр булып үтте.

* * *

Актерлар йортында күренекле җырчы, Татарстанның халык артисткасы Гөлсем Сөләйманованың тууына 70 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булды. Кичәне ТАССР Министрлар Советының телевидение һәм радио комитеты председателе урынбасары Ф. Ф. Фазылҗанов ачты. Җырчының тормышы һәм иҗаты хакында музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина сөйләде. Татарстанның халык артисткасы, композитор Сара Садыйкова, РСФСРның атказанган артисты Илһам Шакиров, Татарстанның атказанган артисткасы Зифа Басыйрова, күренекле музыкант Исмәгыйл Һилалов, язучы Афзал Шамов, шагыйрә Гөлшат Зәйнашева һ. б. лар истәлекләре белән уртаклаштылар. Кичә сәнгать осталары концерты белән тәмамланды.

## ЮБИЛЕЙЛАР, КОТЛАУЛАР, ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Казанның Актерлар йортында РСФСРның атказанган, Татарстанның халык художнигы, Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты, күренекле рәссам Бакый Урманчега 80 яшь тулуга багышланган кичә булды. Юбилярның тормышы һәм иҗат юлы хакында рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов доклад сөйләде. Татарстан Язучылар союзыннан драматург Риза Ишморат, Культура министрлыгыннан Ренат Харисов, Үзбәкстан художниклары һәм Б. Урманченың Урта Азиядә яшәүче шәкертләре исеменнән художник Әнвәр Назыйров, Төмәндәге укытучылар исеменнән Газиз Әхмәтов, республикабызның җәмәгать оешмалары вәкилләре өлкән рәссамыбызны олы юбилее белән котладылар, бүләкләр тапшырдылар. Кичәдә Татарстан Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев катнашты. Юбилярны котлап һәм зур иҗат уңышлары теләп, ул Б. Урманчега партия һәм хөкүмәтебезнең мактаулы бүләге — Хезмәт Кызыл Байрагы орденын тапшырды

* * *

РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы Мәрьям Рахманкуловага 75 яшь тулды. Юбиляр адресына Мәскәүдән, илебезнең башка культура үзәкләреннән котлау телеграммалары һәм хатлар килде. Түбәндә без әле утызынчы елларда ук татар опера студиясендә С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи кебек композиторларыбызны укыткан, татар музыка культурасы үсешенә сизелерлек өлеш керткән профессор Генрих Ильич Литинский хатын урнаштырабыз.

## ШАТЛАНАМ ҺӘМ ГОРУРЛАНАМ

Татар һәм күп милләтле бөтен совет музыка культурасы күгендә беренче дәрәҗәдәге якты йолдыз — Мәрьям Маннан кызы Рахманкулованың тууына 75 ел тулды.

Утызынчы еллар уртасында Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера студиясе ачылган көннән алып, Мәрьям Рахманкулова аны бизәп тора торган бер шәхес булды. Татар халык җырларының иң тирәндә яткан хасиятләренә үтә сизгерлеге җырчыга операда җырлау осталыгын нечкә үзләштерергә ярдәм итте, «Алтынчәч», «Илдар» кебек беренче татар опера хәзинәләре иҗат ителгәннән соң ук Тугзак, Сабира партияләрен башкарып, опера сәнгатендә әйдәп баручы җырчы булырга мөмкинлек бирде.

Бай артистлык таланты белән М. М. Рахманкулова музыкаль һәм уен дәрәҗәсе ягыннан тиңсез опера образлары тудырды, алар артисткага алмашка килүче татар җырчыларының яшь буыннары өчен югары үрнәк булып тора.

Татар халык музыкасы җирлегендә нык басып торуы М. М. Рахманкуловага композиторлык талантын да үстерергә ярдәм итте, аның оркестр һәм төрле вокаль-инструменталь ансамбльләр өчен башкарган хезмәтләре татар профессиональ музыкасының башлангыч чорында зур гына роль уйнады.

Татар музыкасының эшлеклесе һәм иске дусты буларак, мин барыбыз өчен дә кадерле булган Мәрьям Маннановнаны истәлекле юбилее белән котлаганда куанычлы хисләр кичерәм, озак елларга аңа сәламәтлек һәм иҗат шатлыклары телим.

Башкарган һәм башкарачак барлык хезмәтләре өчен зур рәхмәт аңа.

*Г. И. Литинский, профессор,*
*Татарстанның халык артисты.*
*Мәскәү, 12 январь, 1977 ел.*

* * *

Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залында РСФСРның Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор

Фасил Әхмәтов һәм композитор Ринат Еникеевның иҗат кичәсе үтте. Кичәдә аларның яңа симфоник әсәрләре башкарылды. Р. Еникеев эшкәрткән халык җырларын, Татар дәүләт симфоник оркестры кушылып, РСФСРның атказанган артисты Илһам Шакиров җырлады. Яшь дирижерларның дүртенче Бөтенсоюз конкурсы дипломанты Равил Мартынов дирижерлык итте.

## ЯШЬ ИҖАТ КӨЧЛӘРЕ ҮСӘ

Мәскәүдә яшь композиторларның дүртенче Бөтенсоюз пленумында Татарстаннан килгән яшь иҗат көчләре дә катнашты. Концертларда Ш. Шәрифуллинның Казан дәүләт консерваториясе студентлары хор ансамбле тарафыннан башкарылган «Мөнәҗәтләр» әсәре уңыш казанды. Шул ук көннәрдә анда Казан консерваториясенең дүртенче курс студенты Шамил Тимербулатовның виолончель һәм фортепиано өчен язылган сонатасы тыңланды.

## ТЕАТР ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Алма-Ата шәһәрендәге Уйгур республика музыкаль-драма театры үзенең кырык өченче сезонында татар драматургы Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасын сәхнәләштерде. Әсәрне театрның баш режиссеры Кадыйр Җетписбаев куйган, музыкасын Казагыстан ССРның халык артисты композитор Латыйф Хәмиди язган.

* * *

Мурманск өлкә драма театрында Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасы сәхнәгә куелган. Әсәрне русчага Ю. Мочалов тәрҗемә иткән. Режиссеры — РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. В. Киселев.

* * *

Минзәлә татар дәүләт драма театры әзербәйҗан драматургы Имран Касумовның «Тормыш бүләк итәм» драмасын сәхнәләштерде. Режиссерлары — Рафаэль Усманов һәм Татарстанның атказанган артисты Мөхәррәм Зәйнуллин.

* * *

Татар дәүләт республика күчмә театрында Т. Миңнуллинның «Ак тәүбә, кара тәүбә» исемле яңа комедиясе бара. Аны сәхнәгә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты Равил Тумашев куйган. Композиторы — РСФСРның Дәүләт премиясе лауреаты Фасил Әхмәтов.

## ТАТАРСТАН ТУРЫНДА ТӨСЛЕ ФИЛЬМ

Казан документаль фильмнар студиясе «Татарстан» исемле төсле документаль фильм әзерләде. Ул В. Стрельков һәм В. Левашов сценарие буенча эшләнгән. Режиссеры — А. Сырых, операторлары — Р. Гәраев һәм А. Привин. Бөек Октябрьнең 60 еллыгына багышланган бу фильм гарәп илләре һәм Африка илләрендә күрсәтеләчәк.

* * *

Казан телевидениесе экранында күренекле язучы Мирсәй Әмирнең «Саф күңел» романы буенча эшләнгән инсценировка күрсәтелде. Аны телевидение режиссеры Әхтәм Зарипов куйган. Рольләрне Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары башкарды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР ҺӘМ БҮЛӘКЛӘР

Совет театры өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары **Шәхсәнәм Ибраһим кызы Әсфәндиярова** һәм **Әзһәр Шәфыйк улы Шакировка** РСФСР Верховный Советы Президиумының 1977 ел, 11 февраль Указы белән **РСФСРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

* * *

Татар совет опера сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 75 яшь тулу уңае белән РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы **Мәрьям Маннан кызы Рахманкулова** ТАССР Верховный Советы Президиумының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге, кадрлар әзерләүдәге хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән Казан дәүләт консерваториясенең өлкән укытучысы **Георгий Васильевич Виноградов** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.


## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлек утырышында, КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карары уңае белән, нефть якларында яшәүче яшь авторларның әдәби активлыгы мәсьәләсе тикшерелде. Бүлек житәкчесе Ә. Маликов докладында яшь язучыларның соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре күздән кичерелде. Җыелышта язучылардан Ш. Бикчурин, М. Хәсәнов, С. Сөләйманова, Ж. Рәхимов, Лениногорск һәм Азнакай әдәби берләшмәләре җитәкчеләре Әсрар Галиев, Нур Әхмәдиев, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты инструкторы Абдулла Хисамиев чыгышлары тыңланды. Яшь язучылар белән эшләүне тагы да активлаштыруга юнәлдерелгән конкрет чаралар билгеләнде.

* * *

26 январьда бүлек җыелышында яшь язучы Газиз Кашаповның «Еллар тыныч иде» исемле яңа повесте тикшерелде. Әсәр бүгенге ил сакчылары тормышын һәм хезмәтен сурәтләүгә багышланган. Фикер алышуда катнашкан Ш. Бикчурин, Г. Афзал, Ю. Әминов, С. Сөләйманова, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов һ. б. лар повестьны камилләштерү юнәлешендә киңәшләрен әйттеләр.

Республикабызның әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре



*Шагыйрь* ***НУРИ АРСЛАНОВ.***

В. И. КУДЕЛЬКИН портреты.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгы якынлашып килә. Бу бөек бәйрәмне каршылап, Татарстан язучылары күп кенә яңа әсәрләр иҗат иттеләр. Шуларның берничәсен сез журналыбызның алдагы саннарында укыган идегез инде.

«Казан утлары»ның 6 нчы саны Мирсәй Әмирнең «Без бәләкәй чакларда» исемле повесте белән ачылачак. Бу әсәр дә данлы юбилейга багышлап язылган.

Нури Арсланов, Равил Фәйзуллин шигырьләре совет кешесенең омтылышларын, уй-хыялларын, идеалларын сурәтли.

Рәисә Ишморатованың «Язмышлар» повесте яшүсмерләр тәрбиясенә, Фатих Хөснинең «Җуля — кайгылы эт» һәм В. Багряшевскийның «Чуал» хикәяләре әхлак мәсьәләләренә кагыла.

Журналыбызның очерклар һәм публицистика бүлегендә КПСС Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин «Киләчәккә атлый Казан» дигән мәкаләсе белән катнаша. Журналист Мидхәт Миншиннның «Ташкын» очеркы басыла.

Болардан тыш «Сәнгать», «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы», «Шагыйрь турында шагыйрь», «Китап күзәтү», «Төрлесеннән», «Мәсәлчеләр мәҗлесе», «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлекләрендә игътибарыгызны җәлеп итәрлек байтак материаллар урнаштырылган.

Язучы һәм фольклорчы Фазыл Туйкинның тууына 90 ел тулу уңаеннан Э. Шәрифуллинаның «Илебез — кадерле җиребез» дигән мәкаләсен укырсыз.

«Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» бүлеге республикабыз культура тормышын чагылдырган хәбәрләргә бай.

Журналыбызның бу санында Р. Вәлиевнең «Иделем акчарлагы» дигән җыры бирелә. Җырның музыкасын Р. Абдуллин язган.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ